ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

11.2012



## *Татар Дәүләт Җыр һәм бию ансамбленә 75 яшь*













# Казан утлары
# Qazan utlari

2012

11
(1081)

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:
«ТАТМЕДИА»
ачык акционерлык җәмгыяте

БАШ МӨХӘРРИР
Равил Габдрахман улы
Фәйзуллин

ИДАРӘ:
Рабит Батулла
Зилә Вәлиева
Разил Вәлиев
Мөдәррис Вәлиев
Тәлгат Галиуллин
Рәдиф Гаташ
Алмаз Гыймадиев
(җаваплы сәркәтип)
Илфак Ибраһимов
Дамир Исхаков
Хатыйп Миңнегулов
Гәрәй Рәхим
Розалина Шаһиева
Рәфикъ Юныс
(баш мөхәррир урынбасары)

Мөхәррирләр: Гөлзадә Бәйрәмова, Марат Закир, Әлфәт Закирҗанов, Камил Кәримов, Алмаз Хәмзин.

Гамәли хезмәткәрләр: Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.
Исәп-хисап бүлеге: Гөлнара Галиева (баш бухгалтер).

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир — 562-10-62.
Баш мөхәррир урынбасары — 562-10-38.
Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге — 562-11-28.
Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге — 562-11-53.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге — 562-11-53.
Гамәли хезмәткәрләр — 562-11-28.
Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80.
Факс — (843) 562-11-28.
E-mail: kazanutlari@yandex.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Ленар ШӘЕХ. Ак болытлар буйлап яшьлек ага. *Шигырьләр.* ....5
Фәрит ЯХИН. Умырзая. *Роман.* ....10
Рим ИДИЯТУЛЛИН. Заман үзе безне сайлады. *Шигырьләр.* ....58
Вахит ИМАМОВ. Утлы дала. *Тарихи роман.* ....63
Нәҗибә САФИНА. Сиңа багышланган җырым. *Шигырьләр.* ....105
Туфан МИҢНУЛЛИН. Онытмагыз мине! ....109

**ФӘН**

«Авыр чакта гел Казанга ялганам...» *(Рәфикъ Юнысның академик Рәшит СҮНӘЕВ белән әңгәмәсе).* ....121
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ....138

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Гали Рәхим: милләт өчен яшәү үрнәге. ....129

**ХӘТЕР**

Рәдиф ГАТАШ. Халыкчан хисләр җырчысы *(Газизә Сәмитованың тууына 150 ел).* ....141
Газизә СӘМИТОВА. Каләм. *Шигырьләр.* ....143

**БЕЗДӘ КУНАКТА – БАШКОРТСТАННЫҢ ЭСТӘРЛЕБАШ РАЙОНЫ ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘСЕ**

Фәнүр ТУКТАРОВ. Эстәрлебаш Казаннан ерак түгел. ....145
Рәфис ЗИЯЗЕТДИНОВ,Фәнирә ИБРАҺИМОВА, Наилә ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА, Зөлфия ГЫЙЗЕТДИНОВА, Гөлсинә БАСЫЙРОВА, Гаян АРСЛАНОВ, Лилия САБИТОВА, Рәис БАЙГИЛДИН, Гаяз ҮЛӘЕВ, Хәлимә НАЗАРОВА *шигырьләре.* ....147
Рәфгать РЫСАЕВ. Тартай тел еннән таба. *Хикәя.* ....152
Мәҗит КӘРИМОВ. Гарип Мәхмүт. *Хикәя.* ....164
Хисаметдин ИСМӘГЫЙЛЕВ. Явурай. *Хикәя.* ....174

«Казан утлары» архивыннан. ....188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: В.ИМАМОВ. Роман «Огненная степь».
Ф.ЯХИН. Роман «Подснежник» (начало); Т.МИННУЛЛИН. «Не забывайте меня»;
стихи Л.ШАЕХА, Р.ИДИЯТУЛЛИНА, Н.САФИНОЙ.
«Наука»: беседа Р.ЮНУСА с академиком Р.СЮНЯЕВЫМ «Когда мне тяжело, соединяюсь с Казанью»; Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень».
«Литературная критика»: статья Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ, посвященная жизни и творчеству Г.РАХИМА;
«Память»: статья Р.ГАТАША посвященная 150-летию Г.Самитовой;
стихи Г.САМИТОВОЙ.
«Татарский мир». У нас в гостях литературное объединение Стерлибашевского района Башкортостана: Ф.ТУКТАРОВ. «Стерлибаш не далек от Казани»;
рассказы Р.РЫСАЕВА; М.КАРИМОВА, Х.ИСМАГИЛОВА;
стихи Р.ЗИЯЗЕТДИНОВА, Ф.ИБРАГИМОВОЙ, Н.ГИЗЗАТУЛЛИНОЙ, З.ГИЗЕТДИНОВОЙ, Г.БАСИРОВОЙ, Г.АРСЛАНОВА, Л.САБИТОВОЙ, Р.БАЙГИЛЬДИНА, Г.УЛЯЕВА, Х.НАЗАРОВОЙ.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Первый снег»; поэт Салават РАХМАТУЛЛА.

## IN THIS ISSUE:

«Prose and poetry»: V.IMAMOV. Novel «Fire prairie».
F.YAHIN. Novel «Snowdrop» (beginning); T.MINNULLIN. «Do not forget me»;
poems by L.SHAEH, R.IDIYATULLIN, N.SAFINA.
«Science»: interview R.YUNUS with Academician R.SYUNYAEV «When it's hard, I connect with Kazan», F. GARIPOVA. «History of our villages».
«Literary Criticism»: article by D.ZAGIDULLINA devoted to life and work of G.RAHIM;
«Memory»: article by R.GATASH dedicated to 150th anniversary of G.Samitova;
poems by G.SAMITOVA.
«Tatar world». Our guest is literary association of Sterlibashevsk district of Bashkortostan:
F.TUKTAROV. «Sterlibash is not far from Kazan»;
stories by R.RYSAEV; M.KARIMOV, H.ISMAGILOV;
poems by R.ZIYAZETDINOV, F.IBRAGIMOVA, N.GIZZATULLINA, Z.GIZETDINOVA, G.BASIROVA, G.ARSLANOV, L.SABITOVA, R.BAYGILDIN, G.ULYAEV, H.NAZAROVA.
From photo archives of magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: «First Snow»; poet Salavat RAHMATULLAH.

*The magazine edits monthly*

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция жавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә жыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 01.11.2012, график буенча 01.11.2012.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 1/16.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ М – 1414. Тираж 4004.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтнең Татарстан буенча идарәсендә, 2010 елның 1 апрелендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ТУ 16-00337.
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААЖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2012 ел.



Ленар
Шәех

# АК БОЛЫТЛАР БУЙЛАП ЯШЬЛЕК АГА

* * *

**Әй Кырым,
Карама миңа кырын,
Гамьле еллар аша таныш
Синең кайгылы җырың!**

**Кайгылар уртак булган шул,
Борчулар уртак булган.
Тәхет кенә очкан-киткән,
Әйтерсең юртак булган.**

**Гүяки аргамак булган
Гасырлар чабып үткән.
Татарлар Казан, Кырымда
Кан түккән дә яшь түккән...**

**Кимсетелгән, җәберләнгән,
Кагылган һәм сугылган,
Көчләп чукындырылган да,
Ватаныннан куылган.**

**Куылган шул, кусалар да
Китәргә теләмәгән.
Илен баскан хуҗаларны
Ул бер дә өнәмәгән.**

**Рәхәтләнеп яшәр идең
Динеңне кысмасалар,
Туган телең, тарихың бел,
Дип һаман кыстасалар...**

**Гасырлар буе изелеп
Яшәгән кеше генә
Җаны белән якын тора
Чал тарих ишегенә.**

**Кеше нәрсә? Монда милләт
Юкка хөкем ителгән.
Кара җирне тырный-тырный
Соңгы чиккә җителгән.**

Ленар ШӘЕХ (1982) – *шагыйрь; «Дүртенче кат... Бишенче кат...», «Җылытасы килә дөньяны!..» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Әй Кырымым, Кырымым!..
Казанда кыбырсып яткан
Мин синең бер җырыңмын!

Пайтәхетләр очкан–беткән,
Бар ирек — ярты карыш.
Елларда югалып калган
Юртакны эзләп барыш.

* * *

Кырымда төркиләр җыелды,
Үз итеп бу изге җыенны.
Көн саен көрешеп булмый ла,
Көнчеләр сөенә, уйный ла...

Без — күбәү, чәчелгән, сибелгән,
Яуланган, киселгән, тибелгән.
Барыбер яшибез, без — исән!..
Без — моңлы, без — тапкыр, без — чичән!..

Үткәннәр үрелгән бер төпкә,
Көнчеләр киң һәм тиң бөркеткә.
Барыбыз бергәләп утырдык,
Уйларны күзләрдән укырлык!..

Тарих бер, язмыш бер, телләр бер,
Үткәндә – без тоткан илләрдер...
Үзара дус булып, мең яшик!
Берләшик!..
Берләшик!!.
Берләшик!!!

* * *

Җил дә исми. Тынчу һава...
Түзеп карыйк тагын да бер.
Мөгаен бу сафлануга,
Пакьләнүгә — яңгыргадыр?

Өметләник, аның саен
Дөрләп янсын өмет уты!..
Бу дөньяда яшәүләрнең
Кадерле бит һәр минуты...

Бүген көләч, шома йөзгә
Сырлар куна, җыерчыклар.
Без картаймый кем картайсын,
Хәтта тына сыерчыклар.

Елык–елык кара чәчкә
Ялтыр–йолтыр көмеш куна.
Вакыт шулай, чыра кебек,
Гомерләрне телә, юна...

Өмет кирәк, аннан башка
Яшәүләре мөмкин түгел.
Без күпләрдән, бәлкем, артык,
Кимсенерлек бер ким түгел!

**Җан түренә оя корсын**
**Хиснең сафы, шаян-муты...**
**Аның саен күңелләрдә**
**Дөрләп янсын өмет уты!**

* * *

*Әниемә*

**Көннәр әкрен көзгә якынлаша,**
**Тик әлегә чып-чын көз түгел.**
**Күңелләргә җәй җылысы якын,**
**Көзге салкын бер дә үз түгел.**

**Җәй җылысы, җан җылысы кебек,**
**Әллә каян тарта үзенә.**
**Көзгә кергән саен, агачлардан**
**Берәм-берәм яфрак өзелә.**

**Бөтерелеп очкан яфракларны**
**Талгын яуган яңгыр аралый.**
**Торган саен, күңел җылы сорый,**
**Кояш сорый, аңа карамый.**

**Яктылыкка кереп елыша җан,**
**Караңгыны, әйе, өнәми.**
**Юкка гына һаман өзгәләнми,**
**Көз күренү белән йөдәми.**

**Ак болытлар буйлап яшьлек ага,**
**Самими һәм ихлас балалык.**
**Көзгә генә бирешерлек түгел —**
**Хатирәләр белән ара нык!**

**Көннәр әкрен көзгә якынлаша,**
**Тик әлегә чып-чын көз түгел.**
**Күңелләргә җәй җылысы якын,**
**Йөрәк тулы мәхәббәт, моң, ялкын —**
**Көзге салкын шуңа үз түгел!**

* * *

*Флера апа Сафиуллинага*

**Декабрьнең моңсу салкын көне,**
**Бөтен дөнья инде гел актан.**
**Милләтемнең асыл кызы булган**
**Галимәне эзлим ерактан.**

**Бураны да бүген тынып калган...**
**Кемдер чыкты тулай торактан.**
**Татарымның йөз аклыгы булган**
**Остазымны күзлим ерактан.**

**Тел язмышы җирдә аунаганда**
**Кайтып килү түгел кунактан.**
**Күңелемнең нечкә кылы булган**
**Ак апамны эзлим ерактан.**

Казан буйлап җил–җил чаба иде —
Бауман, Кремль, уң як Болактан...
Милләтемә гомер бүләк иткән
Фидакарьне күзлим ерактан.

Декабрьнең моңсу салкын көне
Бер дә китмәс төсле бу яктан...
Кайтмаска дип мәңгелеккә киттең,
Мин кул болгап калдым... ерактан.

## Комедия тәмам!

*Finita la comedia*

Агач очларында җилләр
Котырына һаман.
Күкләрдән килә кайтаваз:
«Комедия тәмам!»

Әйтәләр бит: ач кешенең
Ачуы, дип, яман.
Кемнәрдер анда ачына —
«Комедия тәмам!»

Көн–таң атса, өстерәлеп
Йончыдык бит тәмам.
Татарлар бар да гөж килә —
«Комедия тәмам!»

Күптән вакыт борылырга
Гел кояшка табан.
Урамда халык кычкыра:
«Комедия тәмам!»

Ярыкка кысылуны да
Оештырды заман.
Урманнан Шүрәле дәшә:
«Комедия тәмам!»

Сак–Сок булып сугылулар
Үткәннәрдән калган.
Бүген бар да үзгәрәчәк —
«Комедия тәмам!»

...Сез үзегезгә карагыз,
Мин пәрдәне ябам!

* * *

Хәлең ничек, урыслашкан кавем,
Кырыслашкан кавем?..
Төркилектән һаман качасыңмы,
«Мин — урыс!» дип һаман шашасыңмы?.. —
Хәтер сорый үзенекен, геннар сорый,
Кем соң әйтте: хәтер үлә, хәтер корый!?
Кан хәтере яши, җан хәтере,
Күңелеңдә татарлыгың һаман тере!

**Аннан качып, баш тартып булмый шул,**
**Җан барыбер канны тыңлый шул!**
**Күпме генә телең йотылмасын,**
**Миллилегең изелмәсен, сытылмасын,**
**Күпме генә үткәнеңне җиргә күммә,**
**Йөрәгеңне кыбырсыта тик бер җөмлә:**
**«Син — татар!..» — Уңга китсәң дә, сулга...**
**Салсаң да син татарлыгың утка, суга...**
**«Син — татар!..» — Телең татар булмаса да,**
**Заман синең үзаңыңны урласа да!**
**«Син — татар!..» — Төшләреңә кереп уятамы?**
**Башка милләт арасында күзеңдәге**
**Нур сатамы? Маңгайдагы җөй сатамы?.. —**
**Юк! Бу сафсата да түгел, бу — өн!**
**Язмыш сиңа әйткән: син бет, бүлен,**
**Юкка чык, башка милләтләрне үрчет!..**
**Кулыңда барыбер калган бер җеп —**
**Төркилектән, татарлыктан килгән хәтер...**
**Тыңлап кара, уйлап кара — ул ни әйтер?..**

## Мин Сәйдәшне тыңлыйм...

**Мин Сәйдәшне тыңлыйм кабат-кабат,**
**Мин Сәйдәштә күрәм үткәнне.**
**Җаным белән тоям,**
**нигә халкым**
**Йөрәгендә аны йөрткәнне.**

**Ул, татарның бер бәгыре булып,**
**Килеп чыга минем каршыма.**
**Аның көе — язгы ләйсән яңгыр,**
**Талгын гына яуган кар сыман.**

**Аның моңы, якты кояш кебек,**
**Нурландыра җанны, күңелне.**
**Менә тагын мин Сәйдәшне тыңлыйм —**
**Бар халәтем нурга күмелде.**

**Сәйдәш бит ул — халкым күңеленең**
**Чыңлап торган моңлы бер кылы.**
**Мин татарның яшәешен күрәм**
**Сәйдәш язган көйләр аркылы.**

**Ә ул көйләр киләчәккә әйди...**
**Күз яшьләрем тама. Елмаям...**
**Аны тыңлый-тыңлый үсә татар,**
**Сәйдәш белән бергә олгая.**

**Ул татарга озын гомер юрый,**
**Юраулары, шөкер, юш килә.**
**Мин Сәйдәшне тыңлыйм кабат-кабат,**
**Күңелемә Сәйдәш хуш килә!**



Фәрит
Яхин

# УМЫРЗАЯ

РОМАН

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

### I

1957 нче елның матур кояшлы июль аенда, 24 нче числода, Казан шәһәренә кап-кара бөдрә чәчле, янып торган шомырт кара күзле, кызыл чия иренле, хыялый картиналарда сурәтләнә торган әкияти гаҗәеп бер чибәр татар кызы килде. Моны тарих сәгатенә-минутына кадәр хәтерләп калырга тиеш иде. Шуңа күрә аның, тарихның, исенә төшерәм: вакыт иртәнге алты сәгать тә тугыз минутта булды бу вакыйга! Уфадан Казанга килгән пошмас поезд ул көнне бер генә мизгелгә дә соңга калырга кыймады. Бөек тиран тарафыннан гадәткә кертелеп калдырылган тәртипләрне бозарга ул вакытларда әле һичкемнең кодрәте дә, кулы да җитми иде.

Иртәнге якта инде шәһәр җыештырылган, себерелгән, пөхтәләндерелгән, адәмнәре дә хушбуйланган, кырынган-ясанган, хезмәт дәрте белән балкып торган халәттә. Вокзал репродукторында, көннең яхшы буласын белдереп, ил халкына Мәскәүнең һава торышын тапшырдылар. Моннан егерме минут кына элгәре ул, иртәнге гимнастика башлануын әйтеп, тәннәрдәге җөйләрне таратып җибәрүче музыка белән күңелләрне хушландырган иде. Уфа-Казан поезды шул көй эчендә вокзалга килеп керде. «Начинаем утреннюю гимнастику. Исходное положение принимаем...» — дигән гадәттәге сүзләр генә әйтелделәр югыйсә...

Ә менә хәзер перроннан күбәләк кебек хәрәкәтчән, шөпшә кебек чая, әлеге дә баягы чибәр кыз, шатлыгыннан җан янып сикеренеп, кулындагы кечкенә ак сумкасын болгап-изәп очып-очып диярлек йөгереп китте. Әтисе ак «сталинский» фуражкалы, ак-чиста костюмлы, ирләр йөртергә гадәтләнгән кызгылт галстуклы, ак якалы кеше, кулындагы ярым кыршылган кечкенә чемоданны, биштәр итеп богаулаган авыр гына капчыкны кысып:

— Кызым, ашыкмы! Югала күрмә! — дип, баласының артыннан хафалы тавыш белән эндәште.

Якындагы тәртип саклаучы милиционер, гүяки агайга ярдәм итәргә теләп,

---

Фәрит ЯХИН (1961) — *шагыйрь һәм прозаик; «Пәйгамбәребез Мөхәммәд», «Ак әбиләр догасы», «Сөйкемле сөяк», «Тоз тәме» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

шунда сыбызгысын сызгыртты. Бу олы гәүдәле, зәңгәр галәфи чалбарлы, ак кительле, кызыл каймалы фуражка кигән адәм котны алырлык иде. Ярамаган урында рельслар аша кемдер чыкмакчы булган икән. Милиционер ана сызгырткан. Теге, куркуыннан әле аягын кире алып, әле алга, шпалга таба төшереп, ни кылырга белми гажизләнеп интегеп маташты. Шушылай тәртип бозганы өчен генә ул бичара татар хатынының «читлеккә ябылып чыгасы» килми иде. Милиционер, аның хәленә кереп, ул якка аркасы белән борылды. Татар апасы, бу бәхеткә сөенеп, яшел яулыгының чите белән йөзен каплады да ашыгып-ашыгып кына халык арасына кереп югалды. Күбәләк кебек очып баручы кызының сыбызгы әмере белән туктавына сөенеп, аны капчыклы-чемоданлы атасы куып тотты. Бичара ир тирләргә һәм сулышын югалтырга өлгергән иде инде. Кызы аның әйберләрен күтәрешәсе итте. Бу балага мөгаен унҗиде-унсигез яшьләр чамасы булса да, нәкъ шулай икән дип тәгаенләп кенә әйтергә мөмкин түгел, билгеле. Сабыйлыгы чыгып житмәгән кошчык, балалыгы китеп бетмәгән кузы дисәк, бер дә хата кебек тоелмас.

— Нинди матур шәһәр! — диде кыз, тәмам сокланып. — Мин төне буена йоклый алмадым, әткәй!

— Сиздем, кызым, сиздем! Мин дә рәтле йоклы күрмәдем! — диде әтисе, тукталып, кузгала башлап.

— Йокламаган кеше гырламый ул! — дип әйтте дә куйды кызы, әтисен үпкәләтергә теләмичә генә үртәп.

Баласының гадәтен яхшы белгән ата кеше аның кирегә суктырып әйтүенә игътибар бирмәде. Капчыкны биштәр итеп аркасына асар өчен җайлаган бауларыннан урап алып, кызын алга ашыктырды:

— Әнә трамвай китеп бармакчы. Безнеке булмагае!

Трамвай китеп барырга өлгерде. Аның кыңгырау кагып кузгалуына кадәр кызга көлкеле тоелды. Ул арада әтисе халыктан ничәнче трамвайга утыру мәслихәт икәнлеген белешеп өлгерде.

— Безгә «Дүртенче» дә ярый икән, «Икенче» дә әйбәт булыр, — дип житкерде ул кызына.

Ә баласына — барыбер, ул күкләрдә йөзә, хыял канатларында оча, бәхет күлләренә чума иде. Атасы ана әле аптырап, әле борчылып карап-карап куйды. Көтелгән трамвай юл аркылысын чыга алмыйча, килү ягында кыңгыравын каккалап, кузгалырга торган ат ничек пошкыргаласа, шулай иткән сыман ашкынып маташа бирде. Йөкле машина аның рельслары аша чайкала-чайкала, адымлап диярлек үтеп, көч-хәлгә китеп барды.

## II

Кыз баланың тормышка җилел генә каравы, дөнья йөзендә бар да гөл генә, бар да якты көн генә дип йөрүе ата кеше өчен куркыныч әйбер. 1957 елның 24 июлендә, иртәнге сәгать алтыда Уфа-Казан поездыннан төшкән чибәр кызны күпләр күреп өлгерер дә, тик тарих моны хәтерендә калдырырга теләми әле. Хәер, хикмәт бит тарихта түгел, аның өстенлегенә дә бәйләнмәгән. Хикмәт — чибәр кызның, шушы пионер ялкынында «пешкән», комсомол хисләрендә тәрбияләнгән, бәхетле, иркен, кеше өчен дип төзелгән илдә яшәвендә, һәр көнне кояшка сокланган кебек, партиягә хәйран шушы назлы баланың үзендә иде. Әтисен борчыганы болар гына булса — бер хәл, вакыты житеп, ул юләрлекләре чыгып бетәр, сабын куыгы кебек кабарган хыяллары шартлар да юкка чыгар иделәр. Әмма аның кызы әле шагыйрә дә бит, житмәсә! Тормыш турында язса — бер хәл, әллә ниләр хакында хыяллана, оча бит әнә, оча бала! Ә син, аны менә Казанга, университетка укырга кертергә алып киллдем, дисең. Зиһене яхшы, биш ел элек укыган китапларын да сүзгә-сүз сөйләп бирә ала, дисең. Әйе, кызының бу яктан табигате әбисенә дә,

әнисенә дә охшаган. Әмма да кешенең бер ягында артыгы белән өстенлек бар икән, икенче якларына нигәдер кимлек килә. Холкының утырып җитүен ата кеше көткән иде, булмады. Кызының йөзе тулы кояш. Авылны, әниемне, туганнарымны калдырдым дип бер сагышлансын иде хет, ә ул — очына, күктән төшә алмый. Дөньяга җинел каравы гына җитмәгән, шагыйрә бит әле җитмәсә, шагыйрә! Кайта-кайта мең әйтерсең, мең уфтанырсың! Хәсрәт өстенә кайгы, сагыш янына гамь түгелме соң бу?

— Әткәем, мин шушы университетта укырмынмы?

Алар, трамвайдан төшеп, тыкрык-урамнардан күтәрелеп, ашкынып-ашыгып университетка килеп җиттеләр. Зур, биек, мәһабәт күренде ул аларга. Каршындагы колонналары аңа баш ирешә алмаслык мәртәбә һәм бөеклек биреп тора. Менә ни өчен борынгы греклар төп аллалары Зевсның тау башындагы сараен һәр яктан да колонналы итеп төзегәннәр — илаһилык өчен!

### III

Әйе, 1957 елның 24 июлен тарих хәтерендә калдырырга тиеш иде. Шушы шагыйрә кыз белән нисбәттә генә булса да, аның шушы көнне әтисе белән Казанга университетка укырга керергә дип документларын тапшырырга килүләренә бәйле генә булса да искә алырга тиеш иде. Кабатлап белдерүебезнең сәбәпләре бар, чөнки тарих хәтта бөек Габдулла Тукайга да мәрхәмәтсез булды, аның да Казанга кайту көнен, ягъни Уральскидан килүен сәгате-минутына кадәр төгәллек белән исендә калдырмады, хәтта аен да ачык хәтерендә саклый белмәде. Ә без аны, авызларыбызны тутырып, «Тарих!» дип атаган булабыз. Тарих шундый буламыни?!

Ата кешенең биштәрендә һичшиксез бәрәңге булырга тиеш иде. Ә кулындагы кечкенә чемоданда — кызының берничә катка алмаш киемнәре. Ерак юлдан килделәр бит. Казан кадәрле Казанга!

Вакыт әлегә иртәнге як иде. Кәримә тик тора белми, һаман да оча-очына, университет колонналарының әле бер ягына чыга, әле икенчесенә... Аларга тотынып карый, колачы җитми. Әллә инде үрмәләп менеп китмәкчеме, Ходаем?

Моңа әтисенең эче поша, шуңа да:

— Кызым, Кәримә, син нәрсә инде? — дип, ачуланырга иткән сүзләрен кабатлый. Бала аның тавыш күтәреп битәрләмәячәген аңлый. Күңел канатларында оча бирә ул. Университет колонналарын биш әйләнә. Тагын аларга гаҗәпләнә, кочакламакчы була, әтисеннән кырын сүзләр ишетә.

Арырак урам себерүченең себеркесе чаж да чож итеп ала. Кәримә ул агайга аптырап карап тора. Аңа кызык: мондый урамнарны да себерәләр икән!

Шәһәр шушы була бит инде ул: иркен, киң, рәхәт. Һавасы гына да ни тора! Юк сүз ул авылларда — ирек, авылларда — яхшы дип сөйләүләр. Андагы кысынкылыкны белсәгез, күрсәгез иде сез. Урамга чыксаң да кеше, болынга төшсәң дә кеше. Кичен берәр егет озата кайтса, иртәгә иртән бөтен авыл бу хакта белеп тора. Кәримәне юкка үртәгәннәр, шәһәр эче тулы кеше, бар да ят, берсен-берсе танымыйлар дип. Танымасыннар, кирәк түгел. Үзен танытырга килде монда Кәримә. Менә аны танырлар! Һе, кеше күп, имеш. Вокзалда әнә бер поезд халык төште. Минут эчендә таралды да бетте. Комга түгелгән су кебек тә булмадылар.

Укырга керергә теләүчеләрнең документларын кабул итү комиссиясе иртәнге сәгать тугыздан гына эшли башлый икән. Әле җиде тулып кына үтте. Никадәр вакыт бар. Аны кая куеп бетермәк кирәк?

— Кызым, Кәримә! Комачаулама абыеңа! Кил, монда утырып торыйк, бүген көн бик тә эссе булыр сыман. Иртәннән кыздыра башлады бу.

Әтисе туйдырып бетерде инде. Акыл өйрәтүдән, кисәтү ясаудан узмый. Мәктәп директоры булдым дигәч тә! Үз хәсрәтләрен кызы янында калдырып торса да ярар иде. Күнелле түгел бит инде гел сүз ишетеп гажизләнү: «Кәримә, алай ярамый! Кәримә, болай кыланма!» Ә ничек ярый соң? Кыланмау нинди була? Кузгалмыйча, тик кенә утырып торыргамы? Әнә теге кыз белән абый кебек?

Университет каршындагы бакчага охшаган бер урында эскәмияләр куелган икән. Анда кешеләр дә бар. Менә кая чакыра баядан бирле Кәримәне әтисе. Авылдан килеп, шәһәр карамыйча-күрмичә, ничек тыныч кына утырырга мөмкин икән инде? Әллә күпме матур йортлар, буп-буш урамнар. Шуларны әйләнеп, күреп килергә тиеш Кәримә. Монда бит борынгы Кремль дә бар. Сөембикә манарасы! Шуларны карап йөрсәләр нәрсә булган?

Бакчада утырган агай белән кызның шулай ук биштәре һәм кечкенә чемоданы бар икән. Бер сүз сөйләшсә иделәр. Бу кыз бигрәк иртә әбигә әйләнгән, кузгалырга да куркып утыра. Кәримә кебек университетка укырга керергә килгән инде ул да. Сап-сары чәчле, ак бантиклы. Әтисенә елышкан. Бигрәкләр куркак икән, бичаракай!

Кәримә чем-кара, бөдрәләнеп торган чәчле, кызыл бантлы ичмасам. Кызыл бантлары кара чәчләрендә гөл чәчәкләре кебек балкып тора. Әтисе шуны да яратмады, «скромный» түгел дигән була. Мәктәптә дә кызыл бантлар тагып йөртергә теләмәде. Үз кабинетына чакырып алып, кара төстәгегә алыштырта торган иде. Шуны да белмәде бит: кара бантлар Кәримәгә килешми, чәчләре арасында югала да кала. Өлкәннәр матурлыкны бигрәкләр дә белми инде. Бу кыз да сап-сары чәчләренә саргая башлаган ак бантиклар тагып куйган. Чәчен ике толым итеп үргән әле, кысып-кысып. Менә Кәримәнең, ичмасам, рус кызларыныкы кебек бер толымга калын итеп үрелгән. Ул хәтта йокларга ятканда да аны чишеп тормый. Чияләндерсә — бетте, тарак мәнге кермәячәк! Шәһәр байбәтчәләреннән бет ияртмәсә генә ярар иде. Кала кадәр калада әллә ниләр бардыр әле, тотып ашаулары да мөмкин. Әнисе ана ничә әйтте:

— Төнлә йөрмә, укуыңны гына бел, башыңны ашамасыннар! — диде.

Булыр да. Монда адәм итеннән пирожки дигән нәрсә пешерүчеләр дә бар ди әллә!.. Бөгелмәдә, поезд көткәндә, Кәримәнең борынына шул пирожки-бөккән дигәннәренең тәме кереп җәфалады. Әтисе алдырмады. Әнисенең сүзләре хаклы микәнни? Адәм итеннән пешерелгән дип уйлыйлардырмы, әллә дуңгыз маенда пешкәнлеген сөймиләрме? Юктыр. Әтисе коммунист бит аның, дуңгыз итеннән дә, маеннан да чирканмый-курыкмый. Акча тотарга теләмәгәндер! Анысы, бер пирожки-бөккән алып ашаганнан гына акчалары әллә ни кимемәс тә. Нигә саранланды инде?

## IV

— Исәнмесез! Сез дә документлар китердегезме?

— Әйе, шулай дип тора идек!

Кәримәнең әтисе утырыр урынны бакча эскәмиясендәге кыз белән агай янәшәсеннән алды. Үзара тартынып кына сүзләр башлангач, кайсы яктан икәнлекләрен белештеләр. Кызның исеме Сабира икән, Рева кушмакчы булсалар да, әниләре теләмәгән.

— Арча ягыннан без, — диде агай. — Габдулла булам. Элек бездә ике кешенең берсе Габдулла иде бугай. Хәзер төрләнде инде. Сез кайдан соң?

— Сарман ягыннан ук килдек. Кызым университетны сайлады. Башлангыч мәктәптә, Ләшәү дигән авылда директор мин. Гарифулла исемле булам, Гариф дигәндә дә ярый. Мине шулай атап йөртәләр дә. Кызым — Кәримә. Шигырьләр яза. Әдәбият белән шашынгач, татар бүлегенә

документларын китерә килгән идек, — дип аңа, беренче очраган кешегә, барысын да әйтеп бирде Кәриманең әтисе. Ә үзе таныш түгел кешегә ачылып китмәскә куша. Шигырьләр язуын ник әйтте инде?

Кәримә, кирәкмәгәнчә ояла да белә торган кыз буларак, комач кебек кызарырга тиеш иде. Әмма йөзендә үзгәреш сизелмәде. Баласын яхшы белә торган ата аңа карап алды. Аларның күзләре очрашканда кызы әллә нишләп китте. Каушавы теленә чыгарга өлгерде:

— Әти, — диде ул, — бөтенесен дә әйтеп бетермә инде!

Гарифулла абзый аптыраулы кыяфәткә керде. Аныңча ул әле сүзләрен башламаган да иде. Кызына илтифат итеп тормаска уйладымы, яңа танышыннан сорарга булды:

— Сез нинди теләкләр белән килдегез?

— Без дә татар бүлегенә дип атап килдек. Кызым Сабира шигырьләр язмый анысы. Газеталарда мәкаләләре басылды. Язу эшен сайламакчы. Ә мин аңа укытучы булырга әйтәм.

Беразга сүзләре бүленде. Беренче карашка Сабира белән Кәримә көндәшләр иделәр. Инде бер-берсенә ачылып ук китмәскә дә мөмкиннәр. Тик сүзләр тәртип белән башланган, дәвам итми кала алмый иделәр.

— Документларны иртәрәк тапшырганда да буласы иде, — дип әйтеп куйды Гарифулла абзый. — Арча ерак җир түгел. Ул безгә генә юл газабы — гүр газабы!

Габдулла агай нидер әйтергә теләп тамак кырып та, сүзне ялгамый, өзек килеш калдыру ягын карады. Әмма Гарифулла абзый ашыкмады. Аның ак какча йөзе җыерылып алды. Сәбәпне беләсе килә, әмма сернең асылын яшерергә өйрәнгән шушы үтә сак буын сүзне үлчәмдә тотып тормый кала алмады. Шуңа да:

— Баламны пионер лагеренда эшләтеп, бераз акчасы булмасмы дигән идек. Яшь кешегә кирәк бит, — диде Габдулла агай, бит очындагы олы миңенә таба авызын ергандай итеп.

— Сез дә мәктәптә эшлисезме?

— Әйе, җидееллыкта. Директор. Утын эшләре белән дә озак йөрелде. Җае чыкмый торды.

— Анысы шулай инде.

Тагын ике арада тынлык урнашты. Сылу Казан каласының тын бакчасында сәгатьләр акрын үтә торды. Габдулла агайның да башында ак фуражка иде. Ул, аны салып, маңгай тирен сөртеп маташты. Аңлаган кешегә йөрәгенең сау түгеллеген төшенерлек иде аның бу хәрәкәтләреннән. Кызының сабырлыгы, артык бер генә дә селкенмәве дә шуның белән бәйле булырга мөмкин, әлбәттә. Әтисен борчырга теләмәве сәбәпле баланың үз холкын да тәртиптә тотуы дөньяны белгән кешеләргә аңлашыла, билгеле. Гарифулла абзыйның Сабира кебек кызга ата буласы килә, тик ул үзе хакында, менә шушындый сыйфатларга яшьлектә рухының омтылганына исәп-хисап ясап, бер утырып уйлана да алганы юк. Менә хәзер мөмкинлек туды. Кызында мондый хәрәкәтчел тәвәккәллек әнисеннән килә, үз-үзенә ышану хисе аңа бетмәс-төкәнмәс көч бирә. Теләсә — утка, теләсә — суга ташлана торган адәм баласы янмый-көйми калмаячак. Революция һәм сугыш геройлары шушындый кешеләр арасыннан чыкты. Әмма андый заманнар артка калды кебек. Инде алар кабатланмас сыман. Кеше нинди булырга тиеш хәзер? Тагын «кайнар башларны» чүпли башларлармы? Кыз бала дип тормаячаклар бит!

Гарифулла абыйга боларны уйлавы авыр булырга тиеш иде. Кызын мөмкин кадәр актив пионерка, тырыш комсомолка итте ул. Бөтен районны сокландырып торган, коммунистик идеаллардан өлге алган кеше, шул

утларда кайнарланган йөрәк ялгышмаячак. Илгә, партиягә каршы эш алып баручы да, милләтче дә булмас, буржуаз, хәтта вак буржуаз идеология сөйрәлчеге дип тә атала алмас!

Гарифулла абзый шунда акылы арыганлыгын тойды. Иллә ниләр булмас, аларның барысын да уйлап бетереп, аңлап житкерү мөмкинме соң? Юк, әлбәттә. Нәрсә эшли ул? Нигә әле болай, әле тегеләй итеп кешеләрне бәяли? Партия аннан житдилек таләп итә, үз эшендә ул берәр тапкыр мондый йомшаклык күрсәттеме?..

Жәйге иртәнең эссе жиле, кайсы яктан исәргә белмичә аптырап, уңлы-суллы ничек йөренсә, Гарифулла абзыйның да уйлары шулай иләс-миләс иделәр. Ә кызы Кәримә, кояшка таба сикерергә дип йөгергән-чапкан колын сыман, тыңгы белмәс йөрәген тыя алмыйча, әле эскәмиягә килеп утырды, әле бакчаны әйләнеп чыкты. Сабира хет бер кузгалып карасын.

— Тамак ялгап алдыгызмы? Монда, Чернышау урамында, яхшы гына ашханә бар! — диде бераздан Габдулла агай, нигә эндәшми утырасыз дигән кебек итеп әйтергә теләгәндәй.

— Поездда ашадык. Үзебез белән алган идек. Бездә пешкән бәрәңге калды әле! — дип, биштәрен кузгата башлагач, Гарифулла абзыйны бу теләгеннән тизрәк туктатып:

— Безнең тамак тук. Яхшы яшибез. Кирәкми. Ашханәне сезгә, ерактан киләсез, белмисездер дип әйткән идем. Юл кешесенең тамагы тиз ачыгучан була ул. Шуңа гына... — диде Габдулла агай, кулын яңа танышының капчыгы өстенә куеп. — Безнең Арча монда гына бит!

Шушы сөйләшүләреннән соң алар тагын сүзсез калдылар. Кәримәгә бу тагын эчпошыргыч тынчу хәл сыман тоелды.

## V

Сәгать төгәл тугызга алар университет ишеге төбенә кабат килеп, «Кабул итү комиссиясе»нең инде эшен башлап жибәрүе хакында ишетеп алып, моңа рәхәт кичерешләр белән сөенделәр. Документларны да бергә тапшырдылар. Ике кызның да аттестатларында бары тик «бишле» билгеләре генә иде. Бу исә ике якның дуслыгы ныгу өчен тагын да бер сәбәп булды.

Имтиханнар беренче августта башлана икән. Әллә ни аптырыйсы юк, монда да шул ук мәктәп имтиханнары кабатлана. Сынау алучылар, үз таләпләре белән таныштырып, аңлатма-консультацияләр дә бирәселәре булгач, монысы абитуриентлар өчен тагын да яхшы. Кызларына әтиләре ул дәресләргә йөрүне мәжбүри итеп куйдылар. Әзерлек курслары да эшләгән, аларга да йөрү кирәк булган да бит, әмма соңарганнар, андагы укулар бетеп килә икән инде.

Ике ата да балаларына бер үк әбидә фатир тапсалар, яхшы буласы хакында киңәшеп, Габдулла агай шунда Казанда таныш кешеләре барлыгын, күршеләрендә ялгызак профессор хатыны иркен генә яшәп ятуы, анардан үтенеп караганда, шунда кызларын фатир төшерү кулай булмасмы дигән фикерне әйткәч, шул ишек төбенә барып карарга булдылар. Университет тавыннан төшеп, Болак күперен чыккач та, Совнарком бинасы каршында, Париж коммунасы дигән исемне йөрткән урам ягыннан ике катлы таш пулатлар ышыгында торган ишек алдына керделәр. Мондагы һаваның бераз салкынча булуы, бакчасының агачлык һәм гөлләр белән балкып торуы күңелләренә мең төрле сөенеч бирде. Аларны ишек алдын себерүче һәм караштырып торучы агай туктатты. Кулындагы себерке сабын мылтык көпшәсе кебек китереп алдан баручы Габдулла агайга төртте:

— Сез кая? Кем кирәк иде?

Аның ак киндердән тегелгән чиста алъяпкычы, калын гына русча сакалы, гөрнәдирдәй гәүдәсе монда төп хужа кеше булуын тагын да дәлилләгән

кебек. Бу агайның кыяфәтеннән ул кайчандыр шахтер булгандыр дигән уй кала. Тик ике-өч атлап куюыннан сул аягының агач икәне беленә. Ямаулы гимнастеркасына карасаң, сугыш кичкәнлеген тоясың. Әмма андыйлар сакал-мыекны кырып йөриләр бит! Шуңа яхшылап өйрәнеп кайттылар, көн дә диярлек тамаклары йөз граммлап батырлык эчемлеген сорап торуы да халык эчендә сер түгел. Тәмәкене дә яхшы тарталар. Ә моның — сакал-мыек. Хәер, Казан «дворниклары» иске гадәт буенча шушы кыяфәттә йөриләр икән дигәнне ишеткәләгән Гарифулла, университет алдын себерүче теге агайның исә мондый түгеллеген исенә төшерепме:

— Монда да төрлечәрәк икән! — дип әйтеп куйды.

Аның нәрсә хакында әйткәнлеген беркем дә аңламады. Габдулла агай кемгә дип килүен, балаларының университетка кирәргә документлар тапшыруын, карт профессорның тол калган хатыны фатирга алмасмы дип ышаныч тотуларын, хәтта үзләренең кайсы як кешеләре икәнлекләрен, ничек танышуларын бер генә дә яшерми сөйләп бирде.

— Метри агай, менә шул эшләр йөртә әле безне! — дип, сүзләренә өлкәннәрчә йомгак ясап, сөйләвен тәмамлады.

«Дворник» күзләрен тагын да шырпы калынлыгына кадәр кысып, аңарга карап торды да, шунда гына танып алгандай:

— О Апушчик! Син икәнсең бит! — дип, күрешер ният белән кул сузды.

Мондый зур хуҗа кешенең олылап исәнләшүен кабул итәр өчен Габдулла уң кулындагы биштәрен җиргә куйды. Аннары гына яхшылап исәнләштеләр. Гарифуллага андый хөрмәт тәтемәде.

— Шушы кызларны китердегезме? — диде ишек алдын караучы Метри агай, болар үссә, яхшы мал булырлар иде диярәк күзләрен хәйләкәр елтыратып алды. Аңарда элек тә мутлану булган, ахрысы.

— Өйдә иделәр... иде әле! — диде Метри агай. — Өйдә иделәр. Унбишенче фатирда торалар. Профессоры вафат булгач, яхшы кеше иде, мәрхүм, тормышлары шактый кысылды. Фатирга бер кызны алган иде инде... Бәлки кертер. Унбергә базарны йөреп кайту гадәте бар. Керерсез инде алай булгач!

Бер-беренә диварга-дивар төртештереп диярлек салынган йортларның иң түр башында биек ишекле «парадный подъезд» иде. Шунда таба барасы икән.

Баскычлар агачтан, ныклы итеп эшләнелгән, борынгыча бизәкле иделәр. Мондый урында фатир очсыз була алмый. Икенче катка күтәрелеп, олы ишекне кактылар.

— Әти, «звонок»ка басарга кирәк! — диде шунда Сабира, төртеп күрсәтеп диярлек. Әтисе исә белəм дигәндәй кызына карап алды. Әмма ишекне алай да ачмадылар. Өченче тапкырларын кыңгырау төймәсенә төрткәч кенә аяк тавышлары якынлашып килгәндәй тоелды. Ишекне олы, калын гәүдәле, әби дисәң — әби түгел, житди йөзле ханым ачты. Аның киемнәренең затлы булуы ук кемлеге хакында сөйли иде.

## VI

Хуҗабикә бик тә тәвәккәл ханым булып чыкты. Кызларны күңел үлчәвенә салып, баштан-аяк күз белән сынап карап торды да:

— Укытучы балалары булганга гына ризалашам, — диде, биленә ике кулы белән дә таянып, тантаналы мирза-бикә хатыннар кебек, гүяки әмер бирергә әзерләнгән кешедәй. — Түләвен алдан биреп куярга. Бер бүлмәм бар. Өчәү торырлар әлегә. Ул кызым озакка калмас. Үзләренекен ашарлар. Кичке сигездән соң урамга чыкмаслар, егетләр алып кайтмаслар, укудан артыгын белмәсләр!

— Юк-юк, нинди хәл ди ул, булмаганны! Егетләр белән йөргәннәре юк! — дип Габдулла агай, юантык гәүдәсенә ял эзләп, урындыкка карый-карый,

һаман да шул «юк» сүзенә туктаусыз басым ясап җавап бирде. Аның сүзләре үз кызына гына карый. Ә Кәримә, чакырганны да көтмичә, ике бүлмәгә кереп чыкты. Диварлар буена тезелгән китап шкафларына да ачарга үрелеп алды. Аны хуҗабикә шунда ук ачуланып та өлгерде:

— Бер генә дә охшамаган бу кәҗә бәтиенең егетләр белән йөргәне булмаганга!.. Тимә!.. Китапларга, әйберләргә кагылмаска!.. Бу бала кайсыгызныкы? Ишетсен колагы, берәр әйберем югалса, хәзер милиция чакыртам! Утыртып куялар читлеккә, таш капчыктан чыкмаслык итәрләр! Профессор мирасы! Кирәкле китаплар булса, сорарсыз, үзем алып бирермен!

Аның бу «речен» тыңлаганда Гарифулла абзый мең кат тирләп чыкты. Габдулла агай, тәкъдим ителмәсә дә, тәки урындык җаен табып, шунда утырды. Үзе һаман да бертөрле сөйләде:

— Юк-юк! Нинди хәл ди ул? Укытучы балалары алар. Тәрбияле балалар. Бер генә начарлыклары тимәс. Укырга да керсәләр...

— Укырга кергәнче генә! Сынау шарты белән! Бер айга кертәм әүвәле! Аннары фатирны үзегез табарсыз!

Хуҗабикәнең исеме Хәнифә Галиевна икән. Әтисенең исемен өстәмичә генә Габдулла агай ана эндәшеп караган иде, ханым ишетмәде. «Хәнифә Галиевна» дигәч, шунда ук әйтте:

— Монда кызларга «абый» да, «апа» да юк! Казан бу! Интеллигент шәһәр! Караватка утырмаска! Аның өчен урындык бар. Сала гадәтләрегезне ташларсыз. Авылда гына ул сәкегә утырып ашыйлар, сәкегә ятып йоклыйлар. Карават ул сәке түгел. Профессор кабинетына кермәскә! Берсе караватта, берсе хәзергә диванда йокларлар. Өченче кызыбыз, әнә, идәндә йоклармын дигән иде. Рөхсәт итмәдем. Әллә соң икесе бер караватта йокларлармы? Сыялар, сыялар! Аерым караватлар әлегә буш түгел монда!

Ризалаштылар. Аталар әлеге шартларга бик шат иделәр. Кызлары да каршы килә белмәде. Биштәрләрен бушаткач, аннан бәрәңге, тозлы ит, суган һәм олы түгәрәк икмәкләр дә чыккач, хуҗабикә шунда ук аларны җыеп алды һәм кая куярга урын тапты.

— Икмәк кимереп йөреп өйне чүпләрләр. Ит тә ислән торган әйбер, күз-колак була белмәсләр! — Шунда ук сорап та өлгерде: — Каклаган каз, май ише юк идемени?

Аталар мондый ризыкның китерелмәвен әйттеләр. Кызлары исә, ул төр ашамлыклар да буламыни дигәндәй, үзара карашып алдылар. Хәнифә Галиевна бу сала мөгаллимнәренең хәленә тиз керде:

— Бичаракайларым! — диде. — Авылда яшәп тә инде...

— Алып килермен, укырга гына керсеннәр! — диде Габдулла агай, ике кулы белән тезләренә таянып утырган килеш, анысыннан гына калмабыз.

— Кара әле, бүген Якуп Агишны күрәсем бар иде. Аңа укырга керәбез дисез түгелме?

Хәнифә Галиевнаның сүзләре әүвәле аңлашылып җитмәде. Аннары гына:

— Татар бүлегендә укыта ул. Имтиханнарны да ул ала, — дигәненнән соң, хуҗабикәнең бик тә яхшы һәм ышанычлы кеше икәнлеге тәмам аңлашылып җитте. Көтелмәгән җирдән килергә мөмкин булган мондый ярдәм күктән бәхет ботkасы явачагын вәгъдә итте. Акыллы аталар бу хөрмәткә мең куллап риза булырга тиеш иделәр.

## VII

Әтиләре китеп баргач, кызлар, иң әүвәлдә, икесе тиң бик тә куаныштылар. Алар үзләрен тәрәзә ачылудан һавага очып чыккан күбәләкләр кебек хис итеп, гүяки киң болыннарга, чәчәкле аланнарга таба очтылар. Әмма бу

«киң болыннар һәм чәчәкле аланнар» серле, әлегә бөтенләй дә билгесез бәхет шәһәре иде.

— Болай булса, мин университетка керәчәкмен! Әткәй әйтте, кермәсәң, керә алмасаң, диде, авылга кире алып кайтып китәм, башлангыч сыйныф балаларын укытырсың, диде. Минем кире кайтасым килми. Миңа монда бик тә ошый! — дип, озак, күңелләрне шатлык һәм өмет белән тулырлык итеп сөйләде Кәримә. Шушылай булуы аркасында Сабирасы да ачылып китте һәм ул:

— Икебез дә укырга керә алсак, ничек яхшы булыр иде! — диде дә, шунда ук үзен кулга алырга тырышып: — Син укып өлгермәгән китаплар калдымы әле? — дип сорады. Аның йөзе агарган, көче киткән сыман тоелды.

— Безнең татар әдәбиятында Мирсәй Әмирнең «Агыйдел»еннән дә гүзәлрәк әсәр юк! — диде Кәримә, бүлмәдә дивар биеклек көзге каршында итәк болгаудан да рәхәтрәк эш таба алмыйча. — Безнең мәктәптә дә шундый көзге бар, коридорда тора. «Кулак Сәйфетдин көзгесе» дип йөртәләр!

Сабира көзгедән үзен карарга җөрьәт итмәде. Билгеле инде, Кәримә кебек чибәр кыз янында аңа сурәтенең күпкә кайтыш икәнлеген тоюы бик авыр.

— Кызларым, мин базарга барып кайтам. Бүлмәгездә генә утырыгыз, югыйсә фатирдан куып чыгарам! Ишетсен колагыгыз! Берәр сәгатьтән кайтам! — дип, Хәнифә Галиевна бөтен йортка ишетелерлек итеп хәбәр салды. Аның тавышыннан куркып, тәрәзә төбенә очып килеп кунган, нәрсәләрдер чүпләп чыркылдаучы чыпчыклар пырхылдап очып киттеләр. Ян дивар буйлап сузылган беренче катның подъезд-болдыр түбе түбәсенең кызгылт-көрән калайларына басып-басып, мыштым гына килеп маташкан буй-буй кызгылт-сары мәче, койрыгын күтәреп, олы, юан гәүдәсенә көч биреп, мияулап җиргә сикерде. Боларга игътибар итәргә өлгергән Кәримә шунда ук ишек төбенә затлы киемле Хәнифә Галиевнаның чыгып басуын, җиргә көнбагыш сибеп җибәрүен, анда күгәрчен-чыпчыкларның җыелышып маташуын, теге мәчегә исә колбаса кисәге элгүен карап калды. Ул да түгел, тиз генә фатирны айкап, кулына ике конфет тотып кереп тә өлгерде.

— Юк, кирәкми! — диде Сабира, китап алып утырган җирендә итәгенә төшкән кәгазьле конфетны алырга шикләнеп. — Син нәрсә? Апа кайтып керсә? Аның бу конфетлары санап куелгандыр әле!

— Саналмаган! — диде Кәримә, караватка чумып. — Минем әти алып килгән конфетлар алар. Биштәремнән бушатырга өлгермәгән!

Кәримә белән Сабира бер-берсен танымаучы чебиләр кебек сәер тойгыда калды. Ярый әле өченче кызлары күренми. Әмма аны күрәселәре, аның белән танышасылары бик килә иде инде.

Кайсыдыр бүлмәдә кемнеңдер йөргәне, нәрсәнедер төшереп ватканы ишетелде. Ике кыз да беразга аптырап калдылар, аннары, ашкынып, бу хәлнең шаһиты булырга дип йөгереп чыктылар. Ачык форточкага сузылып-сузылып кызгылт-сары мәче менеп бара, авызында пешкән олы гына ит кисәге иде. Мондый хәл галәмәт таныш тамашалардан булып, авылда да күренгәли торган иде. Кәримә:

— Прес-с-с! — диде, аяк типте: — Карак мачы!

— Ми-яу! — дип, усал итеп җавап бирде бу мәхлук, авызыннан ит кисәген ычкындырырга теләми, тик ташлап калдырмыйча да мөмкин түгеллеген белә, шуңа ачуы килә иде.

Идәндә ватык тәлинкә кисәкләре.

— Хуҗабикәбез үтерә, кызлар! — дип, курку катыш чинау ишетелде. Сабира күрше бүлмәдә генә икән...

Мәче, тагын да бер усал итеп мияулап, форточкадан сикереп чыгып качарга өлгерде. Сабира шунда ук ватык тәлинкәне җыярга керešте.

Кәриманең ана булышырга исәбендә дә юк иде. Бүлмәсенә чыкты да китте. Шунда кемдер кайтып керде. Бу яшь кыз иде. Аның көләч йөзе шунда ук Кәриманең күңеленә хуш килде. Һәм ул, үзен хужаларча тотып:

— Син дә университетка укырга керәсеңме? — дип сорады.

Яшь кызның өстендә шәһәрчә юка, киң итеп тектерелгән кыска җиңле, яшел-яшел, вак-вак, төртмә-төртмә чәчәкле, ак җирлекле күлмәк иде. Башындагы кыекча-косынка, очлары белән муенына таба төшереп, җиңелчә генә бәйләнгән, калын көрән чәчләре җилкәләренә кадәр ишелеп тора. Бармаклары — йомшаклар, ап-ак, гүяки бишек баласыныкы диярсең. Боларның барысы янына, йөзенең сипкелле булуы, күзләренең зәңгәрлеге дә килеп кушылгач, ниндидер ятсыну хисе дә тудыра. Әмма кызның көләчлеге, шушы сыйфатларын күмеп китеп, аны күрер күзгә бәхетле итә. Мондый кешегә сагышлы йөз килешә алмый икән бит.

— Сез Хәнифә Галиевнаның кемнәре буласыз? — диде кыз, өстәл янындагы урындыкка килеп утыргач, кулындагы сумкасыннан китап-дәфтәрләрен чыгара биреп.

Аның артыннан бераз соңарып кергән һәм кая утырырга да урын табалмый бүлмә уртасында калган Сабира нәрсә әйтергә белмичә торган кебек иде.

— Кызларымы? — диде сипкелле гүзәлкәй, елмаю катыш аптырашлы йөз белән аларга таба борылып. — Минем исемем Роза була! Сезнекеләр ничек? Танышыйк!

Ул әүвәле Кәриманең каршысына кулын сузып килде:

— Роза булам!

— Әйе... Аңлашылды! Кәримә исемле мин!

Бераз дорфарак килеп чыкты, билгеле. Танышканда исәнләшергә кирәген белмәүдән иде бу. Әмма Роза соңарып кул кысышуга игътибар итмәде, шунда ук Сабирага таба борылды да:

— Роза булам! — дип, аңа да кулын сузды.

— Сабира! — диде, аның кулын шунда ук кысарга батырчылык иткән Арча «сарбае». — Танышлык булсын!

## ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

### I

Университетка укырга баруның беренче көне Кәримане шундый бәхетле итте ки, ул үзен хәтта ак канатлы кош итеп сизде. Йөгерә-йөгерә диярлек килде. Аягында кара чүәк иде. Өстендә йон көрән күлмәк. Аңа ак яка һәм ак җиң очлары тегелгән.

Калын бөдрә кара чәчләрен ул тагын матур итеп, олы ясап үрде. Аңа бүген ак бантик килешле иде. Шушы Беренче сентябрьнең иртәнге күркәм алтын кояшлы Казан шәһәре урамнарында бу чибәр һәм бәхетле баланы күргән кешеләрнең үзләренә дә сәгадәт канатының очы кагылып китми калмагандыр.

Кәримәне университетның ак мәгърур колонналары каршы алды. Һаман да фәннең бөеклеген саклап басып торучы титаннар кебек иде алар. Колачлап карасаң — кочагыңа сыймыйлар, күтәрелеп карасаң — башың артка чайкалып китә. Монда бары тик зур гыйлем ияләре булсын өчен укыту, фән өчен, аны халыкка тарату теләге белән тулган студентлар гына укый. Башка төрле кешеләрне менә шушы мәгърур, биек колонналар уздырып җибәрми дә, үткәрә дә алмыйлар.

— Исәнме, Кәримә!

— Әйе, исәнме, Сабира! Синме дип әнә аннан ук карап килә́м. Күлмәгең ничек килешә! Яңасын тектерергә кайчан җитештең?

Ике кыз кочаклашып алдылар. Шунда Сабира:

— Хәнифә Галиевна ничекләр яшәп ята? — дип сорады. — Син аларга урнашкансыңдыр бит?

— Роза да анда. Ул берәр атнамы яшәрмен дә тулай торакка күчәсе булыр дигән иде. Белмим инде. Син нигә килмәдең соң? Тәмам аптырап беттек.

— Кичә кич кенә әтием апаларга китерде дә ашыгып кайтып китте. Бүген Беренче сентябрь булгач, мәктәп директоры шул бәйрәмдә булырга тиеш! Беләсең бит инде...

— Их, менә хәзер мәктәбемә кайтыр идем дә, мин дә бәйрәмдә катнашыр идем. Беләсеңме, Сабира, мәктәпне, бигрәк тә Беренче сентябрьне ничек сагындым! Менә хәзер, кулларыма шау чәчәкләр тотып, портфелемне алып, беренче класска дип укырга йөгерер идем! — Кәримә шунда ут итеп Сабираны тагын да ничә кат кочаклап-кочаклап алды. Икесенең дә күзләренә кайнар күз яшьләре килде. Әмма еламадылар. Университетка эшкә ашыгучы олы-олы галим абый-апалардан да, «Укырга, укырга һәм укырга!» дип дәртләнеп атлаучы яшь, шаян-шук студентлардан да оят иде.

— И юләр сүз сөйлисең, Кәримә, әйеме? — диде Сабира. — Без монда, үзең дә белеп торасың, биш ел укып, шул ук мәктәпләребезгә кайтачакбыз! Ел да Беренче сентябрь, Яңа ел, башка төрле бәйрәмнәрне укучыларыбыз белән бергә бәйрәм итәбез! Әйеме!.. Аһ, без нинди бәхетле! Аңлыйсыңмы? Беләсеңме, Кәримә? Ә син мине елатмакчысың!

Алар инде ишеккә таба киткән иделәр. Бу юлы тагын да сүз белән Кәримә туктатты:

— Ә беләсеңме, Сабира, без уң аягыбыз белән атлап керергә тиешбез, барысы да уң булсын өчен, «бишле»гә генә уку өчен!

Кәримә чынлап та уң аяктан атлап, университет ишегеннән эчкә таба узды. Ә Сабира, гомергә булмаганны, аңардан көлә-көлә әйтте:

— Юкны сөйләмә, Кәримә! Әбиең әкиятләрен авылында калдырырга иде! Ышанмыйм мин андый ырым-шырымнарга! Чын комсомолка мин! Менә, юри сул аяктан атлап кердем әле!

Кәримәнең аңа исе китте. Университет фойесында тукталып калып, иптәш кызына усал йөз чыгарып карап торды.

— Алай ярамый бит! Бар! Йөгер! Янадан кер!

Сабира ишетергә дә теләмәде.

— Син нәрсә, Кәримә?! — диде, аңа каршы үзенең сүзләре белән ук кебек кадалып. — Алай ярыймы инде? Куркытма мине! Болай да җаным калтырап тора!

— Шул кирәк сиңа!

«Расписание» язулы такта янында студентлар болыт булып җыелган иделәр. Сабира ике куллап диярлек Кәримәгә чытырдатып ябышкан, сул ягыннан аны култыклап алган. Аларның үз-үзләрен тотышлары каен белән юкәнең бергә, аз гына җилдән дә шәбердәп калтырап, яр читендә басып торуларын хәтерләтә иде.

## II

Университет галимнәре арасында башларына төсле түбәтәй кигән яһүдиләр дә, кара бәрхет кәләпүшле бер татар да бар иде. Кәримәнең күңеленә бигрәк тә «Мостафа мөгаллим» дип йөртелүче лекторның дәресләре хуш килде. Бу абыйның озак еллар хәрби юстиция өлкәсендә эшләве, Мәскәүдә төрек-фарсы телләре белгечлеге буенча белем алганлыгы, инде дә, яшенә карамастан, аспирантура тәмамлап килүе, борынгы татар теле өлкәсендә зур гына һәм гаять әһәмиятле саналган фәнни хезмәт язуы хакында студентлар арасында сүз тиз йөреде. Житмәсә мулла малае да икән бит! Әлегә университетның

үз кешесе түгел, башка бер фәнни-тикшеренү институтыннан вакытлыча кергәләп укытып йөри, ди. Аны өнәмәүчеләр дә, яратучылары кебек үк — шактый икән. Шулай да буламы? Мостафа мөгаллимнең эрудициясе, фәннәрнең төрле өлкәләреннән кин мәгълүматлы булуы, уен-көлке дә сөйләшергә яратуы, бигрәк тә студент халкына хәерхаклы караш күрсәтүе Кәримәнең күңеленә хуш килде. Житмәсә ул абый, татар бүлегенә укырга килүче һәркем кебек, хәзергәчә шигырьләр яза, жырлар чыгара, аларда үзенең бай хыялый күңелен сурәтләп бирүчеләрдән икән. Сугышның әчесен-төчесен күргән, вакыт-вакыт бәйрәмчә медаль һәм орденнарын ялтыратып йөрергә яратучы яшь галимнәр студентларга үзгәрәк тоелдылар, ә аспирант халкының исә күңелләргә бераз куркыту салучан икәнлекләре аңлашыла барды.

Укуларының өченче ае иде инде. Тиздән килеп житәчәк имтиханнар сессиясе, аның нинди булачагы әлегә томан кебек төсмерләнгәнгә күрә, беренче курсларны өркетеп тотты. Шунысы яхшы булды: Кәримәне Хәнифә Галиевна фатирда калдырды. Розага, медицина институтының беренче курс студенткасына, тулай торактан бернинди авырлыксыз, жиңел генә хәл итеп, бер койка биргәннәр. Сабира да тулай торакка күчәргә тырышып караган иде, әмма университет профкомында:

— Кышкы сессия йомгаклары билгеле булсын, карарбыз, хәл итәрбез, — дигәннәр.

Әүвәле ул туганнарында яшәп карады, аннары, икенче айга киткәч, әтисе килеп, Хәнифә Галиевнадан үтенде. Кире борып чыгарырлык сәбәп юк иде. Каклаган казның да күчтәнәчкә китерелүе яхшы булды, Сабира аларда шул көннән башлап кабат торып калды. Хужабикәнең заводта эшли торган зур дәрәжәдәге инженер улы өйләнергә тиеш икән. Шул вакыткача монда яшәп тору мөмкин иде. Хәер, бу Кәримәгә дә кагыла. Әмма кыз моңа һаман да борчыла белмәде. Үзенең фатир эзләп табачагына да ышанычы бар иде. Шул юлга кермичә, аны иртәгәгә калдыра биреп, оныта ук башлады. Ә теге инженер абыйларын ни барысы иртән киткәнендә, кич, кайтып, бүлмәсенә кереп югалганында гына күреп калганнары сәбәпле, аны белеп-танып та бетермиләр, житмәсә анардан бераз шөлләбрәк тә тора иделәр. Ыспай кыяфәтле, тыныч холыклы, кулына һаман да гәжит тоткан, әнисе әйтмешли «Газизчик», нинди дә булса кыз белән өйләнәм дип йөридер сыман түгел. Соңга калып кайтканнарында да ул әле партком жыелышларында, әле местком утырышларында, әле башкасында озаклап калган булып чыга, шулар хакында әнисенә бәйнә-бәйнә сөйләп бирә торган иде. Кәримә ул «Газизчик» абыйсының олысыман борынын да, әнисенеке кебек үк кара тут йөзен дә, кара бөдрәрәк чәчен дә, озынчарак кебек тоелган буен да, кызлар бүлмәсенә таба борылып та карамаган күзләрен дә, тыныч тавышын да — берсен дә сөймидер сыман. Әмма алар Сабирага ошый. Бәлки шуның өчен ул, кыз бала булуы сәбәпле оялып, Хәнифә Галиевнадан фатирга кертүләрен сорап килә алмагандыр? Булыр да! Ә бәлки алай да түгелдер әле! Әнә бит соңгы көннәрдә нинди эшләр булды әле монда!

Аспирантураны былтыр гына бетергән, яшь, өметле галим саналучы Нуруллов дип йөртелә торган укытучылары әүвәле Кәримәнең артыннан килеп тә, ишек башын гына тотып калганыннан соң, менә бер атна диярлек Сабира белән Кабан күле буенда, кеше күзе алдында гына йөргәли башладылар. Бик дуслашып киттеләр! Кәримә аларның үзара яхшы мөнәсәбәтләрен хуплый, әмма:

— Нуруллов һаман да сине генә сораша, нәрсә әйтим? — дип Сабира аптыраткач:

— Гел дә укып кына утыруымны сөйлә, — дип, ике дә уйламыйча жавап биргән иде дә, хәзер тагын куркыбрак калды: «Нигә кызыксына әле аның

белән? Сабираны, ул вакытта, үчекләп, ышандырырга тырышып, алдап йөртә бит!» — дигән шиккә төште. Әүвәледә ошыйдыр сыман тоелган кешесе шуның белән күңеленә ямьсез адәмдәй хис калдыра башлады. Ә аңа Кәримәнең «зачет» бирәсе бар. Алга таба имтиханы да килеп житәр. Хәер, үз күңеленә хуш килгән студенткаларга билгене саран итеп куймый, диләр, анысы. Тик менә ничә озата килеп тә кызның кереп качуын яратып бетерерме соң ул? Андый гыйлем ияләренә беткәнме югары курс студенткалары? Барысы да кияүле булырга өлгермәгәннәрдер әле!

Сабира әйтә, өйләнсәм, фатир мәсьәләсе дә жинелрәк хәл ителәчәк дип сөйли, ди. Нигә моңа кадәрле хәл ителмәгән икән ул? Һаман укыдым да укыдым, безнең иге-чиге булмаган әдәбиятыбыз һәм тарихыбызның бөтенләй дә өйрәнелмәгәнен, бәяләнмәгәнен Кабан күле буенда да каткат аңлата, имеш. Егет кешенең башында андый уйлар гына булырга тиеш микәнни? Кая ул романнарда язылган серле мәхәббәт вакыйгалары? Аларны укыгандыр бит! Әллә чоры, заманасы башкамы? Газизчик кебек ял көннәре генә бер-ике сәгать яки кинога, яки ял паркына барып кайтулар белән төкәнә торган булса, егет һәм кыз арасындагы мәхәббәт дигәннәре нәрсә була инде ул?

Юк, Кәримә андыйлардан булмаячак, ул жаны-тәне белән яратачак, чын мәгънәсендә гашыйк булачак. Башкача мөмкин дә түгел. Тормышмыни ул, ошаган кешем белән яшим дип, яратусыз гомер сөрүләр? Чын мәгънәсендә гашыйк булып кына гаиләне дә, тормышны да дөрес итеп корырга мөмкин. Башкача ярамый! Була алмый! Аның сайлаганы да үзе кебек яшь, үзе кебек акыллы, үзе кебек тәрбияле егет булыр, күреп торырсыз әле! Ул, беренчедән, яше белән үзеннән өлкәнрәк егеткә карамаячак, ә икенчедән, сары чәчле, зәңгәр күзле егетләргә аның исе дә китми, күңеле дә тартмый, сөйгәне кара чәчле, кара күзле, ут янып торучылардан булыр! Өченчедән, монысы тагын да әһәмиятлерәк, егет кеше шигырь язмасын, сөяк күңелле инженер да булмасын! Сыйфатлары шулардан-шулардан торыр, холкы да, жаны да, хисләре дә... Йа Ходай, бу кадәр дә әллә кемне яратыр микәнни? Кәримәнең үзе теләгән, жаны хуш килердәй кешесе кайларда йөри икән? Әллә соң авылында калганмы — карга куып, иген кыры сөреп? Их, очарга итәсең күңел, әмма кагынудан артыкка көчең дә житми, мөмкинлегең дә юк. Шул сары чәчле, зәңгәр күзле, озын борынлы какча Нурулловның нәфес тилгәненә жим булырсыңмы? Ничек котылырсың аңардан? Имтиханнар, зачетлар бар бит әле! Юк-юк, алай гадел түгел! Куркытмасыннар! Кәримә нык торыр, бирешмәс. Тырышып укыр. Белгән, һәр сорауга жавап бирә алган студентына укытучысы начар билге куя алмас. Юкса, гаделлек бетәр, дөнья жимерелеп төшәр!

### III

Кышкы имтихан сессиясе үз жае белән килеп тә житте. Баштарак ял көннәрендә, бигрәк тә Сабираның авылга кайтып киткән чакларында ялгыз калгаларга туры килгән Кәримәнең үзенә генә бик авыр һәм моңсу була торган иде. Мондый хәлләр кабатлана торгач, бераз күнегелеп, кыз шуны ачыклады: күңеле андый чакларда тәмам арып, сагышланудан туктый да белә икән бит! Монысы инде яңалык иде. Ул хәтта жырлап та алгалый башлады. Моңы юктыр инде анысы, әмма беркөнне шулай мавыгылып кителгән, үзе табак-савытларны юып, идәннәрне ышкырга керешкән иде, ниндидер шәүлә барлыгын тоемлап, кинәт борылып караса — Газизчик абыйсы басып тора. Шунда ук, кыз баланы өркетүен сизепме, әллә үзен яшерен тыңлагандай тоеп, гаеплегә санапмы:

— Мин әле радиодан яхшы концерт бирүләренә ышанып кайтып киләм!

Гафу итегез... Кыңгырау төймәсенә басарга кирәк булган! — диде дә, башын түбән иеп, үз бүлмәсенә кереп китте.

Кәримәгә бу вакыйга авырлык китерде: ышкып юган идәннән күңеле кайтты. Шабыр-шобыр гына чылаткалап чыкты да бүлмәсенә бикләнде. Эш дәрте бетү кебек авырлык адәм баласын бөтенләй хәлсез калдыра шул ул. Кыз да, китабын тотып утырган җиреннән онытылып, тәмам арыган кыяфәттә йокыга киткән. Шунда, хуҗабикә кайтып:

— Кызым, чәй куй әле! — дип тавыш салмаган булса, кичкә кадәр мәлҗерәп онытыласы булган. Ә аның укыйсы-укыйсы-укыйсы бар!

Ялгызы калган вакытларда ул шушы көннән башлап әле көндезге якта киногa барып кайтуны, дәресләрен иртәннән үк карап куюны үзенә гадәт итеп алды. Әгәр дә тыштан җыйнак, эчтән оешкан булсаң, бик күп эшләреңне җиңел кулдан башкарып куясың икән аны! Көне дә сизелми үтеп китә, әле җитмичә дә кала. Монысы инде сагышта онытылуга бер дә юл куймый!

Сабира элегрәк атна саен, ял көне җитә генә башласын, алдан ук атлыгып, шимбә лекцияләре бетүгә, дәресләреннән вокзалга йөгереп кенә төшеп, поездда Арча якларына китеп бара торган иде. Ул вакытларда көннәре дә озынрак, яфракларның сарылыгы да кояш яктысында нурланып торалар иде. Әмма агачлар да шәрәләнеп калды. Төннәр дә озынайгач, инде карлы-буранлы кыш та килеп җиткәч, бу гадәтен ташларга булды бичаракай. Шулай да, ничек кенә булмасын, туган авылына ике атнага бер кайтып килергә тырыша торды.

Көннәр үз җае белән үтә барып, Кәримәнең укулардан гайре бернинди дә хафасы юк иде. Шушы кап-кара бөдрә чәчле, алсуланыбрак торган тут йөзле, кара күзле, буй-сынга гаҗәеп дәрәҗәдә күркәм һәм сылу татар кызына һичбер егет тә гүяки кызыкмады. Һәрхәлдә бу сүзебез берникадәр хаталы исә дә, Кәримә үзен шул рәвештәрәк сизде. Хәер, ул сүзебез дә дөрес түгел. Тик шунысы бар: кызның яшьлеге чая егетләрне куркыта, өлкәннәрдә соклану тудыра, яшьтәшләрендә кыюсызлыкка сәбәп була торды. Дөнья йөзендә ул алар өчен бар, әлбәттә, әмма юк та әлегә. Төлке дә әйткән ди бит, йөзем җимешенә буе җитмәгәч, әлегә пешмәгән, диеп. Хәлләрнең эчтәлеге шушыннан гыйбарәт. Билгеле, Кәримә ул хакта алай уйламады. Ниндидер җитешсезлеге барлыгы хакында күңеле зәгыйфанә хафага төшеп, шулар аның уй-хыялларын яшьлеккә кереп адашуында тыеп тора иделәр. Ә Нурулловтан гайре егетләр аның янына килеп сүз катарга ояла тордылар. Кыз, бичаракаем, бу хакта күңеленә дә кертеп карамады. Хәер, фикерләгән булса да, дөньяда беренче гүзәлләрдән икәнлеген аңласа, хәтере дә буталырга мөмкин иде бит. Менә кайчан кешегә рух камилияте үз серлелеге белән ярдәм итә, аны тыелгысыз көчкә ия яшьлек бураннарыннан саклап кала! Җирдә адәм баласының яратылышы шулай камил ки, әгәр дә аны кеше-зат үз теләге белән бозмаса һәм мин нигә әле болай, башкача булыйм диген сафсата белән нәфсе һәм котырынкы хисләр утына илтеп ташламаса, бозылудан харабатка да төшмәс иде! Хата бит ул бәндәнең үзендә, язмышында түгел! Дөрес, тозланып-борычланып та калып булмый. Яшәргә кирәк, яшәргә!

Яшь-җилкенчәкнең батырлыгы юклыгын Кәримә бер генә дә күңеленә кертеп карамады. Аның үз-үзенә буе-сыны, чәчләре-күзләре ямьсездер кебек тоелган минутлар аз булмады. Мондый вакытларында ул тагын да моңсу булып кала. Кешеләрдән, бигрәкләр дә яшьләрдән шикләнүе, аларга куркыбрак күз салулары аның менә шул чакларында башланды. Йөрәгенә тын утыра барып, аны эретерлек һичкем табылмас төсле иде. Егет-җилән, яшь-җилкенчәк вакыты-вакыты белән Кәримәне үз итәргә атлыгып карасалар да, шул тың

йөрәгеннән өшенеп, тизрәк күздән югалу ягын карадылар. Ә хуҗабикә Хәнифә Галиевна мондый хәлләргә шат булуын бер дә яшермәде. Ни дисәк тә, кыз баланың үз-үзен тәүфыйклы тотуы бик күнелле күренеш инде ул. Мона сөенеп бетү мөмкин түгел. Хәнифә Галиевнаның ике сүзендә бер:

— Сабираның болай булуын көтмәгән идем. Тын күлдә шайтаннар йоклый икән бит, хәзер уяныргa гына торалар! — дигәннәре кызларның, хәтта Сабираның үзенең дә, котын ала торды.

Ул хаклы сыман иде. Сабираның Нуруллов белән кулга-кул йөри башлауларын Хәнифә Галиевна беренчеләрдән булып диярлек белде. Шушы хәлне бер дә өнәмәде. Әгәр дә кыз баланы сак астына алмасаң, хәзер даны ил буйлап җәеләчәген хатын-кыз заты бик тиз сизүчән инде, анысы. Хәнифә Галиевнаның сүз төртмәләре Кәримәнең дә колагына туктаусыз ишетелгәләп, күнелен сагайта иделәр. Сабираның хисләренә хуҗабикәнең кайнарлык һәм курку белән каршы чыга торулары кызларын шактый борчылырга мәҗбүр дә итте. Нәрсә, егетләр белән танышу, алар белән дуслашып йөрү начар гамәлмени соң ул? Кызларын әтиләре Казан шәһәрендә тозлап-борычлап калдырмадылар бит! Кәримә дә үзенә тиң егетне табар иде дә, әмма хисләренә хуш килерлек егетләр бердәнбер аңа гына карамыйлар, барысының да үз кызлары бар!

Шигырьләр яза башлавын Кәримә мәхәббәт вакыйгалары белән бәйли иде әлбәттә. Яшь йөрәгендәге хисләрне кузгатып җибәрер өчен бер очкын гына кирәк булган, ярый әле ул нәфрәттән барлыкка килмәгән. Аның гашыйк булган кешесе дә чит-ят түгел, бәлки Сарман мәктәбендәге укытучы абыйсы иде. Юк, алар туганнар да, якыннар да түгел. Укытучыны абый яки апа дип тану, мөгаллимнәргә шушы рәвешле эндәшү татарда электән килгән гадәт, аларга карата зурлау, аларны якын күрү билгесе генә, югыйсә.

Ул аларны тарихтан укытты. Кәримәнең хисләрен белми дә калды, сизмәде дә. Кыз аның өйләнүе хакында ишеткәч, авыллары Түбән Ләшәүгә кайтып китеп, мунчага бикләнеп елады, аннары бер атна буена авырды. Ул вакытта Кәримә жиденче сыйныфта укый иде. Хисләреннән әти-әнисе дә хәбәрсез калдылар. Язган шигырьләре дә «яратам», «сөям» сүзләре белән чуарланган булып, ахырда, кайгы көннәрендә, учак ялкынына төрелеп яндылар. Шушы авыруыннан соң Кәримә кайбер чакларда сагышлы, ә вакыты-вакыты белән күбәләк кебек хәсрәтсез кызга әверелеп калды. Аның күнелендә шигырь үз урынын тапкан, алга таба кем булачагын сиздереп өлгергән иде инде. Шагыйрә! Башкача һичкем түгел! Ул инде хәзер үзен аңлап та бетерә алмый, хәтта ургыган хисләрен күп вакытларда тыярга көчсез халәткә керде. Яки тар, салкын сагышка, яисә киң бәйрәмчәлеккә бирелүләренең ахыры һаман да күнелсез бетә торган булдылар. Күпме табак-савыт ватылды, ничәләрнең күнелләре яраланды. Болар — Кәримәнең таныш-белешенә, якыннарына китергән бәлаләреннән иделәр. Ярый әле андый аерата авыр еллары үтеп китте. Жаны кайнарлануы да, утны су белән сүндергән кебек, шигырь язулары ярдәмендә басыла килде. Университетка укырга кергәч, кызның хәле тагын үзгәрде. Очып кына йөргән жиреннән, китапларга-конспектларга күмелеп, тын да алырга куркып, төрле фәннәргә чумды. Ана шушы рәвешле онытылып, чиксез-төпсез гыйлем дингезенә төшеп югалудан да рәхәтрәге юк иде.

Сабираның Нуруллов белән йөреп китүләре ничек көтелмәгәндә булса, дуслыклары бозылу шулай ук уйламаганда килеп чыкты. Кәримә моны әүвәле сизми йөрде, аннары, кызыксынуын яшерә алмый сорагач:

— Холыкларыбыз килешмәде! — дигән җавапны ишетте.

Нәрсә-нәрсә, әмма Сабира белән холыкта килешә алмау мөмкин хәл түгел иде. Ул хәтта Кәримәне дә үз кысаларына куып кертә алды. Кем белән

дуслашасын, анын холык-табигатен дә үзенә йоктыра барасын икән шул. Баштарак Кәримә, аны үпкәләтмәс өчен, үзенең күбәләктәй очынуларын ничек тә тыярга тырыша иде. Аңа бу рәвешле үзен ким куюлары асылда өстенә тау ишелгәндәй авыр тоелса да, бара-бара, яши-яши, күнде тагын. Кыз баланың бәхете сабырлыгында, имеш. Дөрес, бу сабырлык Кәримәнең табигатенә килешеп тә бетмәде. Шулай да ана бу юлы да шигырь язулары файда итте, дәфтәрендә күңеленең ташып чыккан мизгелләре җыр юллары булып тезелделәр. Ул аларның арасыннан уңышлы дигәннәрен сайлап алып, матур язуда ак кәгазьгә күчереп, «Совет әдәбияты» журналына илтеп бирде. Татар әдәбиятының үткәне, бүгенгесе, киләчәге белән туктаусыз кызыксынырга тиешле шушы матбугат органы аңа игътибар күрсәтергә бурычлы иде. Инде икенче ай шул шигырьләренең басылып чыгуына өмет белән яшәде Кәримә. Язмалары яшьлек хисләре белән тулы иделәр. Аларда ул әлеге дә баягы өйләнгән, гаиләсе белән бәхеткә тулып яшәп ятучы укытучысына үпкәләү, аяусыз рәвештә мәхәббәтен кире кагуы, кабул итмәве, шуның белән җанын рәнҗетүе һәм башка шундый мең төрле авыр уйлар, аһ-зарлар, күз яшьләре, кайнар хисләр, ярым ишетелерлек, ярым хис ителерлек моңнар белән тулы йөрәк авазларын бирә алды. Болар укучыны җәлеп итәргә, ә адресаты, укыган очракта, нинди саф һәм сихри сөю иясе сүзләренә тап булуын аңларга тиеш иде. Әмма шигырьләр күренмәде. Кәримә һаман да аларның матбугатта басылып чыгуын көтте. Ара-тирә булсын, атна саен туры килсен, Язучылар берлегенең «Тукай клубы»на барып, анда шыгрым тулып утырган бөекләрнең тынчу исләрен иснәп, ишек төбендә кысылыр урын табып, соклану катыш гаҗәпсенү тойгыларын күңеленә ияртеп алып кайтты. Теге, «Совет әдәбияты» журналы редакциясендә шигырь кульязмаларын алып калган абый кешене дә шунда очратып, аның белән исәнләшкәндәй итте. Кәримәне танырга теләүче юк иде. Абый кеше дә бары тик аптыраулы күз карашы белән шунда ук кызның куанычлы елмайган авызын сүз әйтә алмаслык итеп томалаган кебек мәгърур рәвешендә үтеп китте. Кәримә шунда үзенең мескен адәм баласы икәнлегенә ачык төшенде. Әмма аның, моңа да карамастан, укучысын табасы, татар әдәбиятында үз тавышы барлыгын сиздерәсе килә иде. Хәер, моны теләк һәм нәфсе түгел, бәлки рух халәте аңардан таләп итте. Замана шагыйрьләре, ни хикмәт, һаман да узылган чорларның хисләрен, инде хатирәләрдә генә калган Бөек Ватан сугышындагы батырлыкларны, тыл хезмәтендәге тантаналылык турында йөзенче әсәрләрен укучыларына тәкъдим иттеләр. Аларны бүгенге көн дә, адәм баласына бәлки гомергә бер тапкыр бирелергә мөмкин булган мәхәббәт хисләре дә, яшьләрнең киләчәккә булган өметләре дә кызыксындырмый иделәр. Әдәбиятның төссезлеге, һәр укыган яңа әсәрдән коммунистлар партиясе карарлары һәм мәктәп дәреслекләре исе аңкып тору башкаларны ничек биздерсә, Кәримәне дә шулай туйдырып бетергән иделәр. Хәер, яшь шагыйрә үзе дә шул ук агымнарда йөзә, яши, иҗат итә торды. Башкача була да алмый иде, чөнки бутәнчә дә мөмкин икәнлеген аңарга ишарә ярдәмендә генә дә аңлатучы табылмады. Бары тик күңел дөньясында шигырь кояшы яктырып китеп, хакыйкатьнең башкача икәнлеген күрсәтеп-күрсәтеп ала торды. Бу сыйфаты белән Кәримә бәхетле дә, талантлы да, һәммәләрдән бер башка өстен дә иде. Әгәр канатлары шушы рәвештә ныгыса, ул күтәрелеп китәчәк һәм гасырларга җитәчәк дан калдырачак әле! Башкача була да алмый!

Һәм менә Яңа ел бәйрәме җитәсе көннәрнең берендә Казан зыялылары шаулашып алдылар. «Социалистик Татарстан» газетасында бер карт тәнкыйтьченең әдәби елны йомгаклау хакында уйланулары белән бәйле мәкаләсе басылып чыгып, ул татар әдәбиятының урыннан кузгала алмыйча

таптануы хакында, шул фикерләренә ияртеп, әдәбиятка талантлы яшьләрнең килмәве турында да хафалы җөмләләр бастырган иде. Шулар сүз кузгалуга җитә калдылар. Кәримә үзен талантлы яшь шагыйрә сыйфатында тоеп, бу фикерләрнең турыдан-туры үзенә кагылышлары бар дип хис итте. Әмма ул хакта уй башкаларның күңелендә туарга да өлгерми калды. Дөресрәге, алар әлегә Кәримә хакында белми иделәр, шуна күрә дә аны исәпкә ала белмәделәр. Әдәбиятта яшь талантларның юклыгы — аларның барлыгын күрергә теләмәүдән дә һәм күрергә сәләтсез кешеләрнең редакцияләрдә төпләнеп утыруларыннан да килә, билгеле. Ә моны Кәримә төшенә алмады. Укуына комачаулык итмәсен дип, шигырьләр язмаска иде аның исәбе, әмма бу эше теләгәненчә барып чыкмады. Чишмәнең суы куәтле икән, бер җирдә аны томалауга карап, икенче урыннан бәреп чыкмас, димә. Кәримә белән дә нәкъ шулай булды. Күңелендә шигърият тагын да көч алып кайный башлаганын ул инде сизми дә калачак иде. Кайбер көннәрдә ул, лекцияләрендә онытылып китеп, дәфтәренә ашыгып-ашыгып шигырь юллары тезә торды. Күңелсез алып барылган дәресләрдә бигрәк тә шушы хәлләр кабатланды, хәтере шушы шөгыле белән ямь тапты. Гомере буена шигырь язмыйча гына яшәп булачагын ул белми һәм шигырьсез гомер уздыру мөмкин хәл дип тә күзалламый иде инде. Әгәр дә кеше үз табигате белән көрәшә икән, аның күңеле барыбер үзенекен итеп, бер-бер хәл китереп чыгара, билгеле. Асылыңнан качу юлы юк. Бәлки шул асылың синең чын бәхетеңдер?

## IV

Кышкы имтиханнарны бик яхшы билгеләргә тапшырган Кәримә каникулга туган якларына, төп йортка кайтырга әзерләнеп бетергәндә, Сабира инде юлланган иде. Аңа рәхәт, иле якында гына. Ә Кәримәгә ничә җилдән сугарыласы бар. Әүвәле «Казан−Уфа» поезды белән кайтачак, аннары — Әлмәткә, маршрут автобусында, Әлмәттән — Түбән Ләшәү авылына, юл чатына кадәр утыз чакрым араны ничек тә берәр юлаучы машинада узар әле. Чатта төшеп калып, аннары җәяүләп атлар. Ике көн кайтылыр да кайтылыр инде. Артыкка ук китмәсә ярый да бит. Әмма нишләсең, бу — Кәриманең юлы. Әти-әнисе быел да шул авылда мәктәптә укытуда калдырылганнар. Элекләрне аларны биш ел саен бер авылдан икенчесенә күчергәли торалар иде. Сталин заманы үтү белән бу тәртип тә исәптән төшеп калды, ахрысы. Дөрес, укытучылар үзләре «күчмә тормыш»та яшәргә өйрәнеп җиткәнлекләре сәбәпле, әле хәзер дә хуҗалыкларын булдырырга, бер тукталган урында йорт-җир ясатып, шуны ныгытып корырга тиешле икәнлекләрен төшенеп җитмиләр. Хәбәрләргә караганда, хаксыз рәвештә «халык дошманы» дип сөрелгән, төрмәләргә ябылган кешеләрнең үз илләренә кире кайта-кайтарыла башлаулары да көтелә икән. Әмма монысы ук әлегә бөтенләй аңлашылмады. Ничек инде ул алар, халык дошманнары булган кешеләр, ялгыш хөкем ителгәннәр? Совет суды кебек гадел, социалистик җәмгыять кебек дөрес тормыш Жир йөзендә булырга мөмкинме?

Кәримә бу мәсьәләдә күпләр белән килешә алмый, Сталинның үлеменнән соң, хурлап әйтелгән, анда-монда ишетелгән сүзләрне дә кабул итми. Павлик Морозовны әтисе, кулак, үз әмере белән үтерткәнме? Үтерткән! Сыйнфый көрәш булганмы? Булган! Сугышта сатлыклар бар иделәрме? Бар иделәр! Әнә Муса Җәлилнең дә фашистларга хезмәт иткәнлеген әйтә иделәр. Әмма башкача сөйли башладылар. Тормыш бер генә катлы түгел икән бит! Дөресе башкача булган, Муса Җәлил фашист төрмәсендә дә Гитлерга каршы эшләр оештырган, татар әсир гаскәриләре арасында коммунистик пропаганда алып барган. Менә бит ул ничек! Абау,

әле аны тәмам пычраттылар. Хәзер нишләрләр? Дөрес, болар хакында саклык белән, чама белеп, кызыктырып кына сөйлиләр әлегә. Әмма ул сүзләр хакыйкать булып чыкса? Ул вакытта бу дөньяны каралткан шакшы сүзләрдән күңеленне ничек юып бетермәк кирәк?

Совет мәктәбендә тәрбияләнгән Кәриманең уйлары да, хисләре кебек үк, төрле иде. Шушы халәте һаман да аның белән идарә итте. Каршылыклар кешегә дулкынланулар китерүчән. Хисләр ташкынын бары тик шигырь юллары гына үзләренә сыйдыра һәм сеңдерә алалар. Сер түгел, мондый иркенәеп китү, күз ачылу вакытларында кемнең дә күңеле җырлый. Кешенең җаны моннан мәгънә ала, тормыштан аны эзли башлый. Ә сүзләрнең барча уйларны һәм шикләнүләрне колачлап бетерер куәте юк. Шуңа күрә дә кешегә, аның акылына-аңына моңнар ярдәмгә килә. Хис һәм уйның берлеген менә шул моң тәэмин итә. Шигырьләрен язганда Кәримә әллә нәрсәләр хакында уйлап бетерә. Бала чагы узган Сарман якларының тауларын да, киң кырлардан гына гыйбарәт тарафларын да, исендә өскә ишелеп торгандай куркыныч табигатьле булып сакланган кара урманнарны да, боз кебек салкын чишмә суларының татын да — барысын-барысын да хатирәләрендә яңарта. Йөрәге аша үзенең һәм таныш-белешенең тормышыннан һәр мизгеле диярлек уза. Ул шуларны кәгазьгә төшерә. Тыңларга теләсә, Сабирага да укыр иде. Әмма иптәш кызы үзен ни өчендер бик сәер тота. Яратмый ул шигырьләрне, аның күңелен башка төрле уйлар били. Икесе бер фатирда яшәп тә, бер үк уку йортында бергә, бер үк төрле лекцияләрне шул бер үк профессорлардан тыңлап та, көннән-көнгә икесе ике төрле кешегә әверелә бардылар. Сабира һаман да үз дөньясына чума торды. Кәримә дә нәкъ шулай иде, югыйсә. Тик берсенеке үз эченә бикләнә бару булса, икенчесенеке үзәккә, бер ноктага җыелу, дикъкатен үз күңеленә таба төбәүдән гыйбарәт. Моның кызлар ни сәбәпле шулай булуын үзләре дә аңлап бетерә алмыйлар. Вакыт-вакыт кирәкмәгәнгә үпкәләшәләр, ә аннары, көтелмәгәнчә ачылып та китәләр. Барыбер дә бер-берсен аңлавы аларга авырлаша бара. Сабира үзенең Нурулловына да әле якыная, әле ерагая. Кәримә өчен ул кеше бөтенләй беркем дә түгел. Ул аны хәтта укытучым дип тә әйтә алмый. Укыган лекцияләре дә ошамый, үз-үзен тотышы да. Көтмәгәндә Нуруллов, дәрес уртасында кәефе бозылып китеп, берәрсенә бәйләнеп тә ала. Сабира аның мондый чыгымлауларын «шаярту» дип атый.

— Бүтән профессорлар кебек тозсыз мәзәкләр сөйләп аптыратмый бит, аның ул шаяртулары — үгет-нәсыйхәт дәресе генә! — дип, «җанкисәккәен» күтәреп мактарга тотына. Аңламассың, әллә кайчан үпкәләштеләр, менә тагын аралары җайланырга тора, ахрысы?

— Абау, дустым, әллә син аны яратасың инде! — дия-дия үртәп, Кәримә мондый вакытларда рәхәтләнеп көлә, сөенә. Шушы минутларында аның бәхете артып киткәндәй тоела. Иптәш кызы өчен куануымы бу, әллә үртәве аркасында кызык табамы — боларын ук аңлап та бетерерлек түгел.

Алар ярыша-ярыша укыдылар, практик-семинар дәресләргә әзерләнделәр, китапханәнең уку залында соңгача утырдылар. Нәрсә өй эше итеп бирелсә, шуны өйрәнеп барырга тырыштылар. Аларга баштарак гыйлем нигезләренең күп яклары аңлашылмый да кебек иде. Әмма укый, өйрәнә-өйрәнә, зиһеннәре ныгый барды. Әллә нинди авыр һәм катлаулы булган гыйлемнәр, акрын-акрын «кимерелә» торгач, җиңеләя һәм «йомшара» төсле тоелдылар. Әүвәле профессорлар куллана торган сүзләр аларга авыр һәм серле сыман сизелсә, инде гади һәм гадәтигә әверелеп калдылар. Тел — әдәбияттан, әдәбият — тел гыйлеменнән аерылмана, ераклаша, үзара катнашлары булмаган өлкәләр рәвешендәрәк аңлашыла. Сабира күпчелек очракларда тел

фәннәрен сөючән, Кәримә әдәбиятка мөкиббән. Бу да аларның зиһеннәре һәм табигатьләре аермалы булу хакында сөйли иде.

Кәримәне шигърияттәге уңышсызлыклары эчтән генә изде, эчтән генә яндырды. Ул үзен, беренче шигырен укуга ук, әдәбият халкы күтәреп алыр дип ышанып көткән иде, әмма аңа игътибар итәргә теләүче табылмады. Калын дәфтәренә шактый гына шигырьләр теркәде, аларны үзе хәтта еламыйча укый да алмый. Әмма башкаларның күңеленә түгел, хәтта колагына да барып ирешмәве бик сәер. Бервакыт укып күрсәткәч Сабира да:

— Болар нәрсә инде? Авыл такмакларымы? Сезнең авылда шушындый такмаклар чыгаралармыни? — дип мыскыллап ташлады. Аңа каршы Кәримә, еларга җитешеп:

— Бу минем шигырьләрем бит! Нинди такмак булсыннар? «Умырзая чәчәкләре сыман сине көттем күзем чыланып!» Кая монда такмак? — дип, ә аннары аптырап калды, күңеле уттан суга, судан утка төште. Әмма Сабираның моңа исе дә китмәде:

— Мин дә язган идем андый такмакларны: «Килсәң иде минем алларыма, көтәм, бәгърем, сине сагынып!» — диде дә, авырлык белән әйтте дә салды.

Ул кичне Кәримә караватка капланып елый-елый йоклады. Аның хәтере шушы кадәр җимерелгәне юк иде әле. Хәтта укытучысына булган һәм беренче мәхәббәт сыман тоелган хисләрен дә каһәрләп чыкты. Төне буе саташты. Авырып та алды. Аңа укып йөрүләренең кадере дә, әһәмияте дә югалган кебек тоелды. Ул бит шушы шигырьләре өчен дип университетка укырга керде, хәзер туганнарыннан, әти-әнисеннән, туган якларыннан, аның миләшләреннән, каеннарыннан, тирәкләреннән, чишмәләреннән — һәммәсеннән-һәммәсеннән аерылып яшәргә мәҗбүр. Ә аның шигырьләре гади авыл такмаклары гына булып чыкты. Ничек болай алданды ул? Йөрәк түрендә йөрткән серләре дә, якты хисләре дә, өметләре, сөенече, бәхете — барысы-барысы да буш, ялган һәм саташтыручы булып чыктылар. Нишләде ул, нишләде? Инде хәзер гади укытучы гына буласыңмы? Аңа бит ул эш бөтенләй дә ошамый. Белеп тора, хәтта әтисе, әнисе дә, яшьлектә комсомол кушуы буенча гына, зиһеннәренең яхшылыгы, тәрбияләренең күркәмлеге аркасында гына укытучы булганнар. Гомер буена авылдан-авылга күченеп, бер юньле йорт-җир дә ясата алмыйча, анда балчыктан, монда таяктан эшләнгән салкын, тар, авыр исле хөкүмәт өендә яшәп эшләргә мәҗбүр иделәр. Кәримә дә аларга ияреп йөреп, көннәрен мәктәптә уздырды. Төнгә каршы гына, дәресләрдән, класстан тыш эшләрдән, «Ызба укулары»ннан, ата-аналар белән аң агарту әңгәмәләреннән соң, салкын, мичләре боз булырга өлгергән, шыксыз, җиһазсыз өйгә кайтыр иделәр дә, төтен белән бөтен бүлмәне тутыра торган, акшарлары коела башлаган котсыз мичне ягып, аның җылынганын көтә-көтә, юрган астында калтыранып йоклап китә торганнар иде. Кая барсалар да шушы хәлләр кабатлана торды. Ул хөкүмәт йортлары юри шулай эшләнелгәннәр кебектер сыман тоелалар аңа әле хәзер дә.

Әтисе дә, әнисе дә зарлана белмәделәр. Алар ятим үскән иделәр. Болары да зур бәхет кебек тоела иде аларга. Дөрес, Кәримәләрнең ерак авылда ак әбиләре дә бар иде. Ул аның әнисенең әнисенә апа иде. Әмма аны ул «әбием» дип ышанып үсте. Үз туган әбисе түгеллеген соңрак кына белде.

— Нигә минем үз әбием юк? — дигәч, әнисе, аны юатып:

— Шушы ак әбиең минем әнкәм булды. Туган чагымда ук ятим калганмын. Аның кулында үстем! — дип аңлатып бирде. Ни өчен әби-бабайлары юклыгын Кәримә шушы хәбәрдән чыгып төшенде. Аннары аңа китаплар да ярдәм итте. Аларда элекләрне тормышның бик авыр

булганлыгы, кешеләрнең озак яши алмаулары хакында язылган иде. Патша хөкүмәтен каһәрләп, совет илен яратып үсүендә бу укыганнарының әһәмияте чиксез зур иде. Кәримә авылдагы башка әбиләрнең-бабайларның совет власте аркасында гына шулай озын гомерле булуларын белде. Андый бәхет аның үз әби-бабасына гына тәтеми калган икән бит. Ана әгәр дә «Һади Атласи эше» дигән татар милли зыялыларын кырып бетерү максаты белән оештырылган егерменче еллар ахыры-утызынчы еллар башындагы хәлләрне сөйләсәләр, ул мондый вакыйгаларны әкияткә санар, аларга ышана да алмас иде. Хәзер дә әле Сталинның гамәлләрен хурлап телгә алучыларны анламый, мондый хәл аның башына сыймый. Ничек инде бөтен ил белән бер кешенең кубызына биегәннәр? Шул адәмнең йөзенә бәреп кем икәнлеген әйтерлек батырлар кая булганнар?

Үзеннән шагыйрә чыкмасын аңлаган Кәримәнең ярасына Сабирасы тоз сала белде. Жае килгән саен ул анардан мыскыллы көләргә тырышты. Элек-электән Казанга йөреп, йорт эшләренә ялланып, калача усалланып яшәргә өйрәнгән шушы Тау һәм Арча ягы хатыннарының кызлары да үз бәһаләрен кыйммәтледән тота белүләреннән Кәримә бөтенләй дә хәбәрсез иде.

V

Университетка укырга керү һәм анда данлыклы профессорлардан лекцияләр тыңлау бәхетенә ирешкәнсең икән, аны юктан гына ташлап китү бөтенләй дә күз алдына китерерлек хәл түгел иде. «Укый алмаган!» — дип күзләрен дә ачтырмаячаклар. Әти-әнисе халык күзенә ничек карар? Аларны һәммә хөрәсән, күтәрелеп карарлык итмичә: «Нәрсә, балагыз укый алмадымыни?» — дип оятлы итеп бетерәчәкләрен күңеленә китереп, Кәримә кабат лекцияләренә йөреп, конспектларын тырышып төзеп, һәр дәрестә белемен яшермичә күрсәтүчегә әверелде. Ул инде хәзер гыйльми диспутларда да актив катнашып, кайвакытта укытучыларын да кыен хәлгә куя башлады.

Кәримә икенче курста укуының башында бигрәк тә шушы яктан «азынды». Жәйге каникулда әтисе мәктәбендә пионервожатый булып эшләп, вак балаларны ике ай буена үз карамагында йөртеп чыныккан, алар белән алны-ялны белми шөгыльләнгән кыз, матур кичләрдә клубка да чыкмыйча калмый, су буендагы уеннарга да төшми тормый иде. Чаялыгын телләргә алып сөйләрләр, гайбәт ителер дип башына да кертмәде. Яшьләрнең уеннарында кызларны бер үбеп алу өчен корылган хәйләләрнең җәтмәсенә дә төшкәли иде ул. Әмма шулай кызык иде. Авыл кызлары, көнләшеп:

— Кәримә бүген Хафизга үптертте... Кәримәне уенда Гатаулла кочаклады... Кәримәне Самат каптырмакчы иде, янагына алды... — дип, әллә нинди ямьсез һәм көтелмәгән сүзләр сөйләделәр. Боларның ул сүзләре Гариф мөгаллимгә дә килеп иреште. Ул, гайбәттән котырынып кайтып:

— Бүген су буена уенга төшәсең юк! Әнисе, чоланга бикләп куй кызыңны! Клубка да җибәрәсе булма! — дип дау куптарды.

Әйе, аныңча булды. Кәримәне чоланга ябып куйдылар. Ә ул аптырап калмады, салам түбәне тишеп чыгып качты. Әти-әнисе, бичаракайларым, бу хәлдән нәрсә эшләргә дә белмәделәр. Кәримәгә егетләрнең үбүләре, кочарга омтылулары ошый иде. Алар боларны, аулакта качырып түгел, кеше алдында эшләделәр. Авыл кызларының мыштым-посып, егетләре белән бакча башларында үбешүләреннән ул бик яхшы хәбәрдар иде. Тик моның хакында авыз әчеттереп сөйләп йөрдеме? Юк! Хәтта әти-әнисенә дә, күңелләрен тынычландыру өчен генә булмасын, һичбер әләкләп әйтмәде. Белсеннәр иде кемнәрнең кем икәнлеген! Әмма, юк, андый түбәнлеккә төшәргә ярамый. Гайбәтче дигән атың чыкса? Шулаен шулай да бит, әмма гайбәтнең авыр канаты аның үзен какты.

Бу вакыйгалар зур оят хисе тудырган иделәр булса кирәк, август башыннан әти-әнисе, сенлесе һәм Кәримә, бердәм кубарылып, Түбән Ләшәү авылыннан Әлмәткә күченеп киттеләр. Анда ике атналап эшләгән иделәрме-юкмы, — мәктәпләре дә яхшы, фатирлары да иркен иде, — әтиләрен район мәгариф бүлегенә чакыртып алып, киредән шул ук Түбән Ләшәү авылына кайтырга боерык бирделәр. Җыелыр өчен бер көн, китәр өчен икенче көн житкәнен әйттеләр. Югыйсә әтисенең партбилетын да, дипломын да алачаклар икән.

Кәримә шунда гына тынычланды. Түбән Ләшәүнең чишмә сулары да, һавасы да аны янадан дәрткә күмә башлады. Пионер лагерендагы эшләрен тапшырганының икенче көнендә үк ярый әле Казанга китеп барырга туры килде аңа. Бу юлы кызын әтисе озатып мәшәкатьләнмәде. Хәер, Кәримә үзен кала кызы итеп хис итә иде инде. Әти-әнисен никадәр җәфаларга салуын ул бары тик аларны сагына башлаган минутларында гына төшенеп, озын-озын итеп хатлар язды, түбәнчелек белән гафулар үтенде, мәңге-бакый бары тик тәүфыйклы гына булырга антлар итте. Җаваплары да озак көттерми килеп житте. Ата-ана үз баласын аңламыймы, гафу итмиләр димени?

Бу елда да ул тагын Хәнифә Галиевналарга фатирга төште. Гомер булмаганны, бер-берсен шулкадәр сагынышкан иделәр, хәтта базарга да бергә чыктылар, хуҗабикәнең иптәш хатыннарына да кереп, озаклап чәйләп утырдылар. Сүз һаман да:

— Бу кыз бала, Хәнифә Галиевна, сезнең киленегезме әллә? — дигән тәртиптә башланып китте.

— Юк инде! Сез нәрсә? Ул минем үз кызым кебек! — дип, Хәнифә Галиевна белән очраганнарында да, иптәшләрендә дә сүз башлап китүләре нindидер бер серле өмет һәм дулкынлы хыял челтәренә уралып искән жилнең аһ итүләре сыман иде. Шушы йөрүләрендә Кәримә хәтта данлыклы профессор Якуп Агишның да шигырьләр язуы хакында хәбәрләр ишетте. Әмма бер дә бастырмый икән ул аларны, мыскыл итәрләр, көләрләр дип курка, имеш. Әгәр дә мондый акыллы, олы белемле кешеләр дә шигырьләрен матбугатта чыгара алмыйлар икән, Кәримә кебекләргә бәхет кояшы елмаерга мөмкинме?

Сабира бу елда да беренче ике атнасын туганнарында яшәде. «Бәрәңгесен кимереп бетергәч, үзен дә «ашый» башларлар әле, — диде аның хакында Хәнифә Галиевна, — аннары монда елап килер. Ә мин сиңа иптәшкә башка кызны китерермен. Сабираны фатирга алмам!»

Һәм менә Кәримә дә моның шулай булуын күңеленнән теләп йөри башлады. Әмма фатирда яңа кыз күренмәде. Хәнифә Галиевнаның улы Газизчик һаман да иртә таңнан эшенә китеп, төнлә генә кайта торды. Аның сабырлыгы, уйларының артыгы белән башыннан ашулары бер хәл, ул хәтта хатын-кыз белән дә кызыксынмый иде булса кирәк. Кәримәнең килүен дә, исәнләгән белешеп тупсасыннан атлап керүне дә кирәккә санамады. Хәтта ялгыш кына да алар күзгә-күз очрашмадылар. Ә Кәримә аны да сагынган, аның өчен дә кайгыра иде. Шулай ялгызы яшәр микәнни буйдак булып?

Ә менә Сабира, лекцияләрдән соң, Кәримә китапханәдә калгач, Хәнифә Галиевна янына килеп, фатирга кертүен үтенеп, хәтта килешенеп тә киткән. Нәрсәләр вәгъдә иткәндер — билгесез. Әмма Кәримәне хурлап алуын фатир хуҗасы шул ук көнне житкерде:

— Иптәш кызыңа бик ышанып ачылма әле, кызым! — диде ул аңа, кайтып кереп, чәйгә утыруына ук. — Сабира килгән иде. Бүген кич фатирга монда күченмәкче идем, ди. Керттем инде. Әллә үпкәләшкән идегезме? Сине хурлады әле бу юлы! Аңа әллә нәрсә булган! Әмма үзенә әйтмә! Кара аны, белдермә! Үзең генә уеңда йөрт. Сер саклаган кешенең күңеле ныклы да, аптыраусыз да була аның, белеп тор!

Сабиранын начарга алып сөйләгән булулары Кәримәне гаҗәпкә калдырды. Тик ул авызындагы «сөякне» төшермәде, капкан килеш калдырды. Шунлыктан:

— Белмим, — дигән булды, — минем белән университетта бик тә үз итеп, сагынып кочаклап алып сөйләште. Аны-моны сизмәдем.

— Ярар, алайса... Мина гына шулай тоелгандыр! — диде Хәнифә Галиевна, шунда ук Кәримәне якынрак күрүен ни өчендер артыгы белән сиздереп һәм аркасыннан сөеп кагып.

Шул минутта диярлек ишек кынгыравы чынлады. Озын гомерле Сабира хәерле кичләр теләде, чемоданын һәм биштәрен тоткан килеш тупсадан узды. Әмма ишек ачкан Кәримәгә якты йөз күрсәтмәде. Моны начарга алмасыннар өчен:

— Уф! Ардым! Күрше подъездан монда кадәр киләсе, ничә баскыч менәсе булды! — диде, тәмам кыяфәтен китереп. — Ярдәм итүче дә юк!

Хәнифә Галиевна гына түгел, Кәримә дә моның бары тик кылану икәнлеген аңлап алдылар, шулай да Сабирага әйберләрен күтәрешергә булыштылар. Биштәре кухня ягына китте, чемоданы кызлар бүлмәсенә керде.

Быел анда аерым-аерым ике карават куелган иде.

— Син — хәйләкәр! — диде Сабира, шунда ук ачу китереп. — Үзенә тәрәзә янындагы якты урынны сайлап алгансын. Мина ишек буе гына калган!

Әмма Кәримә дә сер бирмәде:

— Алдан килгән — урын өчен! — дип, аның күнелен тынычландырды.

Кызларның быел дустанә яши алулары икеле иде.

## VI

Бу җәйдә Сталин төрмәләреннән, сөргеннәреннән ничәмә әдипнең кайтуы хакында хәбәрләр хәтта авыллар буйлап та йөргән иде. Студентлар белән очрашу кичәсенә шундыйларның берсе — Һади Такташ дәверендә үк татар шигъриятенең төп әдипләреннән саналганнарыннан, әмма бу хакта тарих әлегә онытып торган Фәхри Хисами исемле шагыйрьнең чакырылуы, аның яшьләр алдында шигырьләрен дә укыячагы хакында хәтта Хәнифә Галиевна да ишеткән, кызларыннан:

— Сез барасызмы? — дип ныклап сораган, үзенең дә һичшиксез анда булырга теләге барлыгын белдереп өлгергән иде.

— Без аның нинди шагыйрь икәнен түгел, кемлеген дә белмибез бит, — дип кирелә̄нгән Кәримәгә ачуланып:

— Ул минем яшьлегем хисләрен, уй-хәсрәтләремне сурәтләп бирә алган әдип! Син нәрсә беләсен! — дип авыр кагылып та алган иде. Аннары, йомшарып:

— Бездә аның бер китабы бар. Бирим әле, укып чыгарсың! — дип, кызлары өйдә юкта шул кичә кулга зур булмаган шигырьләр мәҗмугасын эзләп алып, табып та куйган иде.

Аны Кәримә курка-курка гына укып чыкты. Баштарак бары тик шигырьләрдәге хисләрнең сафлыгы кызыксындырды. Алар артык гади, ә күп очракларда вакыйгаларны таркау сөйләү кебек язмалардан гына гыйбарәт сыман тоелдылар. Дөресе шул: яшь шагыйрәнең җаны ул Фәхри Хисами дигәннәренең шигырьләрен кабул итмәде. Аларда сөекле әдибе Габдулла Тукайның рухы сизелми иде. Тукайча түгел икән — шигырь ул такмак кына! Кыз башка төрле уйламады.

Ә аннары, икенче юлы, ял көнне радиодан тапшыру тыңлап утыра иде, шул Фәхри Хисами дигәннәренең берничә әсәрен укыдылар. Алар

Кәриманең күңеленә шундый кискен тәэсир иттеләр ки, ул, хәйран калып, кабат шул шагыйрьнең мәҗмугасын кулына алды. Гадилек, сабырлык, сафлык, эчке хис агымы бу юлы аның күңел дулкыннарына килеп кушылдылар. Инде кыз йотылып укыды. Алар аңа бик тә танышлар сыман тоелды. Бу шигырьләрне язган шушы гадәттән тыш гадел абыйны күрәсе, хәтта аңа үз шигырьләрен дә биреп укытасы килде. Шушы уе аны тагын хыялларга күмде. Инде хәзер үзенең шигырьләре тупланган калын дәфтәргә ябырылып, арадан унга якын шигырьне сайлап алып, аларны акка күчерергә, очрашу көнендә шагыйрь Фәхри Хисамига ничек тә бирергә тиешмен дигән нияткә килде. Аңа ни өчендер шушы абыйсы бик якын, рухи туган кебек тоела башлады. Ул аны аңлардыр, хәтта шигырьләренә басылып чыгарга булышыр сыман иде.

Үз шигырьләрендә дә Кәримә Фәхри Хисами абыйсыныкы кебек хис-тойгыларны тапты. Аның өчен бу зур шатлык иде. Күңелнең нинди киңлекләргә тартылуын аңлап та бетермәскә мөмкин. Бигрәк тә Кәримәгә, соңгы ике елда күбәләктәй очынган хисләрен басып тотуда күнегә барган кешегә, җанын кысып торуы кай вакытларда авырлаша иде, әгәр шигырь язарга сәләте булмаса, бәлки шашынып та китәргә мөмкин иде. Шушындый инде без барыбыз да. Хисләребез ныгый алмыйча, утырыр урын тапмыйча интегәбез. Хәсрәтебез баштан ашкан кебек тоела. Күңелне таратыр өчен җырлап та карыйбыз, шундый да моңлы чагыбызда артыбыздан берәр хәерчесе килеп, шайтан баласы сыман сәлам бирә, котны ала. Никадәр мәрхәмәтсезлек. Ул хакта уйлап та карамыйдыр бәлки? Ул адәмгә ничек рәхәт, әлбәттә. Уен-көлке. Ә син бөтенләй хәйран хәлдә каласың. Моңа, үзенең ахмаклык кылуына игътибар итмичә, сереңне бүлешмәгәнең өчен үпкәли әле җитмәсә, нәкъ Сабира кебек Кәримә үз иҗат хисләренә чумган мизгелдә генә, юри үчекләгәндәй, аның аркасы ягыннан килә дә, язып утырган җирендә, җилкәсенә таянып:

— Эше беткән берәүнең! — ди.

Мондый да хәерсезлекне ничек аңларга да белеп булмый. Кәримә шашына кала. Ярыймы инде ят кешенең күңеле ачылган минутта өстенә килеп басарга? Әгәр комачауларга теләсәң, башкача да бик мөмкин бит, юллары җитәрлек. Үзенең аның, дөрестән дә, эше беткән. Башкаларның вакыты артыгы белән, дөнья кадәрле дип белә торгандыр инде?

Кояш болыт артына яшеренеп, йөзен бер күрергә теләгән бәндәләрне ничек зарлы итсә, Кәриманең соңгы вакытларда күңеле нәкъ шушындый хәлгә бәрабәр иде. Кеше төрлечәрәк була. Берәүләргә гадәти көн дә рәхәтлек бирә, икенчеләргә бәйрәм аралаш яшәве күбрәк ошый. Кәримә элекләрне һәр көнен бәхет һәм бәрәкәт буларак тоя иде. Әмма яшьлеге ни өчендер һаман да аны моңсулык белән озатып бара. Әле бу гамәле дөрес түгелдер сыман, бүтән эше дә барып чыкмыйдыр кебек. Бәлки моңа кадәр үлеп бер гашыйк була алмавы да йөрәген шушындый кара томанлы хисләр эченә куып кертә торгандыр?

Җәйге уеннарда авыл егетләре белән ямьсез кыланулары, аларга шукланып үбеп алырга мөмкинлек биргәләүләре хәзер аңа бик тә күңелсез вакыйгалар сыман тоела. Ничек ялгышты ул шулай? Кирәкми иде әти-әнисен хәсрәткә салулар, гайбәт таралыр өчен юллар куярга. Әмма акланырлыгы да бар: уен кагыйдәләре шушындый булуны таләп итә иде. Ә менә иптәш кызларына көнчелекләрен ташытып чыгарырга бик җитә калды. Аһ, ничек ялгышкан ул, ничек ялгышкан! Шул егетләр арасында комсызлары да, оятсызлары да бар иде. Бит очыннан гына үбеп калу җитмәгән, иренгәчә үрелүчеләре, эшләре барып чыкмаса, мактанып:

— Безнең кызлар ирек бирәләр әле! — дип үпкәләүчеләре.

Кәримә андыйларга ышанып куя язды. Нәкъ менә шул егетләрнең ахырдан, үз ишләре алдында мактанып:

— Кәриманең чия иреннәрен ашадым әле! — диярәк сөйләнүен ишеткәч кенә, кыз тәмам хәйранга калды, кичке уеннарга чыгып йөрмәскә антлар итте. Әмма әтисе, аны, әлеге дә баягы сөйләнгәнчә, чоланга ябып куйгач, салам түбәне тишеп чыгып, болынга кәҗә бәрәне кебек ахмакларча йөгерде. Ана яшьләр арасында күнелле дә, рәхәт тә иде. Бергә уйнап үсмәгәнлектән, ул аларның нинди холыкта, хәйләдә икәнлекләрен белеп тә бетерми. Хәтта арада Ләке керәшеннәреннән:

— Сезнең авылныкы Кәримә белән бергә анадан-тума килеш су коенып үстек, — дип сөйләгәннәрен ишеткән егетләр дә барлыгын, алар моны сабый балаларның бер-берсеннән ятсынмый торган вакытларга бәйле сүзләр икәнлеген анламыйча, яше житкән чибәр кыз турында булырга кирәк төсле аңлауларын да белми иде.

Кәриманең балачагы Ләкедә узганлыктан, ул андагы Метри, Аксана һәм башка дусларын бик тә сагына торды. Әтисе мәктәптә директор, әнисе — укытучы, ә андый кеше баласына асылда хөрмәт чиксез зур иде. Керәшеннәр үзләре дә әгәр Кәримане район үзәге Сарманда очрата калсалар, тәмам шатлыкка күмелеп:

— Безнең Кәримәбез! — дип кочаклап ала, хәтта егетләре дә ятсынып тормыйлар иде.

Татарда андый гадәтләр юк. Үзләрен хис-тойгыларында, күңелләрен ачып куюда бик чиклиләр. Әмма, мондый хәлләргә аптырагангадыр, Кәриманең керәшеннәрдән кочаклатуын гайбәт итеп сөйлиләр. Азмы булды андый очраклар? Ихласлыктан яманлык эзләү татарның авыруы микәнни? Нишләп табигый түгел бу татар халкы? Кеше алдында кочаклашу һәм үбешү аларга котчыккысыз хәл кебек тоела. Ә үзләрендә, аптырамаслык та түгел, һаман да бер-ике кыз, ел саен диярлек очрый шул хәл, буйлы булып өлгерә дә, көмәнле хәлләрендә кияүгә чыга. Сабыр гына, пөхтә генә, оятлы гына йөргән кызлар шуны эшлиләр бит. Җәй көне әтисе Гариф абыйның шашынуын да Кәримә аңларга тиеш иде бит. Ул да кызын шулай астыртын, егетләр белән качып йоклап йөридер дип уйлаган, бу оятның никадәр авыр булуын күз алдына китергән, шуның аркасында акылыннан язар хәлгә житкән, йорт-жирен, мәктәбен ташлап, Әлмәткә күченү җаен караган иде. Эше әле дә ярый барып чыкмады. Аның әтисе дә, әнисе дә, ике атна яшәп, шәһәрчә төзелгән мәктәпкә урнашып, анда да тәмам аптырашта калган иделәр. И сагындылар шул ничә көн эчендә авыл тормышын. Кем уйлаган аларның шул авырлыкка күнеп яшәүче Түбән Ләшәүне шушы кадәр дә ярату ларын?

Сугыш елларында ул авылда Ленинградтан күчерелеп китерелгәннәр яшәгән. Алар бик тә тырыш, эшкә батыр булганнар. Түбән Ләшәү авылының тирә-ягындагы сазлыклардан шакмак-шакмак кисеп торф чыгарырга, аны киптереп, ягарга халыкны өйрәткәннәр. Алар китеп барсалар да, бер тәртибенә күнегеп калгач, утын эзләп аптырамыйча, әле хәзер дә ул авылда торф ягалар. Һаман шул Ленинград маржаларын рәхмәт белән искә алуларын бер дә яшермиләр.

## VII

Фәхри Хисами белән студентларның очрашуы атна кичкә кичке сәгать бишкә билгеләнгән иде. Актлар залында шактый күп халык җыелып, алгы рәтләрдә чал чәчле галим-голамә халкы тезелешеп утырган, шәһәр кешеләре дә бар, студентлар исә һәммә калган урыннарны, дивар буйларын, тәрәзә төпләрен тутырганнар, ишекләргә өелгәннәр. Хәнифә Галиевна, махсус театрга гына киеп бара торган өс-башка төренеп, үзенә урын табу теләге белән әле Якуп Агиш, әле башка профессорлар тирәсендә кайнашты. Ана хөрмәт күрсәттеләр, каяндыр җайлап, олы, киң урындык китерделәр. Ул да утыргач,

университетның Актлар залы тәмам тыгызланып калды. Инде башларга вакыт иде. Әмма Фәхри Хисами әфәндене ректор үз бүлмәсенә дәштереп чәй эчерә икән, сөйләшәләр, дигән сүз күпләрне тынгысызлап йөрде. Халык шул сәбәпле җанын борчулы һәм ризасыз тотты. Әмма тынычлану һәм канәгатьлек аларның да арасына җәелә барды. Сталин төрмәләрен, сөргенен күтәргән, ул гаделсезлекләргә сабыр иткән, кешелеген югалтмаган шагыйрь Фәхри Хисами хакында халык арасында риваятьләр бары тик соклану хисләренә генә төренгән иделәр. Ленинград, Мәскәү якларыннан килеп ирешкән хәбәрләр буенча гына фикер йөрткәндә дә, татарның бу шагыйрен күкләргә чөярлек иде. Анда, сөргендә дә, төрмәләрдә дә, Фәхри Хисамины холкы, гадәтләре, кешелегенә бәйле «Әүлия» дип атап йөрткәннәр булып чыкты. Нәкъ солдат хезмәтендәге кебек, сөргеннәрдә-төрмәләрдә кешеләрнең чын йөзе ачыла икән. Әгәр дә син хайван икәнсең, андый җирләрдә хайванлыгың арта, инде дә син чын кеше булсаң, кешелегең өстен чыга, имеш. Фәхри Хисами чын кеше икәнлеген иптәшләренә йөз өлеше белән күрсәткән. Шунлыктан аңа сокланганнар, аны һичкемнән кимсеттермәгәннәр, әле хәзер дә, дуслары-танышлары аша хәбәрләшеп: «Казан гололобыйлары» безнең «Әүлияне» какмыйлармы анда?» — дип белешеп торалар ди. Дөньяда кешеләрнең хөрмәтен казанудан да зуррак мәртәбә була аламы? Җәннәткә юлны менә шушы — кешеләрнең чиксез хөрмәтен казану — сала түгелме соң?

Шагыйрьнең сәхнәгә күтәрелүе унбиш минутка соңартылды. Көткәндә тамашачы сабырсызлана, сүтелеп алучан була. Алдагы рәтләрнең аяк өсте басулары тәрәзә төбендәге студентларның хәрәкәткә килүе шул вакыт калганнарның кул чабулары белән кушылып китте. Ректорның үзе, аның янында озын буйлы, ак куе, мул чәчле, озынча йөзле кешенең оялып кына атлавы, тагын унлап калын-калын адәмнәрнең аларга ияреп килүләре залны тәмам сабырсызлады. Алгы рәткә килеп җитеп, андагы халык белән озаклап кул бирешеп күрешү күренеше булып алды. Утырыштылар. Кәримәнең бәхетенә урыны сәхнәдән әллә ни ерак түгел иде. Ул хәтта сулышында да онытылды. Кулындагы дәфтәрен бөтереп диярлек кысып тотса да, аны ялгыш төшереп җибәрә язды. Күңеле тулы дулкынлану иде. Шунда хорчылар чыгып тезелештеләр, башта гимн башкардылар. Һәммә кеше үрә басып тыңлады. Ахырда кул чаптылар. Утырыштылар. Ректор, сәхнәгә күтәрелеп, куе алкышларны кабул иткәч, кичәнең ни сәбәпле уздырылуын, татарның бөек шагыйрьләрен искә төшереп әйтте. Партия һәм советлар хөкүмәтенең кылдан нечкә, кылычтан үткен сәясәте мактадды. Бу чыгышы үзенә күрә вакытлы һәм әһәмиятле кебек тоелды. Беразга тын торганнан соң, ректор сәхнәдәге хорчылар хакында да әйтеп узды, шушы хор коллективының университет горурлыгы булуын искәртте. Инде сүзен йомгаклап диярлек, кабат шигърият мәсьәләсендә, кешелек өчен аның әһәмияте турында берничә сүз әйткәч, Фәхри Хисамины үз янына күтәрелергә сорады.

— Бу — гаҗәеп дәрәҗәдә кешелекле, шигъри җанлы, оялчан, артыгы белән тыйнак кеше, һәммә-барчабызны сөендереп, безнең өчен кадерле очрашуга килергә вакыт тапты. Әйдәгез, аңа чиксез рәхмәтебезне белдереп кул чабыйк! — диде.

Зал дәррәү купты.

Ректор янына чыгып баскан чал чәчле чандыр шагыйрь күзләрен кулъяулыгы белән сөртте. Шунда Хәнифә Галиевнаның пышылдап, әмма ишетелерлек итеп әйткән сүзләре Кәримәнең колагына керде:

— Елый, бичаракаем!

Зал аһ итте. Кәримәнең дә күзләренә кайнар яшь килде. Моңа Хәнифә Галиевнаның сүзләре генә түгел, Фәхри Хисами абыйсының үзен тыйнак һәм дулкынланган халәттә тотуы да сәбәпче иде.

— Исәнмесез! — диде ул, чал башын түбән иеп. — Мин бу, мондый хәлне көтмәгән идем, бу хакта хыяллана да алмаган идем...

Зал кабат аһ итте. Култыклап тотып торган ректордан Фәхри Хисами читкәрәк тартылды. Сәхнәдән төште. Кичәнең тәртибе шулай корылганлыгын беркем уйлый алмады. Зал шагыйрьнең сүзләрен, күп-күп сөйләвен көтә иде. Шунлыктан бераз канәгатьсезлек тойгыларын белдереп алучылар сабырсызлыкта тавыш салдылар. Кемнәрдер, шау-шуга көчү чигенә житеп:

— Шигырь укысын, шигырь! — дип куәтле аваз салды.

— Шигырь дә булыр, ашыкмыйк! — диде ректор, катгый тавышын йомшак тотып. — Хәзер студентларга сүз бирәм. Алар нәрсәләр әзерләгәннәр икән — күрик!

Шулай концерт башланып китте. Сәхнәдән төшкән ректорны конферансье алыштырды. Әүвәле туган илне, ватанны сөю турында дәртле шигырьләр булды. Аннары җырлар, биюләр башкарылды. Тагын да шигырьләр укылгач, инде ике сәгатьтән артык, тәнәфессез концерт барганнан соң, ахырда шагыйрьнең үзе — Фәхри Хисами чакырылды. Бу юлы ул ялгызы гына чыгып басты. Сүзен башлый алмыйчарак торды. Күзләрендә яшь энҗеләре иде булса кирәк, алар ялтырап алды. Әмма шагыйрь иптәш йомшаклыгын сиздермәде. Бераздан соң, тыныч тавыш белән генә:

— Мин бүген үземне бәхетле кеше итеп тоеп утырдым, — дип сүзләрен башлап алып китте. — Күңел татар җырына, моңына, җылылыкка сусаган булган. Тормыш өчен алар бик тә кирәкле, бик тә кыйммәтле байлыклар. Моны миңа анларга туры килде. Тормышка, әдәбиятка яңадан кайту өчен сезнең күңел җылыгыз миңа бик тә кирәкле! Рәхмәт сезгә, рәхмәт!

Ул тагын да түбәнсенеп башын иде. Тывышы сабыр һәм тыныч иде. Халык тын чыгармыйча аны тыңлады. Сүзләре күп нәрсәләрдән хәбәр бирде. Аңлаган кешеләргә тормышындагы авырлыкларны кузалларга шушылар да житә иде. Күп кешеләрнең ул җәһәннәм газапларыннан чыга алмыйча һәлакәткә очраулары да билгеле булганлыктан, Фәхри Хисаминең исән кайтуына шатлану хисе барыбер дә йөзләргә яктылык бирә торды. Тамашачыларның эчке куануы, чиксезлеккә тоташкан ихлас алкышлары һәммә бөеклекләрдән өстен бер хәл иде.

Кәримә исә кичәнең башыннан ахырына кадәр үзен югалтыр дәрәҗәдә дулкынлану кичереп утырды. Менә халык аягүрә торып кул чаба башлады. Кәримә дә аларга иярде. Шунда көтелмәгән хәл булып, тамашачы ташкыны сәхнәгә таба тартылды. Бергә кайтырбыз дип алдан килешенгән Хәнифә Галиевнаны Кәримә шунда күздән югалтты. Аны ташкын этеп, сәхнәгә китерә бирде. Кәримә карышты. Буйсынырга теләмәде. Әмма ул бу ашкыну көченә каршы тора алмый иде инде. Буталу, халыкның сәхнәгә таба сөрелә бирүе, аһлар һәм уһлар, һәммәләр бергә катышу, унга-сулга тартылулар Кәримәне үз эчендә адаштырып йөрттеләр дә, ул, карышкан хәлендә, көтелмәгән бер очраклылыкмы, тәкъдирнең уңай җиле аркасындамы Фәхри Хисами абыйга йөзгә-йөз килеп туктады. Аларның күзләре очрашты. Алдан ук шагыйрь абыйның кулына тапшырырмын дип уйлап үзе белән алынган дәфтәре гүяки кулын хәрәкәтләндерде. Нияте үз көчендә калып, билгесез бер әмер белән шунда аны Фәхри Хисамига таба сузды. Аларның күзләре болай да бер-берсенә бәйләнгән кебек иделәр. Кәримә читкә карарга теләде, әмма карашын ала белү көче әлегә аңарда юк иде. Шагыйрь абыйсы исә, автограф-имза сорап сузылган кәгазьле-открыткалы кулларны күрмәде. Аның да күзләре бары тик чибәр Кәримәдә генә иделәр. Ул нәрсәдер әйтергә теләде, әмма сүзләр таба алмады. Кыз шунда үзен кулда тотарга тиеш икәнлеген уена китерде. Карашы дәфтәр сузган кулына күчте. Аны Фәхри Хисами абыйсы аңлады. Дәфтәр аңа күчте.

— Бу миңамы? — дип сорады ул.

Кыз, каушавын тоеп:

— Әйе, сезгә! — диде.

— Монда шигырьләрме?

— Әйе, шигырьләр!

Шагыйрь абыйсы ишеттеме-юкмы, аларны халык ташкыны бер-берсеннән аерырга өлгерде. Кәримә читкә чыгарылды. Ул үзен гүяки авыр дулкыннар белән су өстеннән куып китерелгән чүп-чар кебек хис итте. Ни елый, ни көлә алмас дәрәҗәгә җитте. Хәле бигрәкләр дә аһ иде. Хисләре һаман күтәрелә бирделәр. Сулышы кысылганнан-кысыла барды. Бу иркен, киң, олы залда аңа һава бетте. Ишеккә таба юнәлде. Ауган урындыклар һәм китаплар, аунаган кием-салымнар аңа алга атларга комачаулыдылар. Ә ул ниндидер бер илаһи аңсызлык белән бара бирде. Өстенә юка җәйге пальтосын киде. Букчасын кулыннан төшермәде. Баскычтан иңеп, озын коридор буйлап килә бирде. Шунда гына Нуруллов белән сөйләшеп торган Сабираны шәйләде. Аларны күрмәгәндәй узып, урамга чыкты. Колонналар янында туктап калды. Күңеле, һава салкыны тәэсиреннән булыр, тынычлана башлады. Бу нинди дулкынлану иде — моны аңлый алмады. Аңарга дөнья бөтен барлыгы белән билгесезлек эчендә чайкаладыр кебек тоела башлады.

## ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

### I

Кичәдән Фәхри Хисами зур дулкынлану белән кайтты. Сөргеннән соң, Казанда яши башлавына әүвәле куанып туймаган иде, хәзер менә тагын яңа үзгәрешләр — халыкның зурлап, якын итеп кабул итүе аны яктылык нурына килеп кергән һәм аннан коенып чыккан бәхетле әкият героедай итте. Ул үзенең күңел сыкрауларын да, алар белән бергә йөрәк авыруларын да онытты. Күз алдыннан кара бөдрә чәчле чибәр шагыйрә кыз китмәде. Аның самими якты карашы, алсулык йөгергән бит очлары, усак яфраклары кебек калтыранулары — барысы Фәхри Хисаминың хәтерендә янарды. Кызның биргән дәфтәрен дә ачып-ачып укыды. Беренче шигырендә үк ярату хисенә юлыгып, күңеленә әле шомлану, әле горурлану, әле бәхет, әле сагыш тойгылары инде. Шушы халәт аңа рәхәт, бик рәхәт иде. Язмышы һәрдаим шушылай гына булыр дип күз алдында торткан егеттәй йөрәге тибрәнде. Бу вакытта ул үзенең инде илле алты яшьтә икәнлеген дә хәтереннән чыгарып ташлады. Моңарчы кемнендер шушы кадәр гашыйк иттергәне бар идеме икән аны? Боларын ук хәтеренә алып җиткерү исенә дә кермәде. Ул сихерләнү халәте эчендә иде. Бу — мәхәббәт кенә түгел, мәхәббәтнең үзенә гашыйк булуыннан килде, билгеле. Шунлыктан анарда дулкынлану хисләре диңгездәй кайнадылар. Ә күңеле чиксез яктылык эчендә иде. Бу сөенечен ул ничек тә йөрәк түренә бикләргә, аларны шигырь орлыклары итеп күңеле бакчасында чәчеп үстерергә теләде. Хәтере генә, салкынлык күрсәтеп, моңа комачаулык тудыра торды. Әле сөрген елларын исенә төшерде, әле хатынын югалтуын. Аның яшәве дә көйләнмәгән килеш. Казанга кайтып, монда ялгызы яшәүче сеңлесенә әүвәле кунак буларак килеп төшсә дә, хәзер инде фатирчы хәленәрәк кереп бара. Баштарак сеңлесенә ул ничек кояш җиргә яз китергәндәй тәэсир итсә, хәзер, көннәрнең берендә, шушы язның көз белән алышынырга мөмкин икәнлеген дә белә. Адәмиләр арасында шулай бит инде, кунакның вакыты өч көннән артмый. Үз туганыңның да тормышы бар. Син аңарда гомер буе арка җылыта алмыйсың, күңел миче бүген ягылган икән, иртәгә шатлык ялкыннарын чәчеп янучы утыны да бетеп китүе бар. Әмма ябага туганы кая барып сыеныр икән?

Фәхри Хисами болар турында хәтер диңгезен кайнатмый кала алмады.

Көннәрнең бер җил кебек ашкынуда узуы уйларының кайбер дулкыннарын хакыйкать, тормыш миһербансызлыгы таш кыяларына китереп-китереп бәрә дә, бары тик авыру күбекләрен генә калдыра. Ул берни дә эшли алмый. Казан шәһәре, олысы-кечесе бәхет кошына юлыккандай аны хәзер кабул итсәләр дә, эссе тантаналарда исә, йөрәген тимер утыдай кайнарландырып, бер туры сүз әйтергә ирек бирмәүләре сәер. Һәр сүзенә җитмеш йозак эленгән. Ул әйтә. Ул исәнләшә. Әмма туры сүздән үзен ерак тотарга тырыша. Куркуы йөрәгенә үткән. Тагын гаделсезлек тавына юлыгыр сыман. Ә алга таба нишләсен? Аның бит:

— Исәнме, газиз милләтем! Син мине нишләтеп ташладың? Йөрәк яраларымны тозлы далаларда ямаштырып кайтып, алдыңдагы түмрәнгә тагын газиз башымны, чәчәктәй гомеремнең инде чал елларын китереп салдым. Кулыңдагы хөкем балтасы йөрәк тамырымнан соңгы тамчы ал ширбәтне эчәр өчен кабат чабарга күтәрелгәнен тоям. Бу синең аһ итүләрең шул балтанны болгау галәмәтеме? — диясе килә, акылы буйлап хисләренең бозлы ташкыны йөгерә. Ул гүяки тау елгасы, хәтеренең кыяларына бәрелә-бәрелә, төпләрендә яткан, инде онытыла язган исәпләнелгән үпкә-рәнҗешнең кара ташларын кузгата, астындагы тынчуланып беткән ләмне болгата, тынгы белми иртә-кич, көндезен-төнен ага. Әле кичәге көндә генә «Совет әдәбияты» журналының авыр һәм куркыныч ишекләре янында хәер эстәп йөрүче ятим бала кебек фәкыйранә оялуда басып торды. Ничә бәхетле яшь каләм иясе коридор буйлап узды. Алар аны танымый. Арада берсе, тәпән корсаклысының, һич тә таныш тоелмаган иптәшләре белән бәрәңгеле авызларын бәлештәй җәеп:

— Бу адәм, картаеп беткәч, саламын тибрәтеп, такмак боламыгы ясап алып килгән, ахрысы! — дип әйткәнен Фәхри Хисами төгәл ишетте. Бәгырендә бу сүзләр, кабих Нәмруд падишаһның җиде җәпле әшәке угы тишкәләп узгандай, авыр кискәләнү калдырды. «Йа Раббым, Үзең белүче һәм күрүче! Казакъ далаларының тозлы чабау-сарынчак үләне үскән сөргеннәрендә тизәкле куй артыннан чапканында, туган якларны сагынудан күзеннән соңгы тамчы энҗе бөртекләренне чәчеп йөрү берни булмаган икән ул. Менә кайда башлана аяусыз тәкъдир кылычының чамасыз гайрәт белән чөелеп кыланулары. Ничек бу кешеләр каршысына асыл күнеленнең ак җаймәсен җәеп салырга мөмкин? Ул анда ипи-тоз китереп куярмы? Шигырь алып килдем әле дип кер алар хөкеменә! «Сәлам тибрәтеп язучы... такмакчы...»

Кичә шушы вакыйгадан Фәхри Хисаминың күңеле тәмам бозылып кайткан иде. Университетка да алдан сүз бирүнең иманлык бәһасе барлыгын белгәнгә генә барды. Беркемгә дә кирәк булмаячагын аңлап, белеп, уйлап барды. Әмма анда кояш һәм айны берьюлы күргәндәй булды. Исәнләште. Нибарысы ике шигырь укыды. Аларда үзе генә белгән, тормышының адәм күзеннән саклык өчен ябып калдырылган алтын бәһасе ике-өч кәлимә сүз генә бар иде.

Аһ ул кыз, ул кыз! Җәннәтләрнең бәрхет кара туфрагында үскән, ефәк болыннарында йөгереп йөргән, бәрәкәт арыкларының зыр-зыр зәмзәм суларыннан тамчыларын учына алып, шуларны эчеп житлеккән фәрештә кыз аңа шигырьләр тулы дәфтәр китергән — Фәхри Хисами абыйсына! Шушымы бәхет түгел?

Ул баланы ай күрде, кояш алды. Әле дә хәтерендә шомырт кара күзләре, зөлеф-бөдрә ефәк чәчләре, кызыл якут йөгертелгән иреннәре, каләме таң нурының сихеренә манчылып, затлы язмыш рәссамы тарафыннан гүзәл итеп сурәтләнгән йөзе-башкасы — барысы бергә юк та булдылар. Фәрештәләр адәмиләр арасында ничек яшәп кала алсыннар инде?

Әмма бу хәл һичнинди сихри чаткыдан коелып калган нурлы вакыйга

түгел. Моның дәлиленә хасият иясе — бакчачының күзгә-күз тезеп үстергән затлы чәчәк такыяларына хас, һәрберсендә нур һәм хис чагылышы балкыган бөртек-бөртек энҗе хәрефләрдән торган утлы бер калын дәфтәр шигырьләре... Илле алты яшьлек чал чәчле шагыйрь абыйсының инде хисләргә саранланган ялкау күңеле татарда мондый кыз баланың тууына серле могҗиза буларак ышана алмый аптырый. Әйе, дәлиле җанга суык мунча булырдай, җиргә егып төшерерлек дәфтәр. Мондый шигырьләр генә Бәһрәм Чубин кебекләрне дастани каһарманнардай кеше итә ала, уттан суга, судан утка сала-сала чүкелгән кылыч итеп затлы ир ясый. Әгәр дә илдә юнь, адәмдә им булса, мондый шигырь җимешләре милләтне сыйлы-хөрмәтле итәр иде.

II

Фәхри Хисами тагын да тагын Кәримәнең берничә шигырен укып карады. Күңеленә хисләр дулкыны ярсып кайнаган мохит диңгезедәй кереп тулды. Ниндидер сәер халәт иде бу. Күгенең кояш тулып балкуы, тойгыларының чиксезлеккә ашкынуы, йөрәге тулы хисләр дулкынының шашынуы аны шундый да аңлашылмаслык бәрәкәт эченә сала — ул моннан чыгасын да, аның төпләрендә башы каласын да уйламый. Бары тик бик тә, бик тә рәхәт кенә, бәхет кенә.

Фәхри Хисами гасыр башында дөньяга килеп, канлы революция һәм Гражданнар сугышының кешеләрне изә торган елларында инде үсмер егет иде. Яраннары кебек патшага йодрык төйнәп йөргән башкисәр дә, кылыч айкап акларга томырылган гаярь кызыл сугышчы да аның язмышы аша узмады. Ул «Галия» мәдрәсәсендә кызыл комитет тоткан егетләрнең дә ышанычын яулый алмады. Үзен бик тыныч тота алуы, кайнап-кайнап чыкмавы, әле шәригатькә, әле муллаларга каршы ярсулы һөҗүмнәрдә катнашмавы шәхесенә карата иптәшләрендә бары тик ышанычсызлык кына тудыра алды. Әүвәле моны Фәхри Хисами аңламады, күңеле тулы шигырь булып, ул аларны куен дәфтәренә төшерә иде дә, әллә нинди зур эшләр куптаручы шәкертләр арасында ак карга сыйфатлы йөри торган иде. Ә аннары, ярлы батрак гаиләсендә үсүе дә, һаман да җәбер һәм кимсенүләр генә күрүе дә аннан кызыл бугазлы егет ясый алмады. Кием чабуының ертыгы ачылыр да китәр дигән курку хисе аны һаман да сак йөрергә мәҗбүр итә иде.

Башкорт аймакларына килеп урнашкан татарлар ныклы тамыр белән яши иделәр. Андыйлар мәдрәсәдән куылудан курыкмады. Фәхри Хисами үз тормышын көйләү өчен Уфада азмы ялчылык итте? Хәер, чоры да шундый иде. Байлар хак түләүдә бик кысмыр булдылар. Фәхри Хисами һаман да Галимҗан абыйсын көтте. Бу кешенең ул язучы икәнлеген дә, шигырь өлкәсендә зур гыйлем иясе булуын да беренче дәресләреннән үк хәтерли. Галимҗан Ибраһимов «Галия» мәдрәсәсе мөгаллимнәренең берсенә дә охшамаган иде. Аның артка кайтарып таралган кара коңгырт чәчләре, елтыр күзләре, сеңерләрен тибрәтеп торган көчле йөзе, уртачадан калкурак буй-сыны, сүздә төгәллеге, пөхтәлеге, урыс зыялылары кебек киенеп йөрүләре, башына кәләпүш салмавы, әле ак эшләпәдән, әле карадан йөрүләре сокландыра да, сәерсендерә дә, хәтта куркыта да иде. «Галия»дә шәкертләрне бер-ике ел гына укытып калды. Китүенең сәбәпләрен төрлечә сөйләделәр. Ул, хушлашып чыкканында:

— Мин кайтырмын әле! — дип, шәкертләрен юатып киткән иде. Фәхри Хисами аны менә кайтып килер, менә кайтып килер диярәк көтте. Бу елны да, вакыйгалар чуарланып китүгә карамастан, ул бары тик шушы Галимҗан абыйсының дәресләрен ишетми калмагаем дип, мәдрәсәгә кабат керде. Җәе

Урал заводларында авыр кара хезмәт белән узды. Укуын дәвам итәрлек акча туплый алды. Ә Галимҗан Ибраһимов сүзендә тормады. «Галия» мәдрәсәсендә сагынып калган шәкертләре көтәдер дип мөгаен исенә дә алмагандыр?

Кышка каршы Уфада Петроград шәһәрендә чыга торган «Чулпан» газетасы хакында сүз таралды. Анда Галимҗан Ибраһимовның социалистик революция турында мәкаләсе булып, ул язмасында халыкның ничә йөз еллар буена йөрәгендә йөрткән өметенең акланувы хакында белдерелгән иде. Фәхри Хисами яна дәвергә яңа кешеләр кирәклеге хакындагы ул язма юлларын аеруча йотылып укыды. Үзенең мәдрәсәдә белем алуы заяга түгеллеген, зыялы, аңлы яшьләрнең яңа тормыш төзүгә өлеш кертергә тиешлекләре хакындагы күрсәтмәләрен чын күңеленнән аңлап кабул итте. Шушы мәгънәдә үзен дә революционер буларак күзаллады. Кызыл бугазлар бүрәнә артыннан бүре куучыларга әверелеп, буш сүз тегермәнен тартучылар сыман тоелдылар аңа. Фәхри Хисами «Галия»гә укыр өчен керде, ул шагыйрь булу максатында белемнең ни мәртәбәдә зарур икәнлеген үзенчә күзаллый иде. Язган әсәрләрен газета-журналларга җибәреп карады. Әмма аның сүзләренә, йөрәгендәге хисләренә бу дөнья мохтаҗ түгел иде шул. Басылып чыгуларын көтүләре әрәм китте. Моңа карап кына ул әле егылмаска да тиеш иде. Бусы ук булмады, язулары сирәгәйгәннән-сирәгәйде. Инде шигырь чыгаруны ташлар да кебек иде. Аның укыйсы, беләсе, гыйлем диңгезенә чумып бәхет табасы килә иде. Ул елларда белем алуга ярлы-батрак уллары зур дәрт белән тартылып, караңгылыктан чыгуны караңгылыктан котылу буларак аңлый башлаган иделәр. Ә данлы революция ташкыны аларның күбесен үз дулкыннарына болгап алып кереп китте. Читтә торып калучылардан бер Фәхри Хисами гына иде булса кирәк. Бу аның шигырьдә генә яшәвеннән килә иде. Ул бары тик эчтән янды, тыштан исә аңсыз һәм уянмаган сыйфатта күренде.

### III

Киң казакъ далаларында сарык көтүләре йөрткәнендә бер бәрәнне ул үз куенында үстерде. Сугышлар бетеп, тыныч хезмәт еллары башланган иде инде. Фәхри Хисамины Сталин суды, төрмәдән чыгарып, мәңгелек сөргендә калдырырга хөкем итте. Бөек юлбашчы һәм халкы каршында гаебе нидә икәнлеген ул чамалый: аның шигъри хисләре бәхетле җәмгыять төзүчеләргә комачаулык тудырырга гына сәләтле! Хәер, тынчу-караңгы төрмә камераларыннан, Урал һәм Себер базларындагы авыр эшләрдән соң, казакъ даласы җәннәт җиредер сыман тоела башлады. Беренче тапкыр ул үзенең кеше икәнлеген менә шушында кабат тоемларга тотынды. Бу хис аны тормышка кайтарды. Дала җиле еракта сиземләнгән Казаннан сәлам китерәдер сыман. Әмма ул шушы казакъ җиренең бер дә ят, чит түгеллеген белә. Татар атларының томырылып Аурупа кыйтгасына ташланган җире, тарихының чишмә башы менә шушыннан түгелме соң? Чиксезлек, дөньяның тыныч агыш белән үзгәрешсез баруы, замана тәгәрмәченең куәреннән бүселеп чыккан, таралып калган урыны бу.

Аның куа китереп йөрткән көтүеннән бер сарыкның өч бәрәне булды. Мондый хәлне Фәхри Хисаминың гомерендә дә күргәне юк иде. Туган төбәгендә күрше авыл чуашларында ул бала вакытында ике атналап көтү йөрткән иде. Аксубайның сай сулы инеш ярларында иркенәеп җәелеп йөрергә сыерга түгел сарыкка да тарлык. Маллары ач, вак үлән ашап интегәләр. Ун яшьлек малайның гаебен чуашлар күп таптылар:

— Татар да булдымы көтүче? Мал бага белмиләр! — дип, авыл ризасызлыгын яшермичә сөйләде. Фәхринең көтүчелегеннән баш тарттылар.

Әмма шушы эшендә ул сарык бәрәнләтүгә чуаш Микуладан өйрәнеп калды. Арык малның хәле дә юк икән шул. Адәмнән ярдәм кирәк.

Казакъ даласында сарыклар иркен утлыйлар. Бер яки ике бәрән китерүләре — табигый хәл. Туган сәгатьтә үк алар сикереп торалар да йөри дә башлыйлар. Аларны монда кузы дип атыйлар. Һәркайсына шунда ук сан сугыла, кәгазьгә башы теркәлеп тә куела.

Өченче бәрәнен китергәндә сарыкның хәле беткән, Фәхри Хисами, сәбәпне шунда ук аңлап өлгереп, малай вакытыннан белеп калганынча, аңа ашыгыч ярдәм күрсәтте. Бу кузы бик зәгыйфь булып чыкты. Тавышы — зәһәр, аяклары — көчсез. Фәхри Хисамига аны күтәреп йөртергә дә, башка сарыклардан имезергә дә туры килде. Күз-колак иткәндә, бу эшенең дә әллә ни авырлыгы юк иде. Сарык бәрәне, көннәрдән бер көнне ныгып алып, үз көенә утларга да өйрәнеп китте. Ә тавышы барыбер дә зәһәр булып калды.

Һәм ул көтүдә беренче куй булып үсеп житте. Бер ел эчендә аның зәгыйфьлектән өстенлеккә ирешүе адәм баласының дөнья каршында гамәлләренә һәм яшәешенә мисал кебек аңлашылып, өлге сурәттә иде. Кояш ничек үз жаенда жир йөзен үзгәртеп, әле яз, әле көз китереп, елмайган хәлендә йөрсә, кеше дә шушындый түгелме соң дип, элекләрне уйланып аптырый торган Фәхри Хисами, үзенең шагыйрьлеген исенә төшереп, яшәешнең галәмәтләре әллә кайда күктә түгел, бәлки туфрак бәрәкәтендә икәнлеген дә аңлый башларга бу кузы вакыйгасы бер этәргеч иде.

Шушы усал сарык бәрәне, көтүчесе каршына вакыт-вакыт килеп басып, зәһәр тавышы белән котны алырлык итеп сәлам бирү гадәтенә кергәч, моны рәхмәт йөзе буларак кабул итми мөмкин түгелдер дигән фикергә төште. Аңа жавап итеп үзе дә эндәшә, хәлләр сорашкандай итә, хәтта, күнеленә ятканда, сөйләшә дә торган булып китте. Бу куй аңа Кабилнең корбаны, Исмәгыйль пәйгамбәрнең хөрмәте, Мөхәммәд пәйгамбәрнең бурагы кебегрәк тоелганлыктан, икмәк кисәкләреннән дә аңа өлеш чыгаргалап, ризыгын бүлешеп сыйлаган чаклары да бар иде. Әмма алары сирәгрәк булгалады. Азык ягыннан кысынкы еллар ул...

Кич життеме, бәрәкәт биреп Урал якларыннан жил исә, янгыр сибеп үтә торган булды. Көннең буена сузылган кайнар кояш тәмам хәлсезләсә, кичләрен рәхәт иде, аның каравы. Шушы тормыш шартларында да кешелеклелекне саклап калырга, тормыштан зарланмаска өйрәнергә кирәк иде. Шагыйрь Фәхри Хисами элекке гадәтенчә үзен сабыр һәм тыныч тотты. Каударланмады. Ул үзен: «Дөньяны хәзер су басса да — синең өчен барыбер!» — дигән сүзләренә күндерергә тотынды. Һәр сәяси үзгәреш, кешеләрдәге һәм жәмгыятьтәге күренешләр, шылт иткән тавыш та аның шигъриятендә кайтаваз булып яңгырарга тиеш булса, болар инде бары тик үткәндә калды. Хәзер ул, чаң каксалар да сикереп торып йөгерүче түгел. Башта уяныр, аннары уйлар, шуннан соң тагын бер кат уйлар, ахырда — борылып ятар. Ул инде янгын сүндерүче дә, халыкны әйдәүче дә була алмый.

Әмма битарафлык? Юк, монысына ук Фәхри Хисами өйрәнә алмады. Ул бары тик дөнья йөзенә сабыр канатын жәйгән арышлы-бодайлы, алмалы-чияле август ае кебек кенә иде ул чакларда. Алда гомеренен көзе булуы аның сабырлыгына хуш килер сыман иде. Ә ул югалды да китте. Әбиләр чуагында далада саташып мәк чәчәк атучан була. Кәримәме соң әле аның исеме? Әйе, Кәримә икән! Дәфтәренә шулай язылган... Таңбикә дә, Таңсылу да, башкача да түгел, Кәримә икән, Дулатова!

Соңгы вакытлардагы хәтерсезлеге Фәхри Хисамины борчырга тиеш иде. Әмма бу аңа шатлык кына китерде. Күргән газаплары жиңел кул белән сыпырып алынгандай онытылып калды кебек. Ул аларны хәтерендә дә

янартасы килмәде. Теге атнада, Ленин урамыннан узганда, Сибгать Хәкимне очратты. Чирләшкә генә бер шагыйрь кисәге дип сөйлиләр иде, бигрәк тә Муса Җәлилнең аны өнәп бетермәвен каләмдәшләре белә иделәр. Әмма егет яралы бөркет баласы гына булган икән бит, шушы еллар эчендә чын лачын булып ныгып житкән. Татар шигырендә хәзер анын сүзе баш, аның сүзләре кода, аның әйткәне — хөкем, диделәр. Алар йөзгә-йөз туры килделәр. Узып киткәч кенә Сибгать Хәким икәнлеген абайлап өлгерде Фәхри. Әмма юлыннан кире кайтмады. Сибгать аның белән исәнләшмәде. Танымавы хак иде. Аннары, ул бит сугыш батыры, «Курский дугасы» дигән котларны алгыч мәхшәрдән исән-аман чыккан. Андыйлар сирәк. Шигырьләре хәтта «Правда» газетасында күренгәлиләр икән. Фәхрине танымавы сәер түгел, өтек «халык дошманы» белән дуслык түгел, белешлек тә каза кебектер андыйларга? Олпат кеше сакчыл да, саклы да була ул.

Фәхри аны гафу итте. Үзара танышлыкны янартып җибәрүнең мөмкин хәл түгеллеге анлашыла. Дөньялар хәзер бөтенәеп, тәртипкә кереп бара, аны кабат бозып ташлыйсы килми. Әгәр дә моннан унбиш кенә ел элек Сибгать белән күрешмичә болай узып китсәләр, Фәхринең ачу ташы хис кайнарында кызып шартлар дәрәҗәгә житәр иде. Хәзер алай итә алмый, сабырлыкта калырга мәҗбүр.

Кешеләрнең исәнләшмәве бер Сибгать белән генә бәйле түгел, Фәхрине аны сирәкләр таный. Элекке танышлары күзенә чалынмаска тырышалар, махсус күрми узып китәләр. Унбиш ел эчендә дөньяда кешеләр дә үзгәргән билгеле. Бәлки ул танымый узучы кешеләр анын танышларынын балалары гынадыр? Ил өстеннән ничә ел рәттән кара сугыш утынын куркыныч төтене аккан, житмәсә «даһи»нын канлы балтасы муен тамырларына чабам дип эленеп торган, кайчан һәм кемнең башын өзәсен беркем дә белмәгән. Бәлки шушы бәлаләрдән ил коргаксып калган да, бу сагышлы йөзләрнең чалымнарында вакыт-вакыт уйнап алучы елмаю нуры илдә үсеп килгән буыннын киләчәккә өмет белән каравының билгесе генәдер?

Яшьләр. Алар кемнәр? Күп очракта — беркатлы кешеләр.

Фәхри Хисами үз күнеленә тулган уйларнын төрлечә булуына бер дә сәерсенмәде. Ана шулай рәхәт. Хәтта күнелле иде. Мона кадәр һаман да бер үк нәрсәләр генә хакында, илгә, Ватанга, партиягә һәм Сталиннын үзенә тугрылыкны саклау, аларга коммунистларча фидаи рәвештә жан-тән белән берегү, әмма шушы мәхәббәтен анлата алмавы, шушы хисләренен ил, Ватан, партия һәм Сталин ягыннан жавапсыз калдырылуы аны изә, кисә, ваклый иделәр. Бу кадәр сөеп тә, сөексезлек утында янудан авыррак газапны коллык хезмәте дә бирмәде ана.

Фәхри Хисами Сталин исеменә ничәмә хат кына язды, өмет, ышаныч, мәхәббәт хисләре белән тулы иде алар. Һәммәсендәге һәр сүзгә, һәр өтер һәм ноктага аерым мәгънәләр сала иде. Менә алар иптәш Сталиннын кулына керер дә, йөрәгендәге жылы хисләрнең бәрәкәтенә эләгеп: «Минем сөекле Фәхри Хисамины гаделсез хөкем иткәнсез! Инде аны иректә итеп, янымдагы тәхеткә чакырып китерегез! Ул минем изге яраным, тугры дустым!» — дигән әмер килеп ирешер, газаплаучыларнын үзләренә хөкем чыгарылыр сыман иде. Акланмады, берсе дә, бер генә өметенен мыскал кадәр өлеше генә дә чынга ашмады. Мондый мәхәббәттән чүлләр гөлбакчага күмелер иде, югыйсә!

## IV

Бу Фәхри дигәннәре «отпавши» нәселнен эче-тышы мөселманга әверелгән көннәрдә табылган һәм дөньялык йөзендә ин матур исем сыман тоела иде. Хисамиев фамилиясен аларга агалары тапты. Имеш, борынгы заманнарда

бер куәтле нугай мирзасына Хисаметдин дигән мишәр бабасы муллалык хезмәтенә кергән дә, тугрылык һәм итагать белән анын ышанычын яулап, шушы Карахмәт авылынын жирләрен һидия буларак алган, әмма ил өстенә урыс килеп, баш бирмәс чуашларны тыныч холыклы татарлар арасына күчереп утыртып, тәмам дөнья йөзен бозган, гореф-гадәтләрдә бичара бәндәләрне саташтырганнар икән. Боларын Фәхри Хисами, коммунистик рух белән соңрак төшенеп, үз рухында интернационализмның беренче адымнары дип атарга, анларга, бәяләргә өйрәнде. Ә шулай да ул, кайсыдыр күңел омтылышлары белән хис итеп, һәр халыкның үз бәхете белән үзенчә яшәргә хакы барлыгын тоя һәм тормышның шундый булганында гына бәхетле барачагына ышана башлады. Бу уйлары патша заманнарында ук барлыкка килеп, илгә совет кергәч онытылып һәм коммунистик кызыл таш белән бастырылып, томаланып торды. Соңгы көннәрдә генә ул, хатирәләрен янартканда, иске мәдрәсәдән калган гыйлемнәре белән бергә шул уйларының жеп очларына юлыкты.

Һади! Бу бөек кешене анын һичкайчан һәм һичбер жирдә онытасы юк. Габдулла да түгел, Пушкин да, башкасы да... Ә Һади Такташ! Ул анын өчен, данлы исем белән бергә, яшьлек хатирәләре дә иде. Әгәр дә кешенең бөек хисләренә жавап бирерлек таулары, чишмәләре, урманнары, юк-юк, алар гына түгел, хатыны, балалары бар икән, ул — бәхетле, әлбәттә! Әмма Фәхри Хисами хатынын югалткан, гомерен кысыр уздыра барган кеше. Ул моны шәхси фажигасе итеп тойса да, Һади Такташтан аерылуын гүяки жаныннан мәхрүм калган матдә хисабында хис кыла иде.

Ул Казанның Бишбалтасында, анын да татар мәктәбендә милли тел һәм әдәбият укытучысы булып эшләп, шактый гомерен уздырды кебек. Әйе, ул яшь иде. Анын бер яшәү көне — бүгенгенең өченә, бәлки жидесенә, ягъни атнасына тигез килгән. Әй Һади! Син ничек үзеннен яшьлек каләмдәш дустынны ташлап китә алдың?

Бәлки бу сүз хатадыр? Ялгандыр?

Һади Такташ Бишбалтага дусты Хәсән Туфан янына килә иде дә, әгәр аны өендә таба алмаса, Фәхригә керә иде. Болары кемгә дә билгеле фактлардан. Фәхри бервакытта да Хәсән Туфаннан Һади Такташ белән дуслыгы өчен көнләшмәде. Ул үзен алар кебек бөек шагыйрь дип белми иде дә.

Ә хәзер күзләренә яшьләр килә. Хәсән Туфанны да Казанга кайткан, ике ел була дип әйтәләр. Тик әле һаман да очраганы юк. Исәндерме, юктырмы — тәгаен гына белеп әйткән кешене табуы да бу заманда бик авыр. Анын да Луизасы, — хатыннар арасында бөек хатын, әлбәттә, — вафат дип әйтәләр. Кабере «Яңа бистә зираты»нда, имеш. Урыны — билгесез.

Бу нинди замана? Бу нинди яшәеш? Кеше киткән, ә анын каберенә чәчәк тә куеп булмый. Моңа кадәр күрелмәгән, бәлки моннан соң гына гадәткә әверелеп китәчәк хәлме бу, әллә хәтер хатасымы, мәгънәсезлекме? Ходай белсен!

Коммунистик хыялларда яшәүче Фәхри Хисами имансыз түгел иде. Анын өчен Коръән һәм большевизм аһәннәре — уртак. Ул, хаталы бәндә, моны шулай дип белә һәм аяныч рәвештә ялгыша. Шуны да анламый. Анлар иде дә — аны Ходай Тәгалә зиһененнән мәхрүм иткән булса кирәк. Большевизм газапларын жилкәсендә күтәрсә дә, амнистия алган мизгеленнән башлап үзен газапларга салучыларны гафу итте шул ул.

## V

Йолдызлар алар күктә генә төркем-төркем күренәләр. Чынлыкта котчыккысыз ялгызлар.

Инде бу ялгызлык үткәндер, беткәндер сыман иде, юк икән. Фәхри

Хисами, Казанга кайтканнан бирле, матбугатта һәм олы бәйрәм очрашуларында бераз ялтырап алды да онытылды. Аны башкалар алыштырдылар. Аларны — яналары. Фәхри Хисами үз дөньясында югалырга мәҗбүр иде. Шушындый көннәрнең берсендә ул әллә бер-бер кемнәнме ишетте, әллә укыды: «Йолдызлар күктә генә төркемдә яналар, ялтырыйлар, ә чынлыкта галәмгә чәчелгән, сибелгән хәлләрендә яшиләр». Хәзер хәтерләп тә бетерә алмый, нәкъ шушы сүзләр тәртибендәме, әллә бу фикер башкача төзелештәге җөмләме — әйтә алмас иде. Мен уйланды. Шул уйлары белән катлауландырып, күнелендәгесен дә кушып, бөтенләй дә башкача анларга һәм анлатырга теләдеме ул сүзләрне — инде белә дә алмый. Аны ялгызлык изә.

Кәримә?.. Әйе, Кәримәсе бар бит әле анын. Олы, матур күзле гүзәл шагыйрә кыз. Әллә фәрештәнең үзе идеме икән? Юк-юк, Аллаһы сакласын, бу кыз ана беркеме дә түгел! Аларнын яшь аермасы да егерме биш еллап түгелме сон, артыгы булмаса? Берен — бабай, икенчен — бала. Йа Ходай, бусы тагын нинди сынау, нинди бәла?

Фәхри Хисами юкны бар итеп уйламаска тырышты. Дөрес, Кәримәнең ул затлы фәрештә булуында ялгыша алмый. Анын кебек гөнаһсыз чибәр шагыйрә кызга кемнең дә кулы күтәрелә алмас, андый кешенен сакчысы Ходай үзе!

Шушы уйлары белән Фәхри Хисаминың күнеле утырды. Анын озынаеп төшкән юка, ябык йөзенә алсулык йөгерде. Хәтта юк кына уйлары да үзен оялтырга житә калдылар. Әмма бу оят хисе һәм оялу тойгысы ана нинди дер серле рәхәтлек алып килде. Әле генә ешланып тибә башлаган йөрәге басылды, сулышы тынычлык алды. Күнеленә олылык белән мәртәбә тойгылары килде. Бая гына тәрәзәдән карап тора иде. Үзе кебек саргая барган ак каен ана бүген дә елмаеп күз кыскандай тоелды. Апасынын фатиры икмәк заводыннан ерак түгел, исемсез тыкрыкта булып, йортларынын янәшәсендә генә якты дөньяга кыяр-кыймас сузылып ак каен үсә. Кәүсәләре зәгыйфь, нечкә. Әле кичә генә яфраклары яшел иде, бүген инде аларнын сарылыгы гаҗәеп бер серле матурлык сыман күзаллана.

Көз көннәрен Фәхри Хисами яратмый. Ә шагыйрьләр киресенчә булырга тиешләр түгелме соң? Бәлки анын чынлыкта үзен шагыйрь дип атарга да хакы юктыр? Ил һәм халыклар атасына: «Мин — халкымнын талантлы һәм танылган шагыйре!» — дип үзе турында беллереп, азмы үтенеч хатларын язган беркатлы юләр кеше! Әгәр дә бу сүзләре хакыйкать булса, Сталин кебек бөек кеше ана җавап бирми калмас иде. Юк, ул сүзләре хатадан икән шул. Аһ, явыз син, дөньялык! Дан һәм хөрмәт белән алдыйсын да адәм баласын, һаман ышандырып йөртәсең-йөртәсен дә, бәла чокырына баштүбән төртеп төшерәсен. Фәхри Хисами да нәкъ шушы кылдай нечкә, кылычтан үткер сират күпере аша узды. Әмма җәннәткә түгел, ут эченә барып төште. Теге дөньяныкына түгел дә түгелен, әмма бу дөнья тәмугына! Болай да була икән шул ул!

Язу өстәлендә ачык калдырылган дәфтәрдә кыз баланын матур кулы белән пөхтә итеп: «Ак каеннын сары яфраккае йөрәгем күк лепе-лепе килә...» — дигән шигъри юллар язылган иде. Фәхри Хисамины алар бик тә гаҗәпләндерде. Башка шагыйрьләр моны әлбәттә: «Йөрәккәем сызлый, каен яфрагыдай бәргәләнә дөнья жиленнән», — дип, әүвәле үзләрен, үзләренен эчке кичерешләренә бәя биреп язар иделәр. Ә Кәримәнең күнеле андый түгел. Ул башкаларны алга чыгара, аларнын хәсрәтләрен үзенеке итеп бирә белә! Менә кайда бөеклек!

Шушы укыганнары һәм уйлары, бәяләмәләре белән бәйле Фәхри Хисами Тукайны, Такташны, үзенен язмаларын хәтере аша уздырды. Кәримә кебек

фикерләгән һәм дөньяның серләрен анлый, күрә, бәяли алган башка бер генә каләм иясе юк икәнлеген анлады. Барысы да алга минне чыгара һәм үзләрен лирик герой итәләр икән бит. Ә менә ничек итеп язарга кирәк: «Нигә шулай борчу тулы булдың, йөрәгемә салдың серләрен?..»

Кәримәнең бу шигыре «Әнкәй» дип атала иде. Фәхри Хисами тагын да уйларга бирелергә, катлаулы балачак тормышларын, газиз әнкәсенең авыр гаилә йөген ялгызы тартып барган, бәхетнең нәрсә икәнлеген дә күрми иртәннән кичкә кадәр барча көннәрен эш белән уздырган чакларын исенә төшерде. Кеше бу җир йөзендә бер генә дә сөенмичә, бары гажизләнеп һәм интегеп кенә яши икән шул. Анда да әле урыс побы килеп, өсләренә карачкы кебек ябырылып: «Сез — керәшеннәр, чукынган православный, чиркәүгә йөрегез, юкса острог булыр урыныгыз!» — дип куркытулары, әнисенең моңа елаулары, апа-энеләренең, куркышып, сәке астына посулары: «Мин керәшен түгел, мөселман!» — диярәк Фәхринең дә поп итәге астында чәбәләнүләре: «Что с этим Федором-Федотом?» — дигән сүзләреннән коты очулары — барысы-барысы да бүгенге көндә генә булган хәлләрдәй хәтерендә иде. Аның әнкәсе төннәрен ай яктысында намаз укый-укый елый иде бит. Фәхри дә, аңа ияреп, бала чагыннан намазга басты. «Динебезне, мөселманлыкны ташламагыз!» — дигән сүзләрне бәгыренә чокып язган иде. Авыр Урал шахталарында да намазын-уразасын калдырмады. Ә Совет кергәч, Бишбалтада татар мәктәбендә әдәбият укыта башлагач, әнкәсенең бу васыяте дә, нәсыйхәт итеп әйткән сүзләре дә, гореф-гадәтне тоту да әкренләп, үз жайлары белән онытылдылар. Ул боларны Сталин төрмәсендә үк исенә төшереп аһ иткән иде. Әмма өзелгән җепне ялгап җибәрә алмады. Шуның белән бергә тоткынга эләккән кешеләр һәммәсе дә диярлек ата большевиклар булып, дин һәм чиркәүгә, алар тирәсендәге кешеләргә карата кискен тәнкыйтьтә торалар иде. Бу хәл Фәхри Хисамига тәэсир итми калмадылар.

Кәримәнең шигырьләрен укыган саен Фәхри Хисами әле хатирәләргә, әле фәлсәфәгә бирелде.

Бишбалта мәктәбендә әдәбият укытуы тормышын көйләү, гаилә кору өчен төп нигез иде. Инде дә иҗат белән шөгыльләнүне алга чыгарып, Язучылар союзына эшкә күчеп, гомерендә беренче тапкыр иркен сулыш аламын дигәндә генә аны төнлә килеп алып киттеләр.

Фатирлары олы капкалы йортта иде. Фәхринең эш бүлмәсе, йокы урыны шул капкага карап торган тәрәзә артында булып, ул кич буена иҗат итеп утырды. Утны сүндереп, инде ятамын дигәндә күнеленә бетмәс-төкәнмәс кебек тоелган уй төшеп, кузгала алмыйча калган иде. Күктә тулган ай тантана итә. Урамда көндез салкын яңгыр яуган, ә хәзер аязган, суыткан. Капка шыгырдап ачылды. Аның йөрәге жу итеп куйды. Күн курткадан йөрергә яраткан Такташ кай вакытларны шулай сонарып килеп керә иде. Инде вафатына сигез ел. Нәрсә, исән микәнни?

Шунда ай яктысында икенче кешенең кулында көпшәле кара тимернең ялтырап алуын күрде. Фуражкасын да, погонлы булуын да күзләреннән төн карасы яшерә алмады. Ул да түгел, ишекне кактылар. Фатир хуҗасы үз ягында йоклый иде: «Кем бар анда?» — дип, гөбе төбеннән чыккан ачулы тавыш белән эндәште. Ишек артындагылар кичекми ачуын таләп иттеләр. Эчке келәнең күтәрелгәне дә ишетелмәде. Шалтырап кую аның гадәтендә иде, югыйсә. Фатир хуҗасының аһ орып авып калуы, ишектән фонарь яктысына каршы сержантның күренүе, кичекмәстән лампа уты кабыну, Фәхри хатынының куркынган йөз белән ак жәймә эчендә күтәрелүе һәм тагын да башка төрле тормыш картиналары күз алдында буталып алды. Мәсьәлә ачык иде: Фәхри Хисамины алырга НКВД килгән!

Бәреп кергән кешеләр үзләренен кем икәнлекләрен әйтеп тормадылар. Житди һәм әрсез кыяфәтле бу кешеләрнең асыл ниятләрен аңлавы авыр түгел иде. Ярты сәгать эчендә башы өскә килгән бүлмә, хәйранлыкта калган хатыны, ансыз хәлгә диярлек житкерелгән фатир хужасы — болар ул чор өчен хас күренешләрдән булып, шагыйрь йөрәгендә мәңге янарып торачак сурәттә уелып калдылар. Фәхри Хисами үзен бик тә тыныч тотты, алып чыгып киткәннәрендә дә:

— Борчылма, хатыным-жаным, минем бер гаебем дә юк! Тиз кайтырмын! — диде.

Озата баручы сержант бер сүз дә әйтмәде, этkәләмәде, төрткәләмәде. Күн киемлесе генә:

— Сохарилар да киптереп куйгансың, ә үзең гаебем юк, дисең! Менә бит ничек! — диде.

Фәхри Хисаминың кулында чыннан да ак яулыкка төрелгән алты телем сохари иде. Бу аларны халыктан килгән гадәт буенча, кара көнгә дип, һаман да китап шүрлегендә тота иде. Аны Фәхри Хисами үзе үрелеп алды. Сержант ачып карады. Рөхсәт иттеләр. Шул сохарилар аны төрмәдә өч көн ач тотканнарында ярап куйды. Ул бела иде: Казанда нинди зыялы адәм бар, һәммәсе дә капчыклап сохари киптереп әзерләп тота. Алай-болай алып китә калсалар, анда аларны кем кайгыртсын? Күпләр китте бит инде. Әмма Фәхри Хисами үзен алуларын көтмәде һәм моны мөмкин хәл дип башына да китермәде. Бу вакытта ил буйлап зыялыларны юк итү эше баруын аның акылы да, күнеле дә кабул итмәде. Ана моның олы бер сәясәт булуын төрмәдә һәм сөргендә кат-кат аңлаттылар. Әмма болар да Сталинга һәм булачак коммунизмга ышануларын сүндерә алмады. Ул мәхәббәте кире кагылган Мәҗнүн хәлендә иде.

Фәхри Хисамины, әллә нинди сораулар биреп, тикшерүчеләр җәзалап аптыратып тормадылар. Басылган һәм язган шигырьләренә «милләтче һәм чит ил буржуазиясе тегерменәнә су коючы», «татар хөкүмәте калдыкларының ялчысы» дигән исем тактылар да, хәрби трибуналның хөкемен игълан итеп, әүвәле төрмә, аннары «вечное поселение»гә сөрделәр. Фатирдан алып чыгып киткән төндә аны атлы арба артыннан ияргән хәлендә китерделәр. Урамда көз иде, салкын иде. Сержант белән күн тужуркалы адәм арбада бардылар. Фәхри Хисамига гүяки: «Син, булдыра алсаң, кач!» — дигән сыман, битараф иделәр. Ул батырлыкны шагыйрь башкара алмады. Берәр урам тыкрыгына агачлар арасына, һич югы күпердән Казан-суга ташланырга мөмкин иде. Ул боларның берсен дә эшләмәде. Хәтта уена да кертеп карамады. «Гаебем юк, чыгарырлар. Бу бары тик зур хата гына. Юри сынаулары! — диде аның күнеле. — Мин — коммунист, Сталинга һәм партиягә гашыйк!» Ул хәтта хөкемгә китерелгәнендә дә: «Менә гафу үтенерләр дә чыгарырлар!» — дигән ышаныч белән атлады. Әгәр дә кем өстеннәндер нилэр сөйләгәнен сораштырып, хәбәр итүләрен таләп итсәләр, язып бирергә кушсалар, ул барысын да бәйнә-бәйнә башкарып чыгар иде, югыйсә. Әмма бер генә дә кызыксынып маташучы табылмады. Аның фикерләре дә, сүзләре дә һичкемгә әһәмиятле түгел иде. Тикшерену органнарының, хөкемчеләрнең аңа карата битарафлыгы күнелен хәйранга калдырды. Фәхри Хисами бу хәлләрдән тәмам аптырашта иде. Ул хакта бүген дә бер фикергә килә алмый. Аны хәтта мыскыллый да иде бу хәл. Житмәсә үзенең беркатлылыгы акылын хәйран итә. Мөгаен язмыш аны тагын да олырак бәладән коткарган булгандыр — монысын инде сөргендә чагында ачык төшенде. Шушы акылы ачылу күнелен тынычландырды. Ана оят, бик тә оят булды. Әле хәзер дә ул шушы кара вакыйгалардагы беркатлылыгы өчен күнеле тулы авыр хисләрне йөртә.

## VI

«Матбугат йорты» дип аталган газета-журналлар, китаплар, журналист-язучылар, шагыйрьләр, хәтта артистлар оясы да шушында — Казанның иң заманча дип саналган бинасы эчендә иде. Зур тәрәзәләре гүяки көннең яктылыгын йотып алып бетерергә теләп шулай дөньяга әрсез итеп карыйлар. Аны төзегән чакларны Фәхри Хисами хәтерли әле — татар китабы, татар мәдәнияте, әдәбияты үсешенә зур өметләр уятты ул. Ә менә хәзер ничектер уңайсызлык, авырлык тоясың аңардан. Сагыш, гамь эченә чумган, гүяки гасырлар эчендә адашып калган. Әллә завод-фабриканымы, әллә югары уку йортынмы, әллә нәрсәне хәтерләткән бина бу. Казанның көяз диварлы өйләре арасына кысылып басып тора, шөкәтсез генә дә түгел, йөзе чытык, үпкәчел, караңгы чырайлы кортка кебек ятсыну хисләре тудыра күңелләрдә.

Фәхри Хисаминың, кайтканнан соң, монда икенче тапкыр килүе иде. Әүвәлгесендә, ишек янына җиткәч, ике яшь кешенең: «Кайта башладылар инде империализм ялчылары», — дип сөйләнеп чыгып килүләрен ишетеп, җитмәсә берсенең: «Болай да тар матбугатыбызга, әсәрләрен китереп ташлап, авыр йөк булып төшәчәкләр әле, күрерсең!» — дип, кистереп, ачу белән әйтүләрен дә, башка сүзләрне дә ишеткәч, бу юлы да борылып чыгып киткән иде. Иске ярага яңасы өстәлде. Куен кесәсендә икегә бөкләп тыгылган шигъри сәхифәләре ничә көннәр шул килеш, кузгатылмыйча йөрделәр. Университетта очрашу өчен, анда шигырь укыганда бик кирәк булдылар, анысы. Әмма теге яшьләрнең сүзләре аның яңадан әдәбият мәйданына очып керү нияте белән җәелгән канатларын ике кат кисте. Инде менә бүген кабат килде. Бу юлы ишектә теге кыска буйлы, чатан аяклы, гүяки бер калыптан чыккан кебек кыска бармаклы кулларын җәеп сөйләшүче ике адәмне очратмавы гына аңа бераз күңел тынычлыгы өстәде. Тик алардан ишетеп калган сүзләр генә, беренчесен икенчесе уза-уза исенә төшеп, һаман да теңкәсен кортып тора. Шунлыктан адымнарында сүлпәнлек һәм йомшаклык тагын да артты. Ул бүген дә шул ук юыла-юыла агарып беткән һәм озак вакытлар киелүдән капчыкка тартым кыяфәткә килгән плащтан, түбе саегаеп киткән, ярым җимерек йортны хәтерләткән тар эшләпәдән иде. Баскычтан, югарыга күтәрелеп карамыйча гына, таный күрмәсеннәр, берүк, дигәндәй, сабыр гына күтәрелде. «Татарстан яшьләре» газетасының яки «Азат хатын» журналының кайсы катта, ничәнче бүлмәләрдә урнашканлыгын беләсе килсә дә, кешедән сорамады. Һәрбер ишекне карап чыгарга итте.

Бәхетенә коридорда кеше күренмәде. Бер җыештыручы ханым гына сулы чиләк күтәреп кайсыдыр бүлмәдән чыкты да аңа каршы килә башлады. Ярым карангылыкта кешене тану мөмкин түгел иде сыман. Әмма Фәхригә ханым ничектер якын белеше кебек тоелды. Аяк атлауларындамы, килеш-килбәтендәме танышлык бар? Туктатып сорау унайсыз иде.

Шушы «Матбугат йорты»ның, төзелеп бетүгә, ачылыш тантанасына сөенеп килгән Фәхри Хисами Язучылар союзында эшли башлаган иде инде. Аңа өченче каттан якты һәм җылы бүлмәне бирделәр. Анда кереп утыргач та ул үзенең чиксез бәхетле әдип булуын тойган иде. Аңа беренче ишек шакыган кеше дә хатын-кыз затыннан икәнлеге исендә. Союз председателен эзли иде ул. Шигырьләр язам, ди. Шуларны алып килгән. Күп түгел, ун-унбиш әсәр генә. Аларны Фәхри Хисами, ханымнан сорап алып, әүвәле үзе укып чыкты. Ул тезмәләрдә тормышның авырлыгы, язмышның мәрхәмәтсезлеге хакында бәян ителгән. «Гөлнар ханым булам!» — диде шагыйрә, үзе хакында. Фәхри Хисами аның шигырьләрен тулы җаваплылык тоеп укып чыкты. Алардагы шигырь көчен бик яхшы тойды. Әмма ханымга:

— Бу әсәрләрегез Совет матбугатында басылып чыгарлык түгелләр, рухларында вак буржуаз төсмерләр җәелеп ята, чекрәеп торалар, — дигән сүзләр тезмәсен тезеп салды. Татар матбугаты, яна әдәбият китаплары аңа бу рәвешле сөйли алырлык кына азыкны биреп куйган иде инде. Ул үзен шыгырдап торган тужуркалы гайрәтле комиссар итеп тоя. Шундый большевик турында язарга хыялланып йөргән кеше менә хәзер, ханымның шигырьләре белән танышкач, рухи яктан житлеккән булуын аңлап алды. Үзенең идеологик юнәлештә үсешен дә, шагыйрь аталырлык өстенлеген дә тою аңа рәхәт иде. Ханым канәгатьсез хәлдә чыгып китте.

Ә менә бүген бу җыештыручы хатын шушы вакыйганы аның хәтерендә яңартты. Исеме ничек иде соң әле? Юк, белми. Хәтерләми... Әле генә исендә иде бит! Гөлчирә, Гөлназ?.. Ә әйе, Гөлнар ханым! Татарда ничәмә «Гөлнар туташ» исеме белән йөртелгән шагыйрәләр булгандыр — аларын инде хәзер тарих гыйлеме үзе дә оныткан. Ә менә бу «Гөлнар ханым» башка төрле иде. Бераз вакытлар югалып торды да «Матбугат йорты»нда кабат күренә башлады. Ул инде җыештыручы хәлендә иде. Бервакыт аннан Фәхри Хисами болай дип сорады бит:

— Сез нишләп мәктәптә балалар укытмыйсыз? Килеш-килбәтегез мөгаллимәнеке төсле! — дигән иде, ханым:

— Укучыларның күнелен гарипләүдән куркам, — дип җавап бирде.

Ул вакытта да Фәхри Хисами аның сүзләреннән дөрес фикергә килә белмәгән икән шул. Инде менә уналты еллап вакыт узып киткәч, Сталин «иләге аша вакланып һәм чиләнеп чыкканнан соң», Гөлнар ханымны аңлый да башлады бугай? Илдә яшәп тә, ул илне сөймәгән кешеләр була ала. «Гөлнар ханым»ның шигырьләрен укыштырып алуга ук, Фәхри Хисаминың күңелендә шундый тойгы калдырган иделәр. Ул аларда теге дөнья белән серле бәйләнешләр барлыгын да, Аллаһы Тәгаләгә ышану көченең үлемсез булуын да, серле символика һәм мәгънәләр дә, бәхет һәм сагыш, гамь һәм фәлсәфә берлеген дә күрде. Ханым турында татарның акмеисты, революция-аударылыш заманнарына кадәр үк матбугатта декадент рухлы шигырьләре белән хәтта Дәрдемәнднең үзен шаккаттырган дип сөйли иделәр түгелме? Фәхри Хисами менә бүген генә шушыларны шаклар катып исенә төшерде. Ничек элекләрне бөтенләй дә хәтеренә китерә алмаган? Әллә бу хәтер бары тик картая-картая гына ачыламы?

Бу очравы да юкка гына түгел, ханымнан гафу сорарга тиеш ул. Аңлар, кабул итәр!

Шунда Фәхри Хисами җыештыручы ханым артыннан китте. Монда коридор борыла, яктыга чыга икән, кояш та туры карый.

Әмма Фәхри Хисами ялгышты. Бу хатында «Гөлнар ханым»ның чалымнары юкка чыкты. Теге — чандыр, сылу, гамьле шагыйрә белән бу тупас, эре кыяфәтле, калын иренле һәм дәү борынлы җыештыручы хатын арасында бернинди дә уртаклык була алмый, билгеле.

Соңгы вакытларда үзенең бүселеп китеп уйлану, тормыш хатирәләрен яңарту гадәтеннән арына барырга тиешлеген, унга-сулга китәргә генә торган фикерләрен җыйнап бер ноктага тупларга кирәклеген Фәхри аңлый иде. Әмма нинди олы, озак елларга сузылган каты авырудан соң кешенең ничек акылы-аңы, күңеле-рухы уянып китә, ул да шушындый үзгәрешләрне үзендә хис итә торды.

«Татарстан яшьләре» дип вак кына хәрефләр белән кызыл тактага кысаланган язуга килеп җитеп, Фәхри Хисами ишек какты. Әмма аны ишетмәделәр. Калын, күн сыйфат дерматин белән тышланган олы ишекнең артында бер туташның көлгәне тоньк кына яңгырап алды. Ул хәтта керергә дә дәште бугай?

Монда иркен һәм якты тәрәзәләрдән эчкә нур бөркелә, урамдагы табигать матурлыгына кояш үзе дә шатланадыр сыман тоела. Бер калын гына адәм, шкаф кадәрле олы гәүдәсен бераз алга бөгә төшеп, өстәл артында утырган секретарь кызга нииндидер ягымлы сүзләр әйтеп маташа. Фәхрине шәйләп алып, телендә тагын да бер-ике ялкынлы фраза биетте дә, шигырь сыманрак бөтереп, кайнар итеп укып китте:

— Керәләр вакытсыз, йөриләр тактсыз, тыз да быз, тыз да быз — машина-машина кешеләр, паровоз-паровоз кешеләр...

Бу аның экспромты иде. Фәхри бик яхшы аңлады. Хәтта түргә таба узып, ишек якка төртеп күрсәтүе дә бары тик кереп качар җир таба алмагандай артыгы белән каушавыннан иде.

— Әйе, үзендә! Сезне кем дип әйтик? Нинди йомыш белән идегез? Ярты сәгатьтән обкомга китәселәре бар! — диде кыз, үзенең тугры секретарь икәнлеген сиздереп. Аның өстәле янында ярым биегән карт пеләш «шагыйрь» кисәге:

— Ничек? Сез бит әле генә «үзендә юк» дигән идегез! Мялүшкә! Сез нәрсә? — дип, ризасызлык белдерде. — Мин бит уен белән түгел, эш белән кереп чыгасы идем.

— Аның сезне кабул итәсе килмәсә?

Секретарь кыз бу сүзләрен шундый да җитди итеп әйтеп куйды, Фәхри артка чигенергә мәҗбүр булды. Шушы кояшлы бүлмәдә ул бүген инде икенче кат оятлы. Каядыр барырлыгы да юк. Ник кенә килде, керде?

— Абый, сезгә түгел! Безнең Сабир абыйга ул сүзләр. Баш редактор аларга эш кушты. Шуны язмый торып, күземә күренәсе булмасыннар, диде!

Кызның бу сүзләре калын шкаф Сабир әфәндегә җитә калды. Ул дәү корсагын тагын алга чыгарып, бөеренә таянган килеш әйтергә дә өлгерде:

— Вәт тек яндыгыз, сеңлем Мялүшкә! Яндыгыз! — Күкрәк яны костюм кесәсеннән урталай бөкләнгән кәгазь битләрен чыгарды. — Менә ул, язылып та бетте. Шуны хөкемнәренә алып килгән идем. Ә сез — тоткарладыгыз!

Туташ бер агарынды, бер күгәренде һәм Сабир әфәндене ишектән кертеп тә җибәрде. Аннары гына Фәхри Хисамига:

— Абый, сез мине гафу итегез инде, — дип үтенеп, — бу безнең данлы Сабир Хәсәншиныбыз иде. Соңгы көннәрдә тәмам бозылды. Әллә нинди хәйләләр кора, редакторыбыз белән дә телгә килеп алды, — диярәк аңлатма ясады.

Кызның болай ачылып китүе сөенерлек хәл түгел иде. Күңелендәгесен мең йозак артына яшерергә өйрәнгән халыкның шушы соңгы елларда кинәт сулышы ачылып алудан серләрен сибәргә теләвенең сәбәбе нилектән икәнлеген Фәхри Хисами төшенә, әлбәттә. Әмма аңлаганы саен күңеле шиккә төшә бара.

## VII

«Татарстан яшьләре» газетасында Кәримә Дулатованың өч шигыре берьюлы басылып чыкты. Кирәк дигәч, аларга фатихалы сүз башын Фәхри Хисами язды. Ансын китерә килгәч, баш редактор:

— Үзегезнең шигырьләрне дә бастырырга иде. Университет сезне бик җылы кабул иткән. Ике атна буена бары тик шул хакта гына сүз йөрде. Котәбез. Яшьләр газетасына яшьләрчә шигырьләр җитми, — дип, шундый җылы итеп сөйләде, аңа ышанмыйча мөмкин дә түгел иде.

— Минем яшьлек узган инде, — диде Фәхри Хисами, аңа җавап бирергә ашыгып. — Хәзер шигырь турында түгел, тормыш, ничек яшәү турында борчылырга кала.

— Әйе шул! — диде редактор, онытылып китеп, янында фикердәше утыргандай үзен хис итеп. — Әллә ничек кенә, барысы да кинәт кенә жимерелде дә төште. Көтелмәгән үлем...

Әмма ул шунда ук үзен кулга алды. Сүзе Сталин хакында икәнлеген чак кына әйтеп ташламавына шаккатты. Әле кем алдында бит — Фәхри Хисами кебек жан көеге, «халык дошманы» дигән адәм актыгы каршында күңелен ача язды. Хәерсез!

Редактор комач кебек кызарып утыра иде. Өстәл артыннан чыгып, тәрәзә форточкасын барып ачты. Карыш буйлы бу адәм моннан унбиш ел элек «Матбугат йорты»на комендант булып эшкә кергән иде. Фәхри абыйсы янына сугылгалап, чәй эчеп йөргәләп, һәммә юкны-барны сөйләп аптыратучылардан иде. Танымас кебек тоелса да, алай кыланып маташмады. Беренче көнне үк:

— О Фәхри агай! Күптән көтә идек. Әмма ашыгам. Анда Миләүшә әйткәндер, обкомга барып житәсе! «Совещание»! — дип, әмма кулындагы шигырьләрне алып калып: — Бер-ике авыз сүз кирәк булыр. Иртәгә килеп, туры үземә керерсез. «Икегә» көтәм, сәгать икегә! Килештекме? Бик яхшы! Миләүшәгә әйтеп куярмын! — диде дә, сөреп чыгаргандай ашыктырган иде.

Ярый әле бүген Фәхри көндезге сәгать бердән үк монда. Редакторның «икегә» тагын да «совещание»се икән. Миләүшә әйтеп куйды. Ул да түгел, редактор да төшке аштан кайтып житте. Әмма кыяфәтен ясалма үзгәртеп өлгерде. Күреште. Кабинетына керергә тәкъдим итте.

Бик тә үлчәп сөйләшкән кеше белән әллә ни озын әңгәмә корып булмый. Әмма Фәхри яшь шагыйрә хакына түзәргә булды.

— Сер итеп кенә сорасам, нәрсә әйтерсез икән? — диде шунда редактор, Фәхригә карап-карап куеп.

Редакторның уенда нәрсә икәнлеген белүе авыр иде. Мөгаен аны бу шигырьләрнең авторы кызыксындырадыр?

— Ничегрәк анда? Авыр булмадымы?

Фәхри Хисами аның тел төбен шунда ук аңлап алды һәм алдан әзерләп куйган жавабын да бирде:

— Миңа әллә ни кыен ашатмадылар. Монда да жиңел булмаган. Сугыш. Кырылыш. Фашизмның дәһшәтенә түзеп кара! Көн дә фронтка, кайнар ут авызына жибәрүләрен сорадым!

Алар күзгә-күз карашкан хәлләрендә бераз сүзсез утырдылар. Кечкенә башлы редакторның күзләре дә чепи иде. Әмма елгырлар. Сиземлеләр. Мондый кешеләр, асылда, күз белән ишетә, күз белән сөйли. Азмы бәндәләрнең бәхет юлын аркылыга кискәндер?

Әгәр дә кемдер хакында кирле-мырлы уйлап, аның каршында начар фикер йөртеп утырсаң, мондый әңгәмәнең ахыры бер дә яхшыга бетмәячәк. Тел чишелеп китүчән бит ул. Юктан гына уйларыңны ачып ташлавың бар. Кешеләр хакында яхшы уйларга, кешеләрне мактый белергә кабат өйрәнергә кирәк Фәхригә. Әмма вакыт жилдереп бара тора. Моны «реабилитация чоры» дип атыйлармы әле?

Фәхри Хисами ничек тә яхшы уйларга бирелергә теләде. Кәримәне исенә төшерде. Шунда йөрәге жу итеп куйды. Аһ, Кәримәне ярата икән бит ул! Бу нинди диваналык тагын?

Әгәр дә кешеләрне хөрмәт итәргә, аларга сокланырга күңелеңне кабат өйрәтмәсәң, авыр, бик тә авыр булачак яшәүләре. Жәмгыятьтә башкача була да алмый. Үзара көнчелек белән януучылар әйләнә-тирәңне урап алсалар, сиңа тормышның мәгънәсе калырмы соң? Юк, билгеле. Андый коллективта үзеңнен дә эшлисең килмәс. Бары тик мәхәббәт кенә кешенең хисләрендә

тотрыклылык уята ала, бары тик мәхәббәт кенә кешедән чын кеше ясый. Фәхригә бу хакта Кәримәнең күзләре сөйләмәделәрме? Тормышка янадан, кабат кайтыйм дисә, аңа газапка салучыларының һәммәсен дә гафу итәргә кирәк, шуңа, ярлыкауга өйрәнергә! Әгәр дә тормышның каршылыклы җилләре кемне дә булса какмыйча, екмыйча, тимичә калдырган, җитмәсә аны, күтәреп алып, югарыга, үзе дә уйламаган тау сыртындагы тәхеткә илтеп утырткан икән, мондый язмышка насыйп ителүе өчен һич үпкәләргә ярамый. Бәлки ул борынгы берәр әүлиянең нәсел баласыдыр, бәлки аның буыныннан киләчәктә берәр игелекле бала туачактыр?

Менә бүген дә күнелендә Фәхри изге хисләрен кузгатырга теләп уянган иде. Кәримәнең сабыйларча беркатлы, табигый агымдагы ягымлы шигырьләрен искә төшерүдән көне башланып китте. Ул кызга күнеле якын икәнлеген дә исенә төшерде. Инде редактор әфәнде белән күрешсә, Кәримәнең шигырьләре хакында фикерен ишетсә, аңа шушылар бик тә җиткән. Тик ул буш түгел, «совещание»сенә ашыга, Фәхринең аны тоткарларга хакы юк.

— Без барыбыз да ул яшьтә мондый шигырьләр яза идек инде... Үзегез дә бик яхшы беләсез...

Редакторның сүзләрне нәрсәгә болай тәмамлавын Фәхри аңлый алмады. Тәне буйлап әрнү хисе йөгереп узды. Кинәт, көтмәгәндә бәгыренә китереп типтеләрмени, сүзне зат белеп төгәлли алмас, уендагысын әйтмәс хәлгә төште.

## ДҮРТЕНЧЕ БҮЛЕК

### I

Кәримә бер ел эчендә бөтенләй дә әллә кемгә әверелде. Ул хәзер иң талантлы, иң өметле, татар әдәбиятының бөек киләчәге саналган шагыйрә иде. Язган әсәрләре һәркайда зур теләк белән басыла, алар хакында матур-матур мактау сүзләре әйтелә. Ә Фәхри Хисами абыйсы аңа үлеп гашыйк. Кәримә моңа да чиксез куана, мәңге шулай буласын белә. Әгәр берәр шигыре газета яки журналда басылмый калса, яисә көттереп газапласа, хәзер Фәхри Хисамига җиткерә һәм ул, кара кайгыга батып, барча эшен ташлап йөгерергә генә тора. Хатын-кыз халкы шундый инде ул, аңа аерым зур игътибар бирсәң, сине үзенең колы ясарга гына тора. Әгәр дә яратканыңны сизенсә, яки яратам дип ышандырсаң, синең алда үзен бөтенләй дә әллә кемгә куя башлый. Әмма чын хатын-кыз андый булмый, диләр. Ялган хатыннар ир-егетләргә карата шундыйлар, имеш, ә дөресләренең күнеле тормыш иптәшенә хөрмәт белән тулы...

Кәримә исә кемгә дә охшамаган, үзенең яшьлеге аркасындамы, әллә шагыйрә булуыннанмы — үзен чын белән ялган арасында кебек тойды. Әмма кыз шуны да төшенеп өлгерде: кайбер кешеләрдә йөрәк мескенлеге гомер буена була, андыйларны тормыш, дөнья әллә ничекләр сынап, ныклы итәргә теләп, чүкеп-яндырып та карый. Ә алар һаман да элекке хәлендә кала. Андыйлар яисә әүлиягә әверелә, яки диваналыкка чыга. Фәхри Хисами нәкъ менә шундый кеше, хәлсез, бичара һәм бер ел эчендә Кәримәнең уенчыгына әверелде дә куйды түгелме? Ул әлегә Кәримәнең елдан-ел көч аласын белми, күз алдына китерми, һаман да аны шушындый булыр дип күзаллый. Аңа ышана. И юләр карт! Ә Кәримә аның мескенлегеннән файдаланачак әле! Әгәр дә бер ел элек кыз үзенең мондый буласын белсә, борчу-хәсрәт эчендә ничәмә шигырь язар идеме соң?

Хәер, бу соңгы елда Хәнифә ханымның Газизчигенә «күз тиде». Көтелмәгән хәл буларак кабул ителеп, йорт эче сулышын югалтты. Аның Кәримә белән кызыксынуы кышкы бозларны күтәреп ташып чыккан язгы сулар кебек әрсезләнә барды.

Беркөнне кызлар гадәтләренчә дәрес әзерләп утыра иде, яннарына Газизчик (гомер булмаган хәл) килеп керде һәм өстәлгә яшьләр газетасын җәеп салды да:

— Бу сезме? — дип сорады.

Кәримә кып-кызыл булды. Киреләнеп: «Бу мин түгел, минем шигырьләрем генә!» — димәкче иде, сүзләре дорфа килеп чыгасын уйлап алды. Шунда дөньясы үзгәрде, күңеле булып елмая алды.

Дәү һәм күркәм егет Газизчиккә кыенлык кичерү өчен шушы да җитә калды. Ул үзенең ак һәм озынсыман тоелган кулларын кая куярга белмәде. Баскан урынын онытты. Җитмәсә Кәримә аңа үтәли карап тора иде.

— Укыдык инде без аны! — диде Сабира, шунда газетадан карашын Газизчик ягына юнәлтеп.

Ике яклап кисешкән ут эчендә калгандай егет артка чигенергә мәҗбүр булды.

— Менә ошады, — диде ул, маңгаена чыккан тирләрен кесәсеннән алган кулъяулыгына сеңдерергә тырышып. — Шагыйрә белән яшибез икән бит без!

Ул әллә көлә, әллә куана иде. Кызлар, аны бервакытта да мондый билгесез һәм бәя биргесез хәлдә күргәннәре булмаганга, бераз аптырабрак калдылар. Сабира да, Кәримә дә әүвәле аңарда мыскыллау төсмерләрен сизенделәр, аннары кыяфәтенә балаларча эчке куану билгеләре чыкканын да тойдылар. Ә бераздан бөтенләй дә аптырашта калдылар. Газизчик абыйлары аларга сәерләнгән сыман тоелды. Егетнең гыйшык утына төшкәнлеген, шунлыктан акылын җуйганлыгын, тәҗрибәләре булса аңлар иделәр. Әмма моңа кадәр үзләре генә мәхәббәтне белеп, башкаларга да яратырга мөмкин икәнлекне уйламадылар булса кирәк. Алар өчен гашыйк егетләр бары тик романнарда гына! Ә тормышта бу мөмкин түгел. Әнә Кәримә мәхәббәтендә саташып шигырьләр яза. Кемне сөйгәнен дә белми бугай? Сабира аннан:

— Бу шигырьләрең дә аның турындамы? — дип сорый.

— Әйе, — ди Кәримә, — аның турында!

Сүзләрнең кем хакында барганлыгын кызлар үзләре бик яхшы беләләр дә кебек. Кәримә Сабираның, әнә шул әллә нинди Фатыйх хакында сөйләп, колак итен быелтыр ел буена ашады. Аһ итте дә шигырь язды, ваһ итте дә җыр чыгарды. Кәримәнең көтмәгәндә мыштым гына көйләп алу гадәте берара вакыт Сабирага да күчеп, чак кына гадәтенә әверелеп куймады. Авылга кайткач, шулай онытылып җыр сузганнарын бер, ике, өч тыңлады да, әнисе канәгатьсезлек итте:

— Бу нинди диваналык икән тагын? Укыган кешенең акылы авыша ди торган иделәр. Кызым, зиһененә зыян килмәгәндер бит? — диде. Сабирага оят булып китте. Тора салып, юктан да җырлау гадәтеннән ваз кичү өчен аңа тырышырга, үзен кулда тотарга өйрәнергә туры килде.

Ә Кәримәнең җырлауларына әти-әнисе бер дә аптырамый, бу гамәлендә зиһен буталуны да, диваналыкны да күрмиләр. Нигә бу дөньяда кешеләр үзара тигез түгел? Кайдадыр ерактагы, Сарман районы дип аталган Ләшәү авылында авыз тутырып җырларга, күңеленне сагышка-моңга салырга ярый, ә менә Арчада моны юләрлеккә саныйлар? Ул Сарман ягын җырлы як диләр шул, ә Арчаның, әнә Тукай дөрес яза, тавыклары гына җырлый.

Бүлмә ишеге кабат ачылып, инде күптән чыгып киткән Газизчик абыйлары тагын да күренде. Аның кулында бу юлы газета түгел иде.

— Кызлар, мин бүген кичке сеанска киного билетлар алган идем, кайсыгыз белән барырмын икән? — диде ул, әле Кәримәгә, әле Сабирага

карап. Моңа кадәр Газизчик абыйлары аларның икесен дә үзе белән ала торган иде. Бүген башкача. Әмма кызлар икесе дә бу юлы чаялык күрсәттеләр:

— Мин барам, абый, мин! Мин! — дип, хәтта балалар кебек кулларын да югары күтәрделәр.

II

— Сез Казан шәһәрен яратасызмы?

Газизчик абыйсыннан мондый сорауны ишеткәч, җитмәсә үзенә төбәп әйтелгәч, чая Кәримә тагын да югалыбрак калды. Аннан гүяки: «Сеңлем, сез мине яратасызмы?» — дип сораган кебек булды, ахрысы? Соңгы вакытларда әллә ничек килеп чыга тора шунда. Әле Фәхри абыйсы аны, кулыннан тотып, тәмам каушаткан иде. Инде менә Газизчик абыйсы әллә нинди сәер һәм ят күз белән карый, гүяки нидер әйтергә тели. Ярый ла янәшәсендә Сабира барса? Аның артына, әнисенең итәк янына качкан бала сыман, күмелеп сыенырга мөмкин булыр иде. Һай ул күңел, әллә кайларга ашкына. Нәрсәгә дип әллә кайларга тартына инде? Бу кадәр хыялый булуын әтисе дә яратмый. Бары тик әбисе генә аңлый торган иде. Инде ул да еракта. Элек, хәтта былтыр гына да Кәримәнең күңеле тулы башка төрле хисләр иде. Ул үзенең шагыйрә булырга тиешлеген, шигырь белән генә яшәүдә рәхәт табуын йөрәгендә саклый торды. Ә хәзер, быел барысы да башкача юнәлеш алды. Газета-журнал тирәсендә дә юлына абый кешеләр аркылы төшәргә, сөю сәгадәтләре турында искәртергә генә ашкыналар. Кәримә аларны аңлый да, аңламый да. Җитмәсә, юри төрттереп:

— Фәхри абыегыз белән борчаклар ничегрәк пешә соң? — дип, һырхылдаган булалар.

Элекләрне Кәримә мондый үртәүләрне аңламый торган иде, хәзер төшенә дә сыман: Фәхри абыйсы белән икесе арасында нииндидер нечкә мөнәсәбәтләр урнашканны сизәләр икән шул алар. Моның сәбәбен Кәримәнең һаман да мәхәббәт турында шигырьләр язуыннан күрер идең дә, Фәхри абыйсы үзе дә кабат яшьлегенә кайткандай булуын ничә кат тәкрарлаганы бар. Әүвәле аның хисләре аңлашылып җитми кебек иде. Әмма Кәримә сизенә, бөек шагыйрь Фәхри Хисами аңа гашыйк. Араларында яшь аермасы зур булуга карамастан шушы хәл. Бәлки моның сәбәбе шагыйрь абыйсының балалары булмаудандыр? Әгәр дә Кәримә кебек кызы үссә, ул андый хисләргә чуммас та иде. Аһ, никадәр мәрхәмәтсез булган Фәхри абыйсына карата тәкъдир, гаиләсен дә харап иткән, үзен дә төрмәләрдә, тоткыннар лагерьларында газаплаган.

— Туташ, нигә сез минем сорауларыма бер дә җавап бирмисез?

Газизчик абыйсының барлыгын, үзе белән сөйләшеп атлавын, Сабираның, сын күрсәтергә теләгәндәй, берничә адым алгарак китеп, энәдән-җептән киенгән хәлдә, энҗе бөртекләрен тезгәндәй сак та, күркәм дә уч төбендә генә йөрүләрен онытып җибәргән Кәримә бераз оялгандай итте. Ни әйтергә дә белмәде. Кешенең күңеле күкләрдә йөзсә, җиргә тиз генә әйләнеп кайта алмый диган сүз шушы хәл түгел идеме? Кәримә тагын да кызарды-алсуланды, җавап бирергә ул Газизчик абыйсының нәрсә хакында сөйләгәнен хәтеренә китерә алмады. Кабатлап сораса, зиһене хакында нәрсә уйларлар?

Шулай да сүз тапкандай булды һәм:

— Әйе, — дип җавап бирде.

— Нәрсә турында әйтәсез?

Кәримә Газизчик абыйсының бу соравына да җавап бирә алмый иде.

Хәзер инде «әйе» дип кенә котылу да мөмкин түгел. Бары тик тыныч кына, уйлангандай атлавы мең тапкырлар дөресрәктер кебек.

— Кәримә туташ, сез үзегезне эредән тотасыз. Бу хәл бик тә күнелсез. Яныгызда барган кеше өчен бигрәк тә!

Газизчик абыйсының болай ук дип әйтерен көтмәгән кызның йөрәге аһ итте. Мона кадәр үзен һаман да балаларча тотуы азмы аны борчый иде. Бигрәк тә Сабира, җанына тиеп:

— Синең әле үсәсен дә үсәсен бар! — диярәк азмы әйтте.

Әйе, ана җинел, йөрәге дә күбәләк канатлары кебек күтәреп алып китүче шигъри хисләргә бирелми, акылын да төрле юк-барлар белән тутырмый. Кәримәнен генә җаны әрнүчән. Ул һәммә нәрсә өчен хафага төшә. Сабирадан берүк кенә: «Ни өчен безнен гадел партиябез Сталин кебек вәхшиләргә юл бирде икән? Нигә аларны вакытында хөкемгә тарта белмәде?» — дип сорап кара әле син, хәзер ул кара көеп чыга, бөтенләй дә сөйләшмәс була. Элгәрерәк вакытта Кәримә аны монын өчен ачулана, хәтта канына тоз да сала торган иде. Ә хәзер алай итәргә курка. Кайвакытта Сабира ана шымчылык өчен махсус тагылып куелган кешедер сыман тоела башлый. Анын Кәримә язган шигырьләрне һәрдаим укып баруы да, кульязмаларыннан алдан ук күп нәрсәләрне белеп торуы да әүвәле рәхәтлек бирә иде. Әмма соңгы вакытларда хәл башка якка үзгәреш алды. Сабира беркөнне:

— Партиябезгә тел тидерәсе булма, Кәримә! Төрмәдә черетерләр! — диде, шуннан бирле араларына суыклык йөгерде. Инде менә хәзер дә Сабира анын белән янәшә атлап барырга теләми, юри алдан китте. Бәлки үзенең сылу буе белән Газизчик абыйсын кызыктырасы киләдер? Белмәссен, анын да күнеле бар бит! Ул үзе чәчәк кебек шул!

Сабира, Лобачевский урамыннан борылып, алдан сөйләшенгәнчә, Киров бакчасына барырга юлны сайлады. Анда көндезләрен дә халык күп йөри. Кичләрен Сабира белән Кәримә шул бакчага, истирәхәт кылып, һава алыштырып керергә чыгалар. Газиз абыйлары ял көннәрендә аларга ияргәли. Гадәттә ул читтә, үз уйларына бирелеп йөрүчән.

Вакыты-вакыты белән шушы бакчаның Фукс йортына каршы почмагында җинел товар сатучыларның базарлары оеша. Газизчик абыйлары, анда төркемнәр җыелуны күреп алуга, тизрәк араларына кереп катнаша. Әле берәр яхшы, күптән эзләгән китабына юлыга, сатулашып, аны, зур бәяләр биреп, үзенеке итә, әле яхшы каләм яки кара савыты ишеләргә кызыгып, аларны ала, шулар хакында соңыннан Кәримәләргә озаклап берәр кыйсса сөйли. Анын белмәгәне юк.

Хуҗабикәләре Хәнифә Галиевнанын тәрбиясендә үскән бөртек улы булса да, Газиз абыйлары бер дә анарга охшамаган: кешелекле дә, юаш күнелле дә. Хәтта кул бармакларына кадәр сөякчел һәм озыннар. Ана берәр скрипкәче булырга кирәк иде дә бит. Хәнифә Галиевна әйтә:

— Агач кылын тибрәтеп йөреп, кем дә була алмас иден, — ди. — Инженер кешенең анын мәртәбәсе дә зур, дәрәҗәсе дә олы, эше дә акчалы.

Скрипкәче дигәннән, Газизчик абыйлары әлегәчә бүлмәсенен диварында түрдә, ишегенә каршы якта эленеп торган шул серле уен коралына бармак белән дә чиртеп караганы юк. Ике ел эчендә Кәримәнен күзенә шул скрипкә дигәннәре ничә тапкыр чалынды, хәтта күнеленә: «Нишләп анда эленеп тора икән?» — дигән сорау да килгәләп алган иде. Әмма кызыксынуын канәгатьләндерерлек җавапны таба алганы юк. Хуҗаларыннан сорар иде дә, әллә ничек, җайсыз.

— Кәримә туташ, сез тагын минем сүзләремне ишетмәдегез!

Газизчик абыйсы бу юлы юри шаяртты. Юк инде, хәзер Кәримә аны

үзе кызык итәргә тиеш. Һаман-һаман юри шаяртырга димәгән, шаклар катарлык булсын әле!

— Ә сез берни дә әйтмәдегез бит! Мин колак куеп килдем! — диде кыз, Газизчикнең йөзен кызартып, җиңелчә көлеп алып.

— Әйе, шулай икән бит, — диде егет, — ә мин әйткәнмен сыман булган иде.

— Нәрсә дип?

— Кәримә туташ, сез миңа бик тә, бик тә ошыйсыз дип!

— Аңламадым.

Кыз чыннан да берни дә аңлый алмады. Газиз абыйсының нәрсә дигән сүзе иде соң бу? Юк, мөмкин түгел!

— Кәримә туташ, мин моны бәлки күптән әйтергә тиеш булганмындыр?.. Мин... Мин... Мин сезне яратам!

— Нәрсә ди ул?

Сабира аларны көтеп торган икән. Газизчик абыйсы Кәримәгә мәхәббәтенең асыл серен ачкан вакытта аның ишетеп торуы, җитмәсә хәйранлыкта сорау бирүе кичке ямьне берьюлы юкка чыгарды. Алар инде өчесе дә аптырашта калган иделәр. Шунда Сабира кисәк кенә борылды да, йөгерә-атлый, ашыгып китеп барды. Аның җилкә башлары калтыранудан, йөзен учлары белән каплап бетергән хәлдә баруыннан елавын аңларга мөмкин иде. Берьюлы ике кешенең эчке йөрәк серләре шушы вакытта ачылу Кәримәгә үзенчә тәэсир итте. Ул кая керергә дә, китеп югалырга да белмәде. Каушады. Ничек белми йөргән? Сабира, әнә бит, Газизчик абыйсын ярата икән! Ә Кәримәнең бу хакта уйлау түгел, башында да килмәгән иде.

— Сабира, сеңлем, сез кая?

Газизнең эндәшүен ул инде хәзер ишетми, ишетсә дә, мыскыллануы аның үзегенә төшкән. Шулай хәтере калыр дип кем уйлаган?

— Сез минем хисләремнең саф, чиста булуын аңларга тиешсез, Кәримә туташ! Җил дә тидермәм! Без бәхетле яшәрбез! Сез шигырьләрегезне язарсыз! Мин заводымда эшләрмен. Урыным, дәрәҗәм — яхшы. Ил каршында хөрмәтем кечкенә түгел. Мин сезне бәхетле итә алам!

Әле кайчан гына кыюсыз, хәтта хатынша тоелган Газиз абыйсының шушылай катгый төстә, хәтта киләчәк бәхетле тормышын да яхшы күзаллап сөйләүләре Кәримәне тәмам хәйран иттеләр. Шушы түгелме аның бәхетле булуына дәлил?

— Сез инде, Кәримә сеңлем, бу Газиз абыем шашкан, юләр сүзләр сөйли дия торгансыздыр? Мәхәббәт, чын йөрәктән булгач, акылны да буйсындыра икән ул, колы ясый. Мин сезне сөюем, сезгә гашыйк булуым белән бәхетле, хәтта мең тапкырлар бәхетлемен! Үзегезне дә, йөзегезне, буй-сыныгызны, шигырьләрегезне дә яратам. Сезгә карата булган изге хисләремне әнкәм дә белә. Мин ул хакта, быел, башка сезне фатирга кертмәбез, акчаны да җитәрлек алып кайтасың, кешедән оят дигәч, әнкәмә яшерми сөйләп биргән идем.

Аның бу сүзләреннән Кәримә уңайсызлык та, авырлык та тоярга тиеш иде. Тәвәккәллекне иярләгән егет, моңа кадәрге булган тынычлык кабырчыгыннан чыгып, инде кыздан җавап таләп итә башлар сыман тоелды. Әмма ул, ничек тиз кайнарланып алса, шулай ук суына да белде. Ә сүзләре барыбер дә Кәримәнең бәгыренә төшәргә, анда мәхәббәт орлыклары булып чәчелергә, озакламый сугарылырга һәм шытып чыгарга тиеш иделәр. Ә бит белә, кызның йөрәгендә егеткә дигән урын буш. Әйе, сөю-сәгадәт турында Кәримә шигырьләр яза, әмма алар кемгәдер гашыйк булуыннан түгел, мәхәббәтне олылавыннан, мәхәббәткә дан җырлавыннан! Хәтта шушы Газиз абыйсы турында да алар! Башкача була алмый. Һәр авазы, һәр сүзе изге хисләр белән сугарылган шигырьләрдән түгелмени? Газиз абыйсы да,

аларны укып, хәтта күнеленә сендереп, инде ничәнче көнен бәхет эчендә яши. Кәриманең холкын-фигылен дә, тирәсендә йөргән кешеләрне дә даими күзәтеп торган. Барысы да яхшы иканлеген белә, бик белә. Сабира кебек тупас та, йомыкый да түгел Кәримә. Хужабикә Хәнифә Галиевнага да мөнәсәбәте искиткеч яхшы, хәтта кайбер кичләрдә алар икәүдән-икәү генә калып сөйләшкәләп утыралар. Газиз эшеннән кайтып кергәндә, аларны шул хәлдә ничәмә тапкырлар күрде. Әнкәсе ана улының мәхәббәте турында бер дә әйтмәдемени? Шушы кадәр дә тел бистәсе, сүздә шомарган, капланмый-батмый торган чәпи ташыдай Хәнифә Галиевна һич тә әйтми-белдерми кала алмас. Газизчигы моңа бер дә шикләнми.

Әллә соң әйтмәгәнме? Менә сиңа, ничек алай була ала? Әнкәсе куркып калганмы, улының үзе башлап сүз әйткәнен көткәнме? Кәриманы яратып бетермәвеме бу? Алай дисәң, серен чишкәч: «Сабирадан өстен яклары күп. Сиңа карармы икән?» — дигән иде бит. Шул сүзләреннән соң, мөмкин булса, бөтен Казан халкын үзенең уч төбендә биетергә әзер йөргән әнисе әллә чыннан да куркып калганмы?

Кәримә исә хәйранлыкка төшкән хәлендә атлый бирде. Алар инде Фукс йорты каршындагы Киров мәйданы бакчасына да килеп керделәр, җир шарын күтәреп торган өч кешеле һәйкәлне дә әйләнеп уздылар. Ә кыз барыбер аңына килә алмады.

— Миңа җавабыгызны бирергә ашыкмагыз. Көтәргә дә ризамын. Аңлыйм, сезгә бер-бер фикергә килергә бәлки авырдыр да?.. Әмма үтенеп сорыйм, хисләремне санга алмыйча, мәхәббәтемне берүкләр кире кага күрмәгез! Миңа бик тә, бик тә авыр булыр. Ашыктырырга хакым юк!

Газизчикның шушы йомшак, һичкемгә күтәрелеп авыр бәрелмәүче, итагать һәм намус иясе, чибәр, пөхтә кешенең хәтта сүзләре дә мең кат алдан уйланып куелып, җебен-җепкә тезеп сөйләүләренә кадәр нинди таш йөрәкләрне дә эретерлек иде. Ә Кәримә? Ә Кәримә, шагыйрә җан, күптән инде күкнең җиденче катына күтәрелеп, аннан ничек җиргә төшәргә белмичә әлбәттә хәйранлыкта! Аның эндәшмичә ияреп кенә барулары моңа җитмеш җиде дәлилнең берсе лә!

— Газиз абый... Газиз абый, мин бит әле бик яшь. Укыйм. Укуымны бетерәсем, кеше буласым бар... Икенче курста гынамын бит әле, унтугызга гына җитәм!

Кәриманең сүзләре Газиз абыйсын тагын да сөендерде. Булсын, унтугыз да тулмасын хәтта, ул аның унтугызын да, егермесен дә көтәр, бары тик яратсын гына! Менә бит күңеле ничек саф, укуы, кеше булуы хакында кайгырта. «Телләреңә гөлләр үссен, Кәримәкәй! Газиз абыең сине салкын кыраулардан саклар, усал җилләрдән ышыклар! Моннан соң тормышта бернинди кайгы-хәсрәт тә күрмәссең!»

Боларны ук Газизчик хәләл теле белән әйтергә ашыкмады. Ул аларны Кәримәгә кулын сораган көнне ант эчеп тезеп сөйләп бирәчәк. Ә бүгенгә — ишеткәннәре дә күп булды. Уйланыр. Фикеренә салыр. Юләр кыз түгел ул Кәримә, ишелеп үсеп килгән урман кебек бәхетенә балта чапмас. Әһ Кәримәкәй, назлы гөлкәй! Нинди чибәр син! Йөргән юлларыңа Газиз абыең ак җәймәләр булып җәелер иде.

### III

Сабира шашынып, еламсырап кайтып кергәндә Хәнифә Галиевна өйдә, ишек төбенә килеп җитеп маташа иде. Кызның хәлен шунда ук аңлап, йөрәгенә ут йөгерде. Әмма сизенүен белдерәсе итмәде. Тормышның нинди салулы чаналарга утыртып адәм баласын йөрткәнен яхшы белгәннән һәм, җитмәсә, Казанның татар хатыны буларак, шунда ук акылын эшкә җикте:

— Абау, кызым, кайттың дамыни? — дип, шундый да матур, рәхәт һәм иркә тавыш белән сорады ки, Сабира чак кына аны үз әнекәе белән бутап, җилкәсенә башын салып, үксеп елап җибәрмәде.

Бу уңышы Хәнифә Галиевнаны икенче тәвәккәл адым ясарга этәрде. Бары тик Газизчигенә генә әйтелә торган затлы сүзләрен беренче тапкыр Сабирага да юллады. Аннары, аның тынычлана баруын күреп, хәтта киемнәрен дә элгечкә куешып:

— Менә хәзер чәй эчәрбез. Үзем генә, ялгызым күңелсезләнеп утыра идем. Шундый да тәмле итеп чәй әзерләдем. Кеше юкта, икәүләп кенә, баллап-майлап алыйк әле, кызым. Тиз генә таба коймагымны да пешереп алабыз хәзер, — дип, Сабираны, «арыдым, күңелем кителде» кебек авыр сүзләренә дә карамыйча, кухня ягына алып чыкты. — Бергә-бергә күңелле була бит ул!

Кыз аның сүзеннән чыга алмады. Хуҗабикәнең, беренчедән, сүзләрне җайга китереп кенә тасма телдә сөйләнүләре, икенчедән, син күр дә мин күр, серләшеп-чөкердәшеп чәй эчәргә үз янына чакыруы — күптән күрелмәгән, могҗизага санарлык хәл иде.

Бары Сабира тынычланып җиткәч кенә, инде коймаклар пешеп, чәйгә утыргач:

— Күренмиләр әле һаман. Минем Газизчигем сезнең белән кинога киткән иде түгелме соң? — дип, юри бутапмы, әллә буталыпмы сорады.

Сабираның авызы бүртеп чыгуы Хәнифә Галиевнаның күзенә тиз чалынды. Гайре табигый берәр хәл булганлыгы, моны кызның әйтәсе килмәве аның күңелен тагын да югартып җибәрде.

— Кәримә белән бакчада йөри калдыlargмы әллә? — диде ул, барысын белеп торган кеше сыман үзен тыныч тотып. — Бигрәк яхшы, аулак өй ясарга җайны Ходай биреп тора бит ул. Кызларым бик яхшылар, Аллага шөкер! Әйдә, коймак суынып китмәсен, житеш, Сабирам, житеш!

— Аны, белгәч, ник сорап торасыз инде, Хәнифә Галиевна?

Сабираның болай дорфа итеп сөйләшү гадәте булгалавын хуҗа ханым яхшы белә иде. Ул шунда ук: «Бу кызны корт чаккан! Араларында нидер булган! Әйтешкәннәр, ахрысы!» — дип уйласа дөрес буласы иде. Әмма Сабираның хөрмәтсезләп әйткән сүзләре аның бәгырен кисеп алгандай итте.

— Кәримә беләнме Газизчик абыең? — дип, ул барыбер дә тыныч күңел белән сорап алырга үзендә сабырлык тапты.

— Әйтмәгез мина шул Кәримә турында, сорамагыз да! — дип Сабираның тагын да дорфарак җавап бирүен ишеткәч һәм аның өстәл янынннан кузгалып китәргә җыенуын да күргәч:

— Мина да ошап бетми ул кара чәч Кәримә! — диде дә куйды.

Кызның йөзенә шунда ук ялтырап кояш чыккандай булды. Хуҗабикәгә сынаулы караш ташлады. Ә Хәнифә Галиевна, Казанның кырык ишегеннән каршылыксыз керә-чыга йөри алган татар хатыны, бер дә сер бирәсе итмәде, үз җаена сөйләнә торды:

— Күбәләк тә күбәләк, ул да күбәләк! Егетләр белән гомерен уздырырга гына тора. Лекцияләренә йөрми бугай әле. «Бишле» билгеләренә генә укуы да күз буяу өчен, әйтелә торган сүзгә генә охшаган!

Болай кирегә сукалау юлы белән ул ике көймәнең койрыгын бер кулга алды. Шунда ук Сабираның күңелен аулады һәм Кәримәнең нишләп йөрүләрен белешергә ният итте.

— Анысы егетләр белән йөрми иде әле ул моңарчы, — диде, теле яхшы сүздә ачылып китә алмыйча Сабира. Шунда ук тагын күңелендәге тигезлекне бозып, авызы еламсык баланыкыдай сытылып китә барып һәм җанындагы ачыны чыгарырга җай эзләп.

— Егетләр белән йөрмәве дә минем катылыктан гына, кызым... Ә менә син — башка, өлгер дә, тырыш та, булган да, уңган да...

Болай мактап куюлары ярады тагын, Сабиранын күңел күге кабат аязланып алды. Хәнифә Галиевна шунда ук телгә осталыгын эшкә җикте:

— Кәримәнең укуын әйтер идем инде. Бер дә китап тотканы күренмни башлады. Китапханәләргә дә йөрми бугай? — диде.

Сабираның кабат ачуы кабарды, әмма бу юлы ул:

— Болай да белә бит, Хәнифә Галиевна. Ана тырышасы да юк. Шигырьне өч укый, дүртенчесендә яттан сөйли. Китапка бер карый — исендә кала. Аның баш, Хәнифә Галиевна — адәмнеке түгел, — диде, сөйләп алып китеп, әмма шунда ук көнләшүен дә сиздерәсе итеп. — Алай бер дә гадел түгел бит ул... Хаклык та, дөрес тә була алмый! Аның миннән ни артык җире бар!

Хәнифә Галиевна һаман да сүзне матур тотты:

— Бик дөрес, бик дөрес, кызым Сабира, борынын чөймәсен әле! — диде, Кәримәне юри яманлап, әмма: «Кызый, мин сине үтәли күрдем бит. Иптәш кызыңны да үз итмәгәч, дустың өчен дә сөенә белмәгәч, син кем инде?» — диярәк уйлаганын да күңелендә саклый белде: — Аның ул якларына игътибар итмик әле!

Чәйләре тәгәлләнеп килгәндә инде Хәнифә Галиевна үз улының бәхетенә насыйп булырга тиешле Кәримәнең кемлеген тәмам ачыклап өлгерде. Аны хәзер Сабира кызыксындырмый иде. Газизчиге дә кемне сайларга белгән бит — асыл кошка үрелгән. Зиһене дә камил, укуы хактан да «бишле», чибәрлеге дә бер кашык су белән йотарлык сурәттә, акыллы да зат, таланты да бар! Җитмәгән җире юк. Аның әле шигырьләр язуы нинди яхшы. Күренеп тора — күңеле саф, йөрәге чиста. Мондый асыл кош аларның фатирына үз канатлары белән очып кергән икән, чыгардым юк инде! Кешегә әрәм итәләр, димени? Акыллы шул улы, Газизчик, бик акыллы! Илдә бер! Һичбер генә дә кызлар дип, хатыннар дип баш катырмады. Насыйбын көткән икән, насыйбын!

Ә менә бу көнче күбәләк Сабира белән нишләргә? Араларына керәчәк аларның, йөрәк бәгырьләренә үтәчәк. Аны бит фатирдан өреп чыгарып та булмый. Бергә укыйлар. Аягына чалыначак.

Шушы уйларында аптырап алган Хәнифә Галиевнаның йөзенә шат елмаю йөгерде. Ул инде бер-бер фикергә килеп өлгереп, бу кыен хәлдән чыгу әмәлен дә табып алырга җитешкән иде.

Шунда улы Газизчик белән Кәримә дә кайтып керде. Сабира алдында сер бирмичә, Хәнифә Галиевна алар белән үзен гадәттәгечә коры тотты. Аның болай үзгәрүе һичшиксез файдага гына иде. Сабира үзе белән аның ихластан сөйләшкән булуын төшенде, хәтта:

— Рәхмәт, Хәнифә Галиевна! — дип, тыныч күңелдә бүлмәсенә кереп китте.

Хәер, Газизчик тә өстәл янына килмәде. Хәнифә Галиевна да улын Кәримә янына чәйгә чакырасы итмәде. Үз бүлмәсендә ябылып алган Газизчик тыныч кына бер көйне скрипкәсендә уйнап җибәрер дип берсе дә көтмәгән иделәр. Ул «Тәфтиләү»не башлады, авырлык белән, озаклап эзенә керде. Өченче тапкыр башлаганында гына көйне ахырына кадәр ерып чыкты. Бу юлы ул бик тә матур, моңлы, үтемле килеп чыкты.

*Ахыры киләсе санда*



Рим
Идиятуллин

# ЗАМАН ҮЗЕ БЕЗНЕ САЙЛАДЫ

## Поездда барганда

**Август кичләре төренгән**
**Сутлы чия төсенә;**
**Карт күзләрем чат ябышкан**
**Вагон тәрәзәсенә.**

**Әй, сихри урман, акланнар! —**
**Сез дип, өздем дә ялгадым**
**Бәгырьнең чук кылларын;**
**Яшел куакларга кунып**
**Калса иде җырларым!**

**Хас та поезд тәгәрмәче, —**
**Чаба уй келтер–келтер;**
**Басып офык өркәченә,**
**Кул болгый кебек кемдер...**

**Чү, ни күрәм! Рәшәме ул? —**
**Карыймын күзем кысып:**
**Япа–ялгыз йорт утыра**
**Урман читенә посып.**

**Киртә йөзендә ак сөлге,**
**Чиләк — казык очында,**
**Төзек кура, үрли төтен, —**
**Мич башында арт кыздырып**
**Ятмыйлардыр кышын да.**

**Кем ул?**
**Үпкәләрен чәрдәкләтеп,**
**Шахталарда күмер чапкан**
**Шыр татар Шәмгунмы ул?**

Рим ИДИЯТУЛЛИН (1940) — *Башкортстанда яшәп иҗат итүче татар шагыйре. Башкорт һәм татар телләрендә чыккан берничә китап авторы. Башкортстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре.*

Әллә,
Китапларын чүпкә атып,
Ак хыялын заман ваткан
Шау мискин шагыйрьме ул?

Туйгандыр ул хәсрәтләрнең
Ашап ачы алмасын;
Кидергәндер сукыр язмыш
Күлмәкнең кап-карасын.

Их, өмет коштай җилпенгән
Дәвер тумас беркайчан;
Әйт, ник Толстой кыршаулы
Җәннәтен ташлап качкан?!

Бәндәнекен — бәндә белмәс,
Юрамыйк аламага;
Бәлки тыны кысылгандыр
Тук, тынчу калаларда...

Бит монда... Иһи, мондамы, —
Күзгә сыймас иркенлек;
Ызанга кер дә, җигелеп,
Михнәт сабанын сөйрә!
Кайнамас сару,– күзләмәс
Аллаһтан гайре түрә.

Бассаң чыгып ялан тәпи
Чык сарган үләннәргә,
Көмеш чишмәдәй ялтырар
Керләнгән күңелләр дә.

Батыш як — урман, кәккүкләр,
Яшәр гомерне санап,
Туктамый кылса фараз, —
Төшмә шиккә, әнә кояш,
Эләгеп агач башына,
Баемый торыр бераз...

Кемне генә тетрәндермәс
Гомеркәйнең поезд сыман
Ашкынып чабулары?!
Сызлак җанга яга бәлзәм
Ятларның да, якын итеп,
Кул изәп калулары...

Сикерепләр төшәсеме,
Кочасымы һәммәсен?
Көндезен йолдыз күзләгән,
Җирдә риясыз яшәгән, —
Сез ул,– газиз кардәшем!

...Чаба поезд келтер-келтер;
Татлы хисләр бишегендә
Тирбәлеп үтсен төнем;
Тамчы бәхет тапканнарга
Бәхетле үлем телим!..

## Чиккә җиткәндә

Тәмам җиләдем,
Зәңгәр рәшәләргә алданып,
Чәчи–чәчи чабып барыштан;
Чәнчеп тезләрем,
Чүгәлим дә басу читенә,
Ятим сыман алыйм сулкылдап,
Ач башаклар койган сагыштан.

Галим–голәма,
Ләззәт табасызмы җаннарны
Коргаксыткан фәнни ачыштан?!
Сез бит гамәлдә
Юатасыз төсле сабыйны,
«Тереклек бар, — диеп, — Марста»,
Үлеп яткан чакта ул ачтан.

Кемнәр туймаган
«Изм»нардан ачып кабарган
Ахыры юк ызгыш–сугыштан?
Әйдә, мәйданга!
Чүлмәк ватыш, көрәш, чабышка! —
Арттан җилгәненә элдерәм,
Такыялар үреп берочтан.

Мәхбүс хәлдәбез:
Күңел мүкле, бикле йөрәккә
Керә алмый күрше кайгысы;
Пошмый көтәбез:
Бетәр кайчан тәмам ерткалап
Изгелекнең юка элпәсен
Явызлыкның тупас кайчысы?

Булды хак эшем:
Телем–телем кисеп бәгырьне,
Күшеккәнгә җылы өләштем;
Өнем, төшемме?
Тугры дошманнарны өемә
Дәшеп алып, авыз иттердем
Әнкәм мичтән алган күмәчтән.

Йомгак чорнадым:
Гасырларны кичеп ни белдем? —
Ил баеган саен мин бөлдем;
Җилдән сорадым:
— Бармы җирдә кыргый утрау?
Эһе–й, Робинзон!
Киттек, брат, ертык кесәгә
Шытар бодай салып биш бөртек...

**2010**

*Много их, идущих против Неба.*
Ли Бо

«Күккә кизәнгәннәр күбәйде», —
Исләдем шагыйрь сүзен
Ил тоташтан янган бу җәйне.

Күккә багып үскән көнбагыш
Ник җиргә башын ия,
Җимешләре тәмам тулышкач?

Айга карап улый ач бүре:
Улмы залим аучыдан
Мең кат мәрхәмәтле күренә?!

Янар таулар серен кем белә?—
Чөеп утлы быргысын,
Кайнар хисен Күккә белдерә.

...Тезләнеп ул коргак камышка
Көн—төн яңгыр ялвара, —
Яумый, Күкләр баткан каргышка.

(...Мәскәү — түрә, Мәскәү бәйрәмгә,
Атып сусыл болытны,
Кояш элеп куя гөмбәзгә.)

Йә, ни—нәрсә җитми бәндәгә?!
Гүрдә килер тәүбәгә,—
Кизәнгәне өчен Күкләргә...

## Кичүдә ат алыштырдым

Сайлап алып булмый заманнарны,
Заман үзе безне сайлады;
Татлысы — бер кабым, тормыш күбрәк
Ачылары белән сыйлады.

Тапкан әллә берсе, аткач угын
Ач даланың төпсез күзенә?
Вакыт тузанында аунап яткан
Елларыңны, җаным, эзләмә!

Җилдем төпкә җигеп хис атымны,
Акыл аргамагын — мичәүгә;
Алынырлык һушың, — кай арада
Килеп җиткәнмен соң кичүгә?!

Нигә кирәк, калсын ярда! — аттым
Дәверемнең тузган сандыгын;
Эзләсәләр, таба алырлармы
Дәвамымның тере сабагын?

Гел яшелен өзеп, гел өзешеп
Яшәдекме гомер туенда?
Илләр елаганда җырладыкмы
Алсу чәчкә тотып кулларга?..

Дөнья бүген мәрткә киткән кебек,
Акмый төсле агым һавалар;
Заман сырхау, чире нинди — белми,
Ә белмәгәч, ничек дәвалар?!

Алыштырдым атны мин кичүдә:
Хис атымны куйдым мичәүгә;

**Ертык заманнарга ямау булгач,**
**Безнең өчен тумас иртәгә.**

**...Әйе, алдың, ә ни бирдең диеп,**
**Сорап җәзалады үткәнем;**
**Иртәгәсен үләр күбәләк күк,**
**Татлы битен үбеп чәчкәнең,**
**Яшәгез сез!..**

## Гыйбрәт

**Гаҗәеп хәл! Ансыз — егерме ел,**
**Ә ул һаман керә төшемә:**
**Ике кулга дүрт төенчек тотып,**
**Тагын берсен асып тешенә,**
**Башак җыеп кайта Әнкәем...**

**...Кино карап яткан идем кичтән:**
**Нидер бугазлаган ач бүре,**
**Тешләп алып мәхлук балаларын,**
**Томыра да түшкә өстенә,**
**Күзләп ята читтән, — чак тере.**

**...Ишеттегезме сез: әзмәвер ир**
**Җан асрап яткан Әнкәсен**
**Куган өйдән, биреп төенчек;**
**Адәмнәрнең гыйбрәтләрен күзләп**
**Түзеп торасың соң, аһ, ничек,**
**Ходаем?!.**

---

## «Казан утлары» елъязмасы



*Журналыбыз 1922-1930 елларда «Безнең юл», 1930-1932 елларда «Яңалиф» һәм «Атака», 1933-1965 елларда «Совет әдәбияты», 1965 елдан «Казан утлары» исеме белән дөнья күрә.*

**Ноябрь**

90 ел элек (1922) «Безнең юл»да Һади Такташның «Урман кызы» шигыре;

50 ел элек (1962) «Совет әдәбияты»нда Ибраһим Газиның «Онытылмас еллар» романы;

45 ел элек (1967) «Казан утлары»нда Гомәр Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» автобиографик повесте; Атилла Расихның «Ямашев» романы;

40 ел элек (1972) «Казан утлары»нда Хәсән Сарьянның «Туган як моңы» хикәясе;

35 ел элек (1977) «Казан утлары»нда Мәдинә Маликованың «Язгы такыялар» повесте;

30 ел элек (1982) «Казан утлары»нда Мәгъсум Хуҗинның «Өч каен ышыгы» хикәясе;

20 ел элек (1992) «Казан утлары»нда Тәүфикъ Әйдинең «Йөртә безне язмышлар» исемле сәяхәтнамәсе; Фоат Садриевның «Тан жиле» романы дөнья күрә.

Вахит
Имамов

# УТЛЫ ДАЛА

ТАРИХИ РОМАН

## ТУГЫЗЫНЧЫ БӘЙЛӘМ

### 1

Бату төмәннәре унбиш ел элек кенә Болгар кирмәне булган Нижгар каласына кышның уртасында гына барып житте. Мондагы килмешәкләр яна баскыннарга каршы дивар-урлар корып маташмаган, амбарларында атка солы түгел, хәтта күселәр өчен дә ярма бөртеге юк. Воевода тиешле түрәләре каланы сакларга дип кара чирмешләрнең Пургас бәген чакырган булган да бит, тегесе, элек талаганнарына үч итеп, барча укчылары белән урманнарга качкан. Нижгар мунчада парланып чыккан хатын-кыз шикелле бар гаурәтен ачып утыра, ләкин чит-ят ир-ат кызыгырдай байлыгы калмаган шул. Янгыннан качкан шикелле, Бату төмәннәрне Муром, Рязань тарафына куды. Юлда — кара урман, атналар буена шуны ерып чыга алмый интектеләр. Хәвефнең урап үтмәсен сизенгәндер, ахры, бер елга ярында Бату хан янына чирмешләрнең бәге Пургас килеп житте. Әле теге, әле бу якка аумакайланып йөрүенә кыенсынмый бугай, сагынган туганын очраткан шикелле авыз ера-ера якыная.

— Чаңгыларга баскан биш мең укчы сиңа юл ярып барырга әзер. Нәүкәрләрең өчен биш мең бәрән дә куып китерәбез...

Юл күрсәтергә атлыгып торучылар әле Ука ярында да көтеп яткан икән. Беркөн кичтә ермак алай аю сыман кыргый сукбайны тотып кайтты. Киенгән, дисәң, көлке. Бишмәт урынына кәжә тиресен ябынган, анысы да бүре талагандай өзгәләнеп, теткәләнеп беткән. Ботларына нинди дер жәтмә калдыклары ураган, аның өстеннән каен тузы япкан. Күкрәгендә, билендә, тезләрендә дистәләгән юкә бугалаклар. Иннәренә житкән куе чәче себерке шикелле тырпаеп, тузгып чыккан. Бозланып каткан сакаллары арасыннан ике күзе генә карак мәченеке төсле гел уйнаклап тора. Мона кагылу гына түгел, якынаю да хәтәр.

— Рязаньга чаклы юлны мин күрсәтәм. Анда мине кенәзлектән куган хәшәрәт Георгий утыра. Георгийның Муром белән Коломна, Прон белән Воронеж калаларына хужа булырга да бер хакы юк. Рязань жирен сатлык Изяслав, Олег, Константиннардан мин чистарттым, кенәзлек миңа тиеш. Сасы Ярык атлы ерым аша Рязаньга тикле үзем алып барам, — дип туктаусыз бытыртаган карачкынын сөйләмен Пургас шәрехләде.

— Рязань каласыннан үзенең туганнарын үтереп качкан Глеб кенәз бит

*Ахыры. Башы 9 санда*

бу. Аны инде тилгәннәргә ризык булгандыр, дип гоманлыйлар иде. Әнә, пычак та булмаган, янә кенәз урынына кайтып утырырга очына икән әле...

Рязань кенәзе Георгий, үзенең энекәше Ингварны, тагын Муром белән Прон каласындагы воеводаларын да ияртеп, Борын-Инеш ярында Бату хан гаскәре алдыннан барган ермак алайның юлын кискән булды. Бату боларның шымчылык өчен генә алларына чыккан дружина икәнлеген чамалый иде, билгеле. Шуңа күрә ул Гөек ханны, йә Сүбүдәй нойонны да чакырып маташмады, «җиһан кендекләре» хозурына илчеләр генә куды.

— Булган барча байлыгыгызның уннан берен безгә бирсәгез, яуга кереп тә тормыйча алга кузгалабыз, — дип аңлатты Батуның меңбашлары. — Чыңгызхан калдырган «Яса» кануннарын санламыйсыз икән, яу белән тартып алудан башка чарабыз юк.

Урыс кенәзләре чышан-пышан килеп тордылар да, һәммәсе урынына Георгий җавап тотты.

— Без бер батман бал йә бер олау тирене дә үз ихтыярыбыз белән китерәчәк түгел. Урыс җирләрен талап баерга исәплисез икән, безне соңгы кешебезгә кадәр кырып бетергәннән соң гына моңа ирешерсез.

— Ярар соң, — диде Бату хан, кул селтәп. — Элмәккә менгән сантыйны тартып төшерүдән бер мәгънә юк. Бүген тартып төшерсәң, ул иртәгә яңасына менә. Әле гаскәр-мазар да алып килмәгәнсең, бар, кире кит.

Батуның «гаскәрең юк», дип ачы мыскыллавы биткә төкерүдән кайтыш түгел иде. Георгий, койрыгын бот арасына яшергән урам эте сыман, шыпан-шыпан гына Рязань ягына шылды. Шул көнне үк Владимирдагы олуг кенәз Юрий янына чапкын юлладылар. Анысы да эре бәрәңгене капчык-капчык йоткан.

— Лапас кебек вак каланы саклап, дан киметеп булмас. Пайтәхеткә килсәләр, аны менә мин берүзем сабый балам сыман яклап калам. Ә сез келәт-лапас өчен үзегез кан коегыз...

Бату хан Рязань диварлары каршына җиткән чакта декабрь бураннары котырына иде. Ул таш тотырган дивары, ур һәм ерымнары да булмаган кала өчен бар гаскәрне туплап вакланмады. Гөек белән Сүбүдәй төмәннәрен ян-яктагы Прон, Муром, Воронежга куды. Дөрес чамалаган. Дивар каршында дингездәй җәелгән ике төмән җайдакларны күреп, Георгий кенәз тәмам өнсез калды. Аның фәрманы буенча, бик тиз генә, кенәз сараенда булган бар тирене, алтын йөгертелгән чиркәү шәмдәлләрен, юнаннардан кайтартылган парча күлмәкләрне, хәтта киптерелгән чөгә белән мәрсин[1] балыгын да зур-зур чаналарга чыгарып төяделәр. Георгий, кулын улы Феодорның иңбашына салды да, ерып чыга алмас бурыч өеп, аны дошман ыстанына озатты.

— Ни сораса, шуны вәгъдә ит! Кирәк икән, капкаларны ачып, бар каланы талатырга бирәм! Ирләребезне Владимир, Суздальларга каршы яуга алырга җыенса, аларын да алсын. Иллә мәгәр синең белән миңа тимәсен дә сараебыз гына төзек көе калсын.

Ярымбөгелеп килгән Феодорны Бату ияр өстенә утырып каршылады. Дружинадагы ирләр китереп өйгән бүләкләр җәлеп итә алмады, Бату хан, Феодордан бигрәк, бер як читтә күркә сыман кабарынып баскан качак Глеб ягына ым кагып аваз салды.

— Иң зур бүләгенне яшергәнсен, кем, ни, Фидыр кенәз. Синең хатының Япраксинжаны бик тә матур, диләр. Әйдә, шуны чыгарып күрсәт әле миңа!

Феодор терелә́й йотардай булып сатлык җан туганы өстенә ябырылды. Ләкин аны кишектиннәр Глебтан миллек яфрагы шикелле бик җиңел

[1] Чөгә — стерлядь, мәрсин — белуга.

каерып алды да Бату ханның чаптары каршына сузып салды. Феодор яшь, дуамал, мин-минлеген калыптан чыгарырга ярамауны белми.

— Изге христианнар даладан килгән кыргыйга төс түгел! — дип бар саклыкны онытып кычкырды ул. — Синең кебек кыргыйга Епраксиньяның йөзенә күз салу да насыйп булмаячак!

— Ярар, син үз язмышыңны үзең сайлап алдың, — диде Бату хан тыныч кына. Аннары Феодорны җиргә бөгеп баскан кишектиннәренә борылып әмер бирде.

— Бу ахмакның башын чабып, калага җибәрегез! Әйткән сүздән кайтмыйм. Исән каласылары килсә, Япраксинҗа чыксын!

Илчеләр дивар буенда байтак вакыт көтте. Ниһаять, чанага утырган кенәзбикәне капкадан чыгардылар. Өстенә көмеш җепләр белән чигелгән, кеш тиресе белән каймаланган затлы җилән кигән. Аякларында читек сыман күн читекләр, маңгаенда асыл таш тезелгән көмеш кәккүш[2]. Үзе дә бик чибәр. Бит алмалары алсуланып, күмердәй кара күзләре сап-сары чәчләре астыннан йолдыздай балкып тора.

Бату аның инбашлары белән күкрәкләрен иярennән иелеп кенә капшап карады да, яраннарына борылып, зәһәр сүз ташлады.

— Кишектиннәр, сезгә! Исән калса, Рәзән кенәзенә кире кайтарып бирергә онытмагыз.

Кишектиннәр арттагы чатырлар ягына сөйри башлагач та, бичара Епраксинья илереп еларга тотынды. Аның өзгәләнү авазларын дивардагылар да ишетеп өлгерделәр. Кенәз тарафыннан һичбер төрле әмер булмаса да, дивардан тышка сикереп, барча ялан буйлап сибелделәр. Әзерлексез-нисез яу башланды. Коломна-Муромнардан кенәзлек үзәген сакларга дип килеп җиткән ирләр кылычларын — чалгы, сөңгеләрен тәртә урынына аяусыз болгаса да, ауга һәм яуга йөреп күнеккән татар, мангыт, ойрот ирләре әле мәче елгырлыгы белән читкә сикерделәр, әле көтү булып кабат җыйналдылар. Орыш караңгы төшкәнче сузылды. Ике як та үз ыстанына кайтып ауды. Тышта буран көчәйгәннән-көчәя бара иде, хәтта мәетләрне дә җыеп тормадылар.

Икенче таңда Георгий яу башлыгы итеп кенәз Олегны яланга куган иде. Кыл аркаллар ташлап, мангыт җайдаклары аны әле төш җиткәнче үк Бату чатырына сөйрәп китерделәр. Бату урыс кенәзен күрде дә гел шаккатты. Егеткәйгә күп булса уналты-унҗиде яшь кенә тулып килә. Ни гаҗәп, мыегы бик сирәк. Ә чибәрлек дигәне — япь-яшь кызлар бер як читтә торсын! Арыш сабагыдай сап-сары чәчләре бөдрәләнеп иңнәренә яткан. Озын керфекләр астында күлдәй зәңгәр күзләр. Тәне кершән яккан шикелле ап-ак.

— Мин сине чатырымда калдырам, — дип бик ягымлы пышылдады Бату.

Егетнең берни аңламыйча төбәлүен күргәч, ишек катында бөтерелгән Глебны дәшеп алды.

— Яшь кенәзгә аңлат. Аның гомерен кисмим. Алда яулыйсы урыс калалары әллә ничә йөздер. Сәркатипсез булмас. Мин аны чатырыма юлдаш итеп алам...

Шул төндә Георгий кенәз каланы ташлап пайтәхеткә качты. Яман чирләр йогышсыз булмый калмый. Владимирдагы олуг кенәз Юрий, Рязаньның качак түрәсен тыңлады-тыңлады да, чи камыр шикелле калтырап ук төште.

— Киев белән Новгородка тизрәк чапкын куыйк. Энем Ярославны Киев тәхетенә мин илтеп утырттым. Аның Новгородтагы улы Александр да, унбиш яшендәге үк аерым биләмәгә хуҗа булган өчен, иң беренче чиратта,

[2] Кәккүш — калфак, кокошник.

миңа бурычлы. Мин олуг кенәз генә түгел, алар өчен атай урынына калган өлкән абый да бит әле. Бар гаскәрне күтәреп ярдәмгә килми калмаслар. Бердәм булсак, ул Батуның көтүчеләрдән тупланган төмәннәрен кырмыска оясы шикелле туздырырбыз!..

Юкка көрпәләнде, кәпрәйде бу олуг кенәз Юрий. Бер ай узганчы ук ике яктан да чапкын кайтып төште. Туганнарның җавабы канны катырырдай кырыс, салкын иде.

— Синең кайгың гына җитмәгән, ди. Киевка Галич кенәзе Даниил да тынгы бирми әле.

— Новгородка бертуктаусыз алман алпарлары янап тора. Хәлеңнән килсә, үзең өстәмә алайлар юлла инде, агай...

## 2

Рязаньны түмгәк урынына изеп үткәннән соң Бату хан һөҗүм угын Коломнага таба борган иде, юк кына бер дружина аркасында аның төмәннәре, сазлыкка кереп баткан мүкләк сыер сыман, ничә көн буена һаман бер урында таптанырга мәҗбүр булды. Әллә каян гына табылган шул дружина кенәзлектән чыгып барган чакта мәңгелләрнең койрыкта сөйрәлгән азык олавына һөҗүм итте. Бер төн эчендә меңәрләгән алмаш атлардан гына түгел, дивар җимергеч тараннардан, таш, тимер ук һәм шәрҗир аткычлардан, хәтта он белән тоз олауларыннан да колак кактылар. Бату, котырынып-ярсып, бер мең җайдакны кире борган иде, тегеләр көрт ерган сәфәрдән алты-җиде саугат-әсир генә тотып кайтты. Авызларына су капкандай торган саугатлардан анлашылырдай җавап алып булмый.

— Без — чаң кагып, олылап, сине алдагы яуларга озатырга җыелган карачулар, без — холоплар, — диләр.

— Рус жиренә шундый тәртип күптән кергән инде. Без синең кебек көтелмәгән, олы кунакларны ук-сөңгеләр очырып озатабыз, — дип еландай телләрен күрсәтеп алудан да тартынмыйлар.

Бату боларны агачлар ботагына элдереп, аяк очларында учак тергезергә әмер бирде. Көек исе инде аланнарга тарала башлагач кына беркадәр чишелделәр.

— Башлыгыбыз — Евпатий Коловрат. Юк, ул кенәз түгел. Рязаньда элегрәк сәүдәгәрләр башлыгы булып торган иде. Йортын Георгий кенәз кереп талагач, Черниговка китте. Георгий качканны ишетеп, менә, кире кайткан. Дружинасында меңьярым сугышчы бар. Бату ханның табаннары астына ут элэм, аны янган күмер өстеннән йөгертәм, ди.

— Кайда соң ул? Аның ыстаны кайда? — дип үкереп сораулар да өркетмәде.

— Бернинди ыстаны юк. Бу — аның үз иле бит. Күнеле кая төшә, шунда барып тuктый. Сезне тынычлыкта калдырачак түгел...

Бату хан алга таба биш мең җайдакны гел койрыкта калдырып барырга мәҗбүр булды. Ләкин барыбер дә тынычлык күрмәделәр. Евпатий — җен шикелле. Кайсы ерымнар аша гына узып өлгерәдер, ул үзенең дружинасы белән йә урман арасыннан килеп чыга, йә тау башында көтеп алып чукый. Әлләни зур зыян да салмый үзе, бер һөҗүм вакытында илле-алтмыш кына мангыт йә кыргызны кырып өлгерәдер. Ләкин әтәч сыман туктаусыз чукып торгач, Батуның төмәннәре каны саркып торган яралы җанварга тиң. Унны-суллы аралап тормыйча алга да бара алмыйлар, ныклы ыстан корып көтәргә дә җаен табып булмый.

Ватык арба кебек туктый-туктый бару үзәгенә үтте, Бату хан ике төмәнгә берьюлы бар тарафка төбәлергә әмер бирде. Евпатий дружинасын таң алдыннан, Сура дигән елга өстеннән чыккан чакта килеп камадылар. Яу

бик кыска, нык аяусыз булды. Урыс ирләренең тере көе бирелергә исәбе юк иде, мәңгел нәүкәрләре аларны суган түтәле урынына тоташ турап чыкты. Евпатий каһарман үзе дә котылып кала алмады. Аны алты-җиде мәңгел, сөңге очларына берьюлы күтәреп, боз өстенә атты.

3

Коломна дружинасы, каланы җимертмик дип, баскыннарны дивар тышына чыгып каршылаган иде дә, Бату җайдаклары сакчыларны монда да чабагач астына салган көлтә сыман изеп кенә үтте. Сынар чиркәве белән кукраеп утырган Коломнада кызыгырлык байлык күренмәде, кала эченә кереп тә тормадылар. Кул сузымындагы Мәскәү барча капкаларын бикләп куйган иде, Бату аның диварларын яулап та маташмады. Өч ягыннан ут төртеп, Мәскәүне тоташ янгын эчендә калдырды да, тагын юлга чыкты. Авылларда атларга ашатырдай солы-печән таба алмадылар. Аерым хәрәкәт итү җиңеллек китерүгә өметләнеп, Бату ике төмәнне элек аерым кенәзлек үзәге булып торган Суздальгә юллады. Ә үзе өч төмән гаскәр белән яңа пайтәхет саналган Владимир каласына төбәлде.

Олуг кенәз Юрий өлкән улы Всеволодны — Коломна каласына, төпчеге Владимирны Мәскәүгә вак-вак дружиналар белән ярдәмгә дип озаткан булган иде. Караңгы төн уртасында сарайга тоташ канга баткан Всеволод кайтып керде. Аягында егәр гел калмаган, ахры, тупса аша узуга ук иДәннәргә ауды.

— Әткәй, бәла! — дип, Юрий кенәзгә таба үрмәли-үрмәли гыжлап кычкырды ул. — Коломна дружинасын кырып бетерделәр. Мәскәү ут эчендә. Бату, явыз, өстебезгә килә!

Юрий кенәз коргаксыган мичкә сыман гел таралып төште.

— Ничек инде, ничек? Коломнаның воеводасы Еремий тәҗрибәле, җитмәсә, кенәз Роман да шунда иде бит, юкса, — дип сөйләнүләрендә бер лөгать йә хаклык күренмәде.

Ярсып беткән Всеволод кычкыруын белде.

— Бату ханның җайдаклары кара урман сыман. Аларны санап кына бетерерлек түгел. Ул барча урыс калаларын саранча шикелле коргаксытып бара. Бездә аның төмәннәренә киртә була алырдай бернинди көч-куәт юк. Ул безнең пайтәхетне дә кандала урынына сытып бетерәчәк!

Кенәз телсез калды. Абыйсы кайту турындагы хәбәрне ишетеп, күрше йорттан Юрийның уртанчы малае Мстислав кенәз дә йөгереп кергән иде. Юрий шуларга төбәлеп тиз-тиз тезеп китте.

— Бөтен урыс илен, барча кенәзләрне күтәрергә кирәк. Мин хәзер үк юлга чыгып китәм. Ярославльгә барам, Черниговка барам, Смоленски, Курски кенәзләрен дә ияртмичә кайтмыйм. Минем урыныма пайтәхетне сакларга сез каласыз. Кышкы көртне ерып, Бату төмәннәре бик тиз килә алмас. Инде күренсә дә, мен төрле алдагыз, мең кат хәйләләгез. Мин аңынчы кайтып җитәрмен дә кыргый көтүчене бергәләп туздырырбыз...

Юрий кенәз кечерәк дружина белән пайтәхет капкасыннан чыгып китүгә үк, дивар өстендәге ирләр сытып сүгенделәр.

— Безне ташлап качты. Ул да үз үлемен эзләп китсә генә ярар иде!..

4

Бату хан Владимир каласы янына февраль башланганда гына килеп җитте. Всеволод белән Мстислав кенәзләр, диварларны ныгытмакчы булып, каланы читән коймалар, имән баганалар белән дә ураттырган иде. Бату юллаган илчеләр пайтәхетнең Алтын Капкасын таба алмыйча шактый интектеләр. Ниһаять, бер илченең ияреннән төшми генә кычкырган тавышы ишетелде.

— Олуг кенәз каладан качкан, диләр. Сөйләшүне кемнәр алып барыр?

Җавап урынына илчеләр өстенә ук яңгыры яуды. Карсак чаптарларын кәҗә тәкәседәй уйнаклатып, мәңгелләр читкә чапты. Ерак арадан торып янә кычкырдылар.

— Илчегә үлем юк! Сез шушы дала канунын һаман ятламадыгызмыни әле? Унбиш ел элек Киевныкылар шуны бозган өчен йөз мең сугышчысын югалтып сабак алган иде бит инде.

— Без Киевка буйсынмыйбыз! Хәзер без — пайтәхет! — дигән генә җавап ишетелде, аннан соң илчеләр өстенә инде сәрпи уклар очты.

Ике җайдак иярдән очып төшкәч, мәңгелләр дә тезген югалттылар. Өч-дүрт нәүкәр, баулар белән сөйрәп, дивар каршына бер ир-атны чыгарып бастырды. Илче булып барганнарның берсе аваз салды.

— Сез үз кенәзегезне булса да таныйсызмы хәзер?

Дивар өстенә тезелешкән урыслар артларына авып китә язды.

— Олуг кенәзнең төпчеге Владимир бит бу! Абау, ничек кыйнап бетергәннәр! — дигән сүзләр яңгырап ишетелде.

Тоткын егет, асылда да, кара канга баткан, җинел генә танырлыгы һич калмаган иде. Хатын-кызлар бүре улагандай үкерә-үкерә елый башлады. Илче ирнең сорнайныкы сыман көчле тавышы гына елау авазларын күмеп китте.

— Калагыз да Владимир атлы, кенәз дә — Владимир. Кайсын коткарасыз?

— Бездә ил бәһасе торган кенәзләр юк! — дип илереп кычкырганы бичара тоткынның бертуган абыйсы Всеволод иде. — Капканы ачмыйбыз!

Икенче мизгелдә йомран сызгыргандай әче тавыш тынлыкны ярып узды да киң колаклы сәрпи ук Владимир бичараның муенына килеп кадалды. Дивардагы хатын-кызлар тагын еларга тотынды. Мәңгел җайдаклары, өметсез кул селтәп, читкә китеп барды.

## 5

Ачыктан-ачык мыскыл иткән сыман, Бату үзенең чатырларын нәкъ Алтын Капка каршына китереп кордырттыры. Мәңгел җайдаклары, йә ияр өстенә аягүрә баскан көе чабып, йә чаптарларның корсак астына чумып уйный-уйный, камалыштагы урыс ирләренең җаннарын телгәләде. Дивардагы мәргәннәр түземлекләре корыгач, котырынып-ярсып, баскыннарга дистәләгән уклар да очырып карадылар. Мәңгелләр араны дөрес чамалап тамаша корган иде, укларның берсе дә чаптарларга чаклы очып җитә алмады.

Бату сәрдәрләре урыс пайтәхетен ничек яуларга дип озак баш ватмады. Әүвәл Владимир каласын да, нәкъ Биләр янындагы шикелле, читән коймалар белән уратып алдылар. Аннары шулар арасыннан дилбегәдәй озын баганаларга асылган һәм баш-башлары калын тимергә төрелгән имән җимергечләр шуып чыкты. Күз ачып йомарлык арада җимергечләр өстенә читән коймаларны өеп түбә ясадылар. Һәр түбә астына кырык-илле чамасы мәңгел кереп качты, ул да түгел, җимергечләр, ташбака йә керпеләр шикелле, пайтәхет буена шуышырга тотынды. Берзаманны, дан да доң китереп, йөзәрләгән имән җимергечләр кала диварларын төя башлады. Бөтен кала янартау өстенә эләккән сыман дөбердәде, сикерде, калтыранды, диварлардан чиләкләр йә чүлмәк кенә түгел, хәтта сакчылар да очып-очып төште. Кала сакчылары мәңгелләр өстенә кайнар сулар, сумала, зур-зур ташлар да коеп карады, файдасы күренмәде. Әле теге, әле бу диварда ярык пәйда булды, урыны-урыны белән бар булган таш өеме җимерелеп ауды. Җәяүле мәңгелләр ярыклардан язгы ташкын сыман кала

эченә агылды, ләкин тәүге сәгатьләрдә кала сакчылары аларны бик тиз себереп чыгардылар.

Биш көн буе барган һөҗүмнән соң пайтәхетнең Бакыр Капка, Идел Капкасы дигән терәкләре дә, Алтын Капка янәшәсендәге диварлар да ауды. Мәнгел төмәннәре буар елан сыман эчкә томырылды. Всеволод белән Мстислав кенәзләр, иң гайрәтле ирләрне генә туплап, Идел капкасы ягына чигенәләр, шуннан иркен кырга чыгып качарга исәп тота иде. София соборы янынннан үткән чакта ачыргаланып кычкырган бер хатын-кыз тавышы яңгырады.

— Улларым, улкайларым! Без монда бит! Хатыннарыгыз, сенелләрегез, хәтта сабыйлар белән бергә, коткару һәм ярлыкау сорап, Ходайга ялварабыз. Сездән башка ничек исән калыйк? Безне ташламагыз!

Кенәзләрнең һәр икесе кисәк тукталырга мәҗбүр булды. Собор баскычына басып сөрән салучы хатын аларның аналары Агафия иде. Мстислав чарасызлыктан башын түбән иеп, күзләрен яшерде. Өлкән кенәз, үз мичендә ут тергезү өчен күрше йортка утлы күмер алырга гына керүче малай сыман, ваемсыз кыяфәттә салкын җавап атты.

— Соборга керегез дә тагын Ходайга ялварыгыз! Сезне ташламыйбыз, без кайтабыз!

Кенәзләрнең чаптарлары Идел тарафына атылды, Агафия, күзләрен читләрдән яшерә-яшерә, кабаттан собор эченә кереп китте. Анда епископ Митрофан атакай бер кулына тәре, икенчесенә бик олы шәм тотып, мөнбәренә менеп баскан иде. Аның Ходайга төбәлгән сүзләре дә ялварудан бигрәк хушлашу шикеллерәк булып яңгырады.

— Гөнаһлы кулымны кичер дә, каршыңа үз теләге белән киткән колларыңны хозурыңа кабул ит, йә Ходаем!?.

Кенәзбикә Агафия әле һичнигә аңларга да өлгермәгән иде, шул мизгелдә таш соборның ишек-тәрәзәләре шапылдап ябылды да, Митрофан атакайның кулындагы зур шәм идән уртасына очып төште. Анда киндер мае сибелгән чыпталар җәеп куелган икән, аларны шундук ялкын чорнап алды. Аннары ялкын, тиендәй сикереп, собор диварларын тирәләп, ишеккә терәтеп өелгән сүс тауларга күчте. Соборны тутырып баскан халык кая барып бәрелергә белмичә илереп акырды.

— Тереләй янып үләсебез килми!

— Коткарыгыз! Безне коткарыгыз!..

Митрофан атакайның жиз торбадай тавышы каплап китте.

— Сез Ходай Тәгалә каршына бер гөнаһсыз күе барачаксыз. Янып үлгән коллар изгегә әйләнәчәк!..

Коточкыч янгын турында хәбәр алуга ук, Бату ханның колагында яралы Колгали Биләр хәрабәләре каршында пышылдаган сүзләр чаң тавышы булып яңгырады.

— «Чыңгыз бабаң Үргәнечтә Коръәни Шәрифне ат тоягы астына салган өчен бер тилемсә меңбашның гомерен кызганмады. Ә син Болгар дәүләтенең хәтта мәчетләрен дә исән калдырмадың. Синдәй вәхшидән икенче Чыңгызхан чыкмаячак инде, мәңге чыкмаячак!»

Бату барча җансакчылар меңлегенә борылып сөрән салды.

— Собордагы янгынны сүндерегез! Халыкны коткарыгыз! «Яса» кануннарын бозган һәр мәнгелнең гомере кыелачак!..

Кайчандыр болгар остасы Даир төзеп биргән собор исән калды. Диндарларның гына барчасын да коткара алмадылар. «Всеволод... Всеволод улкаем... Килен кичерде, хатының кичерде бит», — дип сөйләнеп йөрүче хатынның чәчләре акбур яккандай ап-ак, ә үзе акылга җиңеләйгән иде. Әмма барыбер бәхете бар икән. Идел Капкасы янындагы кырда ике улының да кылыч белән турап ташлануын үзе күрмәде бит...

## 6

Кайчандыр «Бөек» кушаматын йөрткән Новгородка төбәп барган чакта ермак алайдагы нәүкәрләр җан көйдереп көткән хәбәр алып кайтты.

— Юрий кенәз Сить дигән елга буендагы бер урманда аю сыман качып кына ята. Дружинасының яртысы качып киткән. Аның ыстанындагы ирләр хәзер өч меңнән дә артык түгел икән.

Бату ханның Биләр, Кашан, Алабуга, Казан, Аккирмән калаларыннан җыеп килгән биш мең болгар ирен әле бер яуга да кертkәне юк иде. Хәзер шуларның менбашларын дәшеп, күкерт кабынырдай кискен тавыш белән тезде.

— Сезнең барчагыз да — минем төмәннәремдәге татар, башкорт, кыргыз, кыпчак, кайсак нәүкәрләре кебек үк мөселманнар. Үз туганнарыгыз белән бергә сәфәр чыккансыз икән, яуларда да алар белән иңгә-иң торып орышырга кирәк. Аннары сезгә минем сәүдәгәрләр өч ай буе өләшкән ризыкларның әҗерен дә кайтарырга вакыт. Моннан ары сезгә, көйсез кәләш шикелле, мәңгелләр ышыгына качып ятып булмас. Әнә, качак кенәз табылган. Аның Болгар өстенә әллә ничә тапкыр яулар белән килүен дә, Ашлы дигән калагызны яндырып китүен дә, ахыр чиктә, ярдәм сорап баргач, битегезгә төкереп җибәрүен дә беләм. Үчегез тау кадәрле. Менә шул әрвахны минем табан астына кайтарып ыргытыгыз!..

Көрт тауларын ерып, көн баешына таба атнадан артык барырга туры килде. Юрий кенәз үз ыстанын биек яр өстенә корып куйган булган. Ыстан әйләнәсен су сибеп катырылган боз диварлар белән дә ныгыткан-ныгытуын. Ләкин кояш март башында ук җылыта башлады шул. Дивар дигәннәре әрдәнә өеме шикелле ишелеп төшкән. Кенәз ыстаны хәзер — тол калган хатын ихатасы төсле, дәртең җитә икән, кер дә тала.

Болгар җайдаклары бәреп керүгә үк Юрий кенәз елгадагы боз өстеннән Тверь каласы ягына качып котылмакчы булды. Мондагы бозның да көпшәкләнеп бетүен искәрмәгән, ахры. Бер чакрым чамасы чабуга ук атыкылычлары белән боз астына чумды. Боз өстеннән шуышып яр читенә чыкса, яудан исән калган Биләр ире тора.

— Алмазларым, алтыннарым билдә, — дип сату итә башлаган кенәзнең гозерләрен дә тыңлап бетермәде.

— Этка — эт үлеме! — дип кенә кычкырды да кылычы белән кенәз гәүдәсен урталайга ярды.

## УНЫНЧЫ БӘЙЛӘМ

## 1

Бачман тархан яр читенә корылган печән шалашына кереп яткан иде. Ул бүген дә Идел өстендә су чыпырдаган тавышка уянып китте. Уткүз[3] итеп Актүбә ягына озатылган Мисбах кайткан икән. Көймәсен такталар өстендәге чирәм кәскә тезелгән ялган камышлыклар арасына бәйләп азаплана. Кара җиләненең аркасы юпь-юеш, читек куңычлары шыр-тузанга баткан. Төпченеп торулар да артык, Мисбах чаптарында байтак фәрсах үткән. Шулай да, яр өстенә менеп тын алуга, кыза-кыза тезде.

— Мүнкә бүген, таң белән үк, Кысырбия яланы ягына мангыт меңен куды. Ул тарафта Тәтеш би белән Юныс би җәйләүләре генә таланмый калган иде. Хәзер аларга да Мүнкә камчысын татырга чират җиткән, димәк.

— Нишләп Мүнкә үзе бармагансың соң әле? — дип бүлдерде Бачман, йөзендәге кырыслыгын һич тә үзгәртмичә. — Ул келәт-сандык актаруны чит-ятка тапшырмый бит.

[3] Уткүз — күзәтүче, шымчы, разведчик.

— Мүнкә ханнын ыстаны һаман Елаксу буенда. Күченергә исәпләми, ахры, чатырларынын берсен дә җыйдыртмаган.

— Ярар, — диде Бачман, нилдидер уйга килеп. — Пайсанны йөзбаш Мөхәррәмнең улы Әкрәмгә тапшыр да, аны янә Мүнкә ыстанына җибәр. Үзен ял ит. Төнлә Кысырбия яланына тозак куймый булмас.

Мен Торна утравы җир өстенә эңгер-меңгер ныклап төшкәч кенә уянгандай булды. Олы бер ерым авызын ялган камышлыклар гына каплап торган икән. Шулар ачылуга, Идел өстенә дистәләгән саллар, каек-көймә, хәтта баркаслар да шуып чыкты. Аларга читән коймалар, эреле-ваклы арба, усак бүрәнәләр, камыш, ияр, калкан, сөнгеләр тутырдылар. Сал-каеклар утраудан ярга таба кузгалгач, Идел өстенә олы күпер җәелгәндәй булды. Кайсы гына көймә-салларга тарафына гына күз ташлама, һәркайсында дистә-дистә таза ир-егетләр, чын бөркетләр йөзә. Олы баркас борынына менеп баскан көе һәрбер хәрәкәтне күз уныннан ычкындырмый барган Бачман бүген уртадагы ике салны этә-этә йөзгән егетләрне аеруча бирелеп күзәтә. Алар әле сандалларга салып кыйналмаган, шулар сынатмасмы?

Алар Бачманга биш-алты көн элек Хаҗитархан хәрабәләре ягыннан кайткан чакта, Урак чишмә буенда очрадылар. Бачманның уткүзләр урынына алгарак җибәргән җайдакларын мәңгел нөгәре дип кабул иткәннәр дә, унны-сулны да аралап тормыйча, Идел яры буйлап түбәнгә ташланганнар. Нәкъ шул чакта Бачман ике йөз җайдак белән Урак чишмә янына менеп килә иде. Качаклар, читтә йөгереп күнел ачканнан соң әнисенең күкрәкләрен талымлап кайткан сабый бала төсле, Бачман нөгәренең уртасына гына килеп керде. Утызлап ир. Борын яфраклары киерелгән, күзләре ут әллергән күкерт кебек яна. Кулларында кылыч. Бик котыртсаң, өркеп тормыйча, болар ике йөз җайдак өстенә дә ташланырлар сыман.

— Сез кай яктан? Кемнең яугирләре? — дип киеренкелекне Бачман үзе таратмакчы иде. Тегеләр элекке шикелле үк әтәчләнеп торгач, аңлатма бирергә мәҗбүр булды.

— Мин Бачман тархан булам. Саксин әмире. Ишеткәнегез бармы?

Качаклар арасындагы яшь егетләр гаҗәпләнүләрен дә яшерә алмады, күзләре тамаша кылган сыман ялык-йолык килде. Арада иң өлкәне булган чал мыеклы бер ир сүз башлады.

— Без — Хаҗитарханнан. Гөек хан калабыздан көл калдырып киткәч, әзериләр ягына качкан идек. Аларда да хәрабәләр генә. Ризык та юк. Болгарда мәңгелләргә баш бирмәүче Бачман тархан калган, ул ихтилалчылар[4] гаскәре җыя, дигән хәбәр ишеттек тә, менә, кире кайттык. Бучаклы маҗ килер дә тарханның үз куенына килеп эләгербез, дип кем уйлаган?

Канәгатьләнүдән Бачман әүвәл елмайгандай итте.

— Бирәм дисә колына, чыгарып куяр юлына, дигәндәй килеп чыккан инде алайса? Минем нөгәр турындагы хәбәр әзериләр иленә тикле барып житкән, диген.

— Килде, килде андый хәбәр! — дип гөрләште ирләрнең һәммәсе дә.

Тархан житдиләнде.

— Ә сез ихтилалчылар тәкъдирен бизмәннәргә салдыгызмы соң әле? Безнең бик күбебез азат хәят өчен яуларда башын югалтырга да мөмкин бит.

— Кәлтә сыман качып яшәгәнче, бер көн булса да күктәге тилгән кебек иректә очып калуың кыйммәт! — диде чал мыеклы ир бар качаклар өчен.

Бачман җайдакларның бер-икесен кочагына алды.

— Алайса, кушылыгыз. Ә син Хаҗитарханныкыларның башлыгы булачаксың. — Бачман чал мыеклы иргә таба бармак төртте. — Исемең ничек әле?

[4] Ихтилал — азатлык, бәйсезлек өчен көрәш.

— Хәйри. Миңлехәйретдин.

— Юк, син бүгеннән башлап «Йөзбаш Хәйри» инде!

Мондый олылауга Хәйринең үзеннән бигрәк яшь качаклар җәелеп елмайдылар. Әнә, әле бүген дә аларның йөзеннән шул елмаю китмәгәндер сыман. Һәммәсе канәгать, һәммәсе тәүге яуда сыналырга бара...

Көймә-саллардагы арба-калканнарны яр читенә ташып өяргә дә өлгерә алмадылар, Хәзәр дингезе ягында пошкырып-дулап чапкан ат көтүе күренде. Аларны бер дистәләп ир-ат куып килә. Хәйри кебек яңаларга сорап тору артык, атларны ниндидер яшерен утлыктан чыгарганнар, уйнап чабулары да иркенлектән иде.

Нөгәрнең бар куәте яугирләр иярләргә менеп, сафка тезелешкәч кенә төсмерләнде. Көймәләр сагында калганнарын, арбаларга менеп кунаклаганнарны да кушсаң, барчасының саны меңгә тула икән. Болар язгы кар шикелле җепшек, көпшәк түгел. Тезләренә куйган сөңге-кылыч кулларына береккәндәй уйнап кына тора. Беләкләре таза, кыяфәтләре кырыс, күзләрендә шайтан уты яна. Берсенең генә карашында да шикләнү, куркаклык юк, болар белән яу йөрсәң дә була!..

Актүбәгә төбәп кузгалдылар. Бачман нөгәр борынында, дөядәй эре гәүдәле Галинең сыртында тирә-якка күз уйнатып барды. «Кыпчак даласы» дип аталган һәм офыкларга кадәр сузылган киң яланнар, кульяулыктай гына вак-вак күлләр, кызларның чәчләренә үргән ефәк тасмалардай уйнак инешкәйләр, җилдәге күл өсте шикелле дулкынланып яткан кылган түтәлләре, акбаш, мәк, кызалак, күкбаш кебек чәчкәләре белән чиккән түбәтәйдәй купшыланган туган туфрак, газиз тугайлыклар, и-и, матур сон! Тирә-якта эреле-ваклы таулар, Сабантуйда капчык киеп йөгерергә чыккан малай-шалай төсле, берсен-берсе узышырга чамалап тезелгәннәр. Арада иң зурысы — чал Анатау. Түбәсен, ян-якларын гел кылганнар чорнап алгангадыр инде, ул, чыннан да, чәченә чал төшкән, кайгылы ана кебек. Аның турындагы риваять искитмәле!

Үзи, Тын елгалары[5]* ягыннан килгән дошманнар ябырылгач, алар Кыпчак даласындагы барча калаларны кырып бетергәннәр. Япь-яшь кызларның, яшүсмер егет-җиләннең һәммәсен дә, арканнарга чорнап, коллыкка озатканнар. Арысланнарга да биргесез бер пәһлеван гына менә шушы биек тау өстенә менеп качкан икән. Даладагы орыш барышында баскыннарның берсе аның баш түбәсенә гөрси белән сугып өлгергән дә, тора-бара пәһлеванның күзләре әкрен генә сукырайган булган. Дошманнар да белеп алган моны. Егетне терелэй кулга төшерү өчен әүвәл баһадирлар юллап караганнар. Ләкин егет үзенә якынайган һәр дошманны курчак шикелле генә эләктереп ала да кыя түбәсеннән упкын эченә тотып ата икән. Кыпчак пәһлеваны шулай берьялгызы дошманнарның җитмеш баһадирын кырып салган. Аннары дошманнар бер мең яугирләрен һөҗүмгә ташлаганнар. Дошманнар һәрьяклап, ыргаклы сөңгеләрен, элмәкле арканнарын селки-селки, пәһлеванга якыная икән. Инде тагын бер таш аша гына сикерерләр дә пәһлеванны әсирлеккә эләктерерләр сыман. Ләкин шул вакытта кыпчак пәһлеваны сызгырып җибәрә дә күк йөзендә канатлары үгез тиреседәй зур-зур каракошлар пәйда була икән. Алар пәһлеванны томшыклары йә тырнаклары белән эләктереп, икенче тау башына күчергәннәр. Пәһлеван шуннан янә дошманнар өстенә таш яңгыры койган, тегеләрне камыш сыман кырган.

Аптырагач, баскын дошман ханы явыз хәйлә корган. Моның каршына әүвәл пәһлеванның әнисен китереп бастырганнар.

— Йә улыңны үзең безнең алга килеп тезләнергә үгетлисең, йә без

[5] Үзи — Днепр, Тын — Дон елгалары.

синең башыңны чабып өзәчәкбез! — дип дошман ханы кансыз таләп куйган.

— Халкымны болай да кырып бетердегез. Әгәр газиз улымны да сезнең кулга бирсәм, бөтен кыпчак киләчәктән коры калачак бит. Юк, баламны бирмим! Сез минем башны чабып үтерегез! — дип җавап биргән ана.

Шуннан аны артыннан сөңгеләр белән куалый-куалый, улы яшеренгән тау өстенә алып менә башлаганнар. Мескен ананың авызын да, күзен дә кара чүпрәк белән бәйләгәннәр. Анасы да, улы да бөтенләй берни күрми. Әмма аның күкрәк сөтен имеп үскән бала газиз әнкәсенең исен тоймый, аяк атлауларын аермый каламы соң!

— Әнкәй! Син мине тоттырырга килдең, мине саттыңмени? — дип ачыргаланып кычкырып җибәргән дә сукыр пәһлеван кыядан упкын эченә томырылган икән.

— Синнән башка яшәүнең яме юк, балакаем! — дип үкси-үкси, мескен анакай да улы артыннан чумган.

Менә шуннан бирле чал кыяны гел Анатау, диләр...

Аның ышыгындагы бер тау, әнә, хәле бетеп ялга тукталган карт бабай шикелле, чалмалы башын бер якка кырынайтып, түбәндәге малайлар өерен күзәтә. Аның түбәсенә вак болытлар тиеп-тиеп уза, ныклап баксаң, алҗыган карт торып-торып уфтанадыр, пошкырадыр сыман. Тауларның итәкләрендә имән, өрәңге, зирек түтәлләре. Бу якта агачлар кәттә булып үсми, иң елгырының биеклеге дә ярты дилбегәдән артып китмәс. Мәгәр җирдән мәңге аерылмаска җыенгандай таза кәүсәлеләр, мул ботаклы бит ул кәрлә зирек-имән. Араларына керсәң, яшь-җилкенчәк малайлар үтеп барган кыз-кыркынны капшаштырган кебек, озак җибәрмәсләр...

Шушы тауның итәгендә тирә-юнен куе камыш сарган Сигәк күл бар. Бачман әле малай чагында ук аның янына әтисе Тургай алып барган иде. Яр буена җиткәч тә, шундук кисәтте ул.

— Азгынланып-мазар сия күрмә, улым. Су Анасы тартып алмагае!

Аннары әтисе бик хикмәтле бер риваять бәянләгәч белде. Имеш, шушы күл буена берзаманны бик тә азгын бер хан туктаган, ди. Үзе белән алты-җиде яшьләрдәге малаен гына түгел, олы чатырына тутырырлык кәнизәкләрне дә ияртеп килгән икән. Зирек агачлары ышыгына чатыр корып куйгач, әле бер, әле икенче кәнизәген алып китеп, күл суына чумып шаяра башлаган, ди. Ә малайның әнисе күптән түгел генә яман чирдән китеп барган булган, монда аңа хәтта ризык каптыручы да табылмаган икән. Хан малае әтисенең күл эчендә кәнизәкләр белән анадан тума чишенеп азынуын күзәткән-күзәткән дә, үч итмәкче булып, күл суына сиярга ниятләгән, имеш. Ул яр буена җитеп ыштанын төшерүгә, күл өстенә Су Анасы ярсып килеп чыккан.

— Суымны пычратасы булма, малай актыгы! Тыңламасаң, хәзер күл төбенә тартып алам! — дип кычкырып кисәткән, ди.

Хан малаеның әтисенә ярсуы бик көчле бит, ул кисәтүне барыбер тыңламаган. Ләкин аның сиеп кенә бетерүе булган, җан җиреннән эләктереп, Су Анасы аны күл төбенә алып төшеп киткән. Хан аны йөзәрләгән сакчыларын чумдырып эзләткән, ди. Һичкем таба алмаган. Ярсудан хан кәнизәкләрен дә күлгә ташлаттырган. Хәзер Су Анасын шул кәнизәкләрнең берседер ул, дип тә гөманлыйлар, имеш. Риваятен риваять бу бәян. Иллә мәгәр күлнең сәер ягы бар бит. Андагы су ачы камыр сыман гел уйнаклап тора. Бер атнада килсәң, ул корырга җыенып яткан сыман. Ә икенче атнада инде ярларыннан ташып, камышларны баскан. Төптәге чишмәләр шулай уйнаклыйдыр, шаять. Ә үзен узгынчылар барыбер Сигәк күл, ди...

Шушы таулар, камышлар ышыгында бер йомгак тәгәри. Бачман аны әллә кайчан күреп алды инде. Гали дустыннан мәңге аерылмас ялгыз Мара бит ул! Аксак көе тыйтаклавы җинел түгелдер дә, барыбер иярә шул. Уе белән ул Галине хәвеф-хафа, бәла-казалардан сакламакчы инде. Бачман исә аны үзенең фәрештәсе, яклаучысы сыман кабул итә. Ялгыз бүре Мара янәшә атлаганда тарханның яуда яра алганы йә җиңелеп кайтканы юк. Бачман җинеп кайтса, айгыр Гали исән. Гали исән икән, сиңа да көн якты. Әйдә, атла, Мара!

...Үзән дәрьясы ягыннан җан-фәрманга очкан җайдак пәйда булды. Һәммәсе дә әсәренеп, сагаеп тукталдылар. Җайдак малны тиктомалдан гына болай интектермәс, берәр хәвеф бардыр.

Чапкын егет иярennән төшеп тормыйча да сөрән салды.

— Мангытлар Юныс бинең җәйләвен туздырып бетергәннәр! Бинең үзен, тагын житмешләп ирне турап ташлаганнар! Йөзбашлары хатыннарны көчли, нәүкәрләре булган малны суя!..

Бачман меңне урталай бүлергә әмер бирде.

— Мөхәррәм, Юлай, Низам! Сез биш йөзне Ярык сырт ягыннан алып барасыз. Калганнар белән мин Бәнҗә яклап киләм. Барып җитүгә үк, искәрмәстән, яуга ташланыгыз! Әсирләр кирәкми, тоташ тураклагыз!..

Юныс би җәйләве куе төтен белән каршылады. Мангытлар тирмә-алачыкларның барчасына да ут элдереп чыккан, киез япмалар ялкынга бирешергә теләмичә кара төтен сузган. Мөхәррәм-Юлайлар беркадәр алдарак килеп өлгергәннәр инде. Ярык сырт ягында каты орыш бара. Мангытлар тулгамага алган хатын-кызларны, бала-чагаларны ташлаганнар бугай, чыр-чу килеп, кычкырышып-елап, шулар хәзер җәйләүдән читкә чаба. Сакчыларсыз калган сарык-кәҗә, сыер көтүләре дә иреккә чыккан. Мөгрәп, мәэлдәшеп, һәр якка сибелгәннәр. Тоташ тузан, төтен арасыннан хәтта туганыңны да араларлык түгел.

— Яугирләрем, дошманнарны ура! — дип Бачман тархан аваз салуга ук, болгарлылар мангыт йөзлекләренә арттан ябырылды. Җәягә ук элсәң, ялгыш очуы бар. Болгарлар мангытларны әүвәл сөңгеләр һәм гөрзиләр белән урталайга ярды, аннан кылычлары белән тураклый башладылар. Йөз иллеләп мангыт тулгамадан чыгып качкан иде, артларыннан ташланган болгарларны Бачман тархан тыйды.

— Аларны Мүнкә үзе дә турап ташлаячак. Кайтып, ханнан сөенче алырга өлгерсеннәр инде.

## 2

Юныс бинекеләрне кабат жыеп алгач, ап-ак сакаллы ике-өч карт Бачман тарханга ялварып гозерләде.

— Болай ташлап китсәң, Мүнкә, барыбер, баскыннар җибәреп, җәза алмый калмас. Безне калдырма, үзең белән алып кит?

Бачман чын күңелдән сыкрый-сыкрый дәште.

— Булмый, агайларым. Без бит яу кешеләре. Менә хәзер сезне ипкә-сапка гына китерәбез дә аннан тагын юлга. Мүнкә хан этләре талап киткән җәйләүләр һәм авыллар бихисап. Аларның һәркайсы өчен дә үч алырга кирәк. Эзгә басып, инде алар үч алмасын өчен, безгә тау-кыялар артына качарга да кирәк. Мәңгел этләреннән үч алучы калмый. Сезне ияртә алмыйм. Бигайбә, агайларым...

Ак сакаллы картлар башларын түбән иеп киткән генә иде, йөзбашы Мөхәррәм ак яулыкка төренгән, әмма шашып елаудан инде шешенеп беткән япь-яшь кенә бер кызны житәкләп килде. Бачман аңа текәлде дә корт чаккан шикелле хәрәкәтсез калды. Йә Ходаем! Бучаклы да Алтынчәчкә

охшаган кыз булса-булыр икән! Алтын йөгерткәндәй шундый ук саргылт чәчләр. Елмаюлы бер карашы өчен ярты гомеренне бирерлек зәңгәрсу күк кузләр. Сандугач канатыдай кыйгач кашлар. Арыш кылчыклары кебек озын, куе керфек. Үпкәләп турсайткан шикелле кабарынган алсу, хәтфә ирен. Алтынчәчнекедәй ягымлылык, сылулык һәм тылсым бу кызыйга ничек күчкән икән?..

Мөхәррәм Бачманның күзләрендә кабынган кайнар утны шундук шәйләде дә тарханны беркадәр читкә алып китте.

— Бу — Юныс бинең кызы Аппак икән, — дип Мөхәррәм сүзне ныклы карар белән башлап китте. — Беркеме дә калмаган. Әнисен, сеңелләрен дә турап бетергәннәр. Сыеныр кешесе юк. Ә син, күреп торабыз, Алтынчәчсез калганнан бирле ут йотасың. Ныклап уйла. Бәлки, шушы Аппак җаныңа дәва булыр. Хатынлыкка алсаң, нөгәрдә сине гаепләүче кеше табылачак түгел.

Бачман Ярык сырт ягына төбәлде дә бөтенләй телсез калды. Ул Алтынчәчне югалтканнан бирле утлы табага баскандай газаплана. Янәшәңдә җаныңны җылытырдай хатын пәйда булса, яралар да төзәлер иде сыман. Ләкин, Бачман, син хөррият хакына яу юлына чыккан бер мең ир-егетнең сәрдәре бит. Син хатын аласың икән, аларга да тиеш. Ул чакта син күтәргән меңлек нинди яу гаскәре була да хөррият явыннан нинди генә күләгә кала инде? Өстәвенә, синең янда ике малаең бар. Аларның аналары булган Миңлебикәне Юныс би кызы Аппакка алыштырсаң, Нарык белән Әлсуфый ни әйтер? Юк, барча Болгар иленә бердәнбер башбирмәс һәм җиңелмәс сәрдәр булып калган Бачманның хатын алып, никах укытып уйнарга хокукы юк!..

Мөхәррәм җавап көтә, Бачман һаман дәшми, янә үлчи, янә газаплана. Кара гавәм сүзенә төкерим әле, дисәң, бу кызыкай белән атна-ун көнгә берәр куышка да бикләнеп була инде. Тарханның ярты ел буена җылы, наз күргәне юк. Ярты ел буена йә ияр өстендә тыркылдый, йә камыш шалаш эчендә аунап газаплана. Белеп-сизеп тора: Бачман карар итсә, яклаучысыз калган чибәр кызыкай үзе дә карышачак түгел, яугирләрдә дә сәрдәрне гаепләрдәй ташбаш табылмаячак. Бар илгә бердәнбер булып калган башбирмәс тарханга үлемнән үзе ук коткарган сылу кызның иркә-назын татыса ярыйдыр ла инде, Алла колы! Тик... Нарык белән Әлсуфый да бар бит! Аннары газиз улларының күзләренә ничек күренәсе?..

— Минем янга өлкән угылымны чакыр әле! — дип эндәште кинәт Бачман үзенең йөзбашына.

Йөгерә-йөгерә Нарык килеп җиткәч, аның иңсәсенә кулын салып, әмма барыбер читкә карап тезде.

— Әнә, тегендә Юныс бинең кызы Аппак тора. Аны күрдеңме соң?

Кап-кара бөдрә чәчле, чүтерт-кара йөзле Нарык та кызарынды.

— Әйе, күрдем, әткәй, — диде бөтенләй кыюсыз гына.

— Аның яклаучысы, хәтта сакчысы юк. — Бачман тавышында һични сиздермәде. — Үзе чибәр. Хатынлыкка алсаң да, үкенерлек түгел. Әллә тәвәккәллисеңме?

— Әткәй, нинди хатын алу? — дип кабынды Нарык. Асылда да ул мондый адымга әзер түгел иде. — Мин — ихтилал юлына баскан яугир. Хөрриятне яуламыйча торып, өйләнәчәк түгел!

Бачман чын күңеленнән кисәк сыкрап куйды.

— И-их, юкка, юкка болай кырт кисәсең, улым! Ихтилал, хөррият дип, безнең барыбызның да шәһит китүе бар. Хөррият хакына бар нәселне корытыйкмени инде? Безнең нәселнең, минем оныкларның җир йөзендә калырга хакы да юкмыни? Син үз борыныңнан арыракны күрә белмәгәнгә

генә шулай каркылдыйсың. Минем, синең кебек башбирмәсләр, хөррият яклаучылар болгарлылар өчен алда да кирәк әле. Йөзәр-йөзәр булып, меңәр булып. Мәмләкәтне кабат аякка бастыру хакына, халкыбызны бер учак янына җыеп туплау өчен. Бачман каны, Бачман оныклары менә шул вакытта таләп ителәчәк!

Нарык сынды, ахры, озак көттермичә сорау бирде.

— Алайса, мин ни эшләргә тиеш?

— Синсез калсам, җиңел булмаячак. Болай да күп югалттым. — Бачманның тавышына кадәр тетрәп куйды. — Иллә мәгәр... син янымда булган чагында да җиңел түгел. Бизмәнгә салгандай үлчәп хәл иттем. Мин — яу сәрдәре. Үземә ышанып килгән ирләрне ташлап, кәлтә сыман, ярыкка качарга минем хокукым юк. Ә Әлсуфый белән сез икегез үлем кочагыннан ычкынырга тиеш. Әнә, Юныс бинең чибәр кызын ал да иң әүвәл син пайтәхеткә юнәл. Биләрдә дә безнең кебек хөр һавага сусаган башбирмәсләр табылмыйча калмас. Аннары синең эздән энекәшең китәр. Ул әле кечерәк, аңа күз-колак бул. Илсез-җирсез халык озак яши алмый. Без җиңәргә тиеш!

### 3

Мүнкә хан инде сигез ай буена Идел ярын ташлап китә алмый. Башка яктан агылып килгән хәбәрләр аны ут шикелле талый.

— Гөек хан Юрьев, Ростов, Ярославль калаларын талап узган, диләр.

— Бату хан урысларның пайтәхетен егып салганнан соң Волок Лам, Тверь, Торжок дигәннәрен дә сытып үткән икән.

— Бату ханны хәзер әллә ничә мәмләкәт гаскәрен җыеп та туктатырлык түгел. Ул Чыңгызхан шикелле үк җиһангирга әверелә бугай...

Һәрбер яңа хәбәр Мүнкә ханның мин-минлеген үт шикелле сыта. Башка ханнар җәйрәннәрдәй җитез кәнизәкләр куенында ятып рәхәт кичерәдер, Каракорымга да, үз чатырларына да тау кадәрле нигъмәт ташытадыр. Ә ул монда бер тилемсә тарханны, бүре сыман аулап, ничәмә-ничә айлар уздырырга мәҗбүр. Әй, аяусыз тәкъдир!..

Тәки Мүнкә ханның үзәккәен корытты бу Бачман! Шушы Елаксу тамагына кертеп бикләде дә, төлке өненә алдын-артын чамаламый чумган аю сыман итте. Хәзер Идел аръягына чыгып, мукшыларны, йә булмаса урыс җирләрен дә талый алмый Мүнкә. Артка чигенеп, төмәннәрне колач кебек җәеп орышырга да һичбер мөмкинлек юк. Хәтта, гаскәр өчен авыллардан мал-туар йә ризык талап кайтырга да ирек бирми, каһәр. Бачман — шайтан, җеннәр сыман, һич тоттырмый. Атна саен елан кебек астан гына чагып ала да, күз бугандай шундук юкка чыга. Мүнкә хан аның эзеннән берьюлы бишәр мең җайдакны ияргә күтәреп тә карады. Идел өстеннән дистәләгән ишкәкче, яр буеннан йөзәр-йөзәр күзәтчеләр куды. Юк кына бит, каһәр суккыры, һичбер мәнгел Бачман-шайтанның эзен таба, үзен күрә алмый. Нинди генә җир тишегенә кереп качадыр ул, тәүлекләрне кайсы җәһәннәмгә посып үткәрәдер? — шайтан гына белсен!..

Мүнкә ханны мыскыл иткән сыман, менә, чираттагы чапкын пәйда булды.

— Бачман алае, Идел яклап, ыстанга бәреп керде! Ханиям, бәла! Дала ягына кач!..

Мүнкә тау өстенә менгәч әйләнеп карады да гел шаккатты. Идел өстендә камыш сарган алты-җиде утрау хасил булган. Ничек батмыйлардыр, алар алга-артка таба гел күченеп йөри. Яр читенә килеп җиттеләрме, камыш түтәлләре арасыннан Мүнкә хан ыстанына ук яңгыры ява, мәнгел нәүкәрләре чалгы белән чабылган шикелле, рәт-рәт булып, кырылып кына бара. Атка

менгән нәүкәрләр малларын елга өстенә чыбыркылап куа, тик бичаракайлар, елан күргән сыман, кире чигенәләр. Кыйнауга чыдамыйча суга сикергәнен чоңгыл тартып ала. Күчмә утраулар өстенә сөнге-ук атудан бер файда юк. Хәтта колагына ут элеп очырган сәрпи уклар да, камыш-кәсләр арасына чумгач, чыжлап кына куя. Мәңгелләрнең үч алырга кыжрап сикерүе — бер янагына сугылган мескеннәрнең икенче як янагын куеп торуга тиң.

Бачманлылар менә шулай иркенләп кыйнады-кыйнады да, мәңгелләрнең шәрҗир аткычларны әзерләвен күргәч, икенче як ярга чигенделәр. Мәңгел җайдаклары сайлык табып Иделне кичкән чакта Бачман гаскәреннән җилләр искән иде.

Мүнкә кабат чатырына кайткач, яраланган менбашы килеп керде.

— Мин бер тотык эләктердем, хания. Фетнәчеләр көймәсеннән егылып төшеп калды.

— Апкер! Үзем аның табаннарын теләм! — дип акырды ярсуыннан котырынган Мүнкә.

Әсир төшкән фетнәче дә беләгенә ук кадалып яраланган икән. Сорау алуны җәзалауга чаклы житкермәде. «Син кем? Каян?» — дигән тәүге сорауларга шундук тезеп китте.

— Малмыж атлы елга буеннан мин. Карамбай мин. Кара чирмешләрдән. Сез, барыбер, чирмешнең кем икәнен белмисез дә инде. Алтынбәккә икеләтә салым түләп торган мескен кавемнән мин. Болгар казанчылары ханның казнасына ун сарыктан берсен илтеп бирде, ә без малны шул ук яланнарда, тугайда үстерсәк тә, инде ике сарык. Чөнки без аларның Алласы хозурына күчмәдек, үзебезнең Тулбагыш атабыз белән Мардыш анабызга[6] табындык. Үжәтлегебез өчен безне гомер буе акыртып таладылар. Менә сез «Яса» кануннары буенча малның уннан бер өлешен генә салым итеп җыясыз. Тора-бара арттырмассыз микән? Шуннан чамалыйбыз. Бәлки, болгарларның Аллаһы Тәгаләсенә караганда сезнең Тәңре безгә якынрактыр?..

Мүнкә яңа сорау кузгатканчы ук казначы менбашка әмер бирде.

— Берәр тәпси алтын акчалар керт...

Алтынлы тәпсине тотык Карамбай ягына этеп куйгач, юха телгә күчте.

— Боларның һәммәсен дә берүзеңә бирәм. Азсынасың икән, тагын өстим. Мәгәр миңа Бачман-шайтан качып ята торган урынны әйт.

Карамбайның күзләрендә бер уч күкерт ялкын элдергәндәй ут кабынды. Мүнкә хан билендәге кылычын да зеңгелдәтеп алгач, тотык чирмеш, таудан ычкынган тәгәрмәчтәй кызулана-кызулана, ант сулары эчте.

— Идел Хәзәр диңгезенә барып кушыла торган төштә утраулар бихисап. Бачман шул утрауларның берсе эченә яшеренеп ята. Кайда ул утрау, аты ничек, мин тел белән генә аңлатып бирә алмыйм. Мәгәр чирмеш — аучы, даладагы эзне бүре сыман таный. Мин аны тапмый һәм мәңгелләргә хәбәр итми калмыйм!..

## 4

Бүген дә көн сөенечле үтте, Бачман мәңгелләрнең Каракорымга юнәлгән чираттагы бер кәрванын талап кайта иде. Кәрван сакчыларын кырып бетерделәр, кулга төшкән малны Бачман бер йөз җайдак сагында Тәтеш би белән мәрхүм Юныс бинең җәйләүләре ягына озаттырды. Бүген тархан утраудагы барча яугирләрен дә куптарып маташмаган, үзе белән өч йөзлекне генә алып чыккан иде. Тауар белән киткәннәрне озатканнан соң калган

[6] Тулбагыш ата — мариларда ут алласы, Мардыш ан — җил алласы.

жайдакларга Мең Торнага төбәп кайта торырга кушты да үзе тагын ялгыз Мара белән көрешмәкче булды. Тегесе дә нык сагынган бугай. Әле Гали дусты янына килеп сикеренгән була, әле Бачманны якын җибәрмичә читкә кача. Бачман элегрәк тә әллә ничә тапкыр сынап карады инде. Тархан аңа берәр калҗа ризык ташладымы, горур Мара һичбер вакытта да моның ише капкын-сәдакага ябырылмый, хәтта әле, мыскыл иткән сыман, аңа тибеп китә. Бирсен Ходай, шундый була күрсен. Барыс-капланнардан артып калган, адәм баласы юри ташлап киткән калҗа — дала бүресенә ризык түгел!

Көн кичкә авышкан чакта гына Бачман иплəп сызгырырга мәҗбүр булды. Галигә шул да җитә, соңарырга курыккандай шундук чабып килде. Мара белән хушлашырга да өлгерә алмадылар, Тәтеш биләр җәйләве ягында алты-жиде жайдак пәйда булды. Бернинди дә хәвеф-хафа чыбыркылап кумый, ахрысы, бик көттереп кенә якынайдылар. Бачман төсмерләде: әле бер ай элек кенә ихтилалчылар нөгәренә килеп кушылган Хаҗитарханныкылар болар. Мүнкә юллаган кара этләргә юлыгып тар-мар булганнармы, әллә тауар белән киткән йөзлектәге берәр ир җан биргәнме? — чырайлары корым сарган кебек кара көйгән.

Якынайгач, җайдакларның берсе карашын җирдән аермыйча гына әйтеп салды.

— Йөзлек, мәңгелләрнең бар тауарын алып, Сакмар ягына качты. Менә без, егермеләп егет, аларны туктатырга тырышып караган идек тә, уныбызны шул угърылар турап атты.

— Ничек качты? Ничек инде качты? — дип Бачман тарханның ярсып-шашып кычкыруына каршы шул ук җайдак аңлатмалар бирде.

— Ничек, ничек? Кәрваннан таланган малны алып китүгә үк, чирмеш Карамбай койрыкта баручы Бәнҗә белән Сакмар егетләрен котырта башлаган. «Бачман тархан Юныс бинең кызын үзенә килен итте дә хәзер бар байлыкны шуның җәйләвенә генә ташытачак», имеш. «Тархан кеше — безнең сымак ачыгавыз түгел. Ул таланган кәрваннардан үзенә олау-олау алтын хәзерләп куйган инде. Андый-мондый куркыныч туа калса, Бачман безне аңгыра бәрән урынына мәнгел бүреләренең тәгаменә ыргытып бәрәчәк тә үзе Кыпчак даласыннан әллә кая чыгып олагачак.» Тора-бара Кернәк белән Кашан унлыклары да шул коткыга бирелгән. Кысырбия яланында ызгыш-талаш купкач, йөзбашыбыз Хәйри дә шулар ягына ауды. Ә ахыры ничек беткәнен баштук әйттем инде.

Бачман туфан, гарасат шикелле кайный башлавын тыеп кала алмады.

— Аһ, кабахәт җаннар! Аһ, сораннар! — дип, үзенең бармакларын чәйни-чәйни, ярсып сүгенде ул. Аннары гаярь Галинең касыгына типте.

— Хәзер үк Мең Торнага таба элдерегез! Юлай белән Низам йөзлекләрен куып җитә алсагыз, алар кичекмәстән минем эздән чыксын! Мин сораннар артыннан! Бөркет чебен-черки ауларга тиеш түгел дә бит, сызгырганнан гына куян үлми. Аларны турамый кайтмыйм! Берегез булса да, Мең Торнага кереп, нөгәрне көтәрегез! Соран җаннар җир йөзендә яшәргә тиеш түгел!..

Бачман Галине ак күбеккә батырып чаптырса да, каракларны куып тоталмады. Юлай белән Низам йөзлекләре килеп җиткәч, җайдакларны чылбыр сыман барча якка таратып карадылар, әмма карак качаклар җир астына убылган шикелле бөтенләй юкка чыкты. Сакмар белән Бәнҗәнекеләр дә дала аугире бит, эзне елан сыман оста яшерделәр. Ләкин елан оясыннан чыкмый һәм, мескен корбан табып, чакмый торамы соң!

Ике атна чамасы вакыт үткәч, Бачман ике йөз яугирен Идел буйлап югарыга, Хаҗитарханга таба куган иде.

— Ул яктагы авылларга кыргыз баскыннары ияләнгән, шул кара этләр барча йортны тоташ талап чыккан, дигән хәбәр килде. Ул кабихләр эзен корытып кайтмый булмас...

Бачман бу ике йөз яугирне өч көн буе көтте, гел йокыдан калды, ә тегеләр суга чумган балта сыман булды. Шул төндә генә, ниһаять, Мең Торнага яраланган йөзбашы Мөхәррәм кайтып керде. Аның бәяне жанны өшетердәй салкын, кансыз иде.

— Кыргыз баскыннары, дигәннәре бездән качкан сораннар булып чыкты. Алар — танымаслык. Һәркайсының өстендә бакыр көбә. Алмаш атлары гына да ике йөзгә якын. Арбаларга ризыгын да, шайманын да шыплап тутырганнар. Хәтта алтын да бар. Унбашлары чатырларда яши, калганнар — тирмәләрдә. Сатлык тәре, чирмеш Карамбай да: «Бачман тархан алдында тезләнеп яшәүдән туймадыгызмени әле? Аны житәрлек баеттыгыз. Инде үзегезнең корсак, туган якта калган балалар турында да уйларга вакыт. Безгә кушылсагыз, сез дә кешечә яши башларсыз. Баш өстегезгә эленгән кылыч та юкка чыгар», — дип акыргач, унбиш унлыктагы ирләр сораннар ягына күчте. Мин илле ир белән качып караган идем дә, Кара чишмә буенда Мүнкәнекеләр тозагына эләктек. Мин дә котыла алмаган булыр идем, ирләр ике арага корыч дивар шикелле кереп басты...

Бер тәүлектән соң Бачман тархан утрауда калган биш йөз ирне туплап юлга чыкты. Кара чишмәгә житкәндә сораннар куйган каравылны элмәккә эләктерделәр. Имән кайрысы шикелле кырыс йөзле Бачман бер генә сорау бирде.

— Этләр ыстаны кайда?

— Карасаз яланында, — дигән жавапны ишетүгә, тарханның кылычы күк йөзендәге яшендәй ялтырады, урталай ярылган гәүдә жир өстенә ауды.

— Һәр соранны шушындый тәкъдир көтә! — дип гыжылдады ул аннары, корыган агачлардай катып калган яугирләргә карап. — Илен саткан кабих яшәргә хаклы түгел!..

Карасаз яланындагы качаклар ыстаны читтән караганда хәвеф тудырмады. Бачман инде йөзлекләрне жәя сыман таратып һөжүмгә ташланырга да әзерләнгән иде. Шул вакытта Идел ярыннан да, Хажитархан каласы ягыннан да, өрәк шикелле, Мүнкә хан нәүкәрләре калкып чыкты. Алар умарта күче, кара болыт сыман. Бу чылбырны бер кулына биш сөңге, биш кылыч тотып орышсаң да өзеп чыгарлык түгел. Бачман алаендагы ирләр инде килгән юлга таба чигенә башлаган иде, аларны тарханның жиз сорнай тавышыдай әмере шып туктатты.

— Ике катлы божра ясап, тулгамага басыгыз! Яраланган ирне арттагылар алыштырырлык булсын! Артка чигенү юк!

Яугирләрнең әле һаман мәлжерәп торуын күргәч, Бачман тархан капылт кына үзенең ияреннән сикереп төште. Кулындагы кылычын күккә чөеп, янә оран салды.

— Чигенергә хакыбыз юк, болгарлар! Безгә хөр яшәгән мәмләкәтне кайтарырга кирәк!

Икенче мизгелдә Бачманның яшендәй кылычы тимеркүк айгырның бугазын телеп үтте. Куркудан күзләре акаеп чыккан Гали, бөтен тирә-юньне кара канга күмеп, жир өстенә ауды. Үзе кан чәчрәтеп пошкыра, гыжлый мескен, ә үзе һаман карашын хужасыннан алмый. Бачман, тезләренә чүгеп, аның бәбәкләрен йомдырмакчы булды, айгыр буйсынмады, пыялалана башлаган күзләре белән һаман карап ятты.

— Кичер мине, жаным! — дип кенә пышылдады да Бачман сикереп аягына басты.

Ирләр тыгыз божра ясап тезелешкәч, Бачман тархан көянтәдәй кылычын

күтәрде дә баскын дошманнары өстенә ябырылды. Камышларны ерган каек сыман, мәңгел нәүкәрләренең җиде-сигезен шундук телеп атты. Күзләренең уны белән гел чамалап торды. Әнә, кызыл ком өстенә, имән агачыдай гөрселдәп, йөзбашы Мөхәррәм авып төште. Менә, йөзбаш Курамшаның ачыргаланып кычкырган тавышы яңгырады да мәңгелеккә тынды.

— Бирешмәгез, бирешмәгез, болгарлар! Мөхәррәм, Курамшалар өчен үчне кайтарыгыз! — дип кычкыра-кычкыра, Бачман һаман кылычын айкады, шабыр тиргә батты.

Юк, аңа мәңгелләрнең икенче дистәсен телеп ташларга ирек бирмәделәр. Иярләр өстеннән әллә ничә кыл аркан очып төште дә җиңелү белмәс сәрдәрне мескен тотык итте. Тарханны Мүнкә хан каршына сөйрәп китерделәр. Хан шомырт-кара айгыр өстендә утыра, нәфрәт тулы күзләре акаеп чыккан иде. Әүвәл үз күзләренә ышанмагандай, сүзсез карап торды. Кылыч очы белән Бачманның имән кәүсәседәй юан беләкләренә, иңбашына төртеп-төртеп куйды. Аннары үзен әллә нинди тилемсә корт чагып алды бугай, һич тә көтелмәгән сорауны ярып салды.

— Яхшы сәрдәрем юк, мина күчәсеңме?

Бачманның хан айгыры тарафына төкерүен күргәч, чыгырыннан чыкты.

— Атабыз Чыңгызхан яраткан бер канун бар. «Дошманыңнан аны ирекә җибәреп тә үч алырга кирәк». Гаскәрең кырылып бетте, илең җимерелгән. Синең хәзер беркемгә хаҗәтең юк. Каршыма килеп тезлән! Шул чакта сәрдәрлегең, осталыгың, үҗәтлегең өчен сине гафу итәм.

Өчме-дүртме мәңгел Бачман тарханның иңнәренә килеп асылынды. Сәрдәр аларны чебеш урынына як-якка сибеп атты. Аннары Мүнкә хан каршына килеп басты да гыжылдаган тавыш белән җавап бирде.

— Синеңише кабих этләр алдында тезләнергә мин каранар[7] түгел!

— Әле шулаймыни? — дип кенә кычкырды да Мүнкә кылычын югарыга чөйде.

Шул ук мизгелдә җиңелү белмәс Бачман тарханның башы дала кылганнары өстенә тәгәрәп төшкән иде...

## УНБЕРЕНЧЕ БӘЙЛӘМ

### 1

Караңгы төн уртасы. Чирмешән яры буйлап Биләр каласына җайдаклар чылбыры якынлашып килә. Атларның авызлыклары, өзәңгеләр, кылыч кыннары юкә, каешлардан үргән бауларга уралган. Сафта әмерләр бирүче, хәтта бер-берсенә сүз кушучы да юк. Җайдаклар арасындагы саклык-киеренкелекне малкайлар да тоеп бара, ахры, ялгыш та пошкырмыйлар. Чирәм яр өстендә кайвакытта ат тоякларына тиеп очкан таш тавышлары гына ишетелгәләп куя. Лачынтау итәгендәге ярканатларны да йокы алмый бугай. Бала үксегәндәй кызганыч моң — шулар сукранудыр.

Тышкы ур калдыклары янына килеп житкәч, нөгәрнең иң очында барган җайдак ике кулын шапылдатып алды. Чылбырдагы атлар шундук тукталдылар. Чылбыр уртасыннан тагын бер күләгә алдагы әйдәман янына килеп басты.

— Без нәкъ килешенгән вакытка килеп життек, — дип акрын гына пышылдады алда барган җайдак. — Хәбәр бирәбезме, бераз көтәбезме?

— Көтик әле, Баян, — диде соңрак кушылганы. — Аларның безне юлда тоткарланган, дип уйлавы да бар бит. Ике ел түзгәннән соң инде пайтәхетнең хозурында тору олы газапмыни?

[7] Каранар — кәрваннарда йөк ташу өчен тотылган һәм тезләнергә өйрәтелгән дөя.

— Ике ел буе читтә интексәк тә, менә монда кайткач та җинел түгел икән шул, Җик туганым! Һавасын сулауга ук йөрәк бәргәләнә. Үзебез ук яклый алмадык бит. Пайтәхет юк инде.

— Кабат тергезү өчен кайттык ласа. Бар дәүләтне кабат бастырырбыз!

— Амин, мәргән, амин!..

Ике җайдак та, авыр сулап, калага текәлде. Элеккеге, биек, зур диварлар сүтелеп беткән инде. Айкапу да, Шәрекъ капка да юк. Биләр калдыкларын хәзер бер катлы казык-коймалар белән генә уратканнар. Чирмешән ягына каратып сынар гына капка корганнар да, диварларның дүрт почмагына биек-биек манаралар төзеп бастырганнар. Капка белән манаралар өстендә майлы сүс уралган зур кисәүләр яна. Алар көтелмәгән дошманнарны шомландырырдай көчле ялкын чәчми, шулай да дивар каршындагы эчке урны, сай ерымны, тар күперне яктыртырга ярап тора инде.

Ике сәрдәр дә, сүз куешкан кебек, үзләре алып килгән җайдаклар төркеменә берьюлы күз ташлады. Гаҗәп, анда нибарысы өч йөз яугир генә, ә үзләре әкиятләрдәге явыз диюләрне, аждаһа һәм албастыларны җиңгән пәһлеваннар, баһадирлар булып күренәләр. Ялларында ут яктысы кайтарылып уйнаган чаптарлары да әкияттәге канатлы ат сыман...

Почмак манара өстендәге ачык мәйданчыктан колагына очкынлы мүк эленгән бер ук очып чыкты. Һәммәсе сискәнделәр. Һәрбер җайдак садак, кылычларын барлап куйды. Баян батыр кыр үрдәге булып аваз салды.

— Кор-рыйк! Кыу-уа-ак!

Шул минутта кала диварының дилбегә озынлыгыдай бер өлеше эчке ур арасындагы тар ерым өстенә күпер булып ауды. Ике манара өстеннән биек имән баскычлар да шудырып төшерделәр. Манараларда алдан ук әзерләп куелган учаклар кабынды, кала яны яктылыкка чумды.

— Карлыгачлар, урга! — дип оран салды янартаудай кайнаган Баян батыр.

Җайдаклар чылбыры ташкын булып алга томырылды. Ике йөзләп җайдак каладагылар төшергән койма-күпер өстеннән эчкә бәреп керде. Тагын шундый ук бер төркем каланың асылмалы күпере алдындагы ерым эченә талдан үргән читәннәр, озын, киң баскычлар, йорт түбәсе кадәрле зур-зур киез япмалар китереп атты. Аннары шул сукмактан асылмалы күпер һәм аның ике ягындагы манаралар өстенә ташландылар. Башка якта җәяүле егетләр ыргаклы сөңгеләр, бау һәм баскыч буйлап диварга үрмәләде. Кылычлар зеңләгән, яралыларның илереп кычкырган, кыска-кыска әмерләр ташлаган тавышлар берникадәр вакыт кына яңгырап ишетелде дә һәммәсе дә берьюлы, өстенә бер мичкә су түгелгән учак сыман, капылт кына сүнде...

Гази-Бәрәҗ көтелмәгән мәхшәр тавышыннан каплан сыман капылт сикереп торды. Сәлим, Илһам, Алтынбәк ханнардан калган ташкирмәннең һәр бүлмәсе, зал, чолан, баскычлары җан-фәрман йөгерешкән ирләрнең аяк дөбердәве белән тулган. Шыгавыллар, җансакчылар урталай ярылырга, башларын югалтырга атлыгып тормыйлардыр, әмер биргән, кылычны кылычка орган бер аһән юк. Өрәк сыман ирләр ишек тибеп керүдән җарияләр өнсез калган бугай, шул як бүлмәләрдән чырылдап кычкырган тавышлар ишетелә.

Беренче каттагы болдырда канны катырырдай усал оран яңгырады.

— Бәрәҗ кайда? Сатлык соран кайда?

Бу оранны Газраилнекедәй котсыз яна тавыш күмде.

— Һәммә ишекләрне каплап бетерегез! Кабахәт җан чыгып качалмасын!

Йә Ходаем! Ике ел элек мәңгелләрнең буар еландай корган тулгамасын пәйгамбәр сөңгесе сыман ярып чыккан Җик мәргән белән Баян батырның

кансыз-норсыз әмерләре бит бу! «Алар исән, мәңгелләрнең кара этләренә тоттырмыйча, Таш Билбау өстендәге өркәчләр арасында качып йөри», дигән хәбәрләр бар иде. Менә шулар аннан үч алырга кайтып җиткән, димәк. Бату Рязань өстенә чыгып киткән чакта Бәрәҗ, телен еландай уйнатып, күпме ялынды бит!

— Болгарлар — гомер буе иген игеп, сәүдә итеп, мал көтүе тотып, үз көннәрен үзләре күрергә ияләшкән халык. Алар бил бөгүне, тез чүгүне белми. «Бүре баласын бүреккә салсаң да, ул урманга карый», дигән гыйбрәтле сүзне дә шулар чыгарган бит. Болгарлар хәзер яраланган бүре кебек кенә. Мине шулар олысына әмир дәрәҗәсендәге баскак иттен. Иллә мәгәр болгарлар теш күрсәтми, бил турайтмый яши алмаячак. Гаскәр калдыр миңа, гаскәр калдыр?

— Өч мең татар җиткән! — дип кенә ыргытты улчагында җиңүләрдән күккә менгән Бату. — Этне ач тотмасаң, хуҗасын таламый ул. Халыкны эт хәленә калдырып талаулардан саклан!..

Бату үзе белән Каракорымнан ук ияртеп килгән Майкы бине баскак алай башлыгы итеп билгеләп киткән иде. Күпме генә өркетеп йә юхалап карамасын, Бәрәҗ Майкы бине барыбер үз кубызына биетә алмады шул. Камчы очын аз гына күрсәттеңме, Майкы би, керпе сымак, энәләрен кабарта да баса.

— Мин — кахан арбасына, Чыңгыз хәтле Чыңгызхан янәшәсенә утырып йөргән бердәнбер би! Мине аның Чагатай, Үгәдәй сымак бозык, әрсез малайлары иркәләп үстермәде. Мин — Чыңгызхан шәхсән үзе меңбаш иткән түрә!..

Кайда, ничек эләккән ул Чыңгыз арбасына? — Бәрәҗ моны төпченергә өлгерә алмады да. Майкы бинең үз ыруы Таш Билбау артындагы Чибәркүл дигән урында калган булган. Әүвәл шундагы туганнарын чакырып китерде дә Майкы би, баскак алайның яртысын ияртеп, узган җәйдә Чулман аръягына чыгып тайды. Андагы бер тыныч, ипле елга буенда Бату хан ям мәнзәле[8] калдырып киткән иде. Әлеге елганы бер-ике айдан соң ук Мәнзәл елгасы, дип йөртә башладылар. Майкы би әнә шул Мәнзәл буйларын үзенең тугайлары, шәхси утар итте. Бәрәҗ әүвәл аңа йөгән кидерү өчен Биләрдәге бар баскак алайны ияргә күтәрмәкче булган иде дә, чабуыннан тарткан сыман, артына утырттылар. Яңа төбәк күңеленә һуш килгәндер йә өстәмә терәк тә эзләгәндер инде, Бәрәҗ әмиргә әйтеп тормый-нитми, Таш Билбау ягына янә чапкын куган. Майкы бинең Миас дигән күл буендагы биләмәләрендә дә бик күп туганнары калган булган икән. «Кара Табан» атлы сәер ләкаб таккан би кул астында тагын меңәр-меңәр тирмәдәге татар күчеп килде. Алары Ык дигән үтә салкын сулы елга яры буйлап таралдылар. Хәзер инде Майкы бине иманга китерү, тәртә арасына куып кертү турында хыялланып тору да артык иде. Бәрәҗ әмир бар ачу-үпкәсен, бәхетсез килен шикелле, үз эченә йотты.

Биләрдә торып калган татарлар да печтерелгән тәкә түгелләр бит. Ике ел эчендә аларның һәммәсе дә диярлек башлы-күзле булды. Хәзер инде күбесе бала-чага карый, йортын сала, ихатасын кора. Баскак алайның яртысы кала диварын саклаучы токтавыллар булып саналса да, аларның төнне хатыннары кочагында истирәхәт кичереп үткәрүен Бәрәҗ әмир үзе дә күптән белә. Татарларның диварда калганнары да башын кылыч астына тыгардай томана, тинтәк түгел. Шулай икән, Баян батыр белән Җик мәргәннең әмир сараена бәреп керүе җир убылгандай йә күк йөзендә йолдыз шартлагандай сәер хәлмени соң!?.

...Гази-Бәрәҗ, келәм уртасында яткан кылыч-хәнҗәрләрен эләктереп,

[8] ям мәнзәле — почта, элемтә ыстаны. Анда чапкыннар өчен алмаш атлар да тотылган, билгеле ки, пешекчеләр һәм сакчылар да булган. Минзәлә — ул һич кенә дә 1584 елда урыс баскыннары салган кирмән түгел. Хәзерге кала һәм елга исеме «мәнзәл» атамасыннан калган, дип фаразлана.

чабылдыклар артына яшерелгән тар бүлмә эченә сикереп чыкты. Артта, котырынып тибүдән, имән ишекләрнең күгәннәреннән чыгып очкан тавышы ишетелде.

— Кайда бу алабай? Кая кереп качты сатлык Бәрәж? — дип үкерде Баян, тәрәзә пыялаларын зеңгелдәтеп.

Бәрәж моны юньләп ишетмәде. Ау этедәй, ул — һәр михнәткә күнегеп беткән сукбай, бу минутта ташкирмән дивары аша сикереп качкан иде инде.

## 2

Колгали Биләр диварыннан читтәге иске генә йортта яшәп ята икән. Жик мәргән белән Баян кергән чакта сәет өстәл артында язып утыра иде. Кояш офыктан дилбегә буе күтәрелгән инде, ә моның өстәлендә һаман зәйтүн маена салган мамык яна. Батырларны күргәч, каурый каләмен ташлап, урыннан купты. Күзләрен сыпырып алгач кына төсмерләде бугай, ике кулын сузып якынайды.

— И-и, Баян угълан илә Жик икән лә! — дип җәелеп елмаюы ук эчкерсезлек һәм садәлек учагы кабызгандай булды. — Көткән, көткән идем.

Ирексездән, ике батыр да Колгалинең килеш-килбәтен күз уныннан йөгертеп чыгарга мәҗбүр булды. Бетерешкән сәет, нык бирешкән. Чәчләре казанга салып кайнаткан җитен төсле ап-ак. Сәет аларны кисү, кыскарту турында уйламыйдыр инде, чәчләр, чук-чук булып, иңнәренә яткан. Сакалы да ак кар сарган сыман. Ярый, сакал-мыекларын пөхтә итеп кисеп чыккан әле. Кашлары, маңгае, яңагы, беләкләре — һәммәсе дә акбур белән тотып агарткандай. Күрәсең, сәет кояш яктысында бик аз хушланадыр. Шуңа күрә кыяфәте базда яткан бәрәңгеләр үсентесе кебек.

Киемнәренең нинди хәлгә калуы сәетнең үзенә, мөгаен дә, кирәкмидер инде. Колгали тезләре ышкылып беткән, соры төстәге киндер чалбар кигән. Өстендә — җиңнәрен терсәккә тикле кайтарып куйган ап-ак киндер күлмәк. Чүәкләрен дә аякларына оекбашсыз, пулаларсыз гына элеп алган. Сукбай да сукбай, бу да дәрвиш инде!..

— Без синең хәер-фатиханы ишетергә килдек, олуг сәет, — дип тәүге сүзне Баян башлап китте. — Синең ошбу мәгарәңә дә төнге яу шаукымы кереп ирешкәндер.

— Ишеттем инде, оланнар. Ничек ишетмисең? — дип сәетнең баш кагуын күргәч, Баян батыр җилкә-иңбашларын кабартыбрак тезде.

— Без Болгарны мәңгел этләреннән азат итү өчен яу башладык. Яугирләргә син кайчандыр үз фиркаңдәге азатларга кушкан ләкабләрне бирдек. «Карлыгачлар!» Җәнүб яктан иң беренче моңны алып килүчеләр. Болгар җиренә кайткач, иң беренче оя коручылар. Хөрләр, тоттырмаслар! Бик ошый бу безгә! Үзең моны хәтерлисең булыр, олуг сәет?

— Хәтерләмимени! — диюгә үк Колгалинең иреннәре дер-дер килеп куйды. Яшьлек хатирәсе йөрәгендәге утлы күмерләрне актарып атты бугай. — И-и, карлыгачлар булып очынган заманнар да бар иде шул. Ни үкенеч, җиңүләргә ирешеп сөенмәдек!

Баян дәвам итте.

— Без хәзер барча вилаятьтә учак кабызабыз. Һәр аймактан, һәр авылдан нөгәр җыймакчыбыз. Бату явы зур гарасат, шыксыз туфан сыман безнең өстән тәгәрәде дә үтте. Гарасатлар ел да кабатланмый. Батуга, әнә, яңа илләр, яңа җирләр тансык. Аның әллә нинди ләһләр, мәҗарлар, юнаннар ягыннан безнең Болгарга кабат әйләнеп кайтуы да шикле. Ятып калганчы, атып кал, дигән бабакайлар. Без дә куян түгел! Батуның ерактан селкеткән

бармагыннан өркеп, куак арасына йә базларга кача-кача гомер итеп булмас! Синең дә шушы ук мәсләкне тотуына тамчы да шикләнмибез. Болгар халкы сиңа мөкиббән булып яши. Син утка керсәң, Болгар утка керә. Азатлык явын син әйди башласаң, барча гавәм безгә кушылачак. Әйдә, безнең әләмебезгә әйлән, олуг сәет!?

Колгали әлләни көттермичә, анык җавап бирде.

— Мин әләм булып йөрү яшеннән узган инде, оланнар. Мин сез кузгаткан ихтилал фетнәсен дә хуплыйм. Баскын мәңгелләрдән арынмаса, Болгар атлы илнең офыгы юк. Әмма... әмма мондый мескенлекнең тагын, тагын кабатлануы да мөмкин ләбаса. Бүген мәңгелләрне кусак, азат калҗа өстенә угъры урысларның килеп җитүе бар. Алар мондый явызлыкны байтак исбатлады. Болгарны аякка бастырсак та, куәт вә бердәмлек өчен көрәшне туктатырга һич ярамый безгә. Ялгыз агач, ялгыз манараны йә тегесе, йә монысы килеп аударачак. Берләшергә кирәк! Барча мөселманнар белән берләшергә! Мәгърур йодрык булып, тимер калкан булып, таш кыялар булып! Шул чагында гына исән сакланырбыз. Шул чагында безне мәңгеле дә, урысы да таптап үтә алмас!

Күкерт кебек кабынган Колгалинең сүзләреннән Җик мәргән дә, Баян да әсәренде. Ирексездән, инде алар үзләре дә мамык сыман кабынырдай хәлгә килеп җитте. Җик мәргән салкын канлырак, очлы күзлерәк шул, шундук сорап куйды.

— Өстәлеңдә «Сөннәр иле» дигән кереш белән тамгаланган өч-дүрт дәфтәр ята. Ялгышмасам, элек Бәкер атлы, Идрис атлы хәзрәтләр сөннәр илен кабат тергезү, барча мөселманны бер генә, әмма ярты җиһанны берләштергән мәмләкәткә туплау уе белән янып йөргән булган. Суар каласындагы Сөн мәчетен дә шулар төзегәннәр. Еллар үткәч, син дә шушы ук ниятне, зур мәсләкне калкытасың түгелме соң, сәет хәзрәт?

— Менә, аңлаштык та! — дип Колгали хәтта учларын шапылдатты, канатланып китте. — Тач менә шул мәсләк. Мин гомер буе фәкать Болгар илен генә хөррият-сәгадәтле мәмләкәт рәвешендә күз алдына китереп ялгышканмын. Чәчәкләргә күмелгән, гөрләп үскән ялгыз утрау булмый! Иртәме-соңмы, аны елгадагы ташкын юып китә. Безне бердәмлек вә уртак динебез генә коллыкка төшүләрдән, юкка чыгулардан коткарачак!..

Ишек катына утырып, дога укыдылар. Сәет хәзрәт:

— Изге юлга! — диде.

Аны Җик мәргән дә, Баян да кабатлады. Ләкин һәркем бу сүзләргә мәгънә-ниятләрне үзенчә салган иде.

### 3

— Син Биләрдә кал инде, туганкаем. Мин Майкы би янына үзем генә барып карыйм әле. Ячы карчыклар да бер көтү карачкы ияртеп йөрмиләр бит. Тупсадан ук борсалар, хурлыгың да шаһитларсыз була.

Ике ир дә, камыт-йөгәннәрен салган ат шикелле, иркенәеп, дулап көлештеләр. Беренче булып, мәргән житдиләнде.

— Майкы безнең җирдә. Нигез корырга дип казык каккан чын ир кичә генә тол калган хатыннар шикелле иләс-миләс булмас. Яңа толлар гына «теге узгынчы алып китмәсме, монысы тукталмасмы» дип, җил капкасын да япмый, абзарын да җыештырмый яши торган була. Мәгәр үзенең иясез ат сымак утырып калганын аңлауга, тәртә арасына кереп баса, йөкне тарта башлый. Майкы бинең дә хәзер безнең җырга кушылмый чарасы юк. Менәр тирмәле ыруны тегеләй-болай күчереп йөртергә — ул бит ястык түгел. Шуңа күрә син, Баян дус, аяк терәп, хуҗа булып сөйләш. Иманым камил, Майкы би яңа нигезенә игелексез калмас...

Ике баһадир ир бер-берләрен кочып хушлаштылар. Баян юлга чыкты. Ул иярткән йөзлектәге ирләр Чулманны кичүгә үк хәйран калды. Вәт әкәмәт! Бу яктагы Зәй, Мәләкәс, Игәнә дигән елга ярлары тоташ шомырт икән! Әллә вакытында туры килгәнгәме, елгадагы сулар ике яр читенә тезеп куйган ап-ак мамык кибәннәре уртасыннан җырлап ага кебек. Барча агачлар да күбәләк шикелле шау чәчәккә төренгән, алар арасыннан хәтта каусәләрен, ботакларын да ныклап күреп булмый. Бар яр буен тутырып төклетура, бал кортлары оча. Чәчәкләр исеннән, һава сафлыгыннан баш әйләнә!..

Майкы би үзенең ыстанын Мәнзәл елгасы буендагы Зәңгәр тау ышыгына илтеп корган икән. Тауның аты юктан алынмаган. Янына барып житкәч, Баян да нык шаккатты. Биек кыяны гел зәңгәрсу төстәге җепләр чуарлаган ташлар хасил иткән. Шунын хикмәтедер, кыяның очына тәрәлеп узган каурый болытлар да читтән караганда гел зәңгәрсу булып күренәләр. Әкиятләргә кергән Алып тауларын, Каф тауларын эзләп йөрисе юк, җәннәт шушыдыр ул!

Майкы би белән ике дилбегәдәй сузылып аккан Пар Чишмә янында күрештеләр. Инде күптән чәчләре чаларган, хәрәкәтләре салмакланган юантык ир икән. Бер сәер гадәте шундук күзгә ташланмыйча калмый. Ул адым саен диярлек йә кашларын, йә керфекләрен өскә таба сыпырып, төзәткәләп тора. Кош каурые сыман куе, озын булып үскән каш-керфекләр, мөгаен, күрергә дә комачаулык-мазар тудырадыр инде.

Ул Баян батырның сәфәре турында да хәбәрдар булып чыкты, ике кулын сузып, үзе каршы килде.

— Ишеттем, батыр, ишеттем мин синең киләсеңне, — дип һич яшереп тормыйча, елмаеп күреште ул. — Дала кешесенә күп колаклы булып яшәү хаер...

Майкы би «әйтим микән», дигән сыман беравык кына тукталып торды да, каш-керфекләрен өскә сыпырып куйгач, янә дәвам итте.

— Түнтәреш ясап, Биләрнең астын-өскә китерүегез хакында да беләм... Бәрәҗне качырып кына хата ясагансыз... Оясыз эт кире кайтмый калмый...

— Кайтса, үз башына. Аны тотып асардай элмәк әзерләрбез, — диде Баян, сынатырга теләмичә.

— Һәм кирәк тә! — дип эләктереп алды Майкы. — Хыянәте өчен элегрәк тә бер качкан бит инде. Хәзер янә качкан. Анын үзен фәрештә итеп тоя башлавы бар. Кандаланы ул кан эчеп шартлаганчы сыту мәслихәтрәк...

Майкы би казан янына чакыра башлагач, Баян батыр янә бер шаккатты. Ул аш мәҗлесен якындагы берәр тугайлыкта корганнардыр, дип күзаллаган иде, Майкы би Зәңгәр тау астындагы таш куышка таба юл күрсәтте. Куыш авызына барып кергәч, Баян батыр пәри туе күргән сыман авызын ачып катты. Әттәгенәсе! Бу яшерен мәйдан таш куыш кына түгел, ә биш йөз, бер мең җайдакны да чабып барган көенә үз эченә йотарлык олы ялан, елга сыман очы-кырые күренмәс таш мәгарә икән!

— Би, син читтән, ерактан килгән кеше бит. Бу мәгарә турында кемнән ишеттең дә аны ничек таптың? — дип Баян батырның аптырап соравына Майкы, гадәттәгечә, кашларын сыпырып кына җавап тотты.

— Мин Таш Билбауга мөкиббән кеше, батыр. Анда яшәгән чагында Ябалак тау, Сынык Терсәк, Сенертау дигән өркәчләрен, Тишек Таш, Салкын Таш, Янган Таш атлы куышларын ташлап китә алмый иза чигә идем. Нөркәй картка рәхмәт! Ошбу мәгарәне мина ул күрсәтте. Моны күргәч, Таш Билбауга кайткан кебек булдым... Ары китмим инде... Алай-болай булса, җеназамны шушы мәгарә түренә яшерергә кушам.

— И-и, Майкы би, сиңа-миңа җеназа турында уйларга иртәрәк бит әле! — дип Баян бүлдерсә дә, хуҗа кеше башын чайкап куйды.

— Алай димә, олан. Мәгарә иясе бар. — Майкы би тавышын шундук акрынайтты. — Ул ошбу куыш хакындагы серне чит-ятка ачкан бәндәләрне бәхилләми бугай. Нөркәй картны ун көн элек кенә бер чакрым эчтәге чокырдан табып алдык. Анда Күкертле Таш атлы өркәч убылган да ярымсукыр Нөркәй шул чокырга ауган. Без тапканда җаны очкан иде... Васыятында мине телгә алып китте микән инде? Мәгарәнең серен сиңа ачтым... Шулай булгач, хәзер инде минем чиратымдыр.

— Житте, Майкы, җитте! — дип Баян батыр үзен тыя алмый кычкырырга мәҗбүр булды. — Исән көе беркемгә дә тәһлил укымыйлар. Чират җитәр, шул чагында күз яшьләрен түкми-чәчми генә хушлашырбыз. Ә тәндә җаныбыз барда бездән соң каласы туган җир вә бездән соң киләсе оныкларның хөрлеге һәм сәгадәте хакында кайгыртырга кирәк!..

Кайнар ризыклардан авыз иткәч, Баян әңгәмә тәртәсен Майкы би һич көтмәгән якка юнәлтмәкче булды.

— Гыйззәтле би, әйдә, бәян итче. Сине Чыңгыз кахан арбасында сәфәр кылган, дип сөйлиләр. Шул сүз хакмы?

Майкы канәгатьләнүдән юан корсагын сыпыра-сыпыра, кет-кет килеп көлде.

— Эләкте, эләкте андый бәхет, Баян олан, — дип башлады ул, озак көттермичә. — Мәгәр ул хәлдән соң унбишләп җәй дә, унбишләп кыш та үтеп китте инде.

Сизелеп тора, Майкы бигә ерак хатирәгә бирелү рәхәт иде.

— Харәзем шаһы Мөхәммәт турында ишеткәнең бардыр, анысына шикләнмим дә. Хак булса, анысын Хәзәр дингезенең дулкыннары йотты. Ә Мөхәммәт шаһның Җәләлетдин атлы угылын Чыңгыз җиһангирнын бер генә сәрдәре йә нойоны да исән килеш тозакка эләктерә алмады. Ул хактагы хәбәрләр Болгар иленә тикле килеп җитте микән?

Җәләлетдин солтан турында беркадәр хәбәрдар булса да, Баян батыр баш чайкап белмәмешкә сабышуны отышлырак адым санады. Әйдә, Чыңгызхан яраны булып йөргән меңбашы ул солтан тәкъдирен ничек бәян итәр, нинди бәя бирер, тыңлап карыйк әле.

— Чыңгыз кахан, тәхетләрне әйләндереп аткач, нинди дә булса солтан-әмирләрнең исән калуына юл куймады. Мин аның элегрәк Торгытай, Җәмуга, Тогрул, Көчлек атлы куркыныч көндәшләрен юк иткәнен беләм, — дип дәвам итте Майкы. — Җәләлетдин солтанны да кулга төшерми торып, ул җанына тынычлык тапмаячак иде. Шул җәһәттән Җәләлетдин артыннан төмән өстенә яңа төмән куды. Мәгәр Җәләлетдин чүл бүресеннән дә хәйләкәррәк, еланнан да шомарак сәрдәр булып чыкты. Чыңгызханнын, гомумән, шушы солтаннан да тәкәбберрәк һәм башбирмәс дошманы булмады да бугай...

«Валлаһи, Чыңгызханга мөкиббән кеше бит бу!» — дип уйлап куйды Баян, әмма бүлдермәде.

— ...Җәләлетдин әүвәл Хорасанга качты. Андагы атабәк кызының кулын сораган да, ханәкәдән бигрәк, атасыннан утыз меңле гаскәр талап алган. Чыңгызхан фарсы даласында моны куып тараткач, Җәләлетдин солтан Газнә белән Кабул әмирләре алдында янә кияү булып йөргән, боларыннан тагын утыз мең жайдак туплаттырган. Бу яңа гаскәре белән Җәләлетдин Пәнҗәр янында хәтта Чыңгызхан төмәннәрен дә туздырып аткан иде. Җиңүдән исереп, Җәләлетдин уч төбен күрсәткән, җайдакларына Чыңгызның барча олауларын таларга ирек биргән. Бакыр теләнеп үскән кара гавәмнең борыны алтынга төртелсә, күзе сукырая. Дала пуштуннары белән кала әфганнары байлык өчен берсен-берсе кыра башлаганнар. Ахырда ике як та Җәләлетдин солтанны ташлап киткән...

Майкы би тын алды. Юк, ул ике сәргаскәр өчен дә яна-көя, вакыты-вакыты белән аңа әле Җәләлетдин, әле Чыңгыз якын иде бугай.

— ...Мин ул чакта Чыңгызхан эргәсендә йөзбашы гына идем. Җәләләтдинне әүвәл Газнә каласында тулгамага алдык. Ул чылбырны ярып, чыгып качты. Һинд дәрьясы янында янә куып җиттек. Җәләлетдин үзенең сигез яшьлек улын барча гаскәр алдында телеп атты, ә хатыннары белән кызларын кыя өстеннән елгага ыргытып бәрде. Ахырда үзе дә аты белән елгага сикерде. Чыңгызхан оран салса, без Җәләлетдинне куып тота идек. Чыңгызхан юл куймады. «Бу — һәр падишаһ үз эргәсендә күрергә хыяллана торган сәргаскәр», — ди...

Майкы янә тынгач, Баян батырның түземлек чиләге тәмам коргаксыды. Кыбырсынып сорау бирүен бөтенләй сизмәде дә.

— Чыңгызхан Җәләлетдиннән үч алалмый калдымени инде? Ә син үзең кайчан Чыңгызханның якын яранына әйләндең соң? Берни сөйләмисең.

— Ә син һаман яшь әтәчләр сымак икән, Баян! — дип көлемсерәде Майкы, башын чайкый-чайкый. — Сабырлык дигән иң отышлы коралны һаман юнәтмисең.

Баян батыр үзенчә каршы чыкты.

— Сәүдәне, хәятне, гомумән, бар халыкны минем кебек ташбашлар гына алга сөйри ала. Койрык булып сөйрәлүче сабырлар һәм куркаклар — тегермән канатларын әйләндерә торган су ташкыны түгел!

— Аһ, берәгәйле итеп әйттең, аһ, шәп әйттең! — дип Майкы би туарылып көлде.

Каш-керфекләрен кат-кат сөрткәч кенә, элек салган сукмагына кайтты.

— Мин елгадан Җәләлетдиннең бер сеңлесен исән-сау көенә табып чыктым. Аты Хансолтан иде шикелле, әгәр ялгышмасам.

— Кит инде! Шунын өчен сине Чыңгызхан меңбашы иттемени?

— Юк, анысы өчен түгел. Ул Хансолтанны чатырында йөртте, кармады да, кайткач, Батуның әтисе Жучига хатынлыкка биреп куйды бугай. Гәрчә Хансолтан өчен дә сабак булырдай хикмәтле сүз әйтте. «Дошманыңның хатыны, кызлары, туганнары дошманыңның канына караганда да татлы һәм шифалырак.»

Баян һаман түзми тыкырдатты.

— Ә Җәләлетдин солтан белән ниләр булып бетте? Син меңбашына кайчан әверелдең?

— Ә Җәләлетдин, — дип эләктереп алды Майкы. — Җәләлетдин булып калды инде. Елан кабыгын салса да, гадәтен үзгәртми бит. Бу да нәкъ шул. Һинд дәрьясы буйлап Дәһлигә чаклы кача да шунда һиндлар солтаны Илтотмышның кызын хатынлыкка ала. Моның гыйбрәте шул — Чыңгызхан нәкъ шуның алдыннан гына, шушы кызны сорап, Илтотмыш янына илче куган икән. Илтотмыш солтанның бу рәвешчә төкерүен белгәч, Чыңгызхан алты-җиде төмән белән безне Дәһли каласына өстерде. Хәвефне сизенеп алган Илтотмыш кияве Җәләлетдингә нибары дүрт мең генә җайдак бүлеп биргән. Бабасына ачудан күркә сымак кабарынган кияү бу юлы инде Чыңгызханга түгел, ә Баһдад хәлифе Насыйрга каршы яуга чыккан. Имеш, Газнә янындагы яу барышында син генә миңа гаскәр бирмәдең дә, мөселман халыкларын мәңгел этләреннән якламадың. Юлда барышлый, Җәләлетдин өйләнүне тәмам кәсеп иткән. Фарсыларның Борак белән Җанги атлы солтаннары янында тукталып, тегеләрнең кызларын да хатынлыкка алган. Фарсылар борайланган. Җәләлетдин — килде-китте генә кияү түгел, Харәзем тәхетенә кайтып утырачак шаһ лабаса! Җәләлетдингә кушкан нәүкәрләре кырык мең чиген дә үтеп киткән. Бу чаклы көч белән Җәләлетдин, билгеле

ки, хәлиф Насыйрның ике төмәнен тетеп салган инде. Багъдадны унике көн буе тулгамада тотып караган да, җинә алмагач, Хәзәр диңгезе ярыннан әзериләр янына чыгып киткән. Юл уңаеннан Тәбрис каласын яулаган. Тәбристән атабәк Үзбәк чыгып качкач, аның хатыны Мәликәне, көчли-көчли, үзенә хатын итеп алган...

— Бәрәкалла! Машалла! — дип янә бүлдерергә мәҗбүр булды Баян. — Хатын өстенә хатын! Ул Җәләлетдин солтан нәсел айгыры булганмы соң әллә?

Майкы бинең хуплап куюдан башка чарасы юк иде.

— Валлаһи, нәсел айгырыдыр инде! Айгырдыр, валлаһи! Гайрәт тә, дуамаллык та булган шул үзендә. Явына йөрергә дә, хатыннар янында сырпаланырга да ничек җитешкәндер?

Майкы би берникадәр вакыт тын утырды. Аның күңелен яна хатирәләр айкый иде, ахры, авыр сулап куйды. Күзләрен ящереп кенә сүз башлады.

— Безне Чыңгызхан Илтотмыш солтанга каршы озаткан иде бит. Аның филләренә каршы тора алмадык. Өстәвенә, коточкыч эссе интектерде, эч китүдән меңнәр җәфаланды. Ахыр чиктә, кире борылып кайттык. Бер төмәнгә махсус бурыч җиткерелгән иде — Җәләлетдиннең куенынңан Илтотмышның кызын урлап кайту. Без Тургай даласына әйләнеп кайткан чакта Җәләлетдин инде Насыйр хәлиф өстенә барып ята иде. Багъдад янында гына куып тоттык. Яуга кермәдек без. Җәләлетдин Насыйр хәлифнең ике төмәнен пыр туздырган чакта без Җәләлетдиннең олаулары өстенә ябырылдык. Илтотмыш солтанның чатыр почмагына поскан кызын мин әләктердем. Аннан, арттан җеннәр куган сыман, томырылып чаптык. Чыңгызхан ул вакытта тангытлар ханы Шидүргә каршы яу чабарга уйлаган. Аны Сары Чапан дигән өркәч янында гына эзләп таптык. Ә-әй, Чыңгызның ул вакытта сөенүен күрсәң! Илтотмышның кызын чатырдан чыгармады. Мине менбашы, би итте, Миас, Чибәркүл яныннан биләмәләр бирде. Кияү егете сымак, ай буена Чыңгызханның бөркәвечле арбасында кузлага гына утырып йөрдем. Иллә мәгәр бәхетнең елмаювы эт кояшы сымак кыска гына булган. Чыңгызхан ауга китте дә шуннан тәмам сырхауланып кайтты. Ә ахырда Шидүр ханның еландай кызы аңа агу бирде. Шулай, тәкъдирдән узмыш юк. Рәнҗү, каргыш дигәннәре ханнар башына да җитми калмый икән...

Ике җанлы толым сыман сузылып аткан Пар Чишмә янына чыккач та, байтак вакыт буе, бер-берсенә сүз катарга шүрләп, тын йөрделәр. Майкы би мангаен, янакларын көмештәй су белән юагач кына, бәянен үзенә кирәкчә очларга ниятләде.

— Җәләлетдин солтан — җиһанда Чыңгызхан үч алырга өлгермәгән берденбер сәрдәр булып калгандыр, ахрысы. Без инде аны тәмам күздән җуйган идек, хәбәрләре һаман килә торды. Ул Чыңгыз кахан китеп барган елны Чыңгызның төпчеге Тули хан кул астындагы мәңгелләр гаскәрен яртылаш кырып салган. Әгәр энекәше Гаязетдин яу кырын ташлап качмаса, Җәләлетдин Тули хан төмәннәрен тулысынча турап бетерәсе булган. Тули хан соңыннан үзен аклау өчен «безнең сафта мәңгелләр юк иде», дигән хәбәр тараткан, ди. Һи, кесәдән йодрык күрсәтеп кенә ирлек кайтса икән! Акча кебек, йә бар бит ул, йә юк. Ходай Тәгалә Тулиларга тиешлесен дә Җәләлетдин солтанга биреп куйган бугай. Ошбу, ару белмәс Җәләлетдин, Тули төмәннәрен куып таратканнан соң, Каф тау өстендәге гөрҗиләр мәмләкәтен пыр туздырган. Рәсүдәнә атлы патшабикәләре Тифлис каласына кереп бикләнгән, ди. Җәләлетдин вәкарь, хәерхаһлы кеше, ул хатыннарга каршы сугышмый, янәмәсе. Әмма миңа кияүгә чыксаң, Тифлисыңа тимим, дигән шарт куйган бу. Рәсүдәнә чәтә-карман килеп каршы торган. Ахырда

Җәләлетдин Тифлиска бәреп керергә мәҗбүр булган инде. Рәсүдәнә дә ничарадан бичара кыяфәттә Җәләлетдиннең түшәгенә яткан...

Майкы би, бәяненнән тукталып, чишмә суын эчкән булды, корых-корых килде. Баян батырның агач балбал сыман түзем генә утыруын күргәч, тагын бер кабынды.

— Җәләлетдин бу вакытта бөтен Каф тавын, андагы әзери, гөрҗи, әрмән, алан, чиркәсләрне үзенең тез астына салган була инде. Хәтта, Җучи хатынына әйләнгән сеңлесе Хансолтан да ана: «Мин Үгәдәй кахан белән сүз беркетеп куйдым. Алар синең белән туганлашырга да, Җәйхүн елгасы буйлап мәмләкәтне урталай бүләргә дә әзер. Яудан туйган булсаң, ризалык бир», — дигән хат җибәрә. Әмма борыннарын байлык-нигъмәт чишмәсенә төрткән хан-солтаннар суга сусаган аттан да яман бит ул. Аларны шул исерткеч чишмәдән аерып буламыни!? Җәләлетдин-күркә дә Үгәдәй кахан белән солыхтан баш тарткан. Ә Җәләлетдиннең гайрәтеннән өшәнгән гарәп солтаннары, үзләренең гаскәрләрен кушып, бу башбирмәс сәрдәр өстенә бердәм ябырылганнар. Яссы Җамаяк дигән бер далада Җәләлетдиннең гаскәрен тулысынча кыйратып бетергәннәр. Җәләлетдин тулгамадан ялгыз көе генә чыгып качкан. Әле шул ялгыз көенә дә аны эзәрлекләп барырга курыкканнар. Җәләлетдин Каф таудагы Айдар атлы бер калага кайтып, яңа гаскәр тупларга ниятләгән. Ләкин кала капкасына якынайган чакта мона каршы унбиш-егермеләп көрд юлбасары килеп чыккан. «Мин — солтан. Хәзер җибәрсәгез, соныннан һәрберегезне алтын белән күмәм!» — дип Җәләлетдин вәгъдәләр дә биреп караган, ди. Вәгъдә иткән алтын — томаннар эчендә, ә солтанның көмеш көбәләре, алтын белән бизәлгән йөгән-иярле аты инде кулларына килеп кергән. Бер юлбасар сөңге белән кадап үтергән башбирмәс сәргаскәрне. Тәкъдир күпсенгәндер. Күк йөзендә очкан дәү бөркетне, ялгышып кына җиргә кунгач чакта, үләксә козгыны чукып харап иткән...

— Аһ, шаккаттырдың син мине, гыйззәтле Майкы би! — дип Баян батыр бик озак тын утырганнан соң гына телгә килде. — Җир йөзендә нинди пәһлеваннар, үзенең илен хөр һәм азат итеп күрү өчен җанын бирергә әзер торган әүлияләр булган! Татар белән болгарның да шулай җиһан селкетерлек, халыкны кузгатырлык Җәләлетдиннәре үсеп чыкмасмени!?

— Алай мескенләнмә, — дип Майкы би кулын Баян батырның иңбашына салды. — Безнең Җәләлетдин — син инде ул. Булмасаң, бул! Мин Җәләлетдин турындагы бу кыйссаны бәйнә-бәйнә итеп юкка сөйләмәдем. Биләрдә тагын берәү син кайтканны, мин килгәнне көтә. Анысы Җик мәргән. Алла боерса, без барча Идел буен уятырбыз әле!

Баян батыр һаман ышана алмыйча сорап куйды.

— Болай булгач, син дә безнең белән инде, ә, Майкы би?

— Минем бүтән төрле Ватаным юк, Баян. Мина да зынҗырларын салган, азат халкы, азат моңы булган Болгар кадерлерәк!..

Инде хушлашырга җыена башлагач кына, йокыдан уянган сыман, Баян капылт сорап куйды.

— Ә Кара Табан? Кара Табан сиңа кушыламы? Әллә аның янына да мин барыйммы?

Майкы янә туарылып көлде.

— Вәт әкәмәт! Әй, бу «озын колак»! Газиз әле үзенә яңа йорт та салып өлгермәде, ә ләкабе бар Болгарны айкап чыккан икән!

Баянның шәрә хатын күргән малай сыман аптырап торуын шәйләп, инде яңа бәян сөйләргә мәҗбүр булды.

— Асыл аты Минлетимергазиз йә Газизҗан аның. Чәчләре сагыз сылагандай чем-кара, бөтен тәне корымдай каратут булганга, үсә төшкәч,

Кара Газиз, дип тә йөрттеләр әле үзен. «Кара Табан» дигәннәре — яна ләкаб кына. Анысы өчен Чыңгызханның беренче угылы, Батуның әтисе Жучига әҗерле без...

Майкы би бүкән сыман юан гәүдәле бит. Аягурә тору читенрәктер инде, Пар Чишмә буендагы бер түмгәккә барып чөмәште бу. Кашларын сыпырып куйгач, җинел элдереп китте.

— Кара Газизнең абыйсы Насретдин дә Жучи төмәнендә бер меңбашы иде. Жучи аңа да Миас күле буеннан биләмәләр бирде. Мин Газнә, Бәһдад тирәсендә яу кылып йөргән вакыт, Насретдин — Менкышлакта. Мөхәммәт шаһны сасы пумалалап куган бер орышта Насретдин әрәм булган. Хан чаклы хан бүлеп биргән җәйләүләрдән колак кагарга татар тинтәк түгел. Абыйсы Насретдин җәйләүләрен үзенә сорарга дип, Кара Газиз Жучи ханның чатырына киткән. Жучи, билгеле ки, кабул иткән моны, барча гозерен тыңлап бетергән дә шундук ярып салган. «Безнең «Яса» кануннары буенча син Насретдиннын тол калган хатынына өйләнергә тиеш. Ул хатынны алсаң, сиңа җәйләүләр дә кала, киртәләр дә бетә», — дип аңлатмакчы булган. «Юк, мин җингине алмыйм! Насретдиннын ул еланын куенга керткәнче, мин сазлыкка качып яшәргә дә риза!» — дип акыра икән Газиз...

Баян колакларын тырпайтты, күзләре шарланып чыкты. Чит-ятлар язмышы турында сүз барса да, кызык, гыйбрәтле бит. Алла сакласын, үзенә дә, бәлки, шундый тәкъдир язар.

— Аннары Газиз Жучига еландай килен турындагы кыйссаны бәян иткән. Теленең зәһәрлегенә түзә алмыйча, киленнәрен коедагы аждаһа янына илтеп салган ата белән ана турындагы ул кыйссаны син дә беләсеңдер. Ахырда коедан качкан аждаһа теге карт белән карчыкның тәрәзләрен кагып уятканмы?. «Коеда яшәрлегемне калдырмады, үз оямнан куды. Зинһар, алып китегез аны өегезгә, мине коткарыгыз?» — дип ялварган бит әле. Менә шушы кыйссадан гыйбрәт алып, Жучи мине дә кызганыр, дип өметләнгән Газиз. Мәгәр юкка. Ярсуы чыккан Жучи, Насретдиннын тол хатынын кертеп, боларның икесен дә түшәккә салырга әмер биргән. Ни галәмәт, Газиз генә түгел, җинги дә нык карышкан. Бактың исә, Насретдиннын хатыны инде күптән бер көтүче белән азгынлана икән. Шуңа ябышып чыгып, Насретдиннын җәйләүләрен көтүчегә бирергә хыялланган. Моны белеп алгач, Жучи яланда учак кабызырга боерган. Аннары Газиз белән җингәсен утлы күмер өстенә бастырып биеткән бу. «Кара Табан» дигән ләкаб Газизгә менә шуннан йокты.

— Ә җинги? Җингине Кара Табан үзенә алганмы соң? — дип сорады Баян кабаланып, күнелен тырмалаган кырмыскалар кытыклавына түзә алмыйча.

Майкы кул селтәде.

— Алмый кая барсын? Ханнар үзләренең көенә тормаган киреләрне бер дә яратмыйлар. Хәер, нигә моны сиңа сөйләп торган булам?..

Баян иярге менәр алдыннан Майкы би белән кочып хушлаштылар. Майкы вәгъдә бирде.

— Ике көннән соң ике мең җайдак белән синең эздән чыгам.

## 4

Нократ елгасының ике як яры да бүген утлы таяк тыгып болгатылган кырмыска оясыдай гөжләп тора. Таң атканда искитмәле хәбәр әүвәл Нократның уң ярында утырган Түбән Сөн авылын дулаган ат шикелле аякка бастырган иде. Аннары түбән авылныкылар елганың арлар ягына күченгән Югары Сөндәгеләргә яр өстенә басып оран салды.

— Пайтәхеттән елдыр чапкын килде! Олуг сәетебез Кол-Гали хәзрәтләре үзенен бер мөриден юллаган. Аны нәкъ менә безгә атап, махсус куган икән.

Ул олуг сәетебезнең өндәмәсен игълан итмәкче, ди. Бар инсанны яр буена җыеп бастырыгыз! Йөзбаш белән иллебашларны монда чыгарыгыз! Өндәмә нык мөһим, сәет аны шәхсән Сөннекеләр колагына атап юллаган, ди...

Ике яр арасында дистәләгән көймә-каеклар, яшь киленнәр кулындагы тегәрҗепләр сыман, тыз да быз күчеп йөри башлады. Һәртөрле сукалау, гоман купты.

— Биләрдә Баян илә Җикән атлы ике батыр Бату хан калдырган әмир Бәрәҗне турап ташлаганнар. Шулар Болгарны кабат аякка бастырмакчы икән.

— Баян илә Җикән эргәсенә Ык буенданы Майкы би белән Кара Табан да унар мең тирмә ияртеп килгән, диләр. Ул ташбашлар ил өстенә козгын чакырмаса гына ярый инде!..

Бермәлне Түбән Сөннен Чишмә урамыннан мәчет мәйданына таба чаптарын йөгәненнән генә элэктереп атлаучы яшүсмер бер егет төсмерләнде. Ана, ике яклап, олыс башлыгы Байбүләк би белән йөзбашы Бәдри дә ияргән. Күрәсең, чапкын әүвәл олысби йортына тукталгандыр да, чәе-коймагыннан авыз иткәч кенә җыен алдына чыкканнардыр инде.

— Мөхтәрәм җәмәгать! — дип игътибарны башта ил агасы Байбүләк җәлеп итте. — Пайтәхетнен яна хуҗалары, безне санлап, Нократ буендагы авылларга чапкын җибәргәннәр. Олуг сәетебез Колгали хәзрәтләренең дә безгә гозере бар. Әйдә, ил агаларының өндәмәсен күндәмлек вә дикъкать илә генә тынлыйк әле.

Чапкын мәчет болдырына сикереп менүгә үк, Сөннекеләр колак кашып кына шикләнделәр. Моның борын астында кара мыек төртеп кенә килә, егет кара гавәмне уятырдай саллы сүзләр әйтә алыр микән?

— Мөхтәрәм сөнлеләр, заманында бар җиһанны дер селкеткән ирләр!

Егет әле бар көтүне уятырдай гаярь айгыр түгел, бәлки яшь тайныкы сыман әле ныгып җитмәгән, базмас тавыш белән кычкырса да, сөннекеләр шундук сагайдылар. Нинди җиһан селкеткән кавем турында сүзләр кузгата бу?

— Кайчандыр безнең Аттила атлы сыңар гына җинелү дә белмәс җиһангирыбыз булган. Шәрекътән кузгатып килгән сөн кавеме илә гаребтәге барча халыкларны үзенең тез астына бөгеп салган ул. Сөннәр дип макталган шул бабаларыбыз юнаннарны да, мажар илә готларны да җиңгән. Румнар пайтәхете янына барып җитеп, хәтта аның кайсарына да йодрык селкегәннәр. Сөннәр шәрекътән алып гаребкә чаклы булган барча мәмләкәтләрне дә дер селкеткән, хан вә кайсарлары падишаһыбыз Аттила хозурына килеп, күз яшьләрен түгеп егълаганнар...

Түбән Сөннекеләр дә, югары авылдан йөзеп чыкканнар да, билгеле ки, әлеге кыйссалар хакында берни белми, ләкин барыбер дә үзләре бакчасына юнәлтелгән мондый мәдхияне тынлап тору аларда истирәхәт тойгылар уята иде. Байтак ирләр бер карышка үскән кебек булды, «мин җиһангирлар токымыннан булам, агай-эне, син белеп тор», дигән кыяфәттә бер-берсенә үтә вәкарь караш ташлаштылар.

— Әмма ләкин Аттила атлы бөек бабабызны агу биреп харап иткәннәр шул. Җиһангирсыз калгач, сөннәр көчсезләнгән. Дошманнар аларны чеби кәтүедәй вак-вак төркемнәргә бүлеп бетергәннәр. Элеккеге бөек сөннәр, Котрагъ атлы болгар әмиренә ияреп, менә шушы Нократ, Чулман буйларына да күчеп килгән. Сез менә шул бөек сөннәр, бөек Аттиланың токымнары! Пайтәхетез Биләр каласында Баян илә Җикән атлы сәрдәрләр илне мәнгел этләреннән хали кылу өчен зур яу башладылар. Олуг Мөхәммәтгали сәетебез дә сөннәр илен кабат торгызу нисбәтеннән аларга үзенең фатихасын бирде, фәтва әйтте, догаларын кылды. Өмет барча Этил, Чулман, Нократ

дәрьялары, Кыпчак даласы буйлап таралышкан гаярь сөнлеләрдә. Сезгә дә хәзер кабат уяныргa, ил сагына бөек Аттилладай кузгалырга вакыт!..

Чапкын сүзләре әле сөнлеләрнең зиһен тәрәзәсен кагарга өлгермәгән иде, ахрысы, ирләр каккан казык кебек һаман тик тордылар. Мөрид, үзенең чаптарына күз сала-сала, янә берничә авыз сүз ташлады.

— Олуг сәетебез Сөн дәрьясының ярлары буйлап та берничә чапкын куды. Анда да сезнең борадәрләр яши. Мин үзем хәзер Казан кирмәненә төбәп юлга чыгам. Ил төкерсә, күл була ул, дигән бабакайлар. Болгарыбызны хали мәмләкәт итеп аякка бастыруга ирешербез, амин!

— Амин! Ярабби Ходаем, амин! — дип кушылды бар мәйдан.

Чапкын күздән югалып, беркадәр тын алуга, йокыдан уянган янартау шикелле, дәррәү сатулашырга тотындылар.

— Карга сыман каркылдап, ил өстенә яңа тилгән чакырмасак ярый да бит үзе! — дип бер саграк ир җим ташлаган иде, аны ярсу әтәч сыман чукып ташладылар.

— Ялгыз көе генә биләрлеләр күлнең төбен күккә ассынмыни? Сыңар бармак белән энә тотып та, сыер җиленен дә капшап булмый. Берләшергә кирәк, туганкайлар!

— Ил белән бергә атласаң, адашмассың, дигән борынгылар. Туй корганда табын түренә менеп, җеназада мич артына качып, гомер сөреп булмас.

— Тегермән туктады, дип кенә иләкне ташламыйлар. Биләр харәбәләргә әйләнде дип, Болгар иле яшәүдән туктамады лабаса! Илнең төп йортына кабаттан ут капканда без читтән генә кул жылытып утырыйкмени инде? Оныкларыгызның, кабер өстенә килеп, безнең буынга бәддога укуы бар. Туйларны ил белән үткәрәбез икән, яуга да ил белән!..

Икенче таңда Байбүләк би канаты астына баскан ике йөз җайдаклы нөгәр Биләр каласына төбәп юлга чыкты.

### 5

Ярык Таба атлы киң яланга барча меннәр чыгып тезелешкәч, Баян батыр һич тә көтелмәгән карар әйтеп салды.

— Жиһанда бездән алда гомер кичереп киткән бабайларнын чалбар балагыннан бет эзләп маташу, үзебезнен булдыксызлык өчен аларны гаепләү — зур зирәклек түгел. Пайтәхетебез таш тутырылган ике катлы диварлар, ике катлы ур вә ерым белән уратылган иде. Урысларда, әзери, гөрҗиләрдә Биләрнеке кебек ныгытмалар бөтенләй юк. Алар безгә өлге, үрнәк түгел, үзләренең язмышларын үзләре кайгыртсыннар. Әмма Биләр тулгамада калгач, аның пешеп җитмәгән, йомшак якларын да байтак татыдык шул. Урлары, ерымнары икешәр катлы булгач, алар ермак алайлар һөҗүмен яшен сыман күз ачып йомганчы арада үткәрергә, дошман тәненә ук йә хәнҗәр булып кадалырга ирек бирмәде. Иң яманы — мәңгелләр очырган шәрҗирләрдән бүрәнә диварларга ут кабынды, кала эчендә төзелгән йорт-лапаслар салам кибәнедәй дөрләп янды. Бер тырмага ике кат абынмыйлар. Яңа кирмәнне Биләр харәбәләре өстенә салып булмый. Ут капмасын өчен һәм үзебез дә янып үлмәс өчен, яңа кирмәнне таштан-комнан күтәрү отышлырак. Аны нигезли башлау өчен мәңгелләрне якын китермәстәй текә кыя кирәк. Жик мәргән белән икәүләп без тирә-юньне йөз мәртәбә айкап чыктык инде. Лачынтау янәшәсендәге мең баскычлы кыядан да ышанычлырак бүтән кыялар юк. Без яңа таш кирмәнне менә шуның өстенә күтәрергә тиеш. Ул барча тирә-якка, далалар өстенә җимерелмәс калкан һәм болыннар хуҗасы булып балкып торсын!..

Баян батыр белән Жик мәргән сайлаган текә тау, асылда да, гаять биек һәм мең баскычлы икән. Тау түбәсе тик бер яктан гына ачык, анда дала

ята. «Монда тирән ерым казырбыз, үр яктагы чишмәнең суын тутырырбыз», дип, бердәм килештеләр. Ә таунын калган өч ягын ерым булып аккан инешләр дә, берсе-берсе арба зурлыгында булган чуерташ өемнәре дә саклый. Житмәсә, чуерташлар арасында кайсы — тартә, кайсы дилбегә буена житкән зирәк, имән, чикләвек, шомырт агачлары үсә. Мондый табигый чытырманлыкны мәнгелнең тимер жәядән[9] очырган көрәк сабы чаклы уклары да ерып чыкмалы түгел, жир мае тутырган шәржир чүлмәкләре дә агач кәүсәләренә бәрелеп ярылачак.

Ирләр беренче ташларны дивар нигезенә жәя башлауга ук, Колгали сәет бик гыйбрәтле кыйсса бәян итте.

— Сез беләсез булыр микән, балакайлар? Әнә, теге зәнгәрсу ташлар астыннан бәреп чыккан инеш «Изгеләр чишмәсе» дип атала бит, — дигән аның тәүге сүзләрен ишеткәч тә, күлмәкләрен салып, тиргә батып эшләгән бар егетләр бердәм сагайдылар.

— Бәрәкалла! — дип каудар сүз кушканы Биләр тирәсендә үскән егет булды, ахры, шундук каршы төште. — Ә без аны әле Каурый чишмә, дип атап йөри идек, сәет хәзрәт. Имеш, жәнүб якка очкан ике аккош шушында тукталган да ял итәргә уйлаганнар икән. Юньсез аучы килеп чыгып, берсен аткач, икенчесе күккә күтәрелгән. Мәгәр чишмә буенда яткан сөйгәненең жансыз гәүдәсен ташлап китә алмый интеккән, ди. Күктә әйләнә дә бер каурыен жиргә очыра, жилпенә дә икенче каурыен төшереп жибәрә икән. Бөтен чишмә өсте каурый белән тулган. Ә берзаманны канат очларында каурыйлар гел беткән дә, күктәге аккош та үзенең сөйгәне янына егылып төшкән. Имеш, «Каурый» дигән ат та шуннан чыккан икән. Без аны шуна калыплап, Каурый чишмә итеп белә идек.

Хәзер инде Колгали сәет үз калыбын якларга мәжбүр булды.

— Матур кыйсса. Ләкин аны яшь кияүләр, яшь киленнәр уйлап чыгаргандыр. Шул табарак тарта. Ә минем ише, чәчләре чаларганнарга «Изге» аты кыйммәт. Ә ул менә бу рәвешле туган.

Колгали мыек чылгыйларын ялмап куйды. Каз бәбкәләре сыман, ирләр олуг сәет тирәсенә жыелып урнаштылар.

— Безнең өскә элек ойрот[10], кыргыз алайлары да күп килгән бит. Урыслар да кабат-кабат килде. Моннан кырык ел элгәре килгән яуларында мин аларның бер кенәзләрен дә барып күрдем әле. Әткәй аларның кенәзләре янына солых сорап барды, мин кечкенә булгач, үзе белән алды. Сабый бала иярттсәм, үзенә үлем хафасы янамас, дип уйлагандыр инде. Ә урысларның бер кенәзе үлем түшәгенә менеп яткан, сәгатьләре дә санаулы гына калган. Шуны күреп чыктым. Ул бераздан тынды. Урыслар шуннан соң гына Биләр диварыннан кире чигенделәр...

Чал Колгали кирәкмәс кишәрлекне сукалавын чамалады бугай, кулын селтәп куйды.

— Әй, нигә моны сезгә сөйләп торам әле? Изгеләр чишмәсе иде ләбаса минем тоткан мәслүб. Шул, дошманнар элек тә бик күп килгәнлекне искәртмәкче идем. Менә шуларның берсе Болгардагы авыл-калаларны да, мәчет-мәдрәсәләрне дә вәйран итеп чыккан. Биләрдәге Әйшә абыстай мәдрәсәсендә белем эстәүче жиде кыз бала шушы тау башына менеп яшеренгән. Шуннан ук очырып, явыз дошманнарның ярты гаскәрен кырып бетергәннәр. Баскыннарның сәрдәре нык ярсыган. Тулгамага алгач, бичара кызкайларны аккош урынына тетеп салганнар шул. Аларның вафаты турында әтиләре, әниләре, барча туганнары ишетеп алган. Туганнарының өермә булып килүен ишетүгә, дошман үз артыннан жен кугандай качкан.

---

[9] Тимер жәя, арбалы жәя — арбалет.
[10] Ойротлар — бүгенге калмыкларның ерак бабалары.

Туганнар тау башына менгәч, газиз кызларының җансыз гәүдәләренә тап булганнар. Ярсыган бер әти, үкенүдән ни кылырга белмичә, кулындагы чукмарын тау башыннан аткан. Менә шул чукмар төшкән урында чишмә бәреп чыккан. Илен яклап шәһит киткәннәр — һәрчак изге бит ул. Җиде бичара кызга бәрабәр, әлеге инеш тә «Изгеләр чишмәсе» булып калган...

— Җиде кыз бала дошманның ярты гаскәрен кырып салган, диген. Ил хакына шәһит киткән, диген. Вәт, бу кыйсса ичмаса! — дип тел шартлата-шартлата, ирләр янә таш тәгәрәтергә, дивар корырга кереште. Кыздырып тору, ашыктыру артык, боларның һәммәсен Колгали кыйссасы учак сыман кабызган иде инде...

Эш агымын төш вакытында кояш тотылгандай янгыраган яңа хәбәр бүлде.

— Бачман тархан угылы Нарык тархан Биләргә биш мең тирмә кыпчак алып килгән!

Кыятау өстеннән төшсәләр, Ярык Таба иңкүлеген офыкка чаклы сузылып киткән бөркәвечле арбалар чылбыры каплаган. Чатыр япмалар астына поскан кыз-кыркын әле һаман чит-ят ирләр алдына сикереп төшәргә кыймый-базмый сыман. Әмма кузла һәм иярләрне ташлаган ирләр яңа таш кирмәнне төзүчеләр белән кочаклаша-кочаклаша күрешәләр. Божра уртасында — Нарык белән Аппак. Кыпчаклар килү хакында Баян батырга белән Җик мәргәнгә дә хәбәр иткәннәр, билгеле. Чишмә сыман кайнаган халык төркемен ерып, божра уртасына шулар килеп керде. Шап та шоп китереп иңнәренә сугышкач, ирен читләренең колакларына чаклы сузылуын да тыя алмыйлар.

— Син Бачман тарханның тач үзе икәнсең! Чапкын юллаганга атна-ун көн дә үтмәде, бөркет сыман шундук килеп җиттең! — дип Баян батырның баш июенә каршы Нарык тархан тыенкы рәвештә генә җавап тотты.

— Һе, сез әткәйнең бик борынгы көндәшләре ләбаса! Яшь чагында сезнең, парлап, минем әткәйне изәргә кыҗрап йөрүегезне беләм. Килми кара! Аннары сез мине дә килеп тукмыйсыз бит.

Җитдиләнгәч, кистереп өстәп куйды.

— Бер арбаның ике көпчәге кебек, без, кыпчаклар, һәрчак сезнең белән!

## УНИКЕНЧЕ БӘЙЛӘМ

### 1

Бату ханның бүген алтын тәхетләрдә кукраеп утырырдай кәефе юк. Бату кукраеп күрсәтердәй лаеклы дошманы да юк бит әле аның! Кияү каласы янына килеп җитүенә ун көн үтте инде, ә тоташ һөҗүм турында әмер ташлау — җиһангир хан өчен түбәнчелек, хурлык!

Бату кулына әсирлеккә төшкән вак кенәзләр, әлеге кала турында юлда чүбек чәйнәп, күпме баш катырды!

— Изге Киев — элек барча урыс җирләренең башкаласы иде. Кызыл Кояш Владимир ике гасыр элек христиан динен дә шунда кабул иткән. Хәтта Византия кайсары да, үз тиңедәй санап, аңа кызын хатынлыкка бирергә мәҗбүр булган. Киевтагы София белән Печера Лавра соборларын да кайсар юллаган ташчылар төзегәннәр. Киевтагы олуг кенәз элек син тез астына салган Суздаль, Владимир, Рязань, Мәскәү калаларын да үз кубызына биетеп тота, урыс җирендәге йөзләп кала аның биләмәсе булып исәпләнә иде. Әрсез Куллы Юрийның малае Андрей гына, бер гасыр элек зур яу белән килеп, челпәрәмә китереп китте пайтәхетне. Аңа нәрсә? Ул Әрсез Юрийның кыпчак хатыныннан туган малае бит. София соборындагы иконаларга, баскыч култыксасындагы алтын япмаларга хәтле урлап бетерделәр. Андрей

аннары пайтәхетне Владимир каласына күчерде дә куйды. Киевка көн бетте. Днепр ярында ялгыз ана каз шикелле утыра инде хәзер...

Киев каласына якынайган саен, юньсез хәбәрләр ешаеп, Бату ханның жанын өтәләде.

— Ярослав кенәз, Киевны якларга дип, Новгород каласына, үзенең улы Александр янына да чапкын юллаган икән дә бит, тегесе атасы ягына карап төкергән, ди. «Елан еланны чакмый». «Абзыйсы Юрий кенәз Владимир каласы белән Суздальны сакларга чакыргач, минем атай шундый хәйлә белән качып калган иде. Ә мин нигә, авыртмаган башка тимер тарак эзләп, Ярославка ярдәмгә барыйм әле?» — дип әйткән, ди Новгородтагы улы. Ярослав шуннан ары Чернигов, Галич, Каменец калаларына да чапкын куып караган, һәрбересе «безне дә үз артыңнан упкынга сөйрәмә, ялгыз көе кадал», дип кенә жавап жибәргәннәр. Аптыраудан, Ярослав кенәз Киевны ташлап качкан. Владимир каласына барып, башсыз калган бертуган абыйсы Юрий урынына, барча урыс жирләренең олуг кенәзе булырга исәп тота икән.

— Урыс жире моннан ары мин төзегән Урданың бер олысы гына булып саналачак! Миңа кенәзләрнең олугы, вагы да юк! Әле мин куйган очракта да, алар баскак кына! — дип Бату хан үкереп караса да, файдасы бик тимәде.

Бату хан — Хәзәр дингезе, Таш Билбау артындагы барча илләр һәм далалар хакиме бит, хәбәр китерүче чапкыннар аның каршына килмичә, кемгә барсын инде?

— Хужасыз калуыннан файдаланып, Киевка Чернигов кенәзе Михаил бәреп кергән, — дигән хәбәр килеп житкәч, Бату хан әле шаккатмаган иде.

Хужасын атны иярләүче жайдак табылырга тиеш, дала хакиме гажәпләнерлек моның нәрсәсе бар? Әмма чираттагы яңалык Бату ханны өстенә кайнар су түгелгәндәй өтеп алды.

— Михаил Галич дигән каланы улы Ростиславка калдырып киткән булган. Тегесе Галичны гына азсынган да, Перемышль атлы кала өстенә барып, аннан туганы Даниилны куган. Даниил, жанвар урынына, яклаучысыз калган Галичны эләктергәч, Ростивлав, жебегән, мажар ханы Бела янына качкан...

Бату хан тәмам пошаманга төште. Нинди хәл бу? Бүгенме-иртәгәме, Бату хан барыбер барча урыс калаларын да яулап бетерәчәк. Аның унга якын төмән белән Киев өстенә якынлашуын белеп торалар, әмма, үләксә калдыгын бүлешә алмыйча сугышкан эт өере сыман, һаман бугазга-бугаз киләләр, бер-берсенең канын коешалар. Чыңгыз бабай бик хак әйткән икән. Болар ише вак-төяк халыкны бер түбә һәм бер камчы астына тупламыйча торып, үзара ызгыш-талаш белән үзара кан коештан котылу юк!..

Бату хан Киевка Переяславль ягыннан якынлашкан иде. Гөек белән Мүнкә төмәннәре Тын елга буйлатып килеп житте. Гөек, Мүнкә, Байдар, Бучек, Бүре төмәннәре Идел белән Тын елга арасындагы барча калаларны сытып үткән, мукшы, әзери, касога, яс, алан[11], балкар, ингуш халыкларын буйсындырган, хәтта Көбә үзән һәм Кырын Атауны да читтә калдырмаган. Әмма Мүнкә хан баш сәргаскәрдән үч алырга әзерләнеп килгән диярсең, ул жавап тоткандагы соңгы сүзләр Бату йөрәгенә агулы ук кадалгандай итте.

— Кыпчакларны гына куып тота алмадык. Китән ханнары бөтен тирмәләре белән Киевка качып китте. Ул Галич кенәзе Мстиславның кызын алган булган. Шул бабасының култык астына посып котылырга ниятлидер инде.

[11] Касогалар — бүгенге чиркәсләр, яслар, аланнар — осетиннарның бабалары.

— Кыпчаклар — безнең кан дошманнар! Алар — безнең көтүчеләребез булырга ант суы эчкән кавем. Унжиде ел элек Кәлтә буендагы яудан да качып котылдылар. Аларны кырып бетермичә торып, безгә тынычлык киләчәк тә түгел! — дип чал Сүбүдәй батыр ярсып кабынса да, Бату хан аны ипкә-сапка китерердәй генә җавапны тиз тапты.

— Карга, каркылдап, үз башына үлем чакыра ул. Мин ул Киевтагы урысларны җасус җаннар җибәреп котыртмадым. Кыйналасылары килмәсә, ишәк сымак, таякка килеп ышкынмасыннар иде. Кыпчакларны үз канатлары астына алганнар икән, хәзер әҗәтләрен кан коя-коя түләсеннәр инде!..

Бату хан, нәкъ менә шул таләпләрне куеп, Киев каласына илчеләр куган иде. Көтелмәгән кара хәбәр кайтты.

— Илчеләрнең барысын да суеп үтергәннәр!..

Бату шартлар дәрәҗәгә җитте. «Илчегә үлем юк, үлем юк!» — дип күпме тәкрарлыйбыз, ә урыслар бу дала канунын колагына да элми. Унжиде ел элек Сүбүдәй батырның улын бүрәнәләр астына салып таптаганнар иде, хәзер илчеләрне суеп юк иткәннәр. Гафу итеш бетте, мәрхәмәтлек кипте!

— Төмәннәрне яуга әзерләгез! — дип үкереп җибәрде Бату хан, үзен-үзе бәйдә тота алмыйча. — Урыс алайлары Суздальдан бирле, әрәмтамак булып, гел койрыкта гына сөйрәлеп килә. Аларны алга куегыз! Бу кавемне өсләтеп торасы юк, алар бер-берсенең башын ашарга күптән өйрәтелгән. Чигенәләр икән, кылычтан үткәрегез! Юха елан яшәргә тиеш түгел!..

Шул сәгатьтә үк бер сораны Киев ягына качкан. Караңгы төшүгә, төнге торгак итеп Үзи аръягына куелган менлектән исән калган җайдаклар кайтып җитте.

— Китән төмәннәре чылбырны ярып чыкты! Кырык меңгә якын кыпчак ире мажар ханы Бела куенына качты. Киев кенәзе булып йөргән Михаил да алар белән бергә шылган икән...

Һәр тарафка уткүз чапкын кугач, берникадәр тулыланган хәбәрләр кайтардылар.

— Бела Китән өчен үч алуларыннан курыккандыр инде, ул кыпчакларны Үзи дәрьясы буйлап ераккарак куган. Алар шунда үзләренә-үзләре кала һәм кирмәннәр корырга тиешләр, ди. Ә Киевта хаким итеп куярдай бер генә кенәз дә калмаган, барысы качып беткән. Хәзер кара гавәм ниндидер Дмитрий атлы боярга «безне коткар», дип ялвара икән...

Бату янә баш түбәсенә күсәк белән орган шикелле аптырашка калды. Нинди эт — баш, сыер — аяк булган кавем соң бу? Илне имәргә дисәң, хужа тиз табыла. Ә якларга дисәң, юньсез кумак сыман, барысы да кача. Көч куймыйча, кан коймыйча гына үзләре хыялланган оҗмахка күчмәкчеләр. Ай-һай, мөртәт сораннар! Сезне Бату хан әзерләгән кайнар тәмуг көтә!..

Ә бу Киевларын нишләтергә инде? Чатыр корып, әләмнәр күтәреп, үзеннең бирегә килгәнлекне сиздерәсең икән, хурлыгыннан качып кала алмыйсың. Кул астында унбиш төмәне булган баш сәргаскәр Бату Киевтагы бер хөрәсән бояр белән бил алышкан, дип бар җиһанны сасытып бетерәчәкләр! Батуның инде ун төмәнне урысларның Чернигов белән Галич, әллә нинди Ладыжин белән Каменец атлы калаларын камарга, мажар ханының тылына керергә озатып җибәрүен исәпкә алучы бәндә табылачак түгел. Гөек белән Мүнкә чапкыннары бар Каракорымны аякка күтәрәчәк! Үгәдәй каханына төкерәсе! Бал чәчәге кебек сылу Түрәкинә алдында хурлык бит, бар җиһанга оят! Нинди хәйлә табып котыласы? Ни кыласы?..

## 2

Бату ханның Үзи ярына корган тирмәсенә Сүбүдәй килеп керде. Йөзе корымлы мич эченә кереп чыккан сыман кара көйгән. Тавышы да гыжлап кына чыга.

— Болгар жирендә син баскак итеп калдырган ишәк килеп житкән. Кем, дип инде, Бәрәж! Болгарлар Биләрдә фетнә күтәргән дә бу бозау Бәрәжне алып ыргытканнар. Ул ахмак, урыс чабатасы сыман өстерәлеп, монда килеп житкән. Йә, ул сарыкны нишләтәбез инде?

— Тирмәмне ул дуңгыз исе белән сасытасым килми! — дип Бату хан, баш түбәсен ишек ниргәсенә бәрә-бәрә, тышка атылып чыкты. Көчле яктылыкка сөрлегүдән күзләре дә юньләп күрмәгәндер, жиз торба тавышы чыгарып, сөрән салды.

— Кайда ул кабахәт? Сасы көзән кайда?

Шыгавылда торган ике нәүкәр Гази-Бәрәжне, көчек урынына сөйрәп, Бату ханның аяк очларына китереп ташлады. Жебегән качакның киемнәре хәер эстәүчедән дә яманрак теткәләнеп беткән. Чәче, сакаллары сазлык төбеннән тартып чыгаргандай укшыткыч һәм пычрак. Ике күз төбенә дә бармак башы чаклы эрен каткан. Авыз-борын тирәләре үләксә чемченгән этнекеннән хәтәр. Бу адәм актыгы карап торуга ук жирәнгеч, шакшы иде. Бату йөзен читкә борып кына сүз ташлады.

— Үзеңне аклардай сәбәп табалдыңмы?

— Мин барысын да син кушканча эшләдем, ханиям. Баян батыр белән Жик мәргән генә буза куптардылар. Колгали сәетенә чаклы шулар яклы. Биш мең нәүкәр бирсәң, мин барысын да үз эзенә салам. Башлыкларын дарга үзем асам. Биш мең нәүкәр... биш мең... — дип көчек сыман шыңшыган сатлык жанны тагын да тынлардай көче калмагандыр, итек үкчәсе белән генә Бату Гази-Бәрәжнең чыраена типте.

— Чыңгыз атабыз «елан үз агуыннан үлә», дип әйтә торган иде. Чынлап, дөрес икән. Бу дуңгызны читкә алып китеп ботарлагыз! Сасысы яланга йокмасын! Үләксәсе козгыннарга калсын!

— Ханым, ханиям! Биш кенә мең, биш мең, — дигән мескен тавыш бер сулыш алганчы гына ишетелде дә бөтенләйгә тынды.

Бату хан Сүбүдәй ягына борылып әмер бирде.

— Мин Киевны синнән башка да алам. Ә син ике төмән ал да Болгар иленә ашык. Тупларны алырга онытма, аларны да әләктер. Явызлык күрсәтмик дип, моңа чаклы туплар кулланырга кыймый йөргән идек. Сабак өчен, хәзер Биләрне жир белән тигезләргә кирәк!.. Читлектән чыгып качкан арысланнан да куркынычрак бер ерткыч юк! Кабат читлеккә әләкмәс өчен ул юлында очраган һәр жанварның бугазын чәйнәячәк!.. Начар үрнәк — йогышлы чир сыман. Болгарларның безнең сыртка пычак кадавы да, утлы таба өстенә бастырып биетүе дә мөмкин. Әгәр Болгар чире башкаларга йокса, Чыңгыз бабам мәмләкәтеннән берни калмаячак! Ашык син, карт юлбарыс, ут капкандай, корт чаккандай ашык! Юньсез куакны кисеп ташламыйлар, йолкып аталар бит! Болгар илен вәйран итми торып, безгә көн юк!

## 3

Явыз дошман турындагы хәвеф Биләргә Сүбүдәй Борын-Инешкә якынлашкан чакта ук килеп житте. Иң яманы шул — биләрлеләр кыятау өстенә кора башлаган таш кирмән әле һаман төзеп бетерелмәгән, бер атна чамасы элек кенә булып узган бәхетсезлек аны бау шикелле өзеп аткан иде.

Бер меңбашы нәкъ мәнгелләрнеке шикелле үк шәржир чүлмәген сынап

карамакчы булган да, аны чи каешлар белән тарттырылган аткыч өстенә куеп, кыятау түбәсенә очырган. Үксез баланың, чалкан егылса да, борыны каный, диләр, хактыр инде. Чүлмәк тау түбәсендә әлле-мәлле генә эләгеп торган зур таш астына туры килгән. Дары шартлаудан үгездәй олы таш, урыныннан ычкынып, аска тәгәрәгән. Юлда тагын дистәләгән, йөзәрләгән ташларны иярткән. Ә ул янартаудай ташкын яңа кирмән диварын өзеп кенә калмаган, йөзгә якын ирне дә йомычка урынына изеп-сытып үткән.

Әүвәл аеруча Майкы би ярсыды.

— Мин Чыңгызханнан алган бер мең ирне монда түкми-чәчми алып килдем, берсенә бер тузан кундырмадым. Ә шуларның утызы сезнең тауда кирәксез әҗәл тапты. Хатыннары, балалары каршында ни дип җавап бирим?

Әле ярый, атаклы Бачман мәрхүмнең улы Нарык тархан янда гына иде. Шул Майкы би өстенә ярсыган әтәч шикелле очып кунды.

— Әх, симез би! Әле бу таш кирмән «безгә» генә хаҗәт икән дә, үлемкитемнәрне «кирәклегә», «кирәксезгә» бүлеп буламыни? Аның менә монда шәһит булганнары да ил өчен бит! Әгәр син үз татарларыңны гына якын, газиз күрсәң, ул чагында мин дә кыпчакларны өф-өф иттереп, какмый-сукмый гына утыртырга тиеш. Алай икән, нигә шушы Болгар җиренә килдең? Әгәр син дә, мин дә тыныч тугайларга кайтып китсәк, Болгарны кем якласын? Мондагы бар халык Бату табанын ялап, хали хәят күрми үлеп китсенмени!?

— Йә, ялгыш кына ычкындырганмын, кызып китеп кенә, — дип Майкы би Нарыкны ипкә чакырса да, яшь-яшь тархан җил уяткан кисәү агачы шикелле кабат-кабат кызды.

— Йә бөтенебез дә бер йодрык булып яуга керәбез, йә Батуның этләре безне арыш көлтәсе урынына сытып кына китә. Татар, кыпчакларга бүленү юк! Без — шушы җирне сайлап төпләнгән кавем. Бу җир безнең туган туфракка әверелгән. Күрәчәк тә уртак! Артка юл юк!..

Икенче таңда Нарык тарханның хатыны Аппак бикә илне шаккаттырды. Чынлап баксаң, ир белән хатын, икәүләп, әле төнлә үк сүз беркетеп куйганнардыр инде. Әмма иртән Аппак Биләрнең базар мәйданына япаялгыз көе чыгып басты да, һавадагы тургай җыр сузгандай гына тезеп китте.

— Апа-сенелләрем, җанаш-ахирәтләр! Биләр өстенә явыз дошман килә. Таш кирмәнне төзеп бетермәсәк, кереп качар оябыз да булмый. Ирләребез, сезнең абый йә энеләр көн-төн тырышса да, һаман өлгерә алмый. Явыз дошман безнең газиз ирләребез белән туганнарыбызны ачык кыр өстендә куян-төлке урынына куып чүкемәсен. Ир бирмәк — җан бирмәк, ди. Ирләребезне дошман кулына бирсәк, үзебезне дә коллык һәм мәсхәрә көтә. Әйдә, Колгали сәетебез әйткән Изгеләр чишмәсе янына барыйк та, болыннар хуҗасы, ил калканы булып торачак таш кирмәнне төзергә ярдәм итик. Үзебезгә дә изгелек, шәфкать дигән шөһрәт ябышмасмы? Әйдә, ирләребез янәшәсенә басыйк, җанкайларым!?.

Ходай Тәгаләнең «амин» дигән чагына туры килде, ахры, шул сәгатьтә Биләр эченнән таш кирмәнгә таба апа-сенелләр, кыз-кыркыннар чылбыры тезелешеп чыкты. Инбашларында чиләк, көянтәләр, баш түбәләрендә ап-ак яулык, калфак. Һавадагы торна-аккош кәрваннарымыни!

Кызлар таш кирмән өстенә менеп сибелешкәч, кыятау чәчәк аткан түтәлгә охшап калды. Көтелмәгән ярдәмчеләр килү ирләрнең дә минминлеген кытыклады бугай, алар да артларына ут капкандай йөгерә башладылар. Кызларның шаярып көлүеннән бигрәк, таш кирмән эчендә гел ирләрнең җитди әмерләре генә яңгырап торды. Ирләр юкка гына сер

бирмәгән булып кыйлана, ике-өч көн эчендә кыятауга яна исем йоккан иде инде.

— «Кызлар тавы» булыр бу, Кызлар тавы!

4

Сүбүдәй Чирмешән ярына кабаттан күз кергәндә генә килеп житте. Билгеле ки, өч ел чамасы элек калдырып киткән Биләрне дә, Бату хан чатыр корып баскан Латынтау тирәсен дә, Ярык Таба яланын да танымыйча торды. Биләрне бер катлы яңа ур-диварлар белән ныгытканнар. Ул элеккеге пайтәхет түгел инде түгелен. Элеккеге таштан салынган Җәмигъ мәчет урынына сынар манаралы агач мәчет кенә калкытканнар. Илһам, Алтынбәкләр качып яткан ханнар сараеның таш диварлары урыны-урыны белән җимерелеп төшкән. Күперләр, алар өстенә калкыткан каравыл манаралары да бәләкәй, бик сыек. Гомумән, Биләр каласы өч-дүрт мәртәбә кечерәйгән, хәлсез картка охшап җиргә чүккән сыман. Әмма аягы капкынга эләккән җанвар төсле, тешләрен ыржайтып, үз-үзен якларга, тырмашырга куәте бар әле.

Ә менә кичәге Лачынтау белән Каурый чишмә буе кирмән дә кирмән инде! Бу кадәрле таш вә кирпечләрне каян гына һәм нинди тылсым белән ташып өлгергәннәрдер, ләкин ике ел, юк, Бәрәҗне куганнан соң узган бер җәй эчендә Каф тавына биргесез кыятау калкып чыккан! Сүбүдәй Каф тау өстендәге гөрҗи, әрмән, әзериләр төзегән кызылташ кирмәннәрне дә, Һинд, Зәгүфүрат дәрьялары тирәсендәге балчык калаларны да изеп-сытып узды. Ә менә бу таш кирмән аларнын берсенә дә, ялгыш та охшамаган. Берәр тугайлыктан казып сузганнармы, кирмәннең ике як диварын гөрләп аккан пар инеш каплап тора. Дала яклап — ерым. Биләр яклап — берсе-берсе арба чаклы, дөя чаклы эре-эре ташлардан түшәп өелгән дивар. Елгыр нөгәр бәреп керердәй барча ярыкларны ком һәм чуерташлар белән тутырганнар. Катлам-катлам булып биегәя барган баскычлар өстендә имән, зирек, каен агачлары үсә. Шәрҗир чүлмәкләре түгел, арбалы аткычлардан очырган тимер уклар да үтеп керә алмый. Бар, ятаган күтәргән кыргыз-ойротларың белән моның ише таш кирмәнне яулап, сындырып кара!

Сүбүдәйне котырткан шикелле, ике көн элек кенә Чулман ярында Бату хан юллаган чапкын куып тоткан иде.

— Киевны, ут уйнатып, тез астына салдым! Дмитрий боярлары, качып, минем якка чыкты. Амбарларында булган бодай-тарыларын минем нәүкәрләргә тараттылар. Хәзер мажарлар белән Дунайдагы болгарлар өстенә барам. Биләрне җир белән тигезлә дә минем янга ашык!

Ул хәбәрдән соң ике көн үтсә дә, Сүбүдәй нойон әле һаман тынычлана алмый. Үгәдәй белән Чагатайнын юньсез Гөек-Мүнкәләре хәзер инде мажар ханының сарайларын талап кинәнәдер, ә карт юлбарыс монда ниндидер Чулман болгарларынын авылдан чак кайтыш Биләрләре белән, кат-кат чиләнеп, җык түгәргә тиеш! Карт Сүбүдәйне нигә болай рәнҗетәсең, әй, Күк Тәңре!?.

Сүбүдәй шундук тупларны яуга әзерләргә фәрман биргән иде, татарларның бер меңбашы килеп, әйтерсең лә, итәгеннән тартты.

— Ашыкма, чал сәрдәр! Майкы атлы минем туганыма Чыңгызхан үзе меңбашы дәрәҗәсен бүләк иткән иде. Аңа Чибәркүл буеннан бик күп җирләр дә бирде. Әмма «билем кузгалды, ияргә менә алмыйм», дип хәйләләп, ул Майкы би, Бату ханнан аерылып, шушы җирдә калды. Мин «Яса»да «абыйсы үлсә, биләмә энекәшенә кала», дигән канун барын беләм. Мине пәһлеваннар орышына чыгар! Ә мин абыйны чакырам. Хәленнән килә икән, Чыңгызхан бүләк иткән биләмәләрен, җирен саклап калсын!..

Сүбүдәйне яшен кебек уй көйдереп узды. «Татар татарның башын ашарга җыена, каннары сыекланган, әйбәт фал бу! Иллә мәгәр бу хөрәсән җиңелсә, ике төмәннең дә өркеп калуы бар».

— Әгәр син җиңелсәң? — дип иреннәре арасыннан сытып чыгарды Сүбүдәй.

Мәкерле меңбашы әрсез елмаю аша җавап тотты.

— Син җиңелү белә торган сәрдәр түгел! Сине җиңә алырдай пәһлеван тумаган да әле. Мин дә җиңелмим, юкка кайгырасың. Мин Майкы бинең бер сырхавын беләм. Аның уң кулын Тургай даласындагы яуда бер мәргәннең угы тишеп чыкты. Майкы шуннан бирле уң кулына кылыч тота алмый. Аның сөңге яки гөрзи сайлавы да бик икеле. Шулай булгач, җиңү минем якта!..

«Кабахәт! Мәкерле җан! — дип сүгенде Сүбүдәй эчтән генә. — Исән калсаң, мин сине үзем тотып икеләйгә ярам!»

...Сөңге очына ак киндер кисәге элеп чапкан җайдакны күрүгә ук, болгар ирләре сагаюга чумды. Нинди дер солых яки бирелү хакында сүз кузгату да мөмкин фараз түгел. Моны белә торып, Сүбүдәй сәрдәрләре нигә чапкын куа? Әллә чаларган, карт сәрдәр болгарлардан башлыклары Баян батыр белән Җик мәргәнне арканнарга урап китерүне таләп итмәкчеме? Һай, дуамал бу Сүбүдәй, һай, акылы читән! Болгар иле — сатлык Бәрәҗ түгел!

— Сүбүдәй нойон пәһлеваннар орышын таләп итә! — дип акырды чапкын, үз бакчасына кергән карак кәҗәне өркетергә җыенган тавыш белән. — Без Хәлим атлы батырны чыгарабыз. Ә ул орышка үзенең агасы Майкы бине көтә!

— Әх, кабих җан! — дип сүгенде Майкы би бер якта.

«Әх, бик начар фал! — дип таш кирмән өстендә Баян йөзен чытты. — Сүбүдәй, юха елан, татар белән татарны сөзештермәкче, мөселманның канын койдыртмакчы! Туктатырга кирәк! Бәлки, Нарык? Ни әйтсәң дә, кыпчак!»

— Нарык! Нарык тархан! — дип кычкырырга мәҗбүр булды Баян батыр, башка бернинди дә чара таба алмыйча. — Бәлки, Майкы би урынына син чыгарсың?

— Рәхәтләнеп!

Нарыкның җавабын Майкы бинең әрнүле тавышы күмеп китте.

— Сез миңа, исән көемә, җеназа укырга җыенмагыз әле! Хәлим атлы дуңгыз энекәшемне үзем турап ташлыйм!..

Сүбүдәй Ярык Таба яланы өстенә ярты төмән җайдакны чыгарып бастырды. Таш кирмәннән төшеп тезелгән болгарларны Җик мәргән иярләде.

— Мин кирмән эчендә калам. Орыш белән алдап, Сүбүдәйнең дала ягыннан бәреп керүе бар, — диде Баян батыр. — Колгали сәет тә безнең янныбызда. Аны күз унындай сакламыйча булмый.

— Кайгырма, борадәр, — дип Җик мәргән Баянның иңенә төртеп алды. — Безнең Нарык белән Аппакның бәби туйларында да җырлыйсы бар әле!

...Мәкерле җан Хәлим ике дошман көч уртасындагы аралыкка чыгуга ук, аргамагын әрле-бирле уйнаткалап, Майкы бине эзләп чапкан булды.

— Әй, кайда син, кар пәри? Курыкма, чык! Мин сине башта ук бәреп үтермим. Эт урынына куып, җыгынны сыгып бетерәм, аннан гына ат койрыгына тагам!

— Алай бик ашыкма, селәгәй! Тәмугка күнгәнче, әүвәл тәһарәт ал! — дип кычкыра-кычкыра, ниһаять, Майкы би дә уртага атылып чыкты.

Боларны бик якын туганнар, дип уйлашлы да түгел. Майкы би, агач

бүкәнедәй, төптән юан, буе да бик кыска. Беләкләре үгез боты кадәр. Ияренә гөрзинең дә нәкъ шундыен салган. Кылычы бар-барын, мәгәр аны ияр җәясенең артына гына элгән. Ә кулында тартә сыман юан, озын сөңге. Калкан-фәлән алып маташмаган. Монын үгездәй гәүдәсен сакларга калканны да өстәл чаклы итеп ясау кирәк. Үзе төкерми дә. Иренен каплап киткән мыек чылгыйларын ялмап тик утыра. Ара-тирә каш-керфеген сыпыргалап куя.

Хәлим — монын тач киресе. Корыктай озын, үзе юка тәнле. Аяклары шул тикле асылынган, хәтта ияр өзәнгеләре менә-менә җиргә тияр кебек. Куллары белән бу бәндә хәтта иярендә килеш аргамакнын авызлыгын киертергә, салдырырга мөмкин. Бу корыктай шәүлә җәя-гөрзиләрне өнәмәгән. Кулына сөңге тоткан да биленә кылыч таккан. Дөрес, монын иңбашында бакыр калканы да, итек куныччларында хәнҗәр дә бар. Кашларына хәтле төшереп очлым кигән, ләкин колак артларыннан чәченең кырдырып алынганы күренеп тора.

— Йә, кай коралдан башлыйбыз, туган агай? — дип, беренче авазны янә мәкерле җан Хәлим салган булды.

Майкы, бер уч борыч капкан сыман, йөзен чытты.

— И-и, инәнне! Әйтмәсәм дә булмады, сатлык шайтан! Бату табанын ялап, туган теленне дә оныта башлагансың. «Кай корал» түгел, «кайсы корал», ишәк!

— Әй, төкерим лә синең ул теленә! Иң яхшысы, әйдә, иярннән төш тә кылыч сайла. Мин сине ялан буенча куалый-куалый турыйм!

— Тот капчыгың! Орышның тәртибе бар. Җүнле татар иярендә үлә. Иң элгәре, ата-баба кебек, сөңгедән орышабыз!

— Ярар, кадалып кит! Эчәкләренне ялан буйлап таратырга туры килә икән...

Сүз алышы бетте, ике дошман ике якка китте. Майкы бинен аты — дәү тимеркүк бия, Хәлим — тычкан сыман соры алашада. Болар яу-орышка күнеккәннәр инде, җайдаклары касыкка тибүгә үк алга ыргылдылар. Артта тузан купты. Хәлим зур сөлгесен алга сузып чаба, үз-үзенә нык ышана бугай, хәтта иелми дә. Майкы би кулында бер корал юк, ул ияр җәясенә салган гөрзине генә, ике куллап тотып, төшереп җибәрүдән курыккандай чаба.

Менә, Майкы би йөзен югарыга чөйде. Мыек чылгыйлары янак өсләренә кайтарылып чәбәкли башлады. Куе, озын кашлары маңгаена ятты. Борын яфраклары чабышкы атларныкы сыман киерелде. Иреннәре кысылды, күзләре кырысланды.

— Ә без менә болай итәбез! — дип кычкырды ул һич тә көтмәгәндә.

Шул мизгелдә үк ияр өстендәге гөрзи сул кулына күчте. Менә ул, кара болыт булып, өскә күтәрелде. Сатлык Хәлим үзенең качып котыла алмасын чамалады бугай, дәү сөңгесен Майкы бинең бугазына төртте. Тагын бер мизгелдән ике пәһлеван да иярләре өстеннән очып төште. Тузан басылганда Майкы би шыр ачык күзләрен күккә төбәп ята, ә меңбашы Хәлимнең йөзе бер көтү ат тояклары астында калып сытылган табак кебек кызганыч та, куркыныч та иде...

Таш дивардай селкенмичә торган сафлардан:

— Бер як та җинмәде! Орыш, яңа орыш! — дип кычкырып җибәрделәр.

— Нарык, Нарык кайда? — дип, Җик мәргән инде җайдаклар арасыннан кыпчак тарханын эзләргә тотынган иде.

Шулвакытны дошман сафлары артында Сүбүдәйнең корычтай әмере зеңгелдәп яңгырады.

— Дошманнар өстенә! Бөтенегез дә алга!..

Болгарлар беренче мизгелләрдә әле искә-анга килә алмый изаланды. Орыш тәмамлангач, корбаннарны, мәетләрне җыю, ясин чыгу, дога кылу сыман йолалар бар иде. Ил хакына башын салган батырларны ат тояклары белән таптап, изеп буламыни? Ничек инде «алга»?..

Кыргыз җайдаклары болгар сафлары өстенә карурмандай булып ябырылды. Тәүге минутларда ук ат тоягы астына йөзәрләгән яугир авып төште. Яралылар илереп кычкырды, ат кешнәде, меңәрләгән кылыч йөзе зең-зең килеп торды. Ярык Таба яланын мәхшәр көнендәге сыман тавыш күмде, ыгы-зыгыдан, атлар чабышыннан бар инкүлек дер-дер калтыранды.

Ниһаять, яу башлыклары да анга килде бугай. Тәүге әмерләр янгырап ишетелде.

— Болгарлар! Ике катлы бохра ясап тезелегез! Алга — сөнгелеләр, артта — җәя!

— Болгарлар! Бохрадагы килеш артка, таш кирмән ышыгына!..

Җик мәргән сөнгеләрен керпедәй кабартып тезелгән бер нөгәрнең иң очына килеп баскан иде. Көянтәдәй дәү кылычы дошман җайдаклары арасында, аҗаган шикелле, ялт-йолт килеп уйный. Менә, кыргызларның бер нәүкәре үлем ачысы белән кычкырып җир өстенә очты. Әнә, икенче җайдак ияр өстенә урталай теленеп төште. Менә, инде өченче, дүртенче кыргыз да якты җиһан белән саубуллашты.

Сүбүдәй чамалап, сизеп алган бугай, янындагы кишектиннәренең бер дистәсен Җик өстенә чыбыркылап куды.

— Бу пәһлеван — иң төп бузачының берсе булыр, исән калдырмагыз!

Ау этләре сыман остарган кишектиннәр ярымбохра ясап якынайды. Җик мәргән аларның берсенә таба ыргылса, икенче яктагылар ятаганнарын сөнге кебек сузып сикерделәр. Мәргән шулар өстенә ташланса, беренче яктагыларның сөнгеләре тырнап-тешләп алды. Шабыр тиргә баткан мәргән унга ябырылды, сулга ябырылды, ә болгарлар сафыннан ярдәмгә атлыгучы батыр табылмады. Җик мәргән дөрләп янган урман уртасында япа-ялгыз калган сыман булды. Кишектиннәр шуны сизеп алды һәм арадан берьюлы өч айгырдай егет дәһшәтле кылычын болгар сәрдәренең бугазына тыкты.

— Җикән! Җикән! Мәргән борадәрем! — дип үкереп Баян батыр аваз салган чакта сәрдәр җаны күк йөзенә очкан иде инде...

Җик мәргән үлемен таш кирмән өстеннән Баяннан башка кешеләр дә күзәтеп торган икән. Аяз көнне яшьнәгән яшендәй сискәндереп, кыятау ярында япь-яшь хатын-кызның ачыргаланып кычкырган тавышы янгырады.

— Җи-к-ә-ә-ән! Җи-ик мәргә-ә-ән!

Таш кирмән эчендәгеләр сискәнеп борылганда кыятау өстендә ап-ак яулык япкан хатын-кыз гәүдәсен генә шәйләп өлгерделәр. Ул шәүлә зәңгәрсу төстәге олы таш өстеннән сикерде дә, әрәмәләр арасына кереп юкка чыкты. Ә өчаякларга казан асарлык кына арадан соң, ул инде ап-ак айгыр иярендә кирмән күпере аша сикереп чыккан иде. Кулында — көмеш саплы кыска гына кылыч. Иңбашында — нәни, көмеш калкан. Яулыгы һәм алъяпкычы ап-ак, айгыры ак. Әйтерсең лә, ул күк йөзеннән болгарлар янына ярдәмгә җибәрелгән алиһә йә фәрештә иде. Шуны раслагандай, ак чаптар иясе көчле, сихри тавыш белән оран салды.

— Мин дә сезнең белән бергә яуга керәм! Ил хакына шәһит булудан да кыйммәтлерәк шөһрәт табылмаган! Яуга! Яуга, болгарларым!

Җайдак ак айгырын аягурә күтәреп сикертте дә шул мизгелдә алга томырылды. Күк йөзендә кылыч уйнаклады. Бар җиһан «аһ» итте.

— Аппак, Аппак бит бу! Нарык тарханның хатыны, Юныс бинең кызы!

Дошманнарның ике як сафлары да орышны туктатып, катып калган иде. Шул сафлар очында Нарык тарханның өзгәләнеп кычкырган тавышы яңгырап алды.

— Аппак! Синең кәмәнең бар бит! Нигә инде, нигә чыктың, йә, Аппагым?

Ул арада Аппак инде Сүбүдәй кишектиннәре өстенә оча иде. Нарык, ут капкандай, сөйгәне артыннан томырылды. Әле генә бер-берсенә кан дошманнар булган ике як та, казык сыман катып, коточкыч вәхшилеккә шаһит булып торды. Менә әүвәл, сөңге очына эләгеп, ияр өстеннән Аппак очып төште. Менә, аның гәүдәсе янына урталайга ярылган Нарык килеп ауды...

— Яуны туктатыгыз! — дип кычкырды болгарлар ягыннан бер меңбашы.

— Әй, мәңгелләр, артка! — дип гыжылдады исен җуйган сәрдәр. Сүбүдәй — бер йөз, бер мең яу кичергән чал карт, ләкин мондый шаһитлек үрнәге каршында ул да көчсез иде.

## 5

Сүбүдәй таш кирмәнгә бикләнгән болгарлылар янына фәкать бер тапкыр гына илчеләр юллап карады.

— Корал ташлап, кирмәннән чыгасызмы? Ул чагында берегезгә дә тимим!

— Еланны өненә кертсәң, ул буып үтерәчәк! — дип җавап кайтарды рухы сынмас Баян.

— Алайса, мине гаепләмәгез инде, болгарлар, — дип сүгенде Сүбүдәй үзалдына, уртын чәйни-чәйни. — Моннан унҗиде ел элек сезнең Бачманыгыз мине хурлыктан һәм үлемнән коткарып калган иде. Мин шул бурычны кайтармакчы булдым. Санга сукмадыгыз. Алыш-биреш бетте. Ә хәзер бигайбә!

Сүбүдәй меңбашлары ягына борылып фәрман салды.

— Нәүкәрләрне яуга ташлап әрәм итәсем юк! Жиз тупларны алга чыгарыгыз! Мең карганы куркытырга нибары бер таш җитә, дип әйтә иде бөек Чыңгыз кахан. Үлем мәхшәрен болгарлар да татысыннар әле!..

Тәгәрмәчле күчәрләр өстенә куелган жиз һәм бакыр көпшәләрне шәйләүгә үк, Баян батыр кайнар парга пешкән кебек булды.

— Мин бу үрәчәсез арбаларны моннан өч элек, Сакмар буенда ук күргән идем бит, — дип пышылдады батыр, чит-ят колак ишетмәслек итеп. — Мәңгелләр чиннәрдән туп кую серләрен чәлдергән, дигән хәбәр дә бар иде. Әллә, валлаһи да, бу бакыр торбалар чиннәр уйлап тапкан явыз туплар микән?..

Унбишләп туп көпшәләреннән берьюлы ут бөркегәч, Ярык Таба яланын куе зәңгәр төтен чолгап алды. Ниндидер яшерен уклар сызгыра-сызгыра очкан сыман булды, әле һаман игътибар итмәделәр. Яландагы төтен җәлеп итә, үрәчәсез арбаларның тиктомалдан артка таба тәгәри башлавы үтә сәер, мавыктыргыч иде. Һавада аждаһа сыман ысылдап очкан ядрәләр кыятау түбәсенә барып төшкәч кенә, яман гөрселдәүдән һәммәсе берьюлы тезләренә чүкте. Кирмән диварындагылар борылып карасалар, әле теге, әле бу агачлар арасыннан янартау бөркегәндәй таш һәм тузан болыты күтәрелә. Ул да түгел, әнә, үгез чаклы ташлар, дию селкеткәндәй, урыныннан кубып аска таба тәгәри, җиһанны дер селкетә!

— Кыямәт көне килде! Ахырзаман бит бу, ахырзаман! — дип акырды бер тилесе.

— Кыямәт! Кыямәт! — дип тагын берничә сантые элəктереп алды.

Дәп-дәү ирләр, хатыннар шикелле кыйланып, җилән итәкләренә төренә-төренә, жиргә сузылып ятты. Санаулы мизгелләр узуга, кыятау түбәсен елан төсле ажгырып очкан ядрә болыты күмде. Бу юлы югарыдан ычкынган дәү-дәү ташлар астагы кирмән диварларын сытып, җимереп узды. Хәзер дошманга юл ачылган, аның һөҗүмен сугым малы сыман тавыш-тынсыз гына көтеп яту һичкем гафу итә алмаслык беркатлылык иде. Баян батыр бар кыятау өстенә ишетелерлек оран салырга мәҗбүр булды.

— Болгарлар! Елдам һөҗүмгә әзерләнегез! Дошман чылбырын өзеп чыгудан кала башка чарабыз юк! Ваграк нөгәрләр алдарак ерып чыкса, Казан каласына юл тотыгыз! Сакласа, безне хәзер Казан гына саклый алыр инде!

Артта акрын гына Колгали телгә килде.

— Мин дә сезнең белән, олан! Әйдә, бер кылыч бир!

Баян батыр газап тулы караш белән сәеткә текәлде, ике кулын сузып иңнәреннән алды.

— Нинди кылыч ди инде сиңа, олуг сәет хәзрәт? Син яугир түгел, гыйлем иясе бит! Әнә, әле сөннәр иле турындагы китабыңны да язып бетерәсең бар. Син монда кал һәм ул китапны тизрәк төгәлли күр! Мин менә хәзер генә инандым, син хак юлда, сәет! Күлдәге маймыч сыман вак-вак ханлыкларны, сарык көтүедәй сибелгән ыру-кабиләләрне чуртан кебек, чүл бүресе кебек комсыз аждаһалар йотып бетерәчәк. Синең ул китабың бик кадерле безгә! Аттиланыкыдай сөннәр мәмләкәте төземичә торып, барча мөселманны бер түбә астына тупламыйча торып, безгә бәхетнең дә, хали хәятнең дә мәңге киләсе юк!

Колгали сәетнең иреннәре дер-дер килә башлады. Керфекләренә яшь тамчылары бәреп чыкса да, күзләрендә якты нур кабынды.

— Рәхмәт, олан! — дип пышылдады ул, ачы күз яшьләрен тыя алмыйча. — Ул фикерне киләчәк буыннар да кабатламый калмас! Хыялдагы «Сөннәр иле» дигән китапны да менә шулар язып бетерерләр. Ходай кушса, шулар барча мөселманны бергә туплаган хали дәүләт, хөр мәмләкәт төзер. Ә мин бүген үз халкымнан аерыла алмыйм! Аерылсам, илдәшләрем дә, киләчәк буыннар да каргар мине, каргар. «Үз гомеремдә кулыма каләмнән гайре корал алмам!» — дигән бер антым бар иде. Бүген илем хакына шуны бозам инде. Син миңа кылыч бир!..

Аста ирләр җимерелгән таш дивар буена саф-саф булып тезелә иде инде. Ап-ак чәчле, чал сакаллы Колгали сәет белән ил терәге Баян батыр да, кылычларын төбәп, алга атладылар.

— Бөек Болгар азатлыгы хакына яуга, арысланнар! — дип чакырды батыр.

Ак күлмәкле, ап-ак чәчле Колгали хуплап куйды.

— Киләчәк буыннар бәхете хакына изге яуга керәбез, болгарларым!..

*2005 — 2011 ел.*
*Чаллы.*



Нәҗибә
Сафина

# СИҢА БАГЫШЛАНГАН ҖЫРЫМ

## Исемсез җыр

Синсез яшәү —
Кояш–айсыз димим, —
Алар — күктә, йолдызлары да.
Әмма җирдә яшәү башка иде,
Син барында минем янымда.

Синсез яшәү —
Шатлыкларсыз димим,
Әмма моңсу йөзле шатлыклар.
Сөйгән–сөелгәннәр өчен җирдә
Башка икән хәтта аклыклар.

Синсез яшәү —
Кайгы–хәсрәтләрнең
Тирәнлеге — төпсез тирәнлек.
Җан ишеген шакып кына тора,
Яңа кайгылары керәм дип.

Синсез яшәү —
Яшәү булмас иде,
Аера алса үлем җаннарны.
Синең белән бергә каршылыйм мин
Айлы кичләр, алсу таңнарны.

Синсез түгел,
Бары синең белән
Яшәгәнгә генә яшним дә.
Сөю утларында дөрләп янам
Гомеремнең картлык яшендә.

Мәхәббәткә
Картлык киләмени!
Вакыт хәким түгел җанга да.
Мәхәббәтсез яшәп киткәннәрне
Тарих алмый исәп–санга да...

Нәҗибә САФИНА — *шагыйрә, публицист; «Әгәр дә уйлаганда», «Без — шигырь, тормыш — проза», «Кан хәтере» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Синең белән,
Бары синең белән
Сөю серләренә төшендем.
Синең белән күккә күтәрелдем,
Ни икәнен белдем төшүнең...

Синсез мин ул —
Ләйлә–Мәҗнүнсездер,
Ул, мөгаен, Зөһрә–Таһирсыз.
Исемнәребезне язмыйм гына,
Җырларыбыздан да танырсыз.

## Чарам юк

Син бар диеп уйлаганда,
Мин әле яши идем.
Беркемгә дә: «Минем белән
Сөйләш!» — дип дәшми идем.

Син бар диеп уйлаганда,
Иртәләр иркә иде.
Хәтта аякларымны да
Шушы уй йөртә иде.

Син юк. Аяклар атлыйлар
Гел Татар бистәсенә.
Син бар чакта ышанмадым
Син анда китәсенә.

Син бар диеп уйлаганда,
Син булмагансың икән...
Чын мәхәббәтне татымый,
Мин дә дөньядан китәм...

Миңа дигән кабер җире —
Агач төбе — киселгән.
Бераз гына җир иңгән күк,
Туям, ләхет ишелгән.

Җир астында аралар юк,
Мәхәббәттә ара юк.
Кичер,туган туфрагыма
Кайтып ятмый чарам юк.

## Сәер төш

Бүген синме төшләремә кердең, —
Димәк, күңелемдә яшисең.
Төше сәер, сөю ялкынында
Шулай дөрләп яныр яшьме син?

Бик сәер төш, шулкадәрле сәер, —
Башкалардан мине курыйсың[1].
Ялгыш адымнарымны да никтер
Бары яхшылыкка юрыйсың.

[1] Курыйсың — саклый, яклый, аралый мәгънәсендә.

Күзәтәсең үзең читтән генә,
Карашыңнан һич тә чыгармый.
«Әйдә, кылан, — ди күк күз карашың, —
Мин барсына, барыбер, чыдармын»

Ә мин шуны аңлагандай уйныйм,
Бетмәс уен икән бу фани...
Икебез дә мәхәббәттән шашкан,
Икебез дә самый, юк, сабый...

Уяндым да төшне җилгә сөйлим,
Алып китсен җилләр хисләрне.
Бу сәер төш әгәр өннәремә
Бәреп керә калса нишләрмен?

Куркуымнан каплап тордым йөзем,
Тәрәз пәрдәләрен капладым.
Һәм уяндым, хәтта куркуның да
Өндә түгеллеген аңладым.

Сәер бу төш, шулкадәрле сәер, —
Яратудан курка, янудан.
Үз җаныннан курка, һәм җанында
Күкрәп торган хисне танудан.

## Ут белән язу

Мин шигырь язмакчы булам,
Ут камый кәгазь битен.
Җаныңда уттан да гайре
Берни булмавы читен.

Мин сиңа хат язмак булам,
Каләм сыгылып китә.
Язу түгел, синең хакта
Хәтта уйлау да җитә...

Сиңа багышланган җырым
Җилләр болытка салды.
Авырайган болытларны
Җир ничек тартып алды.

Хис туфаны авырдыр шул,
Җир ыңгыраша, елый.
Туфан хисне кабул итәр
Җаннар бар диеп уйлый.

Миллиард еллар әйләнә җир,
Әйләндерә шул өмет.
Минем йөрәкне яшәткән
Зәррә мәхәббәт кебек.

## Сагыну түгел

«Сагындырдың» — дисең дә син,
Ышандырмый сүзләрең.
Күргәнем бар ниндилеген
Сагыш тулы күзләрнең...

«Сагындырдың» — дисең дә син,
Юк сагыныр чаралар.
Килим дисәң, каршылык юк,
Кул бирeme — аралар.

Сагыну— олы хикмәт ул,
Сагыну — җан ташуы.
Олы хисләрдән тулышып,
Җаның күккә ашуы.

«Сагыну»ның тамыры — «сак», —
Җан сагындамы җаның?
Сүз — хикмәт, әйтер алдыннан
Бераз уйлыйлар аны...

Акылны йөрәк җиңгәндә, —
Дөнья юләрләнгәндә...
Ярылды минем җаным
Һәм саркып тора каны...

Мондый чакта юатырга
Башка беркем кирәкми,
Учларыңа кыскан килеш
Киткәнсең бит йөрәкне...

«Сагындырдың» диган булып,
Нигә качып йөрергә?!
Учларыңны ачарга да
Кирәк иде күрергә...

Сагыну шундый була ул,
Аңлатмый аны сүзләр.
Сагынуны бер сүзсез дә
Әйтеп торалар күзләр.

## Үләр алдыннан

Син бәлки минем кадәр үк
Ялгыз түгелдер җирдә?
Ай белән сөйләшер хәлгә
Җитмәгәнсеңдер бер дә?

Синең чәчләреңне бәлки
Җил генә тарамыйдыр?
Сине җәлләп кара күктән
Ай гына карамыйдыр?

Миңа гына өзмисеңдер
Бәлки син гөлләрне дә?
Көлеп кенә карыйсыңдыр
Минем юләрлегемә?

Шулайдыр, ләкин күңелдә
Очкын кабынып китте.
Көзге яфраклар шикелле
Сагышлар янып бетте.

Көз җилләре уфтанмыйлар
Чәчләремне тарыйлар.
Алар миңа мәхәббәттән
Шашкан диеп карыйлар.

Көзге җилләр, соңгы гөлләр,
Кыр казлары тавышы...
Син килмә,көзләр, барыбер,
Кабат язга авышмый.

Ә барыбер, дөрләмәкче
Җанда кабынган очкын,
Белми ут, миңа бу җирдә
Яшәргә калган өч көн...

Туфан
Миңнуллин

# ОНЫТМАГЫЗ МИНЕ!

Яз әле минем турыда роман. Роман булсын, хикәя-микәяләргә сыймыйм мин. Пьеса да була алмыйм, сәхнә дә минем өчен бик бәләкәй. Чын-чынлап әйтәм, дөнья да тар минем өчен. Һәрхәлдә, элегрәк тар булды. Хәзер сыйдырдылар бугай инде.

Минем турыда инде күп яздылар. Мәскәү дә язды, Казан да язды. Мәкалә итеп тә, очерк итеп тә, пьеса итеп тә яздылар. Ләкин анда мин юк идем, минем күләгәм иде ул язмаларда.

Мин сөйләгәннәрне арттырмый да, киметми дә яз. Ышанып ук бетмәсәң дә яз. Мактанып җибәрәм икән, аны да теркәп куй, анысы да мин аның. Телемне генә үзгәрт. Чөнки беләм, минем телем роман өчен бармый — ни урысча түгел, ни татарча түгел. Шулай булганына мине гаепләмә: үзара бөтен житәкчеләр шул телдә сөйләштек, җыелыш, киңәшмә, пленум, утырышлар, үзең беләсең, бары тик урысча гына була иде. Үзеңнән өстәп әйт, хәзер дә шулай, диген. Татарча китап укымаганга кырык биш ел бардыр. Тегендә эшләгәндә дә, Казанга кайткач та язучылар үз китапларына автограф язып бирәләр иде, кайберләрен ачып та карамый идем. Юк, язучыларны хөрмәт итмәгәннән түгел, бизелгән татарча китаптан. Татарча газета да укыганымны хәтерләмим. Андый житәкче татарлар бездә буа буарлык. Нишләтәсең, өйрәтелмәгән. Сине дә мин укымаган килеш, карап кына беләм. Бервакыт син бүләк иткән китапны укырга дип яныма алып яттым. Беренче битен көчкә ерып чыктым. Хәрефләр таныш, сүзләр, җөмләләр ят. Син мине ачуланма инде. Гаебем зур минем сезнең халык алдында. Гаебебез зур. Яз, монысын да яз, барын да яз.

Романның башы була, уртасы, ахыры була. Мин сөйләгәннәрнең башы-ахыры булмаячак, нәрсә искә төшә, шуны сөйләячәкмен. Кирәк икән, үзең тәртипкә салырсың. Тагын нәрсә? Билгеле инде, исемемне үзгәрт. Үзгәртергә кирәк санасаң, бүтәннәрнең дә үз исемнәрен язма. Безне таныганнар безне шайтан дисәң дә, фәрештә дисәң дә танырлар. Танымаганнарга — барыбер.

Роман шуннан башлана. Көннәрдән бер көнне, алтмыш яшьлек юбилеемның шаукымы узгач, тормыш үзенең тапталып беткән сукмагына төшәр алдыннан, биш ел элек төзи башлаган, әле һаман да салынып бетмәгән дачабызда япа-ялгыз калып уйланып яттым. Бер сорауга җавап эзләдем. Күпме ул алтмыш яшь, азмы? Чыннан да, күпме ул, азмы? Бер карасаң, яшәлмәгән дә кебек, еллар кызган таба өстенә сипкән су шикелле тамчылар булып сикеренгәләгән дә парга очкан. Яшәү әле алда сыман. Тынычлап, кабаланмыйча гына, алдын-артын уйлап, кылган гөнаһлар, эшләгән ялгышларны кабатламыйча гына яшисе бардыр кебек. Тәҗрибә дә бар, бераз гына акылга да утырган, яшәве кызыклырак, мәгънәлерәк булыр сыман. Икенче карасаң, алтмыш яшь ул инде пенсионерлар яше. Кешегә бөртекләп кенә биреп, үзенә учлап алырга көйләнгән комсыз дәүләт сиңа — эшләмәгән адәм баласына — акча бирә икән, димәк, синең эшләмәвең эшләвеңнән хәерлерәк. Сине инде тәртә арасыннан

чыгарганнар да, юл кырыендагы үләннәрне чемченеп йөрергә иркенгә җибәргәннәр. Дүрт ягың кыйбла. Әмма карт алашага ул кыйблаларның инде керәге шунының гына кадәрле.

Минем чемченәсем килми. Мин болыннарда иркенләп утлап йөрергә күнеккән. Дөнья яңгыратып кешнисем килә әле минем. Тавышымны мине сагалап йөргән бүреләргә дә, мине сагынып көткән байталларга[1] да ишеттерәсем килә. Әйе, мине иң җегәрле чагымда аратага куып керттеләр, авызлыклап абзар стенасына беркетеп куелган боҗрага бәйләп куйдылар. Мин шул килеш тә әле тибендем, тоякларым белән тиресле җирне казыдым. Ниһаять, бәйдән ычкындым, арата эчендә чабып йөргән мәлем. Каным кайный, сикереп чыгачакмын мин ул аратаның киртәләре аша.

Менә юбилеемны зурлап уздырырга рөхсәт иттеләр бит әле. Юбилей кичәсенә иске һәм яңа дуслар җыелды. Мактау сүзләрен җәлләмәделәр. Минем инде аларга әллә ни исем китми. Үз гомеремдә күп ишеттем аларны. Хәер, бу юбилейдагы мактаулар ихласрак. Мин бит хәзер түрә түгел. Иске дуслар үткәннәрне бик искә алмыйча гына сайрадылар, яңалары үзләрен иркенрәк тотып мактадылар — юбиляр алдында оялырлык эш кылганнары әлегә юк иде аларның.

Мин инде боларның барысын да аңладым. Иске дусларымның мактау мәсьәләсендә тыйнаграк булуларын гафу иттем. Әгәр тыйнак кыланмасалар, ачу да чыккан булыр иде, бәлки. Яңаларының мактавына: «Амин, үзегезгә дә шулай булырга язсын», дип теләк теләп утырдым. Кыскасы, юбилей кичәсе нәкъ без күнеккәнчә, мин уйлаганча барды. Плакаттагы Ленин бабай әйтмешли, «Верной дорогой идете, товарищи». Мондый плакатларны бик күп элдерттем мин заманында.

Әйе, заманында. Минем заманда. Ул заманның герое идем мин. Әгәр дә алтмыш яшьлек юбилеем шул заманга туры килгән булса, болай гына мактарлар идеме? Мондый гына кунаклар чакырылыр идеме мәҗлескә. Өстәл башында беренчеләр утырыр иде, котлау сүзен дә Беренче үзе әйтер иде. Тагын бер орден да куярлар иде. Социалистик Хезмәт Герое дигән исемнең дә эләгүе ихтимал иде. Бар иде заманалар. Политбюро члennары белән мунча кергән кеше мин. Аларны ялангач килеш күргән кеше. Аларның бокалына минераль су, фужерларына затлы шәраб, рюмкаларына әрмән коньягы салган кеше.

Мәскәүдән килеп киткән министрлар, главка начальниклары, үзәк комитетның бүлек мөдирләре күпме. Алар белән мин елмаймыйча да күрешә идем хәтта, син дип сөйләшә идем кайберләре белән. Яраталар иде мине. Сөйкемле сөягем бар иде минем.

Бүтәннәр ничектер, мин үземнең кем икәнлегемне бик яхшы беләм. Дөньяга мин килгәндә — табигать тә бик юмарт булган, миңа бөтен нәрсәне дә өеп биргән. Миңа хәтле инде балалары булса да, әти-әни мине көтеп алганнар.

Язмыш мине ялгышлардан саклады. Тормышта мин бер генә тапкыр ялгыштым. Ләкин ул ялгыш бөтенесен чәлпәрәмә китерде, төзәтә алмаслык ялгыш булды ул. Гел искә төшеп тора ул ялгыш, үкендерә. Әмма инде соң, урманнарга сары яфрак төсе кергән. Юк, аны искә аласы килми әле бүген, калып торсын.

Еш кына мин язмышым турында уйланып төрле вариантлар эзлим. Әгәр дә язмыш мине бу юлдан җибәрмичә, икенче юлдан алып китсә, ни булган булыр иде дип уйлыйм. Әйтик, артист булып китсәм? Театрны үлеп яратам бит мин. Бик күп җитәкчеләр театрга йөрми, кайберләре татар театры ишегенең кайсы якка ачылганын да белми картаялар. Мин эшемнең иң тыгыз чакларында да театрга бармыйча калмый идем. Бер генә премьераны да калдырмадым. Минем аркада минем кул астында эшләүчеләр

[1] байтал — яшь бия

дә театрал булдылар. Ияртеп бара идем мин аларны. Миннән кала театрга еш йөрүчеләрдән Шәймиев кенә иде. Театрга мин спектакльләрнен сюжетын карарга йөрмәдем. Кем кемне ярата, кем кемгә кияүгә чыга, автор нинди проблемалар күтәрә — мина боларның берсе дә кирәкми. Мине артистнын уены кызыксындыра. Төрле кыяфәтләргә, ягъни мәсәлән рольләргә кереп, шуны чыннан да яхшырак, ышандырырлык итеп уйнаулары сокландыра. Аларнын уенына кызыгам, аларча уйнарга өйрәнәм. Әйе, әйе, тормыш тоташ уеннан тора бит ул, яшәүнен спектакль икәнлеген бик шәп беләм мин. Артистнын артистлык сәләте дә бәлки шундадыр — ул бөтен нәрсәгә дә уен итеп карый беләдер. Ангыра сарыклар сыман уенны да чын итеп кабул итмидер. Әйе, әгәр дә мин артист булып китсәм, СССРның халык артисты булып түшкә лауреат значоклары тагып йөрерлек зат идем.

Бәләкәйдән үк артистлык сәләте бар иде миндә. Хәтерлим, бервакыт бала-чагалар жыелышып урманга бардык. Ничә яшь булды икән мина? Алты-жиде яшьләрдер. Укырга кермәгән идем әле. Ана чаклы мин әни белән керә идем мунчаны. Мин керми идем инде, әни алып керә иде. Мине генә түгел, минем ике энекәшемне дә бергә юындырып чыгара иде ул. Шул юындыруларның берсендә мин әнинең күкрәкләренә карап:

— Ник бу әйберләр әтидә юк? — дип сораганмын. Шуннан әни мина сабынлы мунчала белән чәпәгән дә, аннан-моннан коендырып куып чыгарган. Шул көннән башлап мунчага абыйлар белән керә идем. Алар белән рәхәт, ичмасам, юындырмыйлар да, иң рәхәте, ләүкәгә сузып салып каен себеркесе белән кычкырта-кычкырта чапмыйлар. Ничек керден, шулай чыгасың мунчадан. Әни бәйләнмәсен дип чәчне генә чылатасың.

Урманга баргач, әнинен күкрәкләре искә төште бит. Югары очның бездән калмый, безгә тагылып йөргән Нурзидәнен ул әйберләре бар микән дип тикшерергә булдым.

— Күлмәгенне сал әле, — дидем Нурзидәгә. Салмый.

— Бүтән ияртеп йөрмибез, — дигәч, салды. Малайлар белән жыелышып түшеннән теге әйберләрне эзләдек. Табып булмады. Бу эш Нурзидәнен үзенә дә кызык тоелды. Түшен безнең белән бергә карап, андагы ике төрткегә:

— Менә ич, менә ич, — дип күрсәтте.

— Андыйлар бездә дә бар, — дип, үзебезнен төрткеләрне карадык.

— Минеке — зуррак, — дип бәйләнә башлады Нурзидә.

— Юк, безнеке кебек, — дигәч, жылый үк башлады. Без аны биек булып үскән шомырт агачына менеп шомырт тәлгәше өзеп биреп кенә тынычландырдык.

Бу хәл шуның белән беткән дә булыр иде, арабыздан берәү сатлык булып чыкты, Нурзидәне чишендергәнне әнисенә әйткән. Чишендерүче мин булганга, сатлык малайның әнисе бу хакта минем әнигә житкергән. Әни — әтигә. Ә әтинең талканы коры. Эләктереп алды мине.

— Шулай-шулай булдымы? — ди.

Мин дәшмәгәч, бик һәйбәтләп сыйларга керешмәкче иде, мин монын аяклары арасыннан шуып чыктым да урамга сыздым. Әти минем арттан.

Безнен өй каршында юан гына тирәк үсә иде. Мин анын өстәге ботагына хәтле менеп төшкән инде, андагы карга ояларын әллә ничә туздырган. Мәче кебек мендем дә киттем тирәккә. Кирзы итекләре белән әти анда ничек менсен. Минем яланаяк йөреп каешланып беткән табаннар агач башында йөрер өчен генә яратылган.

— Төш! — дип кычкыра әти. Мин анын саен өскәрәк үрмәлим.

— Хәзер мылтыкны алып чыгам да атып төшерәм, — ди әти.

— Төшерә алмыйсын. Атсан, мин үләм. Ә син мине үтермисен, мине яратасың, — дим.

Тирәк янына малайлар җыелды. Көлешәләр. Ә мин алар алдында әтидән курыкмаган булып кыланам. Ботактан ботакка күчеп атынам. Һәм шунда атылып та төштем. Килеп төшүгә нишләгәнемне белми бераз яттым. Үлдем бугай дип уйлыйм. Күземне ачып карасам, үлмәгән икәнмен, өстемә әти иелгән. Үлмәсәм дә, үлгән булу миңа бик ошады, тагын күзне йомдым. Исәп — үлгән булып кыланырга, юкса әтидән эләгә. Үлгәнемә үк ышанмаслар дип авыруга сабыштым, имгәнгән кеше тавышы чыгарып ыңгырашырга тотындым.

Әти мине күтәреп өйгә алып керде. Үзе:

— Харап иттем, харап иттем баланы, — дип сөйләнеп агач караватка салды. Әни атылып килеп җитте. Сораша. Ничек булганын белгәч, җыларга ук кереште. Бүтәннәр дә җыелды.

Кечкенә абый:

— Юри генә кылана ул, — дип эшне бозмакчы иде дә, мин катырак ыңгырашкач, ул да ышанды. Чөнки ышандырып ыңгыраштым. Артистлык таланты булган инде.

Тиз генә ат җигеп кайтып мине район больницасына алып киттеләр. Юл буе ыңгырашып бардым. Арба сикергәндә катырак ыңгыраштым. Әни мине алдына салып юл буе җылап барды. Ә беләсеңме, әнинең миннән башка биш баласы бар иде. Менә шуннан әниләрнең кем икәнлеге аңлашыла инде. Мин моны мәңге онытмыйм, оныта да алмыйм. Больницада ак кием кигән бер апа мине әйләндереп-әйләндереп карады.

— Бу жирең авыртамы, бу җирең авыртамы? — дип сорашты.

Мин күземне ачып-йомып кына җавап бирдем. Югыйсә мине ничек хәйләкәрләнергә берәү дә өйрәтеп куймаган. Авыру шулай итәргә тиеш дип уйлыйм да эшлим. Шундый да үз уеныма ышанып уйныйм, чынлап авырыймдыр сыман тоела башлады хәтта. Ак киемле апа, доктор булган инде, әлбәттә, күкрәгемә көпшәле әйбер куеп тыңлады, шуның белән үк аркамны тыңлады да, тагын:

— Кай жирең авырта? — дип сорады.

— Бөтен жирем дә, — дидем.

Тикшерергә дип больницага ятарга алып калдылар. Тикшергәннән соң кайтарып җибәрделәр. Әти килеп алды. Ул килгәндә мин «терелгән» идем инде, әтинең дә ачуы басылган иде.

Бу артистлыгымны мин беркайчан да беркемгә сөйләмәдем. Бүген сиңа сөйлим, син бөтенесен дә белергә тиеш.

Ә менә безнең урманда нишләгәнне әнисенә сөйләгән теге малайны суктырдым. Ул барыбер үзгәрмәде, үскәч, зур урын биләгәч тә әләкче булып калды.

Нурзидә исемен әйткәнмен икән, сөйләп бетерим инде. Ни галәмәттер, аның күкрәкләрен күрү теләге мине озак еллар буе әзәрләкләде. Мәктәптә бергә укыдык. Бер класста. Мин аның күкрәкләрен карап үстердем диярлек. Беркөнне үзенә дә әйттем:

— Күгәрчен йомыркасы хәтле булган инде, — дим.

— Нәрсә? — ди бу.

— Синең имиләрең, — дим.

Шуннан Нурзидә миңа капчыктан теккән букчасы белән сыламасынмы. Букча эчендә чакма ташы булган, баш тишелде. Шул көнне Нурзидәнең әнисе үлде. Ятим калды ул. Әтисе сугышта. Минем әти дә сугышта.

Сугыш елларын сөйләп тормыйм. Аны инде күп яздылар. Бездә дә шул инде. Ачлык, ялангачлык, ятимлек. Мин аның бөтен хәсрәт-кайгыларын белеп бетермим. Бала-чага гына бит әле. Шулай да бик нык ачыкканым хәтердә. Ашарга яраган бөтен үләнне ашадым. Бүген дә ашарга яраклы

унбиш төрле үләнне беләм. Түтәлдә түгел, кырда, болында, урманда үскән үләннәрне.

Нурзидә өйләрендә үзе генә калды. Абый-апалары да, әне-сенелләре дә юк иде аның. Туганнары да юк иде шикелле. Аны каядыр җибәрергә уйладылар кебек. Шунда мин:

— Җибәрмәсеннәр, үзебезгә алыйк, — дидем.

— Нишләтик без аны, — диде әни, — үзебез җиде җан. Дүртегез аяксыз һәм күтсез.

Чыннан да шулай инде. Мина да унбер генә яшь. Миннән кечкенәләр өчәү. Алай да мин үземне аяксыз да күтсезгә санамыйм. Атка атланып урак өстендә ындыр табагында чүмәлә тарттырдым, әнидән качып булса да тәмәке тартам. Әйттем әнигә җегетләрчә:

— Җибәрмибез Нурзидәне, мин аңа өйләнәм, — дидем. Мондый акыллы фикернең башка килүенә хәзер дә гаҗәпләнәм.

— Нәрсә-ә-ә? — диде әни.

— Өйләнәм. Өйләнгәч, Нурзидәне куып чыгарырга хакыгыз юк, — дидем.

Кече абый белән апа көләргә тотындылар. Аларга әни кушылды. Олы абый саллы гына итеп кайчы белән кыркылган башка чәпәде.

Ачу килде. Мәче шикелле абый өстенә сикердем. Аерып ала алмыйлар. Миңа каты эләкте ул көнне, аның каруы абыйның да муены тырналган, ияге тешләнгән иде. Мин үземә сукканнарын беркайчан да гафу итмәдем. Үзем башлап кешегә сукканым булмады, әгәр дә инде мина суксалар, миннән көчле дип тормадым, үҗәтләнеп сугыштым. Әти белән әнигә генә, үзләреннән шактый эләксә дә, кул күтәрмәдем...

Бер генә тапкыр мин мине кыйнаганда дәшмәдем. Салып таптадылар, дәшмәдем. Менә хәзер уйлыйм, дөрес эшләдемме икән, дим. Дөрестер, мөгаен. Ярый, анысы калып торсын.

Нурзидәгә өйләнеп өлгермәдем, авылдагы бер ялгыз карчык аны үзенә алды.

Сигезенче класста укыганда Нурзидәне кочакладым. Үзеннән-үзе килеп чыкты. Мин ул чакта күрше урыс авылында урысча укый идем. Сугыштан кайткан әти:

— Татарча укып ындыр артына да чыгып булмый. Фронтта мин барысын да белдем, — дип мине — дүртенчене бетергән малайны, өченче класска күрше авыл мәктәбенә илтеп бирде.

Үзебезнең мәктәптә гел «отлично»га укый идем, тегендә баргач та тиз куып тоттым урыс малайларын. Алтынчыда урыс теленнән класста ике укучының гына «бишле» иде. Берсе — мин, икенчесе — чуаш малае Федя. Гармунда «Барыня»ларны уйнап марҗа кызларын биетә идем. Укый-укый шуны да белдем: марҗа кызларының кочаклаганга әлләни исләре китми икән. Татар кызлары гына кул белән ялгыш кагылсаң да чырылдаган-пырылдаган булалар.

Шул гадәт буенчадыр инде, авыл урамында Нурзидәне очраттым да, кочакладым. Күптән, бер атналап инде күргән юк, сагынылган — тоттым да кочаклап алдым.

— Нишлисең, җүләр, — дип ычкынырга маташа. Мин җибәрмим. Җибәрә дә алмыйм. Юка күлмәк аша түгәрәкләнеп беленеп торган күкрәкләре минем түшемә кысылып тора. Минем өстә дә бит җинсез күлмәк кенә.

Торабыз урам уртасында кочаклашып. Нурзидә инде тыпырчынмый. Зәп-зәңгәр күзләрен тутырып минем күзләремә караган да тик тора. Әнә шул тик торуы белән куркытты бу мине, ычкындырдым. Һәм бер ахмаклык әйтеп ташладым:

— Имиләрең үскән инде, — дидем.

Нурзидә:

— Дурак, — диде дә, йөгерде.

Шул көннән башлап мин Нурзидәдән оялып йөрдем. Бу оялу миңа байтак вакытка җитте. Үзем аның турында уйласам да, төшләремдә аны күрсәм дә янына бармадым. Нурзидәне бер егет озата башлаганын ишеткәч кенә, төнлә Нурзидәләр өенә киттем. Монда инде миңа уналты яшьләр булгандыр.

Капка төбендәге эскәмиядә икәү утыралар. Яннарына барып утырдым. Бер сүз дәшми утырам. Тегеләр дә дәшмиләр. Утырабыз өчәү. Шуннан түзмәдем, әйттем егеткә:

— Мин килгәнне күрмисеңме әллә? — дидем.

— Күрәм, — ди теге.

— Күрсәң, — мин әйтәм, — нигә кайтып китмисең? Иди отсюдова.

Теге ыкы-мыкы килгән булды да, торып китте бит әй. Үзе миннән ике-өч яшьләргә өлкәнрәк. Белмим, әллә минем үземнән курыкты, ни әйтсәң дә «читтән» — күрше авылдан кайткан, урысча сүзләр кушып сөйләшүче егет кисәге, әллә инде абыйларым барлыгы өркетте, абыйлы малай һәрчак батыр була бит ул.

Егет торып киткәч, Нурзидә дә кузгалды.

— Ә син кая барасың? — дидем.

— Өйгә керәм, — ди.

— Керми тор, — дим.

— Нигә миңа приказ бирәсең, кем булдың ул кадәрле, — ди Нурзидә.

— Нигә, — мин әйтәм, — мин барында әллә кемнәрдән озаттырасың?

— Синең миңа ни хакың бар?

— Может, мин сине яратамдыр.

— Нәрсә-ә-ә?

— Тозлаган кыяр кәбестә. Я же тебя люблю.

— Урысча белгәнең белән мактанма.

— Мин мактанмыйм. Әгәр дә тагын берәрсеннән озаттырсаң...

— Нишләтерсең?

— Нишләтергә белермен.

— Куркытма.

— Мин сине куркытмыйм. Ну озаткан егетләреңнең иманын укытачакмын.

— Хулиганланып кайткан да... Үзен әллә кемгә куеп... Кит, мин керәм. Әби көтә, вакытында кайт, диде.

— Нигә кайтмадың соң? Нигә утырасың монда?

— Мин керергә җыенган идем инде.

— Җыенган идем, җыенган идем... Кочаклашкан идегез бит.

— Минме? Нәрсә сөйлисең син, ә. Күрәләтә ялганлый берәү.

— Кочаклашмасагыз, кочаклашырга уйлаган идегез.

— Безме? Кит, җүләр. Синнән башка мине берәүнең дә кочаклаганы юк.

Шунда гына мин акылыма килеп сискәнеп куйдым. Олыгаеп киттем дип әйтимме. Нурзидәгә юкка бәйләнәм түгелме соң? Чыннан да, ни хакым бар аны битәрләргә? Аның ни гаебе бар. Гафу үтенергә дә матур гына сөйләшә башларга кирәк тә бит, юк, әтәчлек комачаулый.

— Валлаһимы? — дим Нурзидәгә.

— Менә кызык икән. Нигә дип карганыйм ди. Үзе елга бер күренеп киткән була да.

Монда инде мин ни әйтергә белмәгәннән тиз генә әкият уйлап чыгардым.

— Мин бит сине сыныйм, — дидем.

— Нәрсә дип сыныйсың мине?

— Әгәр мине армиягә алып китсәләр, мин анда моряк булсам, дүрт ел буе көтә алырсың микән дип.

— Кызык икән. Без бит синең белән йөрмибез.

— Ничек йөрмибез? Мин сине яратам ич.

— Каян белим яратканыңны. Әйтмәгәч.

— Менә әйттем ич инде.

— Әйткәч белдем инде.

— Син мине яратасыңмы?

Нурзидә эндәшмәде. Башын әз генә борып миңа карады.

— Ник дәшмисең? — дидем.

— Нәрсә дип әйтим соң?

— Яратам, диген.

— Яратам инде, алайса.

Үз гомеремдә «Яратам» дигән сүзне беренче ишетүем иде бу. Сонрак күп тапкырлар ишеттем мин аны. Урысча «люблю» дигәннәре шактый булды. Чуашчалап «юратам» дигәннәре дә табылды. Татарча әйткәннәренең санын да белеп бетермәслек. Бәлки, яратам дип ихластан әйткәннәрдер барысы да, ләкин чынлап әйтүче Нурзидә булгандыр. Миңа шулай тоела. Гомер иткән хатынымнан мин «яратам»ны ишеткәнем булмады шикелле, әмма яратмады дип әйтә алмыйм. Яратмаса, минем кыланганнарыма түзеп тора алмаган булыр иде. Мине сүзсез генә яратты бугай ул. Тукта, нигә әле яратты дим, әле дә ярата. Хәер, хәзер бу яшьтә андый сүзләр әйтеп сөйләшү килешмидер дә. Мин, мәсәлән, бүгенге хәлемдә, «әле дә янымда Фәридәм бар» дип куанам. Ул бүген минем бердәнбер терәгем.

Нурзидә турында сөйли идем бит әле. Без аның белән мин Казанга укырга киткәнче очраштык. Әгәр дә бүген миннән беренче мәхәббәт нәрсә ул дип сорасалар, Нурзидә белән минем мәхәббәтем дияр идем. Әйе, беренче мәхәббәт ул дәвамы булмаган, иң кызыклы җирендә тасмасы өзелгән кино, йә битләре ертылып алынган китаптыр.Ниләр турында гына сөйләшмәдек без. Үбешеп рәхәтләндек кенә. Нурзидә үбешә белми иде, билгеле. Мин маржа кызлары белән үбешү мәктәбен «бишле»гә тәмамлап килә идем. Үбешүдән башка һөнәрләрне дә үзләштерә башлаган идем. Классташ кызларның берсе ул эшкә мине үзе өйрәтте. Бик серле нәрсә кебек тоелган иде ул һөнәр, берние дә юк икәнен аңладым да, кызыгы калмады. Ләкин мин Нурзидәгә белгәнем күрсәтергә үрелмәдем. Ышанасызмы, берсендә мин аны биленә хәтле өске ягын чишендердем дә. Беренче тапкыр урманда аның күкрәкләрен караган урында иде ул. Мин бик үтенгәч, «җүләр, борылып тор» диде дә... Кире борылганда ул шәрә күкрәкләрен учлары эченә яшереп басып тора иде. Үзе миңа караган да, елмая. Һәм шуның белән шул. Кагылмадым. Кагылсам да Нурзидә бәлки сүз әйтмәгән булыр иде.

Мин Казанга укырга киттем һәм без бүтән очрашмадык. Нигә? Белмим. Гаеп миндәдер. Кешедә сагына белү хисе бар. Миндә ул хис булмаган, ахрысы. Казанга киттем дә оныттым. Авылны да, бергә үскән малайларны да, хәтта әти-әнине дә, хәтта Нурзидәне дә. Казан, студентлар тормышы мине үз эченә бөтереп алды да, җибәрмәде. Хат язуның ни икәнен белми идем. Нурзидә дә язмады. Аерылышканда сүзләр бирешкән идек бугай. Онытылды. Минем хәтерсезлегемне Нурзидә авыр кичергән булып чыкты. Мин моны соңыннан гына белдем. Инде олыгайгач, әби белән бабай яшенә житкәч, авылда очраштык. Мин Казаннан, ул Ташкент ягыннан кайткан. Аны күргәч авызымны ерып килә идем, читкә тайпылды.

— Нигә качасың, Нурзидә, танымадыңмы? — дим.

— Таныдым шул. Кочаклап алырсың дип курыктым, — ди. — Хәзер бит

инде син зур кеше булгансың, урамда кочаклашып тору килешмәс, — ди. — Хәер, теге чакта да син үзеңне әллә кемгә куя идең. Миннән яратам дип әйттерден дә, качтың, — ди. — Очрашканда да күрми китә идең. Ә минем йөрәгем ут булып яна. Үзем синең яныңа барырга уйладым, батырлыгым житмәде. Уналты яшьлек кыз язмышы белән уйнадың, — ди.

— Миңа да бит уналты гына иде, Нурзидә. Гафу ит инде, — дим.

— Гафу итми нишлисең. Мин бит ятим кыз идем. Әбекәй какмаса да, үземне кешеләрдән ким саный идем. Түздем инде.

Озак сөйләшеп тордык урамда. Мине сагынган. Хат язарга да жыенган, адресымны белмәгән. Яныма килергә уйлаган, кайда торганымны сорар өчен әни янына барган.

— Кызым, оныт син аны, — дигән әни, — әллә нинди җилбәзәгрәк ул безнең, оныткандыр ул сине, — дигән. — Хатын-кыз чәченә бәйләп куеп булмыйдыр аны, әтисе дә шундый, — дигән. — Бер нәрсәгә күнелен бирсә, жиренә житкермичә туктамый. Укып зур кеше булам диде, булачак та. Син барыбер аның артыннан ияреп өлгерә алмаячаксың, — дигән.

Ул арада авылга Ташкенттан бер егет өйләнергә дип кайткан икән. Шуңа Нурзидәне күрсәткәннәр. Ошаткан егет. Киткән аның белән Нурзидә. Әбисе дә үгетләгән, калма, калхуз тирәсендә минем иза чиккәнем дә бик житкән, дигән. Әниеңнең башына да калхуз житте. Язгы ташуда симәнә ташыганда салкын тидерде, дигән.

Урманда булган вакыйгаларны искә алып көлештек. Аның да исендә икән:

— Син генә күз тидерден күкрәкләремә. Үткән ел берсен кисеп алдылар, — диде Нурзидә...

Әй-е-е... Шулай... Шундый икән бу дөнья дигән әкәмәт. Артистлыктан башлап кая барып життек, ә. Үземә дә рәхәт булды әле Нурзидәне искә алу. Миңа беренче тапкыр яратам дип чынлап әйткән кыз бит ул...

Март кояшы ике катлы тәрәзә аша үтеп кереп Сәрбиҗамалның янбашын жылытты. Сәрбиҗамал тәрәзәгә яны белән утырып өч айлык Рәсимен имезә. Рәсим комсызланып суыра имине. Ана моңа шатлана. Димәк, аның нарасые сәламәт, таза булып үсәчәк, үзенә дигәнен ала беләчәк. Өч бала анасы бала имезүнең рәхәтлеген тоя, шул рәхәтлекне ул жырга күчерә.

Телеграм баганасы
Олы юлга маяк ул.
Сагынасыңмы дип сорыйлар.
Сагынмаган кая ул.

Жырның сүзләре бүтәннәргә ишетелми. Күнеленнән генә көйгә сала аларны Сәрбиҗамал. Көй исә әллә кайдан янгыраган сыман тынлыкны бозмыйча өй эченә тарала. Өстәл янында детектор радиоалгычны жайлап маташучы Касыйм да ишетә аны. Кулындагы Рәсим дә ишетә бугай. Әнә ул имүдән туктап калды. Сәрбиҗамал ни булды икән, әллә йоклап киттеме дип улына караса, тегесенең күзләре һәм авызы шыр ачык. Ирен читләреннән сөт тышка агып чыккан. Ана көйләвеннән туктап имиен баласының авызыннан алырга теләгән иде, Рәсим ими башын тешсез уртлары белән эләктереп өлгерде һәм тагын үҗәтләнеп имәргә тотынды. Ана тагын рәхәтлек дөньясына чумды, тагын көйләргә керешә. Көйли башлауга ук Рәсим янә имүеннән туктады. Әнисе көйләүдән туктауга янә имәргә тотынды. Сәрбиҗамалга бу кызык тоелды — ул бер көйләп, бер туктап Рәсим белән уйнап алды да, иренә эндәште:

— Карале син моны, нишли?

— Нишли? — диде Касыйм.

— Кил әле, кара.

Улларының нишләгәнен Сәрбиҗамал иренә күрсәтте.

— Вәт машинник, — диде Касыйм, — колакка сак булачак. Җырчы йә дә гармунчы булыр. Туктале, — дип, ул түрдә — киштәдәге өстенә чиккән сөлге каплап куелган гармунын алды.

— Яле, нишләр икән.

Касыйм Сәрбиҗамал янәшәсенә утырып гармун бармакчаларына басты. Бала сискәнеп куйгандай булды. Башын боргалагандай итеп көйнең кай яктан ишетелгәнен чамаларга тырышты. Касыйм уйнаудан туктауга авызы белән әнисенең имиен эзләргә тотынды. Ата белән ана көлешteләр. Төрле әкәмәт уйлап чыгарырга маһир Касыйм:

— Әйдәле, болай эшләп карыйк, — дип озын «Уел» көен уйный башлады.

— Нишли? — дип сорады хатыныннан.

— Тынлый бу.

— Ничек тынлый?

— Кара, олы кешеләр кебек бу, атасы. Күзләре моңсуланган сыман. Ике каш арасында җыерчык та килеп чыкты сыман.

— Ә хәзер? — Касыйм кинәт кенә дәртле бию көенә күчте. — Нишли?

— И, Алла, — дип көлде Сәрбиҗамал. — Елмая бит бу. Сикергәндәй дә итә. Хәерлегә генә булсын.

Тора-бара бу уен болай да шау-шулы өйгә ямь өстәде. Уенга Рәсимнең абыйлары Рәшит белән Рашат та кушылдылар. Әтиләре бию көен уйнаганда әниләрнең нәни тәпиләрен биләүдән чыгарып «биеттеләр». Андый чакта өй эче гөр килеп торды.

— Ярый, булды, күз тидерерсең, — дип кенә Сәрбиҗамал уенны туктата иде.

Әтиләренә ияреп Рәсимнең абыйлары аңа «машинник» кушаматы тактылар.

«Машинник»ның ни аңлатканын белүче авыл кешеләре Касыймны битәрләп тә карадылар:

— Машинник — кеше алдаучы дигән сүз бит, — диделәр.

— Булсын, — диде Касыйм. — Кеше алдар өчен дә үткенлек кирәк, — диде. — Җебегән булып үсмәсен. Мина да бабай машинник дия иде, кеше алдап гомер итмәдем, — диде.

Гармун белән уен уйнау бушка китмәде, дүрт яшендә Рәсим инеш тавындагы чирәмлектә авыл кызларын-егетләрен тальянда уйнап биетә иде инде.

Танылган, хәтта күренекле музыкант та чыгасы иде миннән. Бәлки, композитор да булган булыр идем. Бүгенгә «йолдызлар» язган шыллдырбылдырны мин хәзер дә яза алам. Миңа бер композитор: «Сездә абсолют ишетү сәләте, Рәсим Касыймович», — дигән иде. Бәлки, ул обком секретаренә ялагайланыбрак әйткәндер, ләкин мин үземдә тавышларның сихри моңын тоярлык сәләт барлыгын сизәм. Гармунның теләсә кайсын кулыма алып, теләсә нинди көйне бер ишетүдә отып, уйный башлыйм. Уйнаганда йөрәк үрле-кырлы сикерә, очып китәргә теләп җилкенә. Үзем дә сизмичә гармунга кушылып җырлыйм. Йә сикереп торып биергә тотынам. Укымаган, әзерлексез килеш симфонияләрне йотлыгып тыңлыйм, аңлап тыңлыйм.

Бервакыт төзелешне карарга СССР Министрлар Советы председателе Косыгин килде. Хәтерлисездер, аның кыяфәте житди иде. Сирәк елмая, көлә белми. Коры кеше. Анекдот-мәзәкне яратмый. Көне буе карап йөрде бу төзелешне. Сораулар бирде. Күрсәтмәләр бирде. Аның уң ягында Беренче булса, сул ягында мин йөри идем.

Кич белән, гадәттәгечә, унлап кеше өчен генә мәҗлес сыман кичке аш оештырдык. Андый зур кунак килгәндә без мәҗлескә җырчылар, музыкантлар чакыра идек. Җырчылар инде, билгеле, чибәр кызлар. Тавышын тыңлап, үзенә сокланып утырырлык чибәрләр күп бит безнең. Әзрәк тамак чылатып алгач, күңел урыска әйләнә бит, маржа сорый башлый. Нечкә билләрен боргалап, күпертелгән колак мендәре чаклы артларын уйнаткалап кызлар пәйда булгач, тикшерергә килгән түрәнең дә күңеле йомшый, әйтәсе кисәтү сүзләрен дә онытып тора. Мәскәүдән килгән кунак булса, ана урысча җырлыйсың, ара-тирә экзотика өчен татарның такмакларын да кыстырасың. Татарның озын, сагышлы, моңлы көйләренә Мәскәүнең колагы чыдамый, ачуын гына китерә.

Хөрмәтле Алексей Николаевичның нечкә билле җырчыларга әлләни исе китмәгәнлеген без белә идек. Имеш-мимешләргә караганда, ул Зыкинадан башка җырчыны танымый икән, санга сукмый икән. Шуңа күрә без дә җырчылар чакырмадык. Мылдыр-мылдыр сөйләшеп кенә ашап-эчтек.

Әмма дә ашап туйгач корсакны сыпырып, кикереп йокларга ятарга без авыл мужиклары түгел. Ашаган тәнгә сеңгәнче нидер эшләргә кирәк, ничектер Алексей Николаевичның күңелен күрергә кирәк. Нишләргә? Ярый әле Косыгин үзе коткарды. Бер почмактагы бәләкәй өстәл өстендәге тальянны күрде дә:

— Моңарда кайсыгыз уйный? — дип сорады.

Минем гармун иде ул. Кунак йортында махсус тора. Кайвакыт эч пошканда киләм дә, ярты сәгатьләп уйнап китәм. Җан тынычлана. Кунаклар килгәндә осталыкны да күрсәтеп алам. Кыскасы, ул һәрвакыт шунда тора. Килеп кочаклаганны сабыр гына көткән күндәм кыз-хатын кебек.

Кирәк бит, житди кыяфәтле коры, кырыс Косыгин шуны күреп өлгергән.

— Мин уйнагандай итәм, Алексей Николаевич, — дидем.

— Күрсәт осталыгыңны, — диде Косыгин.

Косыгинны озатып йөрүче Казаннан килгән үзебезнең Беренчегә карадым.

— Давай, сиптер, — диде ул.

Мин урысча көй уйный башлаган идем, Косыгин:

— Үзегезнекен уйна, — диде.

Башта каушабрак, аннан онытылып тотындым уйнарга. «Баламишкин»нан «Олы юлның тузаны»на барып життем. Кызып китеп, үзем яраткан «Телеграм баганасы»н җырладым да:

> Телеграм баганасы
> Олы юлга маяк ул:
> Сагынасыңмы дип сорыйлар,
> Сагынмаган кая ул!

Косыгин бүлдермәде, туктатмады. Йокымсыраган формада башын аска иеп утырды да, мин туктагач, Беренчегә әйтте:

— Менә дигән талантны горком секретаре ясап әрәм иткәнсең, — диде.

Аның бу сүзен ике төрле аңларга мөмкин иде. Беренчесе — чыннан да минем уенымны бәяләү, икенчесе — секретарь буларак эшемне тәнкыйтьләү. Беренчесе дөресрәк булгандыр. Чөнки ул миңа «гармонист» дигән кушамат такты. Мин Мәскәүгә баргач, комбинатта эшләрнең барышы белән аны таныштырырга янына керә идем. Шунысын да әйтим, ул һәрвакыт кабул итте, беркайчан да борып җибәрмәде. Һәм һәрчак саран гына елмаеп:

— Исәнме, гармонист, — дип кулын биреп күрешә иде.

Әйе, гармун... Ул мине арыганда дәртләндерүче дә, кайгырганда юатучы да. Музыканы артык яратуым аркасында төрле гайбәтләр дә таралды.

Жырчыларны үзебезнең шәһәргә чакырып төзүчеләргә жырлата идем. Төннәрен шуларны кунак өендә сыйлап, рәхәтләнеп жырларын тыңлый идем. Соңыннан Бикбаев үз шәһәрендә притон оештырды дип обкомга донос яздылар. Шулай түгеллеген белсәләр дә, мине пычратырга житә калды. Әйтерсең лә мин кыз-хатын кочаклар өчен аулаграк урын таба алмыйм.

Минем гармун яратуымны белгәч, 50 яшьлек юбилеема саратский гармун бүләк иткәннәр иде. Бүләкнең бүтәне булса, бәлки, алмаган да булыр идем, гармуннан ничек баш тартасың. Соңыннан шуны взятка алды дип гаепләргә маташтылар... Ахмаклар! Бәләләр бит алар — без беребез дә әүлия түгел идек — алдык бүләкләрне. Кечкенәсен дә, зурысын да алдык, хәзер дә алалар. Әмма гармуны берәр язучының автографлы китабын яки художникның рәсемен кем взяткага саный. Кайберләрен, бигрәк тә китапларны эчен ачып карамыйча ук чүп ящигына ыргыта идек. Шкафка куелганнарны елга бер чистартып, макулатурага төяп китәләр иде. Арада синекеләр булган булса, гафу ит. Аңа без генә түгел, сез үзегез дә гаепле инде. Нигә татарча укый белмәүче түрәгә татар китабы бүләк итәргә.

Әнә ул сез бүләк иткән саратский гармун. Мин аңарда уйнарга өйрәнмәдем. Тальян минем стихиям. Аның гадилеге мине гашыйк итә. Авыл кызы кебек ул. Наив та, тиз ышанучан, бизәнмәсә дә матур, сафлыгы йөзендә балкып тора. Сипкеленә хәтле сөйкемле аның. Элек мин аңа игътибар итмәгәнмен. Хәзер аерманы күрәм. Хәер, авыл кызлары да инде бүген, шәһәр кызларыннан калышмаска тырышып, табигый матурлыкларын югалталар. Аларның да саф түгеллеге йөзләренә чыккан. Яшерен-батырын түгел, берәр зур түрә булып авылга барып төшсәң, мунча яктырып арка юарга кызлар китерергә кушсаң... Кирәкми, кыз-хатын хакында начар сүз әйтәсем килми. Чөнки мин аларны нинди булуларына карамый яратам. Шулай да бер хәлне сөйлим әле үзеңә. Яшь чакта булган хәл инде ул. Обком комсомолда чакта. Бер район үзәгенә барырга туры килде. Ничек каршылаганнары билгеле. Мәжлес. Мунча белән тәмамланган сый. Әйтмәсәң дә аңлап торалар кунакка ни кирәген. Керсәм, алгы бүлмәдә бер кыз утыра. Чәчен бер толымга үргән дә күкрәкләре уртасына сузып салган, юка гына ситсы күлмәктән. Тезләре өстенә куйган учлары белән туктаусыз итәген сыпыра, кап-кара күзләрен шар ачып миңа карап тора. Бик яшь күренә. Унжиде-унсигезләр тирәсендә. Мин инде ул чакта кыз-хатынны төрле рәвештә күргән кеше, әллә нинди фәлсәфәләргә бирелми генә ирләр эшләргә тиешле гамәлләрне кылам. Ләкин беркайчан да кыз-хатын теләгеннән башка мин аңа кагылмыйм. Кыз-хатынның күзенә бер карау белән аның ни теләгәнен аңларга өйрәнелгән. Әлеге кызның күзенә карау белән үк аның куркытып китерелгәнен аңлап алдым.

Янына утырдым. Сизеп торам, тәне моның тартына, гәүдәсе читкәрәк тартыла. Үзеннән моның нииндидер ислемайга кушылып сөт исе килә.

— Кайда эшлисең? — дип сорыйм.

— Фермада, — ди.

— Ә монда нишләп утырасың? — дим.

Кояшта янып алсуланган йөзе агарды моның.

— Куштылар, — ди.

— Кем кушты?

— Председатель.

— Нишләргә куштылар?

— Синең арканны ышкырга куштылар.

— Нигә чишенмисең соң, алайса? — дим.

Бөрешеп утырган кызый куырылып килде.

— Чишенергә кирәкмени? — ди. Иреннәре дерелди.

— Мунчада чишенәләр, — дим.

Бу селкенмичә, җыларга җитешеп утыра. Калтыранган кулларын угалый.

Мин моңа сораулар биреп газапламаска булдым.

— Бар, кайтып кит, — дидем. Шулай да кочаклап алып бер үптем үзен. Битеннән генә. Бигрәк чибәр иде шул. Кызый чыгып чапты.

Председательне чакырып алып бирдем кирәген. Урысчалап-татарчалап әллә ничә катлы итеп сүгендем. Ул чакта безнең арада сүгенү модада иде. Хәтта бюро утырышында аты-юлы белән сүгенеп сөйләшәләр иде.

— Миңа райком секретаре әйтте, — дигән була председатель.

— Әйтсә, беткәнмени ажгырып торган хатыннар, — дим. — Кемне китердең син миңа?! Хәзер үзеңне чишендереп педераст ясыйм, сволочь, — дим.

Ярый, моның музыкага кагылышы юк. Сүз уңаеннан гына. Телисеңме, мин сиңа үзем яраткан җырны тальянда уйнап күрсәтәм.

Рәсим тальянын кулына алды. Ашыкмыйча гына күрекне җыеп торган каеш тасманы тартмасы борып куелган бәләкәй шөрептән ычкындырды. Гармун өстенә ябылган тастымал белән бармакчаларны сөртте. Гармун каешын терсәгенә киеп уйныйсы көен искә төшерергә теләгәндәй уйланып торды да, уйнарга кереште. Уйнаганы — «Телеграм баганасы», мин инде беләм: кулына гармун алуга ул башлап шул көйне уйный. Көй эченә кереп китеп уйный. Нигә шул көйне сайлаганын үзе дә белми бугай ул. Сораганым булды:

— Әнидән калган, — дия иде...

---

## Рәхмәт, Туфан абый!

*«Берәү миннән үзе турында роман яздырырга теләде, яза алмамдыр инде», — соңгы кат очрашканда шулай дигән иде Туфан абый. Дача өйләрендәге язу өстәлендә калган бу өзелгән кыска текстта чын образ һәм чып-чын тормыш – ул кайбер зур-зур романнарны ормыш! «Рәсим Касыймович»ны танымаганнарга Туфан абыйның бездә ел башында чыккан (1-3 саннар) «Үзгәрү»енең «Шәхес» дигән бүлеген укырга киңәш итәм (№3)...*

*Бөтен гомерен колачлаган «Үзгәрү»не ул тиздән китәсен тоеп язгандыр, күрәсең. Шунда ук: «Бераз бу якты дөньяда яшәп алырга өметләнәм», дисә дә. Шөкер, «Үзгәрү»не инде басылып ятканда да ул теләгән бөтен өстәмәләрне дә кертеп чыгара алдык без... Аннан, 26 апрельдә, шигырь бәйрәмендә яныма килеп, «Фәүзия Бәйрәмова турында мәкалә яздым, сездә бирәсе килә, чыгарырсыз микән?» – диде. Ләкин китереп җиткерә алмады шул. «Сәхнә» журналы аша эзләп табасы булды. Шунда җыйдырткан ул аны, аннары укып төзәттергән. Бер сүзен дә үзгәртмичә бастырдык.*

*Кичә (12 октябрь бу) Тинчурин театрында Туфан абыйның «Төш»ен күреп тетрәнеп кайттым.*

*Таланты ташып ук тормаган яшь актерның дөньядан шушы Туфан Миңнуллин булып китүе могҗиза түгелме соң ул? Камал театрыннан үчләшеп сөргәне өчен Рәшидә Җиһаншинага рәхмәт әйтергә кирәк түгел микән әле?*

*Туфан абыйны халкыбыз өчен азрак эшләүдә гаепләүчеләр дә бар. Эшләгәннәре өчен рәхмәт әйтеп өлгердекме соң? Фәрештә түгел (йә, кайсыбыз фәрештә?), талантлы һәм игелекле адәм баласы гына иде абзабыз. Арабызга хәтта фәрештә иңсә дә, канат асларын иснәп, каурыйларын санап аны шайтанга чыгаручылар табылыр иде бездә. Минемчә, гомерен тулаем татар бәхете өчен көрәшкә багышлаган олуг зат берәү генә ул: Гаяз Исхакый. Шул бердәнберебезне дә олылыйбыз-кадерлибезме соң? Аның көрәш сәхифәләрен беләбезме, китапларын булса да укып чыктыкмы?*

*Рәхмәт сиңа, Туфан абый. Урының җәннәттә булсын.*

**Р.ЮНЫС**

# «АВЫР ЧАКТА ГЕЛ КАЗАНГА ЯЛГАНАМ...»

## АКАДЕМИК РӘШИТ СҮНӘЕВ БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ

*Рәшит Гали улы Сүнәев татарның иң олы галиме булса кирәк. Һәрхәлдә, иң олы ике галимнең берсе. 1974 елдан алып ул СССР Фәннәр академиясенең (соңрак Россия Фәннәр академиясе) Космик тикшеренүләр институтында эшли. 1994 елдан башлап Германиядә Макс Планк исемендәге җәмгыятьнең Астрофизика институты директоры да. Россия Фәннәр академиясеннән тыш АКШ, Европа, Нидерланд академияләренең һәм Бөекбритания Король җәмгыятенең дә әгъзасы. Алган алтын медальләре һәм саллы-саллы премияләре генә дә егермеләп икән.*



*Бу шанлы галимне күптән күрәсем килеп йөри иде. Ләкин Германиягә кадәр үк барырга, йомшак кына итеп әйткәндә, һич җай чыкмый иде. Күктән көткәнне җирдән бирде дигәндәй, Казанга ул үзе киләсе иткән. Үзе дип, үзе генә дә түгел: астрофизика буенча биредә зур халыкара фәнни конференция үткәрергә ниятләгән икән олуг галимебез. Конференциянең биш көн буе барасын белгәч, әһә, хәзер минем кулда бит бу дип тантана итсәм дә, алай булып чыкмады шул. Һәр тәнәфестә дөнья галимнәре чолгап алган Рәшит әфәндене биш көндә мин нибары өч тапкыр 25 минутлык «кофе-брейк»ларда гына эләктерә алдым. Анда да әле басып сыйланган коллегаларыннан йолкып диярлек алып китеп, түрдәге өстәл янына утырткач кына. (Үпкәләмәде, шөкер, «мин кем!»лек чиреннән азат гади-ихлас кеше икән бит бөегебез!)*

*Беренче сөйләшүебездән өч сәгатьләп алда, 5 сентябрь иртәсендә, Сүнәевнең Шаляпин кунакханәсендәге номерында телефон шалтырый. «Рашит Алиевич, здравствуйте!» — ди телефоннан көчле акцентлы, сәер тавышлы берәү. Сүнәев исәнләшкәч, сузып кына әйтелгән һәр сүзеннән соң пауза ясап, һәр җөмләнең соңгы сүзенә көчле генә басып төшереп, дәвам итә теге: «Я посланец планеты, которая вам неизвестна. У нас просьба. Предоставьте слово на конференции для оглашения предложения об установлении контакта между нашими планетами». Сүнәевнең җавабы исә тыныч һәм кыска була: «Я спешу. Скажите, что вам на самом деле нужно?»*

*Әңгәмәбезне мин әнә шул телефон сөйләшүеннән башлап җибәрдем.*

**— Рәшит Галиевич, бүген иртән сезгә бүтән планета вәкиле шалтыратты. Ләкин сез моңа ышанмадыгыз. Ни бу, мин тиешенчә уйнап җиткермәдемме, әллә сезнеңчә мондый хәл бөтенләй дә була алмыймы?**

— Галәм кунакларының миңа шалтырату ихтималы нульгә тигез. Бүтән цивилизацияләр бардыр ул анысы. Ләкин аларның безгә охшау ихтималы бик-бик аз шул. Аннан, безнең ярдәмнән башка алар безнең телләрне дә үзләштерә алмаячак.

Нинди икәнен белмибез, ләкин аларның аралашу ысуллары гел башкача инде. Шуңа күрә сезнең ул планетаара контакт дигәнегез бик тә катлаулы нәрсә.

**— Башка цивилизацияләр нинди планеталарда була ала соң?**

— Соңгы гасырлар дәвамында безгә бары Кояш системасындагы планеталар гына мәгълүм иде. Хәзер исә бик-бик ерак йолдызлар тирәсендә әйләнә торган 700ләп планетаны беләбез. Әле кайчан гына без табыласы планеталар шул безнең планеталар кебек үк булыр дип ышанып яшәдек. Ләкин табылган яңа дөньяларның планеталары нык кына аерыла икән. Алар арасында гигант планеталар, Юпитер кебек газ шарлары гаять күп. Ә менә безгә охшаш организмнар яши алсын өчен иң кирәкле шартлар — су (боз түгел!), атмосфера һәм каты өслек.

**— Адәм балалары шунсыз яши алмаган шартлар кайбер башка җан ияләренә кирәк булмаска мөмкин дигән фикер дә бар түгелме соң?**

— Сез хаклы, бар андый «җан ияләре». Бактерияләрнең атом-төш реакторы стеналарында яши ала торган төрләре дә бар әнә. Ләкин алар бактерияләр генә бит. Алар сезнең кебек миңа телефоннан шалтырата алмаслар шул *(көлә)*. Ниндидер зуррак, атлый-йөгерә ала торган җан ияләре яшәрлек планеталарны эзлибез без.

**— Уйлый да ала торганнарны инде.**

— Әйе, уйлый торганнарны. Менә шундый планеталарны эзләп табу — күзәтү планетологиясенең иң мөһим өлеше инде хәзер.

*Шушы урында мин академик алдына бер кәгазь бите салдым. Анда Сәйф Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен» дастаныннан ике юлны төшергән идем:*

*«Сөһәйлне күрде-йү әйләнде бер тик —*
*Көнәш гирдендә йөргән мисле җир тик».*

*Ягъни шагыйребез кызның егет янында әйләнүен генә түгел, Кояш тартуындагы Җир кебек әйләнүен дә язган! Инде 1394 елда ук! Аска Коперник белән Галилейның туу елларын да куйган идем: 1473 һәм 1564. Академик бу «әдәби-астрономик» фактны да, Мәкъсуд әл Болгари (XIII гасыр) кебек мөнәҗҗимнәребез (астрономнар) булганлыгын да белә икән. Адлер Тимергалинның «Идел» журналында (2000, №№ 7, 8) чыккан «Татар күге» мәкаләсен, бигрәк тә андагы Зур һәм Кече Җидегән йолдызлыкларының сурәтен (йолдызларның татарча исемнәре белән) күрүгә исә журналны миннән суырып диярлек алды.*

—Әти миңа бу йолдызлыклар турында бәләкәй чакта ук сөйләгән иде. Мине бигрәк тә Поляр йолдызның «Тимер Казык йолдыз» дигән исеме әсир итте. Бөтен башка йолдызларның сарыклар күк шушы Казык тирәсендә әйләнеп йөрүләрен күз алдына китердем... Венераның да татарча нинди матур исеме бар әнә: «Чулпан!».

**— «Зөһрә» дә бар бит әле!**

— «Зөһрә»се татарга гарәптән кергән исем инде.

*Бу журнал сезгә кирәк булырмы, дип сорагач, моңарчы русча сөйләгән бөек галим сөенепләр «Алам!» диде.*

**— Йөз елдан Җирдә, Җир фәнендә ни буласын күз алдына китерә аласызмы?**

— Беренче эш коралларын ясый башлаган, сөйләшә-аралаша алган адәм балалары инде меннәрчә еллар элек үк яшәгән. Радиолы, электрлы, машиналы чын цивилизация исә ике гасырлап элек кенә килгән. Телефон станциясендәге кызлар сораган номерны ялгап утырган чаклар әле кайчан гына? Ә хәзер әнә бәп-бәләкәй

балалар да урамда кесәгә телефон тыгып йөриләр. Әниләр балаларын телефон аша контрольдә тота.

**— Балаларын гына түгел, ирләрен дә!**

— Анысы да бар, әйе *(көлә)*. Безнең оныклар компьютерны ничек тиз өйрәнде әнә! Үсеш тизләнү шулай дәвам итсә, җирдә-күктә йөз елдан түгел, 20-30 елдан ни буласын да иң бөек фантастлар да әйтеп бирә алмастыр.

**— Ә сез фантастиканы укыйсызмы соң?**

— Күптән укыган юк. Чөнки безне ураган дөнья кеше уйлап чыгара алганга караганда күп кызыклырак, баерак. Фән хәзер шундый да тиз алга чаба, фантастика инде аны уза алмый башлады. Дөнья хәзер шундый матур ки, аны безгә өйрәнәсе дә өйрәнәсе әле.

**— Хәзерге заман Җир дөньясы турында минем үзгәрәк фикерем бар. Тик монысы калып торсын. Ә менә Галәм дигәне... Минем космик темага поэма да язганым бар. Ләкин мин төнге күккә бакканда сез тойганның мәгънәсен берен дә тоймыймдыр. Әгәр дә мин Галәмне, аның серле балкышларын сезнең кебегрәк тойсам, бәлкем, төннәрен бөтенләй йоклый да алмас идем... Әйтегез әле, сез ничек бу фани дөньяда аның соры көнкүрешенә, ваклыкларына да орынып, галәми нурда да коенып Җир белән Күк арасында яши аласыз?**

— Беренчедән, бу — ваклыклар түгел. Сезнең белән безнең тормышыбыз бу *(көлә)*. Без — кешеләр, һәм кешеләрчә яшибез дә. Һәм без эш белән мәшгульбез. Сез менә гадәттән тыш мөһим эш белән шөгыльләнәсез. Мин бит заманында «Казан утлары»н алдырган кеше.

**— Кайчан бу?**

— 70нче, 80нче елларда. 15 ел рәттән алдым. Хатыным «Азат хатын»га языла торган иде. Аннары ничектер Мәскәүдә яздырмый башладылар да, өзелеп калдым инде. Сез миңа журналның «Сүнмәс утлар балкышы» дигән гаҗәеп китабын бүләк иткәч, игелекле утның һаман әле сүнмәвен-сүрелмәвен тойдым. Бик шәп!

Беләсез бит инде, тормышта төрле хәлләр була. Кәеф кайвакытны күтәрелә, кайчакта төшә. Кайвакыт нык кына арыйсың да. Бик тә авыр чакта, кайда гына булсам да, Интернет аша ТНВ каналын җибәрәм. Казан вакыты белән аерма төрлечә була, ул бигрәк тә Америкада зур. Төрле кинофильмнар, боевикларга тарымыйча, җайлы гына эләксән, кемнәрдер чыгып, татарча сөйләшә башлыйлар. Кайчакны бу районнардан килгән кешеләр була. Ничектер хәлен җиңеләя башлый, рәхәт булып китә. Тагын әле җырлап та җибәрсәләрме! *(Бу мәлдә рәхәтлек галимнең чыраена һәм тавышына ук чыкты!)* Бәләкәй чагыма кайткан кебек булам. Бу телеканалның тәүлек буе һәм бөтен планетага эшләячәген белү бигрәк тә сөендерде... Татар дөньясына, җыр-музыкасына Интернет программалары аша да ялганам әле мин. Вакытым күп түгел, бер 20 минутлап тыңлагач, тагын эшкә тотынам... «Казан утлары» кулда чакта да шулай була торган иде. Актаргалыйсың, укыштыргалап та куясың, һәм шунда нәни чакта әбиләрем белән сөйләшеп алган кебек була...

**— Боларны ишеткәч, миңа да рәхәт булып китте, рәхмәт сезгә, Рәшит әфәнде. Ләкин тормыш гади нәрсә генә түгел. Безнең менә Нәҗип Җиһанов дигән бөек композиторыбыз бар иде. Әмирхан Еникине беләсез бит инде, гәпләшкәнсез. Миңа сезнең турыда әйбәт фикердә калуын да әйткән иде ул. Менә шул бөек әдибебез Нәҗип Җиһановның ике тапкыр өйләнеп, икесендә дә марҗаны алуы турында борчылып сөйләгән иде.**

— Аңлыйсыздыр инде, миңа бу турыда фикер әйтүе бик читен. Олы эш эшләгән кешеләрне без теләмәгән кешегә өйләнгәне өчен генә гаепләү дөрес микән ул? «Любовь зла...» дигән сүз дә бар бит әнә. Җиһанов татар культурасына зур өлеш керткән кеше. Тагын бер нәрсә бар. Без кешенең нинди шартларда яшәгәнен

белмибез. Ана нинди басым ясалганын. Аннары инде безнең арада булмаган кешене гаепләү кадәресе дә...

**— Мин сезнең белән килешеп бетмим, Рәшит Галиевич. «Үткәннәргә карап гыйбрәт ал», ди мәкаль. Үлгән кеше турында йә әйбәт сүз генә сөйлә, йә бөтенләй сөйләмә дигәнне тотсак, без Сталин турында да, Гитлер турында да ләм-мим бер сүз әйтмәскә тиеш булабыз. Бу — кечерәк масштабта да шулай. Яхшы кешеләрнең хаталары да безгә гыйбрәт булырга тиештер. Инде Җиһановка килсәк, ул бит хәтта малаена да «Иван» дип исем кушкан. Аңлыйсыздыр инде, сүзем бу бер шәхеснең гамәле турында гына түгел.**

— Әйе, ансы да бар шул. Милләтара никахлар халкыбызның санын киметә. Хәзер бигрәк тә хәтәр бу.

Халкыбызның язмышы гади генә түгел. Мин үзем Ташкентта туганмын. Гаиләбез әүвәл Пенза губернасында гомер кичергән (хәзерге Мордовия бу). Бабамның бөтен гаиләсен, кулаклар дип, Себергә сөргәннәр. 12 һәм 13 яшьлек туганнан туган ике апам анда ачлыктан үлгән. Алардан балалар калмады бит инде, димәк, нәсел җебен сузу безнең өстә. Һәм күпме кешенең газап чиккәнен онытмаска, хәтерне киләчәккә алып барырга тиешбез. Татар халкы ул заманда бик нык чәчелгән-сибелгән. Күпләр Урта Азиягә китеп котылган. Безнең белән бер телдә диярлек сөйләшкән үзбәкләр, казакълар, кыргызлар (дин дә бер бит инде), шөкер, ярдәм иткәннәр. Күп татарлар анда җинел генә укытучы булып киткән. Минем әти 17 яшендә Ташкентта эш эзләп үзбәк газетасына килгән. Баш мөхәррир, тикшереп-сынап карагач, болай дигән: «Син гарәп шрифтын шәп беләсең, ә менә үзбәк телен белмисең икән. Ярар, берәр атнадан корректор булып эшли башларсын». Анда татарларга мөнәсәбәт әле дә начар түгел үзе. Үзбәкстан аерылып чыкканнан соң анда урыслар саны 4,5 тапкыр кимесә, татарларда бу сан күпкә азрак. Ләкин барыбер меңнәрчә кеше бит. Яшьрәкләре күбрәк тә китә әле. Бик мөһим нәрсә бу: бирегә кайтканнарын үз итеп, болар да татарлар бит дип каршы алсалар иде, сәләт-мөмкинлекләрен ачарга юл куйсалар иде.

**— Гап-гади тоелса да, чынлыкта четереклегә дә әйләнгәли бу мәсьәлә. Юкса үз милләттәшләренә мөнәсәбәттә үзбәкләрдән дә калышырга кирәкмидер инде, әйе.**

**Рәшит әфәнде, 1960-66 елларда сез Мәскәүдә Физик-техник институтта укыгансыз. 17 яшьтә килеп. Андагы ымсынулы-йогышлы тормыш күп нәрсәләрне оныттыра бит. Берәүләргә хәтта — милләтен дә. Сез мондый шаукымны тоймадыгызмы?**

— Юк, тамырлардан өзелеп торганым булмады. Бер тапкыр шулай Союзлар йортының Колонналы залында татар язучылары, зыялылары катнашында зур бәйрәм тантанасы үткәрелде. 1966да булса кирәк. Тукайның юбилее уңаеннан иде кебек бу. Шунда Чыңгыз Айтматов та чыгыш ясады. Бик тә күнелем булды шуна. «Жәмилә»сеннән башлап бөтен әсәрләрен дә бик яратып укып барган идем. Ул чордагы бөтен татар язучыларыннан да данлыклырак әдип бит инде ул.

**— Татар язучыларыннан гына микән? Украинада чыга торган «Рабочая газета» 1971 елны үзенең укучыларына «Иң яраткан язучыгыз кем?» дигән сорау биргән. Беренче урынны, Шолохов, Симонов кебек «пәһлеваннарны» да җиңеп, Айтматов алган *(эңгәмәдән соң аныкладым: Шолохов — 1180, Симонов 450 тавыш җыйса, Чыңгыз агайны беренче урынга 1830 кеше куйган. Безнең Әпсәләмов та сынатмаган: В. Кожевников, Б. Полевой, Г. Марковларны узып, 8нче урынны алган — 400 тавыш).***

— Әйе, кызык бу. Ә мин, ул чакны әле бер студент кисәге генә, тәнәфестә әлләкемләнеп Айтматовны эзләп таптым да, болай дидем: «Килүегезгә бик-бик зур рәхмәт, бу безнең барыбыз өчен дә гаять мөһим! Татар әдәбиятына шулай ярдәм күрсәтүегезгә рәхмәт!» Шунда ул мина текәлеп карады да, «Әниемә вәгъдә биргән идем. Шуна күрә монда мин», — диде. Сонрак мин бу бөек язучының әнисе татар икәнлеген белдем...

**— Кыргызстанда туган икән Нәгыймә апа. Чыңгыз ага гомеренең азагында бабасы Хәмзәнең туган авылы Мәчкәрәгә кайтып килергә ниятли. Әмма Кукмара районына кайтып житә алмый шул.**

— Әйе, беләм. Казанда кунакханәдән — хастаханәгә, аннан дәваланырга Германиягә алып китәләр аны. Шунда дөнья куя...

Миңа шефым Зельдович[1] белән Айтматовның өендә булырга да туры килде әле. Ерак юлга жыенган чаклары икән. Әдипнең яшь хатыны керә-чыга, керә-чыга, безнең сүзне бүлдереп, юлга нәрсәләр алырга икәнен сорый. Мин боларның бөтен сүзен аңлап торам. Моны Зельдович чыккан чакта Чыңгыз Терегулловичның үзенә дә әйткән идем. Ул, көлеп, «Сезнең аңлаганны чамалыйм мин, ә менә Зельдович безне, кыяфәтебезгә карап, бик тә олы мәсьәләләр хәл итә болар дип уйлагандыр инде», — диде.

**— Рәшит әфәнде, сезгә татар мәктәбендә уку, татар җирлегендә яшәү тәтемәгән. Шуңа күрә гади генә булмаган, фәнгә дә кагылышлы бу әңгәмәбез рус телендә бара. Ләкин сүз сөрешегездән татарчаны ару гына белүегез дә чамалана. Европада яшәгән дөньякүләм данлы галимгә татар теле нигә кирәк ул? Татарстанда яшәүче әти-әниләр арасында да, балабыз татарча белә күрмәсен, юкса надан калыр дип тәшвишләнүчеләр юк түгел бит!**

— Телебез миңа аяк чалмады гына түгел, киресенчә, үсәргә ярдәм итте. Әтием аша туган телемдә күп мәгълүмат алдым мин. Аннан, туган телен белгән кеше башка телләрне тизрәк өйрәнә бит. Татарча әйтелеш үзе генә дә миңа немец һәм инглиз телләрен өйрәнүне җиңеләйтте. Соңрак киң дөнья белән аралашканда да кирәге чыга иде әле аның. Телебезнең миңа чын мәгънәсендә ачкыч та булганы бар. Бер тапкыр шулай АКШның Милли академиясе әгъзалары һәм Германиянең институт директорлары белән Кытайга барган идек. Уйгыр җирендә бик матур бер мәчет янына килеп чыктык. Боларның мәчетне эчтән дә күрәселәре килде. Ләкин кертмәделәр. Шунда мин рөхсәтне татарчалатып сораган идем, кертәтеләр бит! Безне озатып йөргән кытайларга гына юл ябылды. Тагын бер кат үтенгәч, «Ярар, керсеннәр, сез теләгән бөтен кешене дә кертәбез», — диделәр.

**— Безнең мәдәниятне, мәгърифәтне түбәнсетү омтылышлары да бар. «Аргументы и факты» газетасы хәтта татарлар Октябрь революциясеннән соң гына әлифбалы булган дип тә шаккатырган иде. Ягъни шуңарчы язу дигән нәрсәне без бөтенләй белмәгәнбез. Бу — Мәкъсуд әл Болгари кебек астрономнары, Коперник-Галилейлар дөньяга килгәнче үк гашыйк кыз Кояш тирәсендә әйләнүче Җиргә тиңләнгән дастан язган Сәйф Сараилары булган халык турында бит!**

— Мәгарифебез турында Ленин бик шәп әйткән. Татар халкында бөтен балалар да мәктәптә укый, дигән. Бу бит Россиядә хәтта урысларның үзләрендә дә тулы гомум белем бирү системасы булмаган чакта әле.

**— Казан университеты ректоры, немец галиме Карл Фукс та шәп әйткән бит: «Читтән килгәннәргә Казан татарларының хәтта кайбер Европа халыкларына караганда да белемлерәк икәнен белү сәер тоела... Укый-яза белмәгән татарны үз якташлары да санга санамаган һәм ул гражданин буларак та ихтирамга лаек булмаган». Сезгә биргән китапның 58нче битендә, Рәшит Галиевич, өч катлы зур һәм матур бер бинаның рәсеме бар. Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсе бу. Өч бертуган Хөсәеновлар салдырган аны. Бер мәкаләмдә мин, хәзерге кайбер ректорлар да кызыгырлык бина бу, дип язган идем. Рас килгән бит: йөз дә ничә яшьлек ошбу йортны яңа бер институт үзенә оя иткән!**

— Хәзер татарча уку мөмкинлеге чикләнгәннән чикләнә бара. Моны мин Мәскәүдән дә чамалыйм. Мондый хәлдә ата-аналар балалары туган телне белсен өчен үзләре бик нык тырышырга тиешләр. Бу шактый четерекле эш. Телне начар

[1] Яи Зельдович (1914—1987) — академик, Ленин премиясе лауреаты, өч тапкыр Социалистик Хезмәт Батыры.

белгән балалар гадәттә сөйләшергә оялалар. Юкка оялалар. Монда аларның гаебе юк.

**— Русчалатып әйтсәк, «это не их вина, а их беда».**

— Әйе, шулай. Бу — без олыларның гаебе. Шуна күрә аларны әлеге халәттән чыгарырга кирәк, хәйләсен-җаен табып, туган телләренә ялгарга кирәк. Бу рус телен өйрәнүгә зыян сала дип куркасы юк. Һәр тишектән ишетелеп торган телне балалар бик тиз отып ала ул. Безнең кече улыбыз Гали Германиягә күчкәндә шәп кенә инглизчә, русча, бераз татарча белә иде, немецча исә бер авыз сүз белми иде.

**— Гафу итегез, Рәшит әфәнде, Германиягә күчү ничек булды ул?**

— Германиядә институт директоры итеп билгеләнгәч, без гаилә Мәскәүдә яшәп, Германиягә барып кына килгәләр дигән идек. Әмма немецлар, әгәр алар минем белән яшәсә, налогка эш хакымнын — 30 проценты, Мәскәүдә яшәсәләр, 57 проценты тотылачагын әйттеләр. Шуны белгәч, хатыным...

**— Исеме кем?**

— Гүзәл. Гүзәл Тәлгатовна. Ул, акчаны 27 процентка күбрәк алган җирдә яшәячәкбез, дип кырт кисте. Үзем дә эшкә урнашырмын, диде. Врач ул.

**— Хәзер Галигә әйләнеп кайтыйк инде. Әтиегезнең дә исеме Гали бит сезнең. Ничек кушасы иттегез?**

— Зельдовичтан башланган эш бу. Ул шалтыратты да, әйтте. Еврей гаиләләрендә, әгәр бабай үлеп, оныгы туса, аңа бабасының исемен кушалар, диде. Сүзне дәвам итик. Мин мәктәп директорын аны укырга немецча шулай бер сүз дә белмәгән килеш алырга күндердем. Бик тиз өйрәнәчәк, дидем. Күпмедер вакыт укып йөргәч, бер көнне башын иеп кайтып керде бу. Еламый гына. «Али! Али!» дип бөтенесе минем исемнән көләләр, ди. Димәк, мөнәсәбәт шәптән түгел инде. Бабаң шушы исем белән гомер кичерде, беркем дә көлмәде, дидем. Көчле рухлы булсаң, бирешмәсәң, үтәр бу, әйбәт, мәгънәле исем, дидем. Бер елдан ул безнең барыбызны да мәктәп театрына чакырды. Нииндидер роль башкара икән. Минем жай килмәде, Гүзәл белән кече балабыз — кызыбыз Зөлфия бардылар. Эшләремне эшләп өйгә кайтсам, Гүзәл елап утыра. «Ни булды, нигә елыйсын?», — дигәч, «Кызыбыз сөйләсен әнә», — диде. Зөлфия сөйләде инде. Гали чыккан да, спектакльдә тиеш булганча, зал каршында ялкынлы нотык тоткан. Һәм шунда залдагы немецлар, алкышлап, «Али! Али! Али!» дип кычкырганнар. Ул чакта инде немецчасы да ару гына иде. Менә бит, максат куеп эшләгәндә нибары бер ел эчендә дә нәрсәгә ирешеп була икән!

**— Хәзерге көндә ни майтара егетебез?**

— Хәзер ул — Кельн университетының компьютер фәннәре профессоры.

**— Тагын ике улыгыз бар бугай бит.**

— Олы улым Шамил Америкадагы Гарвард университетында кеше генетикасы профессоры. Малае — Рәүф, кызы Гадилә исемле. Уртанчы улыбыз Госман зур булмаган бер банкта автоматика бүлеге башлыгы. Зөлфиябез Мюнхендагы Людвиг-Максимиллиан университетынын медицина факультетында 5нче курста укый.

Туган тел турында сөйләнгәннәргә өстәп шуны да әйтим әле. Мине Американың фәлсәфә җәмгыятенә әгъза итеп алганнар иде. Аның утырышларына да чакыра башладылар. Минем һич тә барасым килмәде. Чөнки СССР фәлсәфәчеләренең хакимияткә ничек хезмәт иткәннәрен белә идем. Ләкин бу җәмгыятьнең әгъзасы булу бик тә абруйлы икән. Һәм анын утырышлары да кызыклы үтә икән. Үзем катнашкан беренчесендә үк күнелемә бик тә хуш килгән доклад тыңладым. АКШта яшәүчеләр арасында испан телледәр күп бит. Шулардан яшьләрнең бер өлеше төрле җинаятьчел төркемнәргә тартыла икән. Һәм Америкада, болар инглиз телен юньләп белмәгән, өйдә бары испан телендә генә сөйләшкән, яшьләр дигән фикер яшәп килгән. Кубада

университет тәмамлаган, аннары Фидель Кастродан качып башта Аргентинага, аннары Америкага килгән, анда Принстон университеты профессоры, АКШның Милли академиясе әгъзасы булган галим әлеге мәсьәләне шәпләп өйрәнгән. Киресенчә, теге бандаларга нәкъ менә өйдә инглиз телендә сөйләшүчеләр тартыла икән бит. Әти-әниләренең чит телдә аны вата-җимерә акыл өйрәтергә маташуларын тыңлап үскән балаларда аларга ихтирамның әсәре дә калмый икән. Ягъни бу балаларга тәрбия керми, киресенчә, әти-әниләре кире тәрбия бирә булып чыга. Ә менә испан телендә сөйләшкән әти-әниләренең инглиз телен белеп җиткермәвен балалар беркадәр кимчелек дип санасалар да, булган бөтен гыйлем-мәгълүматны, ерак бабаларына ук барып тоташкан бай тормыш тәҗрибәсен саф туган телләрендә шәп итеп җиткерә алулары моны бише белән кайтара икән. Нью-Йорктагы теге олы 11 сентябрь фаҗигасеннән соң моны инглиз-гарәп телләре җәһәтеннән тагын бер кат тикшереп караганнар. Һәм тагын нәкъ шундый нәтиҗәгә килгәннәр: гаиләдә үз телендә, туган телендә сөйләшергә кирәк!

**— Күренекле фантаст язучыбыз һәм галимебез Адлер Тимергалинның сез яңарак кына күз салган «Татар күге» дигән мәкаләсе үткән заман казанышлары турында. Хәзер исә Галәм киңлекләренә беркайчан да булмаганча күптин-күп татар күзе текәлгән. Теге «ерак планета вәкиле»нең контакт мәсьәләсендә нәкъ менә Казанга шалтыратуы да тикмәгә түгелдер, бәлкем? Галәмне өйрәнү буенча бирелә 2001 елдан башлап үткәрелгән дөньякүләм конференцияләрнең бишенчесе бит инде бу! Шул җәһәттән танылган күкбагарларыбызны барлап чыгу да дөрес булыр иде.**

— Гафу итегез, бүлдереп булса да әйтим әле. Галәмне өйрәнүчеләрнең бик азы гына хәзер күккә телескоп аша бага.

**— Шулайдыр, әйе. Күпчелек күккә хәзер физика, химия, математика фәннәре күзе белән багадыр. Сез дә бит менә астрофизик. Асыл «күкче»ләрне барлауны исә Роальд Сәгъдиевтән башларга тиешбездер. Ул — 19нчы мәктәптә укыган, Шәйхи Маннур белән шахмат уйнарга яраткан чын Казан баласы бит инде. 36 яшендә үк, ягъни СССРда иң яшь академик булган кеше. Аның турында журналыбызда очерк та басылган иде.[2]**

— 1972 елны СССР Фәннәр академиясенең Космик тикшеренүләр институтына килү белән мин, әле аспирантурадан соң 5-6 еллап кына эшләгән кеше, институт директоры Роальд Зиннуровичның шәп йогынтысын тоеп, аның ышыгында үстем. Бик-бик көчле галим ул. Мина АКШның Сан-Диего университетында дөньяның иң олы физикларыннан берсе Розенблюд белән очрашу насыйп булды. Ул чакта вафатына бик аз вакыт калган булган икән инде. Галим мина Сәгъдиевне Максвелл премиясенә тәкъдим итеп язган хатын укытты. Хатның эчтәлеге әле дә сүзгә-сүз диярлек хәтеремдә. «Хәзер дөньяда яшәүчеләр арасында электроннар, зарядлар дөньясын, магнит һәм электр кырларын Роальд Сәгъдиевтән дә шәбрәк белгән бер генә кеше дә юктыр. Максвелл премиясенә аннан да шәп кандидатны белмим мин...» Сезгә исә бу бәянең мәгънәсен ачыбрак бирәсем килә. Розенблюд кебек бөек зат, үзен дә кертеп, дөньяда бүтән мондый кеше юк дип әйтә икән, бу инде гаҗәеп зур бәя. Һәм — дөрес бәя. Тагын шунысын да әйтим. Роальд Зиннурович СССРдагы иң шәп оештыручыларның берсе иде. Ул Космик тикшеренүләр институты директоры чакта гаҗәеп киң колачлы, искитмәле проектлар гамәлгә ашты.

**— Сәгъдиев Америкага китеп баргач, аның урынында Альберт Галиев калды бит.**

— Галиевне мин бик шәп белә идем, без дуслар идек. Әмма, кызганыч ки, Альберт Бакиевичның хәзер хәле авыр, бик каты авырый. Ә болай ул космос плазмасы буенча дөньякүләм танылган галим һәм бик әйбәт кеше...

**— Милләттәшләребез әлеге конференциядә катнашучылар арасында да бар бугай.**

---

[2] М. Гәрәев. Академик. 1979, № 1.

— Бар, әйе. Аларның берсе — шул Космик тикшерүләр институты профессоры Марат Равилович Гыйльфанов. Казанда туып, мәктәп тәмамлаганнан соң Мәскәүдә шул мин дә укыган Физик-техник институтта укып, минем янга әле студент килеш үк килде. Хәзер ул — дөньякүләм танылган бик көчле галим.

**— Сезнең йогынты шундый булгандыр инде.**

— Юк, минеке генә түгел. Бу — беркайда да югалып калмый торган кеше *(көлә)*. Фәннең әлеге өлкәсенә килүендә өлешем бардыр, әйе. Ләкин ул кайсы юлдан гына китсә дә көчле, бик көчле галим булачак иде. Бүгенге докладн да шәп, тәэсирле булды әнә.

Конференциягә Россия Фәннәр академиясенең Ландау исемендәге Теоретик физика институтының сектор мөдире Наил Галимович Иногамов та килде. Ул газ динамикасында да, гидродинамикада да дөньяга танылып өлгергән галим. Хәзер генә докладын тыңладык әнә. Принстон институтының профессоры Роман Равилович Рафиковны да тыңладык инде. Докладында гел Иногамовның эшләренә таянды ул.

Конференциядә Илдар Хәбибуллин да чыгыш ясады. Бу — Башкортстанның бәләкәй генә шәһәрендә мәктәпне алтын медальгә тәмамлаганнан соң Космик тикшеренүләр институтында, Сергей Сазонов җитәкчелегендә аспирантура үткән егет. Бергәләп ике мәкалә дә язды алар.

**— Сез дә бер мәкаләгезне Зельдович катнашында язгансыз бит. Һәм фәнгә «Сүнәев-Зельдович эффекты» дип кергән гаҗәеп теориягез кәгазь битләренә генә түгел, йолдыз томанлыклары белән күккә дә язылгандыр сыман.**

— Арттырмыйк, яме. Сез әллә фантаст та инде? *(көлә)*. Сүз бит бәләкәй татар шәһәреннән калкып чыккан 22 генә яшьлек егет турында, аның искиткеч шәп мәкаләләр язуы хакында. Бу — көчле, төгәл, анык гакылга ия менә дигән кеше. Туры сүзле, ялгышсаң, «юк, алай түгел ул!» дип чәпәргә дә күп сорамый *(көлә)*. Кыскасы, бик шәп бу, мин канәгать.

Биредә, Казанда, бер бик әйбәт фәнни мәктәп барлыгы сөендерә. Бу — КФУның астрономия кафедрасы мөдире, Татарстан Фәннәр академиясе академигы Наил Абдуллович Сәхибуллин мәктәбе. Әлеге мәктәпне дөньяда бик күпләр белә. Казан университеты профессоры Бикмаев Илфан Фәритовичны аерып әйтәсем килә. Ул әлеге конференцияне оештыручыларның берсе. Бу — бик тә югары кимәлдәге күзәтүче. Ул бик күп нәрсәләрне аңлый, һәм шәп аңлый. Электр-магнит нурлары объектларын космостан башка диапазоннарда күзәтүләргә ул җирдән оптика белән күзәтеп ярдәм итә. Һәм Европаның «Интеграл» ясалма иярчене программасында ул гаҗәеп бер роль уйный. Бикмаев Американың берничә иярчене программасы буенча күзәтә. Күптән түгел аны «Планк» иярчене коллоборациясенең ассоциацияләнгән әгъзасы итеп чакырдылар. Бу — бик тә олы, гаять мөһим космологик иярчен. Сез аңлап житкерәсез микән: менә биредә, Казанда, югары дөнья кимәлендәге, бөтенесен дә үзе булдыра ала торган гаҗәеп кеше эшли!

**— Мин моңарчы аның дөньяда барлыгын да белми идем шул.**

— Белегез инде менә! *(Көлә)*.

*Шушы урында ул, Сүнәев, гафу үтенеп, суынган кофесын бу юлы да эчеп бетерә алмыйча, торып басты. Очрашу тагын кайчан насыйп булыр инде. Сораулар күп калды бит әле.*

**Рәфикъ ЮНЫС**

# ГАЛИ РӘХИМ: МИЛЛӘТ ӨЧЕН ЯШӘҮ ҮРНӘГЕ

ГАЛИ РӘХИМНЕҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ

Гали Рәхим — милләткә хезмәт итәр өчен дөньяга киллем дип санаган һәм үзенен акылын, белемен, сәләтен, вакытын тулысы белән шушы максатка ирешү өчен файдаланган, укымышлы, зыялы, нечкә күнелле һәм югары эстетик зәвыкка ия шәхес була. Әлеге максаты төпле, салмак, еракка карап эш-гамәлләр башкаручы Галине татар янарышының үзәгенә алып килә, бу хәрәкәттәге аз сүзле, туктаусыз эзләнә һәм эшли торган затлы, олпат шәхесләрнең берсенә әвереллерә. Онытылуга хөкем ителгән бу шәхесне тууына 120 ел тулганда без янадан «ачабыз».



Мөхәммәтгали Мөхәммәтшакир улы Габдерәхимов 1892 елнын 4 ноябрендә Казанда туа. Әтисе чыгышы белән Лаеш өязе Олы Мәтәскә авылы крестьяннарыннан. Казанга килеп, сәүдә эше белән шөгыльләнә башлаган егет бик тиз аякка басып китә. Шәһәрдә билгеле сәүдәгәр Исхак Айтугановның Бибигайшә исемле кызына өйләнеп, ул үзенең матди хәлен тагын да ныгыта, элемтәләрен киңәйтә.

Мөхәммәтшакир улын да үз эзеннән җибәрергә тели, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыган жиреннән 1905 елны Казандагы Сәүдә (Коммерческое) училищесына керергә күндерә. Бер үк вакытта Мөхәммәтгали үзлегеннән һәм өйгә килеп укытучы хәлфәдән гарәп, фарсы, төрек телләрен өйрәнә, әдәбият һәм фән белән кызыксына башлый. 1909 елны 17 яшьлек егет, рус телендәге «Вокруг света» дигән китапка нигезләнеп, мәдрәсәләр өчен «Жир йөзе» дип аталган география дәреслеге бастырып чыгара. Бөек драматург Г. Камал тарафыннан киләчәктә әдәбиятка зур хезмәт күрсәтәчәк кеше дигән бәя ала.

1913 елны училищены тәмамлагач, әтисе аны Мәскәүдәге Сәүдә институтынын икътисад бүлегенә җибәрә. Ләкин бу елларда Гали Рәхим татар яшьләре арасында милли хисенең куәте, әдәби таланты белән танылa. Үзенең язмышын алып-сату белән бәйләргә теләмәсә дә, әтисе фикерен кире кагарга базмый. 1917 елны, әтисе үлгәннән соң, институтны ташлап Казанга кайта, укыту һәм фән юлыннан китә.

Гали Рәхим берьюлы күп өлкәләрдә эзләнүләр алып бара, бөтен жиргә өлгерә, әйтерсең, үзенең көч-куәтен, гыйлемен, жегәрен файдаланып калырга ашыга. 1920-1930 елларда аның илледән артык фәнни хезмәте басылып чыга. Ул — Казан университеты каршындагы Тарих, этнография, археология жәмгыятендә, Татарстанны өйрәнү жәмгыятендә, ТАССР Мәгариф Халык Комиссариаты каршындагы Гыйльми Үзәктә әгъза. 1934 елдан Казан университетынын фәнни китапханәсенең кульязмалар бүлегенә гыйльми консультант булып урнаша һәм бирелгәге кыйммәтле тарихи ядкәрләрне тәртипкә салу эшенә керешә.

Кызганыч ки, 1917 елда илгә килгән үзгәрешләрне кабул иткән, жин сызганып яна дәүләт төзү эшенә катнашкан, татар милләтен үстерү-үзгәртү өчен инкыйлабны файдалы дип ышанган мондый шәхесләр язмышы аяныч тәгаълләнә. Илдә яна

тәртипләр урнашып бара, татар язучылары да традицияләрне тәнкыйть итеп, яңа әдәбият тудыру хакында хыялланалар. Бу матур хыял еш кына дөреслеккә туры килмәгән, түбән, вак, пычрак тәнкыйть артында күмелеп кала. Г.Рәхимнең 1921 елны «Әдәби ярдәм мәҗмугасе»ндә, 1922 елны аерым китап булып басылып чыккан «Идел» повесте да көчле тәнкыйтькә очрый. Г.Нигъмәти, Г.Толымбайский, С.Җәлал, Г.Сәгъди, Г.Ибраһимов кебек шул чор әдәби хәрәкәтендәге олы фигуралар әсәрне «иске милли язучының белә торып кирле-морлы язуы» дип атыйлар, рухы белән язучы пролетариат идеологиясенә ят дип белдерәләр. Авторга «сәүдәгәр семьясындагы мещан сентиментальлеген идеаллаштыручы» дигән исем тагыла, ул ышанычсызлар исемлегенә эләгә. Кулга алынып, Ак диңгез-Балтыйк каналында эшли, 1934 елның 22 августында азат ителә.

1937 елның язында, Г.Шәрәф, С.Җәлал белән бер төркемдә Г.Рәхим кабат кулга алына. Алар «Идел-Урал штатлары» дигән мөстәкыйль буржуаз-демократик төрки-татар дәүләте төзү өчен яшерен көрәш алып барган өчен гаепләнәләр. 1940 елның 27 февралендә суд Г.Рәхимне 8 ел концлагерьга җибәрергә хөкем итә. Аннан каты авыру хәлендә кайтып, 1943 елның 3 мартында гүр иясе була. 1958 елның 2 февралендә аклана.

Гали Рәхим әдәби барышта 1913 елдан, күпсанлы хикәяләре белән таныла. Әдәби ысул һәм алымнар сайлау ягыннан да, сюжет бирелешен карасак та, бер-берсенә охшамаган, үзенчәлекле әсәрләр: «Эч пошканда», «Яз әкиятләре», «Хан мәчетендә», «Серле-серле әкият» кебек хикәяләр яңа нәшер ителә башлаган, ләкин татар дөньясында шау-шулар уяткан «Ан» журналында басылып чыга. Әлеге әсәрләр татар прозасының әдәби-эстетик мөмкинлекләре хакындагы күзаллауны киңәйтеп җибәрә, Г.Рәхим исә Ф.Әмирханнар, Г.Гобәйдуллиннар белән иңгә-иң торып иҗат итә башлый.

Шушы ук 1913 елны Г.Рәхим тәнкыйтьтә дә үз сүзен әйтерлек әзерлекле булуын дәлилли. «Ан» да дөнья күргән «Тукаев — халык шагыйре» язмасы аналитик фикерли торган, әдәбият теориясе һәм поэтикада иркен «йөзүче», Европа, рус, шәрык әдәбиятлары тарихын яхшы белүче автор пәйда булу хакында сөйли. Аерым әдип иҗаты хакында сүз алып барганда да Г. Рәхим гомумән татар әдәбиятын күздә тотып һәм аны рус-европа әдәбияты фонында карап сөйли. «Безнең яңа әдәбиятыбыз да туганнан ук гомуми булып туды, безнең яшь әдәбиятыбыз да бер-бер аерым сыйныфка гына түгел, ул чын мәгънәсе белән демократический, авыл арасына да, руханилар вә шәкертләр арасына да, сәүдәгәрләр вә хезмәтчеләр арасына да аның юлы ачык...» дигән бәя биреп, утызынчы елларда яңгыраячак гаепләүләргә алдан ук киртә куя.

1914 елны Г.Рәхим «Ан»да «Халык әдәбиятыбызга бер караш» дигән мәкаләләр циклы белән чыга. Татар әдәбиятының тарихи тамырлары белән кызыксынып, аның кайбер сыйфатларын нәзари яктан аңлатып язылган мәкалә әдәбият белеме фәнендәге Г.Ибраһимовлар, Җ.Вәлидиләр позициясенә килеп кушыла, мәкалә авторын исә татар халык авыз иҗаты үрнәкләрен җыйнаучы, тикшерүче итеп таныта.

Талантлы кеше бар яктан да оста була, диләр. Гали Рәхим чит текстны милли телдә бирә алучы тәрҗемәче сыйфатында ат ала. Көнчыгыш шагыйрьләреннән Г.Хәйям, Хафиз, Ширази, Җ.Руми, Р.Тагор әсәрләрен, У.Шекспирның «Гамлет»ын, рус һәм Европа язучыларының шигъри һәм проза әсәрләрен татарчага тәрҗемә итә. Үзе дә нәфис шигырьләр яза, драматургия өлкәсендә дә көчен сынап карый. Аның «Дача кайгысы» (1914) комедиясе, «Җанвар» (1919) драмасы үз вакытында танылган әсәрләрдән була, «Сәйяр» труппасы тарафыннан сәхнәгә куела. Татар театр сәнгате хакындагы мәкаләләре сәнгать мәсьәләләрендә үзен иркен хис итүе хакында сөйли.

1917 елдан соң Г.Рәхимнең татар әдәбиятындагы зур әсәрләр хакында мәкаләләре языла. Г.Ибраһимовның «Казакъ кызы» романы, К.Насыйри, Г.Гобәйдуллин, Һ.Такташ иҗаты турындагы язмалар әдәби җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уята. Һәр әдипнең татар әдәбияты барышында үз сукмагын, үз сурәтләү алымнарын барлап язылган мәкаләләр бер үк вакытта татар әдәбияты тарихына бәя булып яңгырый. Г.Рәхим татар әдәбиятындагы аерым әсәрләр, яңа күренешләр хакында башлап сүз әйтүче була. Мәсәлән, Г.Гобәйдуллин иҗатын Чехов иҗаты белән

янәшә куеп, Г.Рәхим аңа олы бәя бирә, язучының иҗат эволюциясен күзәткәндә, символизмнан башлап, юмор, соңрак сатира чаралары ярдәмендә үз язу рәвешен тудыруын исбат итә.

1920 еллар — Г.Рәхимнең фәнни каләме чарланып житкән, галим буларак аңа шөһрәт килгән вакыт. Бигрәк тә 1925-1932 елларда күпсанлы мәкаләләр, чыгышлар, докладлар авторы буларак исеме һәрдаим матбугатта яңгырап тора. Тел, әдәбият һәм тарих институты архивындагы Г.Рәхим фонды (18 ф., 1 тасв.) материалларына караганда, галим берничә юнәлештә актив эзләнү алып бара: халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю һәм анализлау методикасы; сәнгать, поэтика һәм халык авыз иҗаты бәйләнешләре; сәнгатьнең килеп чыгуы хакындагы концепцияләр; әдәби иҗат теориясе һәм психология; тарих һәм этнография. Татарстанны өйрәнү җәмгыяте кысаларында милли тарихка караган чыганаклар һәм мәгълүматларны бастырып чыгаруы, «Халык зарларыннан» (1929), «Иске бәетчеләрдән берсе» (1929), «Крестьян шагыйре (Вәли Җиһаншин)» (1929) һәм башка әдәбият тарихына караган мәкаләләре, Гыйльми Үзәк кушуы буенча төзегән «Фольклор һәм халык әдәбиятын җыю өчен кулланма»(1926), «Авылны өйрәнү өчен җентекле кулланма-программа» (1930) кебек хезмәтләре дә шушы кызыксыну-эзләнүләр нәтиҗәсе.

Г.Рәхим калдырган мирас арасында иң кыйммәтлесе, иң саллысы — һичшиксез, Г.Гобәйдуллин белән берлектә нәшер ителгән «Татар әдәбияты тарихы». Төрки халыклар тарихын, фольклорын, күпсанлы чыганакларны өйрәнеп, борынгы кульязмаларны барлап язылган хезмәт милли сәнгать тарихын Орхон-Енисей ташъязмаларыннан алып тикшерүне күз алдында тотып уйланыла. 1922-1923 елларда «Татар әдәбияты тарихы»ның икенче һәм өченче кисәкләре басылып чыга. 1924 елны беренче кисәге, 1925 елны «Феодализм дәвере» исеме белән кыскартылган икенче басма дөнья күрә.

«Татар әдәбияты тарихы өчен материаллар җыю юлында бер тәҗрибә. Мәдхәл» исеме белән аталган беренче кисәктә рун, уйгыр һәм гарәп язулы гомумтөрки истәлекләр, суфыйчылык һәм аның шәрык әдәбиятына тәэсире, уйгыр, чыгтай, сәлҗүк һәм госманлы әдәбиятлары турында мәгълүматлар бирелә. «Татар теле һәм әдәбиятының тарихи язмышы», «Идел буенда иң борынгы тел ядкярләре», «Идел буенда чыгтай әсәрләре», «Идел буенда госманлы әсәрләре» дигән өлешләрне берләштергән икенче кисәктә татар әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсүе, борынгы тел ядкярләре буларак «Коман мәҗмугасе», кабер таш язулары, ярлыклар игътибар үзәгенә куела. Рабгузиның «Кыйссасел әнбия»се, Сөләйман Бакырганиның әсәрләре, «Сөбател гаҗизин», «Кисекбаш китабы», «Сәйфелмөлек» кебек әдәби әсәрләр аерым-аерым тикшерелә. Өченче кисәк XVII, XVIII, XIX йөзнең беренче яртысында иҗат иткән әдипләр, аларның әсәрләренә, халык авыз иҗатына, сәяхәтнамәләргә, васыятьнамәләргә күзәтү ясый, әдәбиятыбызның зур этапларын бәяләп уза.

Хезмәт татар дөньясында зур шау-шу тудыра. Г. Ибраһимов, Г. Сәгъди һәм башка галимнәр авторларны марксизм-ленинизм ысулын кулланмауда гаепилиләр. Татар әдәбияты тарихын Идел буе белән бәйләргә чакыралар. Дөрес, башка фикерләр дә яңгырый. Мәсәлән, Ж.Вәлиди хезмәтне татарларга гына түгел, бөтен төрки халыклар әдәбияты тарихын өйрәнү өчен үрнәк дип атый. Чыннан да, китап, басылып чыгуга, күп кенә төрки халыкларның югары уку йортларында дәреслек итеп кулланыла башлый. Татар тарихы, теле һәм әдәбияты тарихының бүгенге үсеш баскычында без нәкъ менә Г.Рәхим һәм Г.Газизләр концепциясенең дөрес икәнлеген таныйбыз, әлеге тарихларны алар билгеләгән вакыт кысаларында, Орхон-Енисей ташъязмаларыннан башлап өйрәнәбез дә.

Гали Рәхимнең әдәби эшчәнлеге башланган 1913 ел XX йөз башындагы иң кызыклы, иң үзенчәлекле бер этап, «күчеш» баскычы була. Мәгълүм булганча, 1907 еллардан башлап татар журналистикасы һәм публицистика, әдәбият гаҗәеп кызу темплар белән үсеп китә. Әдәбиятка йөзләрчә яшь каләм ияләре килә. Яңа жанрлар мәйданга чыга, әдәби әсәрләр, язылуга ук, ташкын булып басылучы күпсанлы газета-журналларда дөнья күрә, китапчыклар рәвешендә укучыга ирештерелә. Әлбәттә, озак та үтми, татар зыялылары бу әдәби продукциянең сыйфаты хакында уйлана башлыйлар. 1911-1913 еллар арасында татар әдәбиятын «мәдрәсә исе аңкуда»

гаепләгән бик күп мәкаләләр языла. Бәхәсләшүчеләр бер мәсьәләдә уртак фикердә торалар: милли әдәбият милли характерларны милли ситуацияләрдә күрсәтергә бурычлы. Гали Рәхимнең беренче хикәяләре дә, әйтерсең, шушы программага туры китереп языла. Яшь автор, чыннан да, әдәбиятыбыз өчен өр-яңа характерлар иҗат итә.

Гали Рәхимнең беренче зур әсәре «Галия» *(Ан. 1914. № 1. 2-4 бб., № 2. 26-30 бб., № 3 65-67 бб.)* — җавапсыз мәхәббәт тарихы. Вакыйгалар җәй көне дачада бара. Ялгызы гына ялга килгән Хөсәенгә бай кызы Галия гашыйк була һәм аны эзәрлекли башлый. Егет, ялын өзеп, кайтып китүдән башка чара тапмый. Беренче карашка, яшьләр икесе дә — яңа тормышның беренче карлыгачлары. Хөсәен — русча укый торган, руслар белән аралашып яшәүче, милләтпәрвәр егет. Галия исә — иске тәртипләр белән килешмәгән, аларга каршы чыгарга җөрьәт иткән кыз. Ләкин алар арасында туган каршылык та, һәр ике геройның үз эчендәге каршылык та яңа белән искегә, шуларга мөнәсәбәткә барып тоташа. Төп каршылык та шуннан бөреләнә. Хөсәенгә Галиянең «төссез» тышкы кыяфәте дә ошамый, ләкин барыннан да элек аның үз-үзен артык иркен тотышы егеттә тискәре тәэсир калдыра. Бер яктан, Хөсәен һәрвакыт татар дөньясын һәм рус мохитен чагыштырып бәяли, татарларның артталыгына ачына. Ләкин традицион татар тормышы кысаларын җимерергә, язмышын үзе теләгәнчә корырга азапланучы Галиянең омтылышлары анда теләктәшлек уятмый. Ул хөрлеккә ашкынучы милләт кызларына терәк һәм таяныч булыр дәрәҗәдә түгел, бу яктан күнегелгән менталитет тарафдары булып кала.

Автор Галияне дә каршылыклы характер итеп ачуга ирешкән. Үз авызыннан бөтен тормышын сөйләтеп, язучы кызның гадәти гаиләдә үскән булуын ассызыклый. Галия романнардагыча мәхәббәт көтә, шул мәхәббәте хакына көрәшергә, теләсә нинди киртәләрне үтеп чыгарга риза. Ул киләчәк тормышын әти-әниләренекеннән үзгә, башка төрле итеп корырга тели. Ләкин моның өчен рухи баерга, камилләшергә кирәклекне аңламый. Вульгар һәм тәрбиясез дә, самими һәм беркатлы да Галия укучы күңелендә каршылыклы хисләр уята. Хикәянең «Кем ул Галия? Нинди кыз ул? Кысынкы татар тормышы тудырган бер реакция җимешеме? Яисә иң гади, ләкин канәгатьләндерелмәгән хиснең колы булган бер кызмы..?» дигән сораулар белән төгәлләнүе әлеге каршылыкны көчәйтә генә. Бу сорау инде Хөсәеннеке генә түгел, бәлки әсәр авторы җавап эзләгән мәсьәлә төсен ала.

Шул рәвешле, әлеге күләмле әсәрдә язучы татар дөньясында күренә башлаган, ләкин әдәбиятта әлегә яктыртылмаган, милли менталитетка ия ике характер тудыра. Аның беренчесе — иреккә омтылучы, ләкин азатлыкны тышкы билгеләр рәвешендә генә күзаллаучы, эчке рухи хөрлек төшенчәсен аңлап бетермәгән татар хатын-кызы, шәһәрдәге бай баласы. Икенчесе — рус мохите белән аралашып яшәүче, ләкин үз милләттәшләренә ирекка омтылу юлында арка терәге була алмаган студент татар егете.

Беренче хикәяләрендә үк Гали Рәхим — кабатлаулар остасы. Бу алымны ул әдәби әсәрнең төрле катламнарында файдалана. Хөсәенгә карата язучы психологик анализ алымын бик уңышлы куллана. Бигрәк тә аерым бер детальләрне алга чыгару күзәтелә. Нәтиҗәдә геройны икеләнү-борчылу дулкынында тотып, автор аның да үз юлын тапмаган, үз мәсләген билгеләмәгән булуын искәртә. Мәсәлән, соңгы күренештә поездга утырган Хөсәен кесәсендә Галия бүләгән — ефәк яулыкка төрелгән ислемай таба. Хөсәен: «Тфү! Бу гына җитмәгән иде тагы!» дип уйлый. Ләкин аларны ташламый: «хәзердә дә миндә сакланалар». Галиянең табышмак булып калуы хакындагы сүзләр белән янәшә килеп, бу детальләр укучыны Хөсәенне гаепләү юлына басудан саклый.

1918 елгы «Ан»да Г. Рәхим «Көзге хикәя» *(Ан. 1918. № 1. 6-9 бб.)* исеме астында әсәрнең дәвамын бастырып, әсәр ахырында куелган сорауга җавап бирә, гомер көзенә җиткән Галия белән Хөсәенне очраштыра. Бу өлешнең тәҗрибә туплаган, оста каләм иясе тарафыннан язылуы ачык: ул бөтенләй үзгә дулкында кабул ителә. Әсәр исеменә салынган күпмәгънәлелек — көз көне булган вакыйганы тасвирлаучы да, геройлар гомеренең көзенә бәя бирүче дә. Бер яктан, әсәр табигать күренешен пар атта баручы герой — доктор Хөсәен Әкрамов күз алдыннан узган күренешләр

кебек тәкъдим итә. Шунда ук табигать һәм кеше халәтен ялгау күзәтелә, татар әдәбиятында күнегелгән кул, жил символлары тәкъдим ителеп, яна бер образ — «буш кыр» килеп керә. Буш кырлар турында сөйләгәннән, аларны ямь-яшел ужым басулары белән янәшә куйганнан соң, шундый ук бушлык герой күнелендә дә күрсәтелә.

Матур, лирик-монсу әсәр шушы доктор Хөсәен тормышындагы бер кичне сурәтли. Автор кат-кат «ватансыз» булуына игътибар иткән картаеп килүче доктор төрле жирләрдә эшләп, күченеп йөри. Көзге кичне ул Башкортстанның бер өяз мәхәлләсе идарәсе тарафыннан чакырылган яна эш урынына бара, идарә рәисе Рөстәм бәк утарына туктала. Кич буе хужалар аны кунак итәләр, аларнын житкән кызлары һәм ике уллары бар, гаилә жылылыгы күзгә ташлана. Хөсәен хужабикә Галиянен студент чагында, Казанда укыганда үзен яратып йөргән, ахырда егетне дачадан качып китәргә мәжбүр иткән кыз икәнлеген аңлый.

Хикәядә төп вакыйга булып торучы шушы очрашу Хөсәеннен тормышына һәм халәтенә укучынын мөнәсәбәтен үзгәртә. Әсәр башында нинди дер хозурлык белән бирелгән көзге манзара әсәр ахырында янадан хикәяләүгә килеп керә. Ул элеккечә матур, хәтта кояш чыгуы аны тагын да гүзәлләткән, ләкин бу матурлык монсу, сагышлы кабул ителә. Үз-үзен тормыштан канәгать икәнлегенә ышандырырга теләгән Хөсәеннен барыбер яшь чагындагы рух күтәренкелекләрен сагынуы, Галиянен гаилә бәхетенә кызыгып-сокланып каравы аермачык. Рөстәм бәкнен жирсез калган мирзалардан булуын сөйләп, әйтерсен автор бу ике ир язмышын янәшә куеп чагыштырырга мөмкинлек бирә. Хөсәеннен яшь чагында ил язмышы өчен көрәшеп яшәвен, соңыннан «ватансыз» калуын искә төшерү дә әсәр идеясенә алып килә: тормышнын көзенә кереп барганда, «ватан» һәм гаилә жылысы бигрәк тә кирәк, болар исә яшьлектә табыла. Рөстәм Галиянен холык-фигылен аңлый, ана дөрес юл күрсәтә алган: шунын белән бәхеткә ирешкән. Галия дә үзе хыялланган, әти-әнисе гаиләсендәгегә охшамаган мохиттә яши. Рөстәм һәм Галия тормышындагы тәртипләр Хөсәен күнеккән рус гаиләләренекеннән аерылмый. Шушы ситуациядә Хөсәен характеры яңа ягы белән яктырып китә: татарларнын артталыгын аңлап, шуннан оялып, аларны үзгәртү турында уйлап, руслар белән аралашып яшәгән бу ир-егеткә язмыш бер кешегә ярдәм итү, аны коткару мөмкинлеге бирә. Ләкин анын ярдәм кулы сузарга көче, кыюлыгы житми. Галиянен иреккә омтылышы белән чагыштырганда, Хөсәеннен икеләнүчәнлеге тагын да ачыграк күренә. Хөсәеннен яшь чагында да «фидакарьлек күрсәтергә» ашкынып тормаганлыгы хакында нәтиҗә күнелгә килә.

«Шагыйрь» *(Ан. 1914. № 4. 70-73 бб., № 5. 90-95 бб., № 6.110-112 бб.)* хикәясе Хөсәенгә психологик яктан якын тагын бер характерны ача. Күрәсен, нәкъ менә XX йөз башы татар дөньясындагы хәл-халәт мондый «шагыйрь»ләрнен күбәюенә китергәндер. Сюжет үткен каршылыкка ия түгел. Ул көзге бер иртәдә Вәли исемле «Учительская школа»да укучы унсигез яшьлек егетнен үзе язган шигырьләрен газета мөхәрриренә алып баруы, анда өметле сүз ишетмәгәч, бик бәхетсез төстә йоклап китүе, төше, иртән уянуы кебек үсә. Көн дәвамында Вәлинен кәеф-халәте үзгәреп бара, анын бөтен тормышы һәм холык-фигыле укучы күз алдына килә.

Әсәрнен беренче жөмләләре белән автор тонык, күнелсез көзге табигатькә Вәлинен «язгы ташулар дулкынлана» торган күнелен каршы куя. Анын ашыгуын, ашкынуын детальләп, юмор белән сурәтли башлый. Газета идарәханәсенә килгәч, шигырьләремне кабул итәрләрме-юкмы, кергәч сәлам бирергәме-юкмы кебек икеләнү-шикләнүләрне, андагы егетләр үзеннән көләләр дип уйлап борчылуларны күрсәтеп, автор Вәлинен хыялы чынбарлык белән каршылыкка керүне ассызыклый. Шушы ноктада автор Вәли характерына карата укучыда билгеле бер караш формалаштыра: таланты булмаса да, тәржемә итеп-ияреп язган шигырьләре белән атаклы шагыйрь булырга, үзенә һәйкәл куйганнарын күз алдына китереп хыялланучы егет көлке тоела.

Ләкин әсәр шушы урында төгәлләнми. Вәлинен урамда уңайсызланып кайтулары, фатирына кергәч кайгыга калуы, дусты Васыйх янына баруы, үзендә шигырь куәте бармы-юкмы дип икеләнүләре, өендә «шәп шигырь» язып карарга утыруы,

моның барып чыкмавы, үзен ялгыз, бәхетсез, булдыксыз санап елавы, яхшы шигырь язуын төшендә күрүе берәм-берәм жентекләп сөйләп-күрсәтеп барыла һәм укучы, Вәлине кызгану-жәлләү баскычын үтеп, аның теләктәшенә әверелә. Алдарак язучы искәртеп киткән мәгълүматлар: ятим бу егетнең чын күнеленнән укырга омтылуы, милләт мәсьәләләре белән кызыксынуы, күп укуы хәтердә яңара. Инде Вәли характеры яңа ягы белән ачыла: самими, милләтпәрвәр, нечкә күңелле, эмоциональ һ.б. Соңгы: «Ләкин элеккеге күтәренкелек, элеккеге ышануның хәзер күңелдә юклыгын, аларның инде әллә кая очканлыгын ул үзе дә сизә иде»,- дигән җөмләдән соң әле генә сурәтләнгән ситуацияне үзгәртәсе килә башлый. Нәкъ шушы җөмлә хикәяне аңлау өчен ачкыч вазифасын башкара. Әсәр кеше аңында үзгәреш хасил булу, тормыш хакындагы элеккеге күзаллауны җимерүче ачыш ясалу хакында. Идарәханәгә барганчы да үзенең талантына шикләнеп карауччы, ләкин дусты Васыйхның сүзләренә ышанырга теләп дан-шөһрәт турында хыялланучы Вәлигә хакыйкать аңлашыла. Үз «шигырьләренең» кыйммәтенә күзе ачыла.

Әдәбият белемендә мондый хикәяләрне «ачыш хикәясе» дип атау бар *(В.Б.Катаев)*, Гали Рәхим дә кешегә тормышның яңа ягы белән ачылу, аның элеккеге инанган күзаллаулары кире кагылу моменты сурәтләнгән әсәрләр яза, героен элеккеге дөрес булмаган күзаллаудан баш тарту ноктасына кадәр алып килә һәм өр-яңа проблемалар каршына бастыра. Мәсәлән, «Артист» хикәясендә төп герой да күп кенә сыйфатлары белән Вәлине хәтерләтә. Кечкенә генә бер калада яшәүче приказчик Хисами, бер төркем яшьләргә ияреп, «Беренче театр» спектаклендә уйнарга ризалаша. Ләкин аның да хыял-өметләре чынбарлыкка бәрелә. Сәхнә ачылып, уйнарга чыккан Хисами, беренче рәттә утырган баен күргәч, оялудан хәрәкәтсез кала. Әле сәхнә ачылганга кадәр үзен милләтпәрвәр, уен остасы дип хисаплап йөргән Хисами хакыйкатькә төшенә: ул профессиясе белән генә түгел, рухи яктан да артист түгел, гади бер приказчик икән ләбаса! Сюжет дәрәҗәсендә язучы һәм укучы Хисамидан көлү ноктасында тукталып калалар. Спектакль өзелә, милли үзаң үсү вакытында күп кенә буш, талантсыз кешеләрнең үзен күрсәтергә теләве нәтиҗә итеп чыгарыла. Фәлсәфи катламда кешенең тормышны аңлау, үз-үзенә һәм тирә-юньдә билгән урынына дөрес бәя бирү моменты кеше һәм тормыш фаҗигасе кебек тәкъдим ителә.

Татар дөньясына, шәһәр тормышына хас аерым характерларны сурәтләгәндә язучының XX йөз башындагы хәл-халәтне шактый тулы колачларга теләве күзгә ташлана. Шушы чор атмосферасы заманга хас кимчелекләрне тәнкыйтьләү, милләт киләчәге өчен борчылу, өметсезлекне күрсәтү, кеше хыялында, кешелек өмете булып яши, саклана торган тормыш моделен тергезү, чынбарлыкны шул модельгә карап үзгәртү чикләрендә тирбәлә. Еш кына авторның фәлсәфәсе укучыны да Яшәеш, үз бүгенгесе һәм үткәне хакында уйланып сызланырга мәҗбүр итә. Мәсәлән, Г. Рәхимнең «Эч пошканда» нәсере *(Аң. 1913. № 2. 23-25 бб.)* сызлануның сәбәбе төсендә милли традицияләрне күрсәтә.

XX гасыр башы прозасында татар тормышының бүгенгесенә бәя биргәндә, хәл-халәтнең сәбәпләрен эзләп, тарихка мөрәҗәгать итү киң тарала. Берничә ел эчендә татар тарихына кагылышлы күпсанлы әсәрләр языла, авторлар милли узгандагы хәсрәтле дә, горурланырлык та, фаҗигале дә сәхифәләрне яңадан тергезәләр. «Аң»ның 1913 елгы 13 санында Гали Рәхим «Хан мәчетендә (хыял)» дигән монсу-лирик хикәя бастыра. Анда «Хан мәчете» ике вакытның: Казан ханлыгы алынуның һәм хәзергенең очрашу урыны буларак символлаштырыла. Автор бүгенгене үткәндәге күренеш белән ялгый, тормышны ике өлеш: үткән һәм бүгенгедән торган бербөтен кебек күрсәтә, бөтеннең кисәкләре тоташкан булуны искәртә.

Гали Рәхим аерым бер очракларда тулысынча шартлы тормыш моделе төзи, аллегорик образлылыкка мөрәҗәгать итә. «Аң» журналының 1913 елгы 4 санында басылган «Яз әкиятләре» хикәясе шундыйлардан. Беренче карашка эт эчәгесе һәм канәфер чәчәге образлары аша мәхәббәт турында сөйләүче кебек тоелган әсәр яшәешнең бер канунын: кояш астындагы урын өчен мәңгелек көрәш законын белдерү булып гомумиләшә. 1915 елны язылган «Әбү Сәгыйд» *(Аң. 1915. № 18-19. 310-312 бб.)* хикәясенең «үзәге» исә — матурлык символы булган юнан сыны. Сюжет безне тарихка алып китә: Мәдинә шәһәре байларыннан булган гарәп Әбү Сәгыйд

гаскәр эчендә Искәндәрия шәһәренә керә. Бай йорт эчендә ак мәрмәр ялангач хатын сыны күреп, тормыш хакында күзаллауларын үзгәртә. Матурлыкның барлык кыйммәтләрдән өстен, югары булуына төшенә. Сын аның «җанын рәхәт, рухани пакь ләззәт һәм сафлык белән тутыра иде». Шушы урында автор дини һәм сәнгатькә соклану хисләрен үз урыннарына «утырта»: «Никадәр караса да, ул аның нәфасәтен, гүзәллеген генә күрә, иман, Алла, дин — һәркайсы үз урыннарында, вөҗданы да тыныч, керсез иде. «Ислам да дөньяга рухани пакьлек, бөтенлек һәм матурлык чәчәр өчен җибәрелгән дин бит!»,- дип уйлады». Әсәр Әбү Сәгыйднең, кылычын кынына тыгып, һәйкәлнең маңгаеннан үбү белән тәгәлләнә. Символ, шулай итеп, сәнгать һәм дин, аларның вазифасы хакында гомумиләштерүләр ясарга ярдәм итә, автор югары мәдәниятктә ирешкәндә дин һәм сәнгатьнең янәшә яши алуы хакында да искәртә, сәнгатьтәге Матурлык диндәге пәйгамбәр белән тигезләштерелә.

Г.Рәхимнең «Миләүшәләр арасында» *(Ан. 1915. № 7. 136-145 бб.)* фәлсәфи хикәясе иҗатында үзенчәлекле урын били. Ике егет, кайчандыр Казанда бергә укыган дуслар-сердәшләр, мәхәббәт хакында бәхәсләшәләр. Аларның берсе — идеалист Рәшид, гыйшыкны «кулга килеп кунган күбәләк» кебек кабул итә, хикәяләүче-мин, материалист буларак, авыру халәт дип атый. Хикәягә эпиграф итеп сайланган Г.Тукайның «Нечкәләп карасаң, бу күлнең бар бугай шигърияте» дигән сүзләре, шактый күләмле фәлсәфи кереш өлеше белән тоташып, кеше гомеренең кызыксызлыгына, әлеге газаплы гомердә мәхәббәтнең бәхет, яктылык алып килүенә ишарә ясый.

XX йөз башы татар әдәбияты аерым бер мәсьәләләрне калкытып, сөйләшү үзәгенә куя. Күп кенә әсәрләр башка язучылар әсәрләренә җавап, авторның үз һәм үзгә позициясен белдерүе кебек иҗат ителәләр. Үзара сөйләшү төрле яссылыкларда килеп туа, көтелмәгән борылышлар ясый. Мәсәлән, «Шәрыкме-Гаребме», ягъни татар дөньясы көнчыгыш моделе яки көнбатыш үрнәге буенча үсәргә тиешме икәнлек хакындагы бәхәс әдәбият белеме, фәлсәфә фәнен, публицистиканы чолгап ала. Гали Рәхим шушы бәхәскә әдәби әсәре белән катнаша. «Ан» да «Ярыш (булган эш)» *(Ан. 1916. № 16-17. 263-265 бб.)* исеме астында басылып чыккан әсәр үзенчәлекле сюжетка ия. Урал төбәгенә тимер юл килә. Көннәрдән бер көнне беренче тапкыр шуңа утырып күрше калага барырга уйлаган сәүдәгәр Юныс карт поездга соңга кала һәм, киләсе станциядә куып җитәргә исәпләп, ак айгырын куа башлый. Ат белән машина ярышы башлана. Алтмыш чакрым үткәч, айгыр поездны куып җитә һәм егылып җан бирә. Хикәянең буеннан-буена автор бу ярышның Европа һәм Азия, ягъни Гареб һәм Шәрык арасында булуын ассызыклап бара. Инде язучының фикерен аерып чыгару авыр түгел: Шәрык юлы белән Гаребне, үлем бәрабәренә, куып җитәргә була! Ләкин мондый корбан бирү урынлымы? Әнә бит, хикәянең соңгы җөмләсе дә болай яңгырый: «Бары тик данлыклы ак юрга үзе генә дөньяда юк иде…»

Башкарак төрдәге иҗади сөйләшүләр дә алып барыла. Шул ук журналда басылган «Догаи Сәйфи» *(Ан. 1916. № 14. 225-230 бб.)* хикәясен язучы «Кадерле Гаяз әфәнде Исхакый җәнабларына багышлыйм» дип тәкъдим итә. Беренче карашка, әсәрдә Исхакый шәхесе яки иҗаты белән бәйле бернәрсә дә юк шикелле. Хикәя морзалар тормышыннан алынган. Габделкәрим абзасына кунакка килгән Габделбарый утарда хезмәтче Мусаның Фатихага җавапсыз гыйшык тотуын белә һәм аны кызык итәргә уйлый. Төн уртасында җиде юл чатына чыгып, Догаи Сәйфи укып, җенне чакырырга, аннан ярдәм сорарга өйрәтә. Үзе исә Мусаны куркыту чарасын күрә. Нәтиҗәдә Муса мәхәббәт авыруыннан «терелә».

Хикәя Мусаның төн уртасында кичергәннәрен сөйләгәндә Н.В.Гогольнең «Вий» әсәрен хәтерләтә башлый. Әйтерсең, автор аңлы рәвештә рус әдибе кулланган мотивны татар җирлегенә «күчерә», тәрҗемә булмаган, үзенчәлекле әсәр тудыра. Шушы ноктада аның ни өчен Исхакыйга багышлануы аңлашыла башлый.

Мәгълүм булганча, Г.Исхакый рус әдәбиятын махсус өйрәнә, тәрҗемә итә. Гогольнең повестен да татар тормышына җайлаштырып тәрҗемә итә һәм 1906 елны «Борынгы алпавытлар» исеме астында бастырып чыгара. Кереш сүзендә мондый фикер әйтә: «Безнең милләтебезгә дә Гоголь тарзында яза торган мөхәррирләр бик кирәк». Күрәсең, Гали Рәхим шушы сүзгә җавап итеп «шаяра»: «Догаи Сәйфи» укый.

Гали Рәхимнең әдәби иҗатында балалар өчен язган хикәяләре шактый зур урын алып тора. Үткен сюжет аша нәсихәт бирүче әсәрләр дә («Елан мөгезе» кебек), халыкның авыз иҗатын, ышануларын әдәби эшкәртү кебек уйланылганнары да *(«Шүрәле», «Убыр» кебек)* бар. Язучы тарихи сәхифәләрне тергезү, милли тарихка, халыктагы аерым сыйфатларга ихтирам тәрбияләү максаты белән дә каләмгә тотына. Аларның кайберләрен олыларга — мәсәлән, «Ан» журналы укучыларына тәкъдим итә. Г.Рәхим дини-дидактик, дини-мистик темаларга мөрәҗәгать итә. Пәйгамбәрләр тарихына ияреп яңадан язылган «Туды..», «Ул кичәдә», «Рабгузи кыйссаларыннан» кебек хикәяләр дини фәлсәфәне заманча бирү, дөньявилыкка якынайтып аңлату, кызыклы язылулары белән аерылып тора. XX йөз башында иҗат ителгән мондый әсәрләрдә дин фәлсәфәсе шәхси күзаллау, автор позициясе белән үрелеп китә, үзгәреш кичерә.

Әдипнең Исмәгыйль Гаспралыга мәдхия итеп язылган «Күз яшьләре саргайган яңаклары буйлап актылар», Болгар шәһәре урынына күзәтү төсендәге «Болгар хәрабәләрендә» кебек ярым публицистик, ярым әдәби әсәрләре дә билгеле. Аларда тарихи мәгълүмат белән хикәяләүченең әдәби формага төреп бирелгән мөнәсәбәте янәшә урнаша.

Ул үзенең иҗат көчен сатира өлкәсендә дә сынап карый («Гыйшык» һ.б.), җиңел юмор белән сугарылган романтик хикәяләр дә бирә («Исемсез хикәя» кебек). Әйтерсең, әдәбиятта үз сукмагын эзли. Шушы әдәби агымны тапканлыгы, үзен лиризм белән сугарылган фәлсәфи-психологик әсәрләр язу өлкәсендә иркен тоюы 1917 ел инкыйлабыннан соң иҗат ителгән әсәрләре мисалында ачык күренә. Әдип «Бер шагыйрьнең өйләнүе» *(Шәрык кызы. 1918. № 5. 97-101 бб.)* хикәясендә үзен иң кызыксындырган проблемаларның берсе — мәхәббәт һәм ирек хакында сөйләшүне дәвам итә. «Ирек» төшенчәсе бу очракта иҗат итү мөмкинлеге кебек аңлатыла. Бу каршылык ирек файдасына хәл кылына. Импрессионистик хикәя өч: мәхәббәт көтү, гыйшыклык һәм аннан ваз кичү — халәтнең үзенчәлекле матурлыгын тергезә. Укучы белән диалог рәвешендә үрелеп барган әкияти хикәяләү әсәрне кызыксынып укырга мәҗбүр итә. Әсәрдәге фәлсәфи идея Ф.Ницше фикерен кабатлау рәвешендә ахырда сүзләр ярдәмендә белдерелә: гашыйк булу җүләрлек булса, өйләнү — аннан да зуррак хата кылу. Гомумән, фәлсәфи фикер белдерү өчен уйланылган һәм язылган бу әсәр татар язучыларында иҗади фикерләүнең яңа тибы формалашу хакында сөйли. Моңа кадәр әдәби әсәр тукымасында ярдәмче вазифа башкарган фәлсәфи проблематика алгы планга чыга, әсәр үзе яшәешне фәлсәфи кабул итү һәм аңлату чарасы, варианты кебек кабул ителә башлый.

Гали Рәхим иҗатының буеннан-буена ниндидер фәлсәфи мәсьәләләргә кагылу, аларга җавап эзләү күзәтелә. Әлеге мәсьәләләр язучының «Идел» повестенда *(Рәхим Г. Идел. Казан:Татпечать,1923. 127 б.)* бергә җыелалар. Әсәр татар әдәбияты өчен гадәти, күнегелгән чикләрдән чыгып китә, бәлки, шуның өчен дә үз заманында аңланылмый, кабул ителми.

Әсәрдә вакыйгалар 1914 елны бара, сюжетны «гыйшык тарихы» дип атарга мөмкин булыр иде. Каты авырудан соң ялгызы гына табигать кочагына көч җыярга килгән Ильяс Рәбига исемле кызга гашыйк була. Ләкин аны күргәннән алып, яздан-көзгә кадәр ара егетнең икеләнүләре кебек уза. Бер яктан, Рәбиганың күзләре, аның янәшәлеге егеткә чиксез бәхет, рәхәт биргән кебек тоела. Ләкин ул бу хисләрне «алтын богаулар» дип саный, әле богауларны өзеп ташлап, ирекле булырга омтыла. Әсәрнең буеннан-буена кабатланып килгән «алтын богаулар» «өзгәләп ыргытыла». Мәхәббәт фәлсәфәсе болай янгырый: «Мәхәббәт шундый бер хис ки, ул инсан тарафыннан җинелергә тиеш! Ул аңар гүзәл чәчәк күк, искиткеч музыка күк рәхәт бирә, ләкин илаһи тынычлык бирми ул аңар. Әгәр дә ул инде чамадан артып китсә, алтын богауларны кешенең рухына салса, шул бөек, мөкатдәс, илаһи тынычлыкның нигезе булган ирекне җәберли башласа, кешегә рәхәт урынына газап бирсә, ул мотлак җинелергә тиеш».

Әсәргә пролог, хикәяләүгә этәргеч итеп бирелгән, күп еллар узганнан соң таныш күзләрне очрату, шул күзләр иясе белән бергә чакны иң кадерле, бәхетле вакыт кебек искә төшерү исә бу фәлсәфәнең дөреслеген шик астына куя һәм укучының

үзгә нәтиҗә чыгаруын сорый. Эпилог шулай ук интонацион яктан төп текстган аерылып тора. Яшьлеге узган кешенең монсу, үкенечле монологы кебек янгырап, ул алда сөйләнәчәк вакыйгаларга укучының мөнәсәбәтен «көйли»: «Сөекле җаннар, сез кайда хәзер?… Ә мин картайдым, картайдым. Менә минем чәчләремдә инде ак бөртекләр күренә… Кая ул чагындагы җүләр яшьлек? Кая киткән ул вакыттагы җинеллек, ялкынлы, утлы көннәр?» Узганны сагыну, үкенеч ноктасында Ильяс белән бергә укучы да ачыш ясый: Рәбига, чыннан да, Ильясның беренче мәхәббәте булган, ләбаса!

Соңгы, 24нче бүлек шулай ук аерым әһәмияткә ия булып, әсәрнең иң югары ноктасы, мәгънә үзгәрешләре китереп чыгарган урын кебек тәэсир калдыра. Бу өлеш — Ильясның авылдан соңгы тапкыр китү вакыйгасы. Хикәяләүче Иделгә мөрәҗәгать итә һәм әсәргә яна мәгънә дулкыннары йөгертә. Мәхәббәт шаһите булган елга — милләт анасы булып гомумиләшә. «Менә ул безнең олуг анабыз, Идел, минем аяк астымда… Син безнең туган Иделебез, үз Иделебез иден ләбаса, ник үзеннен балаларынны ташладын? Ник безне әллә кемнәр синен шәфкатьле ярларыннан сөрделәр?» Мәхәббәтне җуйганга үкенеч милләт өчен үкенү-борчылу хисе белән кушыла. Сюжеттагы кыз-егет мәхәббәте белән янәшә милләткә мәхәббәт дигән яна бер хис пәйда була. Шуннан соң ук милләт улларынын хәленә бәя янгырый: «Әнә аргы якта олуг Татарстан җәелеп ята. Шунда, тирес оясы төсле, искергән саламга күмелгән авылларда, кечкенә генә өйләрдә хисапсыз күп бәхетсез кешеләр гомер кичерәләр. Бәхетсез халыкнын бәхетсез балалары! Аларны бернисез сугышларга илтеп тураталар. Алар, сарык көтүе төсле, ләм-мим димичә, кем өчендер шунда барып, төз җирне түмгәк итәләр. Бәхетсез халыкның бәхетсез балалары!»

Моңа кадәр мәхәббәтнең кавышу белән тәгәлләнмәве романтик кимәлдә аңлатылган булса, шушы ноктадан аның социаль сәбәпләре калкып чыга. Бизгәкләр, иске пальтолар, бөлгән морзалар, балаларның милләткә хезмәт итәргә теләвен аңламаган аталар, кыш буе эт урынына эшләүләр, шәһәрдән башка «ватаным» булмаулар … тулы бер мозаика булып җыела. Укучы текстка мөрәҗәгать итеп, Ильяс язмышын һәм Рәбига язмышын аерым-аерым искә төшерә, бергә булган очракта, аларны да «тирес тормыш» көтүе хакында нәтиҗә ясарга мәҗбүр итәлә.

Тагын бер сурәт тудырыла. Хикәяләүче халкын канаты сынган акчарлакка охшата. «Кемнәр генә синен көчле канатларыңны имгәттеләр икән соң?!» дип мөрәҗәгать итә. Һәм канатлары көчсез кошлар: «алга да бармыйлар, артка да китмиләр, нәкъ бер урында туктаган төсле канатларын селкүдә дәвам итәләр». Милләтнең хәлхәләтенә «бер урында тору» дигән бәя бирелә.

Шулай итеп, язучы кешене дөньяда яшәткән ике омтылыш: мәхәббәт һәм ирек; ике хис: ярату һәм үкенеч хакында сөйли. Сюжет катламында бирелгән вакытлы кыз-егет яратуы һәм фәлсәфи, психологик, иҗтимагый катламнарны да сюжет белән ялгый торган, гомер буе дәвам итүче милләтне ярату әсәрнең тематик үзенчәлеген билгели.

XX йөз башы татар әдәбиятында сыйфат үзгәрешен әзерләүче, башкаручы әдипләрдән Г.Рәхим иҗаты моңа кадәр күләгәдә кала килде. Ләкин ул салган сукмакларны күзалламый торып, татар әдәбиятынын үсеш юнәлешләрен барлаужыю мөмкин түгел. Нәкъ менә талантлы шәхесләрнең күпләп әдәбият мәйданына килүе, милләткә хезмәт итүгә алынуы әдәбият-сәнгатьнең тизләтелгән үсеш чоры — «алтын чор» — кичерүенә юл ача. Булганнары, иҗат иткәннәре, милләтне ярату белән сугарылган рухларын әсәрләрендә күрсәтә алганнары өчен алар безнең күнелләрдә!

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*Татарстан Фәннәр академиясенең баш гыйльми сәркатибе, академик*

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Дусым

Дусым авылы Әтнә районында, район үзәге Олы Әтнә авылыннан 10 чакрым ераклыкта, тимер юл станциясе Коркачыктан — 37, Казаннан 77 чакрым ераклыкта урнашкан.

Дусым атамасы байтак кына тарихи белешмәләрдә очрый.

Д.А.Корсаков (XVIII гасыр) җыеп бастырып чыгарган белешмәдә авыл чишмә буена утырган, анда 80 ясаклы татар яши дип искә алына.

Дусым авылы Җилгелде, Куәм, Күнгәр, Түбән Шашы, Күшәр авыллары белән янәшә урнашкан. Дусымнан 10 чакрым төньякка таба Мари иле республикасы башлана.

Авыл элегрәк Ашыт елгасы буенда ук булган. Суга яшь балалар төшеп үлү сәбәпле, авылның өч токымы Ашыт елгасыннан бер чакрым арырак тау башына күчеп утыралар. Акрынлап авылның башка кешеләре дә яңа урынга урнаша. Элеккеге авыл урынында хәзер аланлык. Анда куе калын печән үсә. Ләкин ул җир сукаланмый, печәне чабылмый. Бу урын изге урыннарның берсе санала. Озак яңгыр яумаса, авыл өлкәннәре бу урынга барып Коръән укый. Хәзерге көндә әлеге урынны Зират аланы дип атыйлар.

Дусым атамасы авыл исеме буларак шактый сәер яңгырый. Аның риваятен халык болай сөйли. Авыл хатын-кызлары арасында әлеге көндә дә бер-берсенә дустым дип әйтү гадәте сакланган. Безнең бабаларыбыз да бер-берсенә дустым дип эндәшкәннәр. Шул заманда бер юлаучы агай үтеп бара икән. Ул янындагы бер кешедән: «Кайсы авыл соң әле бу?» — дип сорый. Бу кеше: «Дустым авылы бу», — дип җавап биргән. Вакытлар үтү белән уртадагы «т» авазы төшеп калган, имеш.

Элек авыл табигате бик бай, тирә-юне карурман булган, яныннан зур гына инеш агып яткан. Инештә ике ташлы тегермән эшләп торган. Хәзер авыл табигате элекке белән чагыштырганда күпкә ярлы. Шулай булуга карамастан, авылда һәм аның тирә-юнендә әби-бабайлардан калган изге һәм тарихи урыннар байтак, Әйтик, бүгенге көндә Рөстәм чишмәсе дип атала торган чишмә шундыйлардан. Исеме заманча булса да, бу чишмә-коеның тарихы бик борынгы. Әтнә белән Коркачык арасындагы Норма авылыннан Рәхмәтулла исемле бер бай кеше ни сәбәптәндер Дусым авылына килеп урнашырга җир сорый. Авыл старостасы һәм халык аңа җир бирергә ашыкмый. Шуннан соң Рәхмәтулла бай авыл халкы белән старостаны бик әйбәтләп сыйларга ниятләнә. Ниһаять, аңа урынны авыл янындагы чыршылыктан бирәләр, әмма авылга кертмиләр. Рәхмәтулла абзыйның Нәфигый исемле улы була, халык аны бик яратып искә ала. Шушы Нәфигый авыл халкын тәмле һәм йомшак суы белән тәэмин иткән кое казыта. Озак та үтми, авыл халкы коены Нәфигый коесы дип атап йөртә башлый. Ватан сугышы елларында бу кое күмелә. Авылның Рөстәм исемле кешесе аны чистарткан, бурасын алыштырган.

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

Акый коесы янгырашы белән бераз сәеррәк сыман. Бу коены Әхмәдулла исемле урта хәлле крестьян казыткан. Ул коенын тирә-юнен бик матурлап куя, өстен яба, аны ак тоскә буйый. Шуннан сон коены Ак кое дип йөртә башлыйлар. Тора-бара атаманың бер «к» авазы төшеп кала, ул Акый дип кенә атала башлый. Авылдан читтә, тау астында урнашуына карамастан, бүгенге көндә ул иң тәзек, иң матур коеларның берсе. Авылның унган кешеләре аның бурасын алыштырып, буяп, түбәсен янадан япканнар. Коенын ак калай түбәсе, ярым ае анын үткән тарихы турында халыкның исенә төшереп тора.

Байлар коесы да бик матур урынга урнашкан. Ул ике тау уртасындагы Коры елга буенда, каеннар арасында. 1910 елларда авылдагы Садыйк байлар нәселе тарафыннан авылда ике кое казытыла. Алардан суны бары тик байлар гына ала. Яманаты чыккан 1930 елларда байлар Себергә сөрелгәч, коелардан су алучы калмый. 1980 елларга кадәр коелар жимерек хәлдә була, аларга игътибар итүче табылмый. Таулар бик текә булу сәбәпле, коелардан файдаланмаганнар, суны якынрак коелардан алганнар. Торбалардан килгән колонка суларыннан аермалы буларак, бу коеларның суы йомшак һәм тәмле. Халык соңгы елларда аларны чистарткан һәм яна бура төшергән. Кер чайкау өчен улаклар да куелгач, яшьләр монда кер чайкарга да килә.

Авылны як-ягыннан таулар әйләндереп алган. Атамасы бүгенге көнгә кадәр килеп житкән тауларның берсе — Әптерәмән тавы. Габдерахман исемле абзый гомере буе авыл читендә, тау башында гомер кичергән. Анын усактан салынган бик яхшы йорты авылның башка йортларыннан тазалыгы, зурлыгы белән аерылып торган. Таза тормышлы булганга, ул авыл кешеләре белән аралашырга теләмәгәндер дә. Габдрахман абзыйның исемен бозып Әптери дип йөрткәннәр. Ул яшәгән тау башын халык Әптерәмән тавы дип атаган. Хәзерге көндә балалар кар ятуга бу тауга чана-чаңгы шуарга йөриләр.

Басуда Үр елгасы ага. Анын үзәнчәлеге шунда, ул үргә таба юнәлгән булып тоела. Үр суы дип аталуы да шуннан, әлбәттә.

Үгез инеше турында әкияткә тартым бер риваять яшәп килә. Өлкәннәр, бу инеш янына ялгыз барырга ярамый, адаштыра дип сөйлиләр. Анда жир жиләге бихисап күп була икән. Дөрестерме, юктырмы, шул елгада бер хатын үзенен кызы белән жиләк жыйганда адашып, юлны таба алмыйча ерак киткәннәр. Үгезләр көтүенә юлыгып, аларны үгезләр сөзеп үтергән, дип сөйлиләр.

Авылдагы атамаларның сугыш алды елларына караганнары да бар. Шундыйларның берсе — Корт бакчасы яки Сәет бакчасы дип йөртелә. Авылның өлкән кешеләре Сәет абзый белән анын жәмәгате Маһирә апаның изгелеген әле дә онытмыйлар. Өлкәннәр сөйләвенә күрә, Сәет абзый утсыман кызгылт сакаллы, төз һәм жинел гәүдәле кеше була. Хәләл жефете Маһирә апа тәбәнәк кенә, матур, әмма яхшы ук усал телле булган дип сөйлиләр. Сәет абзый үзенең бакчасы башындагы кеше йөри алмаслык сазлыкка өянке агачлары утырта. Сугыш елларынын коточкыч салкын кышларында бу өянкеләр авыл халкын катып үлүдән саклап калганнар. Сәет абзый авыл халкы өчен елга буена кара мунча салдыра. Ә тимерче һөнәре анын төп эше була, 70ләрне үткәнче колхозда тимерче булып эшли. Егәре житми башлагач, авыл читендәге тигезлектә корт асрау белән шөгыльләнә. Карчыгы Маһирә апа белән бергәләп, ачлыктан интеккән авыл халкына алар балны бушка да бирә торган булалар.

## Дүсем

Дүсем авылы Сарман районында, район үзәге Сарманнан — 19 чакрым ераклыкта, жирле үзидарә советы үзәге Ләшәү Тамак авылыннан —1, тимер юл станциясе Бөгелмәдән — 92, Чаллы пристаненнән 82 чакрым ераклыкта урнашкан.

Олылар сөйләве буенча, бу урынга башта Дүсмәкәй исемле кеше килеп утырган. Анын тулы исеме Дусмөхәммәт булган. Авыл атамасы шул кеше исеме белән бәйле рәвештә Дүсмәкәй дип, ә аннан соң Дүсем дип йөртелә башлаган.

Революциягә кадәр, барлык авыллардагы кебек, Дүсемдә дә уңдырышлы жирләр, урман һәм болыннар, хәтта таулар да авыл байлары кулында булган. Авылнын

көнчыгышында кечкенә таучыклар, ә өстә урман үсә. Шунысы кызыклы, авыл тирәсендәге тауларның һәркайсына исем кушканнар. Исем-атамаларның үзенә күрә тарихы бар.

Мишәр тавы. Кайчандыр ул тауга мишәрләр килеп урнашып яшәгән. Аларның бер өлеше күчеп киткән, икенчеләре халык арасында йотылган.

Елан тавы тирәсендә элек бик күп еланнар яшәгән.

Алты каен тавы. Бу тау урман авызындарак. Анда башка агачлар арасында бик матур алты төз каен үскән.

Сатарай тавы. Ике тау арасында печәнлек булган, агачлар да үскән. Бу тирәнең хуҗасы Сатарай исемле кеше була.

Фәхри кыяр тавы. Тау итәге үзәнлек, су кырые. Фәхри исемле кеше биредә кыяр үстерә торган булган. Тау шушы кеше исемен мәңгеләштерә.

Бакыр базы тавы. Аннан бакыр рудасы табылганга әйтелгән. Ләкин бакыр чыгарылмаган, чөнки токымнары яшь икән әле.

Кибән тавы. Тау битендә печәнлек булган. Анда печән кибәннәре тезелеп торган, өстәвенә, бу тау үзе дә кибәнне хәтерләтә. Аны шуңа күрә Кибән тавы дип йөрткәннәр.

Авылда чирмеш дип йөртелгән кеше булган. Ул үлгәч аны зиратка түгел, тауга күмгәннәр. Шактый вакытлар кешеләр авыру малларны, аерым алганда сыер һәм атларны шушы тау янына алып килә торган булганнар. Тауны әйләндереп йөрткәч, авыру хайваннар терелгән.

Сөйләүләренә караганда, революциягә кадәр Дүсемдә 100ләп хуҗалык була. Шулардан 50 хуҗалык – 1 атлы, 20 хуҗалык 2 атлы, ә калганнары бөтенләй атсыз булган. Алар байларга көнлекче булып ялланып эшләгәннәр.

Дүсем авылы республикабызның көнчыгышында, Сарман районының Ләшәү Тамак һәм Иске Минзәләбаш авыллары арасында урнашкан. Авылны урталай бүлеп асфальт юл үтә. Юл Әлмәт һәм Мөслимне тоташтыра, Җәлил нефтьчеләр бистәсенә алып бара.

Бу яклар – нефть чыгару төбәге. Нефтьнең экологиягә китергән зыяны бу як кешеләренең күңелен хафага салды. Кара май җир өстенә түгелеп, елгаларга агып төште, су буйларын пычратып өянкеләрне корытты, каз-үрдәк асрау мөмкинлеге бетте. Ләкин нефтьчеләр үз ялгышларын аңлап, табигатьне яңарту, үз хәленә кайтару эшенә керештеләр. Чишмә башларын әйләндереп төзекләндергәннәр, чистартканнар, чишмә суларын торба аша сузып авылга колонкалар куйганнар, басуларны тимер торбалардан чистартканнар, нефть түгү очраклары да беткән диярлек.

Авылның Минзәләбаш очында, елга яры буенда берничә нарат үсеп утыра. Бу урынны Нәдер авылы зираты дип йөртәләр. Анда хәтта кабер ташы да бар, ләкин язуы сакланмаган. Бу урын изге урын. Анда аяк белән басарга ярамый.

Авыл мәдәниятебезгә зыялы шәхесләр биргән. Галим, әдәбият фәне буенча филология фәннәре докторы Фәрит Яхин (Дүсембәк), тарих фәннәре докторы Гамирҗан Дәүләтшин, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәре Заһир Шәйхисламов, оста баянчы Алмаз Имаев һ.б.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# ХАЛЫКЧАН ХИСЛӘР ҖЫРЧЫСЫ

## ГАЗИЗӘ СӘМИТОВАНЫҢ ТУУЫНА 150 ЕЛ

Күнелдә шундый шигырь юллары янара:

*Идел буе — яшел таш.*
*Ник елыйсың, яшь туташ?*
*— Мин еламый кем еласын –*
*Үзем ятим, үзем яшь...*

Газизә Сәмитова исемле шагыйрәне мин әүвәл шушы — җырга тартым, шуна да хәтергә уелып кала торган юллары аша белдем. Аны, 60нчы еллар башында Равил Фәйзуллин (әле яшь шагыйрь, студент егет) еш кабатлый иде. Аннары — булачак шагыйрә Бикә Рәхимовадан башка шигырьләрен дә ишетергә туры килде. Урыны җәннәттә булсын, Бикә ханымның ул чакта шагыйрәнең кулъязмасын өйрәнеп, остазы Ж.Алмаз җитәкчелегендә шигырьләрен туплап, китап итеп бастырырга әзерләп йөргән чагы булган икән. Китап 1965 елда, Ж.Алмазның әтрафлы кереш сүзе белән, Татарстан китап нәшриятында басылып чыкты һәм бик тиз таралып бетте; әле ана кадәр фольклорчы галим И.Надировның «Татар шагыйрәсе Газизә Сәмитова турында» исемле мәкаләсе «Совет әдәбияты» журналында (1962 ел, 7 сан) басылып чыгуын да хәтерлим. Илбарис аганы Г.Сәмитованың җырга бик якын, халыкчан тел-стиле белән аерылып торган шигырьләре үзенә тартуы һич тә гаҗәп түгел: нәкъ шул елларда татарлар яши торган барлык төбәкләрдән җыелган хәзинә — «Татар халык җырлары» кебек уникаль бер китапның әзерләнгән чагы иде бит!



Равил дә, Бикә дә аның белән дустанә мөнәсәбәттә иделәр. Шуна да шагыйрәнең:

*Агыйделнең агын җирендә*
*Ак та балыкларга азык юк.*
*Үзем шәригатьнең юлын беләм,*
*Хәсрәт күп күргәнгә язык юк, —*

юллары Бикә ханым укуында мине тетрәндергәнен яхшы хәтерлим. Беренче (безгә билгеле булган, диик... Ә безгә билгесезләре булмаганмы? Әлбәттә, алар күп булган... Югалган йә онытылган. Тик бу аерым тикшеренү сорый торган тема!) шагыйрәбез бит. Һәм нинди генә әле! Мин аның китабын укып чыккач, һич икеләнмичә, нәкъ шул елларда дөнья күргән Г.Кандалый китабы белән чагыштырып, анын Сәхибҗамалга һ.б. язган шигъри мәхәббәт хатларын истә тотып, «менә кем Кандалыйга тиң талант, менә кем Сәхибҗамал — ягъни шул заман хатын-кызлары исеменнән бу олуг шагыйрьгә лаеклы җавап бирә ала!» дип уйлый идем. Дөрестән дә Г.Сәмитова иҗаты — шул заманның уянып килүче, үз азатлыгын, тигезлеген яклаучы, аны шигъри чаралар белән дөньяга ишеттерүче, иң мөһиме, Вакытларның агышын фәлсәфи тойган назик татар кызының җан авазы ул. Г.Кандалыйның «Якутлар табыладыр вакыт белән. Вакытлар табылмыйдыр якут белән» дигән шигъри афоризмы безгә таныш иде. Ә Газизә Сәмитованың бу юллары?

*Якутны купме сардә итсәң,*
*Табып булмас бу вакытны...*

Димәк, борынгы, күчә килгән сурәт бу! Юкка гына бүгенге бер шагыйрәбез дә:

*Вакытларны булмый туктатып....*

дип, жырда кат-кат тәкърарламыйдыр. Ә Г.Сәмитова үз чоры яшәешен, вакытын инде фани дөнья итеп сурәтләсә, гажәпмени?

*Фани дөнья үтәр китәр, и дуслар!*
*Яхшы булганнар яхшыдыр, и дуслар!*
*Сабырлы баш сәламәтдер, и дуслар!*
*Сабыр — гүзәл галәмәтдер, и дуслар!*

Әйе, бу гүзәл «галәмәт»ләр өчен жирлек шагыйрәнең үз тормышында, үз күнел дөньясында «ачы тәжрибә авазы» булып калыккан мәхәббәт сабакларында да житәрлек чагыла иде...

Шагыйрә Газизә Һаветдин кызы Сәмитова 1862 елда Әстерхан өлкәсе Ташлыяр авылында сәүдәгәр гаиләсендә туа. Бабалары бу якка Казан губернасыннан — Тәтештән күчеп килгәннәр. Ташлыярда исә татарлар белән бергә урыслар, калмыклар да яшәгән. Булачак шагыйрә аларның телен дә өйрәнгән. Бик зирәк, укуга сәләтле кыз гарәп, фарсы телләрен дә камил белгән, «жанының күрке — төрке»не дә... Көнчыгыш шигърияте белән таныш булган, халык аваз ижатын яратып үзләштергән. Әнә каян ул «Идел буе — яшел таш»! Һәм шул чорның хатын-кыз, бигрәк тә буй кызлар фажигасен төгәл чагылдыра аның жырга якын лирикасы:

*Ай, ди, арыш юк, ди, арыш юк.*
*Арышның башлары карыш юк.*
*Заманалар авыр, дошманнар күп,*
*Күңел сәүгәннәргә барыш юк.*

Һәм тагын да:

*Жилгә каршы болыт ята алмый,*
*Буй кыз сөйгәненә бара алмый.*

Шагыйрәне дә шул язмыш көтә: «жаны сәүмәгән» ир белән гомер итә, алты баласы; ахыр чиктә барыбер иреннән аерылырга — үз иреген якларга көч таба. Әмма ... вакытларны инде кайтарып булмый. Үзе язганча, «күп авырлыкларга түзгән» шагыйрә 1929 елда Ташлыярда вафат була, шунда ук күмелә дә. Ә шигырьләре — яшь! Г.Сәмитованың кульязмалары Ленинградта, Көнчыгышны өйрәнү институтында саклана. Укымышлы, күпне белергә омтылган, уйлы-фикерле шагыйрә көндәлек дәфтәрләр дә алып барган, дип язалар. Хәзер кайда алар? Китапка керми калган шигырьләре кайда саклана? Ж.Алмаз, И.Надировлардан соң кем кулында икән аның мирасы? Шагыйрәнең һәр язганы фәһемле, йөрәк һәм акыл сүзе бит. Ул үз заманының мәгърифәтчесе, укырга, белемле булырга өндәүчесе дә, Татар әдәби теленең үсешен, фольклор кебек үк, халыкка аңлаешлы, үз «төрке»се булуын уйлаганда да Г.Сәмитова ижаты өйрәнелергә тиеш, үрнәк булып тора. Ни гажәп: аның ижаты, тел-өслүбе шул чорның керәшен побы, матур, үтешле гади тел белән язган Яков Емельянов алымнарына якын... Бу — бигрәк тә үгет-нәсихәт катыш шигырьләрендә шулай. Икесенең дә шигъри осталыгы югары, тел җәһәтеннән камил диясе килә.

Менә Газизә апабызның инде К.Насыйрилар — «Кырыкбакча»,

«Фәвакиһелҗөләсә»ләр белән бәйләнышлы белем, китап, каләмне данлап язган хитабын тыңлыйк:

*Гыйбрәт өчен язылды күп кешегә,*
*Сәлам дидем каләмнең шул эшенә,*
*Каләм үгәдән, каләм изгегә тартыр,*
*Каләм белгән кешенең бәхете артыр.*

Карасана, нинди ерак заманнардан килә икән бит бу өндәү-шигарь! Насыйрилар, Газизә апалар аша безгә килеп, абруйлы бер газетабызның да йолдыздай балкучы шигаренә әйләнгән бит. Борынгылар сүзе! Җырдай ягымлы, балдай татлы ул.

*Чәйләр татлы шикәр-бал белән,*
*Йокы татлы сөйгән яр белән.*
*Ашадым алманың татлысын,*
*Яңа белдем дусның яхшысын,*

— дигән шагыйрәбез. Шулай, яхшы дус, яхшы китап, яхшы шигырь белән күңелле иде шул безгә монарчы бу дөнья... Газизә апаның шигырьләрен XIX гасыр әдәбияты хрестоматияләренә, «Өмет йолдызлары» исемле әдибәләребез, шагыйрәләребез иҗатын калку күтәреп балкыткан мәрхүм олуг галим Мөхәммәт Гайнуллин да шагыйрәнең иҗатын аерым бер мәхәббәт белән тәкъдир иткән иде бит. Ул да истә безнең! Матбугатта чыккан хәбәрләргә караганда, Ташлыярда Г.Сәмитованың кабер ташы яңартылган, чардуганы төзек, тирә-ягы чәчәкле икән. Казаннан да килеп зиярат итүчеләр булып тора диләр. Рәхмәт! — диик. Кыскасы, «Яшел таш»лар әле дә исән Иделебез куенында. Газизә апаларын яд итүче һәм аның изге иҗат — китап эшен дәвам итүче, ятимә булмаган милли яшь туташ һәм ханымнар да күп, Аллага шөкер! Идел — киң бит ул...

**Радиф ГАТАШ,**
*Татарстанның халык шагыйре.*

Газизә
Сәмитова

## Каләм[1]

**Кара савытта тора**
**Көмеш башлы җиз каләм.**
**Каләмнең хезмәте илә**
**Агарды бөтен галәм.**

**Әй каләмем, каләмем!**
**Сиңа улсын сәламем.**
**Синең кылган хезмәтеңә**
**Юктыр һичбер каләмем.**

[1] Шигырьләр М.Гайнуллинның «Татар әдәбияты. XIX — йөз» (1968 ел) китабыннан алынды.

Кәгазь өстен каралттың,
Дөнья йөзен агарттың.
Ничә миллион нөсхәләрне
Җир йөзенә тараттың.

Китаплар килермиде?
Адәмнәр белермиде?
Әгәр каләм булмаса,
Хөкемнәр йөрермиде?

Диңгез кичергән — каләм,
Җиһан гиздергән — каләм.
Ярны ишеп, тауны тишеп,
Ташны ваттырган — каләм.

Тупны аттырган — каләм,
Шәһәр ваттырган — каләм,
Дау чыгарса, солых кыла, —
Шул каләмгә йөз сәлам!

## «Төрке»м барга күркем бар

*... Борын заманнарда бер фәлән кеше ничә заманнар мәдрәсәдә укып йөргән һәм гыйлем булган. Әмма әйткән:*

Укыдым фарсы —
Фарсы бәңа торды каршы.
Янә укыдым гарәп —
Гарәп китте тарап,
Калдым артыннан карап.
Укыдым төрке –
Җанымның күрке.
Һәм төркем барга,
Һәм күркем бар.

## Алданрак уйламадым

Үткән гомеремнең әрнүе
Йөрәгемнән китмидер.
Зая үткән яшь гомерләр
Янә әйләнеп килмидер.

Бераз гомер сөрер өчен
Үстергән буйларымны...
Алданрак уйламадым
Хәзерге уйларымны.

БЕЗДӘ КУНАКТА — БАШКОРТСТАННЫҢ
ЭСТӘРЛЕБАШ РАЙОНЫ ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘСЕ

# ЭСТӘРЛЕБАШ КАЗАННАН ЕРАК ТҮГЕЛ

Исәнмесез, кадерле туганнар!

Безнен Эстәрлебаш районы 1930 елнын 10 августында оештырылган. 1609 квадрат км. мәйданны били. Районда 20 мен кеше яши. Аларнын күпчелеген татарлар тәшкил итә, ә сан ягыннан икенче урында башкортлар тора. Алардан тыш урыслар, чуашлар, украиннар да яши. Районда 69 авыл бар.

Безнең район көньяктан һәм көньяк-көнбатыштан Оренбург өлкәсе һәм Башкортстанның Федоровка районы, көньяк-көнчыгыштан — Мәләвез районы һәм көнчыгыштан Эстәрлетамак районы белән чикләшә. Ә инде төньякны Миякә районы биләп тора. Районыбыз Башкортстан табигатенең ин гүзәл почмакларының берсендәге Бәләбәй-Бөгелмә калкулыгының челтерәп аккан чишмәләр Һәм шаулап торган урман, чал кылганнар каплап алган таулар куенында.



Элек-электән мәдрәсәләре белән дан тоткан Эстәрлебаш авылы хәзерге көндә дә үзенең дәрәҗәсен төшерми Һәм район үзәге булып исәпләнә. Безнен Эстәрлебаш авылының тарихы бай һәм үзенчәлекле. Шушы Эстәрлебаш жиренә күчеп утыручы татар кан-кардәшләребез ин тәүдә, бернигә карамый мәчет-мәдрәсәләрен тергезеп, тирә-якка белем Һәм мәгърифәт тарата башлаганнар. Һәм Эстәрлебаш тиз арада зур белем ьәм мәдәният үзәгенә әверелә. Тирә-якта ана тиң авыллар булмый. Эстәрлебаш мәдрәсәләрендә белем алырга тирә-як төбәкләрдән генә түгел, ерак-ерак жирләрдән дә шәкертләр килгән. Туксуран, Урта Азия, Түбән Новгород, Минзәлә якларыннан да укучылар булган. Мәдрәсәләрнең саны — кырыклап, шәкертләр исә алты йөзләп, кайсы елларда меңнән дә артып киткән. Ә бит бу вакытларда Эстәрлебашта ике мең генә кеше яшәгәне билгеле. Шулай итеп, ул чакта авылдагы һәр өч кешенең берсе шәкерт була.

Эстәрлебаш мәдрәсәләрендә белем алучылардан соңрак күп кенә күренекле дин әһелләре, имам-хатыйплар, ишаннар, ахун-мөфтиләр үсеп чыккан. Шулай ук мәшһүр укытучы-мөгаллимнәр һәм татар-башкорт әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткән шагыйрь-язучылар һәм фән эшлеклеләре укыган биредә. Мәдрәсәне тәмамлаучылар үзләренең туган татар, башкорт, казакъ телләреннән башка гарәп, фарсы, төрки телләрне дә яхшы үзләштереп, ул телләрдә язышып һәм үзара иркен сөйләшеп аралаша алган. Монда математика, география, биология, урыс теле һәм башка фәннәр укытылган. Эстәрлебаш мәдрәсәләрен тәмамлаган күренекле шәхесләрне саный китсәң, бик күпкә җыелыр иде. Монда укыган һәм укыткан җәмәгать эшлеклеләренең татар-башкорт халкы арасында белем-мәгърифәт таратучы күренекле кешеләр булуы бәхәссез. Күпләренең тормыш юллары һәм кульъязмалары өйрәнелмәгән диярлек. Чөнки октябрь инкыйлабыннан соң барча гарәп графикасында язылган китап-кульъязмаларны, «дингә каршы көрәшәбез» диган булып, мәдрәсә китапханәсеннән НКВД хезмәткәрләре Эстәрлетамакка алып китеп яндырган. Ә китапханәдә 65 меннән артык китап була. Исән калганнары да төрле сәбәпләр аркасында югалып ьәм урланып беткән. Эстәрлебаш авылынын 1905 елга кадәр татар-башкорт халкынын шигърият ьәм мәгърифәт үзәге булып исәпләнүенә

дәлил булып монда укыган, укыткан, яшәгән күренекле шәхесләр исемлеге тора. Язучы-шагыйрьләрдән Гали Чокрый, Шәмсетдин Зәки, Гаделша Богданов, Хәснетдин Жданов, Мифтахетдин Акмулла, Гали Рафики, Төхфәт Янәби, күренекле дин әһелләреннән баш мөфти Мөхәммәтҗан Хөсәенов, Габделсәлам Габдрәхимов, Габделвахит Сөләйманов булса, гыйлем ияләре Мирсалих Бикчурин, Габдулла Фәез (Сатыев), Чокан Вәлиханов, Габделмәних Каргалы, Абдулла Искәндәров, Рифкать Солтанбәков, Зәки Вәлиди Туган, Мирсәет Солтангалиевләр булган. Пугач боласында башкортларны җитәкләгән Салават Юлаев һәм Кинҗә Арсланов та монда укыган. Безнең төбәктән чыккан фән докторлары Зәки Зәйнуллин, Марс Юлдашев, Рифкать Мәсәгутов, Радмир Хәсәнов, Наил Юнысов, Минрәсим Мөрәсев, Равил Гатауллин, Гали Галиев, Марс Сафаров, Камил Сабитов, Тәбрис Фәритов һәм йөзгә якын фән кандидатыбыз бар. Безнең якташлардан язучыларыбыз Фәйзи Гомәров, Равил Шәммас, Әдхәт Синугыл, Зиннәт Галимов, Зәки Зәйнуллин, Мариус Максютов, Мәҗит Кәримов, Зөлфия Гыйззетдинова, Рәфгать Рысаев, Рәлиф Кинҗәбаев, Хисаметдин Исмәгыйлев һәм башкалар. Шулай ук РСФСРның халык артистлары Хәй Фәхри белән Шамил Рәхмәтуллин да Башкортстанның халык һәм атказанган артистлары Хәкимҗан Сәгыйтов, Гайса Галимуллин, Наил Галиев, Әнисә Яхина, Флүрә Мозаһитова, Халидә Хәсәнова һ.б Эстәрлебаш җиреннән илһам алган.

Бүгенге көндә дә Эстәрлебаш җирлегендә мәдрәсәләр салдырып тирә-якка аң-белем тараткан бабаларыбыз рухы сүнми. 1994 елда шәхси эшкуар, милләтпәрвәр Ягъфәр Сәягъфәр улы Хисмәтуллин районыбызда туып-үскән һәм аның данын үстереп, дөньяга танытучы язучыларны, сәнгать эшлеклеләрен дәртләндерү йөзеннән Мифтахетдин Акмулла фондын булдырды. Бу бүләккә бары тик Эстәрлебаш җирен данлаучылар гына лаек була ала. Бүгенге көндә аның лауреатлары 16 кеше һәм тагын Эстәрлебаш Мәдәният йорты каршындагы татар халык театры коллективы (җитәкчесе Нурия Рәхмәтуллина) белән Күндерәк авыл Мәдәният йорты каршында эшләгән «Күндерәккәй» башкорт фольклор ансамбле (җитәкчесе Люция Байназарова). 2007 елда якташыбыз язучы Зәки ага Зәйнуллин тәкъдиме белән район үзәгендә әдәби-мәдәни берләшмә оештырылды. Бу берләшмә, районда туып-үскән каләм тибрәтүчеләрне һәм сәнгатьнең төрле өлкәләрендә иҗат итүчеләрне бергә туплап, талант ияләрен тагын да дәртләндереп җибәрде. Оешмада әгъза булып татар-башкорт милләтеннән 45ләп иҗатчы тора. Бу үзе үк районда яшәгән тугандаш милләтләрнең дус һәм тату яшәешенә үрнәк. Җитәкчесе Рәфгать Шәмгун улы Рысаев булган әлеге әдәби оешма елына ике тапкыр «Стәрлебаш балкышлары» дигән әдәби-нәфис, иҗтимагый-сәяси журнал чыгаруны оештырды. Шушы матур да, шул ук вакытта мәшәкатьле дә эшне оешманың хәзерге җитәкчесе Наилә Кадыйр кызы Гыйззәтуллина дәвам итә. Бу журнал белән хезмәттәшлеккә мәктәп балаларын да җәлеп итәргә тырышабыз. Уку чорында әдәби берләшмәнең актив әгъзалары тарафыннан авыл мәктәпләренә барып, төрле кичә-очрашулар оештырыла. Алар туган телдә генә алып барыла.

Дус булып, туганнарча яшибез дигәнгә янадан әйләнеп кайтып, шуны әйтәсе килә: татар белән башкорт арасындагы иң суык елларның берсендә, ягъни 2009-2010 елларда, безнең район Башкортстанда беренче булып Татарстан ягына дуслык капкасын ачты. Һәм шушы капка аша ике туган, кан-кардәш республикалар арасына җылы кереп, ике халык өчен дә шифалы җилләр исеп, туганлыкны тагын да ныгытып җибәрде. Моңа сәбәпче булып бөтен төрки дөньяга танылган аталы Камал театрының якташыбыз Зәки ага Зәйнуллинның «41нең арбалы хатыннары» драмасын куюы һәм дә Акмулла фонды рәисе Ягъфәр Хисмәтуллин, районыбызның милләтпәрвәрләре, татар морзалары нәселен дәвам иттерүче Рифкать Дәүләтьяров белән аның тормыш иптәше Люция ханым, Рәфгать Рысаев Һәм Хисаметдин Исмәгыйлев инициативасы белән Камал театры коллективының Эстәрлебашка чакырылуы булды. Шул ук вакытта кунакка, олы хөрмәт йөзеннән, татар милләтенең күренекле улы Туфан ага Миннуллин да чакырылды. Алар, спектакль геройларының балалары, туганнары белән якыннан аралашып, район җирлеге белән таныштылар.

«Кунак ашы — кара-каршы» дигәндәй, шул ук 2010 елда камаллылар эстәрлебашлыларны «41нең арбалы хатыннары» премьерасына чакырды. Дуслык һәм туганлык үрнәге менә шундый булырга тиештер дә инде. Эстәрлебаш җирендә

шытып чыккан туганлык агачының тамырлары ныклы булыр дип ышанам. Һәм данлыклы «Казан утлары» журналына, Татарстан Язучылар берлегенә, шәхсән Рафис Корбанга безнең район җирлегендә туып-үскән язучыларга игътибар һәм хөрмәт күрсәткәннәре өчен олы рәхмәтебезне җиткерәбез. «Казан утлары»н укучыларга, барча татар халкына Эстәрлебаш җиреннән кайнар сәлам! Камаллылар һәм эстәрлебашлылар башлап җибәргән традиция, кунакка йөрешү-аралашулар, Башкортстанда яшәгән татарларның тормышы белән татарстанлыларны таныштыру киләчәктә дә дәвам итәр дип ышанасы килә.

**Фәнүр ТУКТАРОВ,**
*Эстәрлебаш район хакимияте башлыгы.*

# Рәфис Зиязетдинов

*Зиязетдинов Рәфис Минегали улы 1952 елның Кече Бузат авылында туган. 1978 елны БДУның тарих факультетын тәмамлап, туган районында завуч, мәктәп директоры булып эшли. 1980 елдан хәзерге көнгә кадәр Башкорт дәүләт аграр университетында: ассистент, өлкән укытучы, доцент, тарих һәм мәдәният белеме кафедрасы мөдире, мәгълүмат технологияләре һәм идарә итү факультеты деканы.*

*Тарих фәннәре докторы. 150ләп фәнни хезмәт авторы.*

## Казаным

**Туган җирем булмаса да:**
**«Казаным!» — дип сөйлимен.**
**Сиңа булган сөюемне**
**Җырга салып көйлимен.**

*Кушымта:*
**Казаныма мин барамын**
**Хаҗларга барган кебек!**
**Әнисенең кочагына**
**Йөгергән бала кебек.**

**Йөзе дә — Син, йөзеге дә**
**Гүзәл татар җиренең!**
**Ае да — Син, Кояшы да**
**Горур татар иленең!**

**Күп гасырлык тарихың бар —**
**Бабамнарның мирасы!**
**Шәһәрләрнең шәһәре син —**
**Бар татарның кыйбласы!**

**Сөембикә манараңнан**
**Яңгырый моңлы азан...**
**Тагын мең ел яшә, Казан!**
**Мәңгегә яшә, Казан!!!**

## Казаннарга барам әле

Татар өчен изге төбәк
Казан диеп атала.
Еракларда яшәсәм дә,
Күңел аңа уктала.

*Кушымта:*
Горурлыгым да син, Казан,
Терәгем дә син, Казан.
Исемең үк сафландыра,
Әйтерсең лә ул азан.

Казаннарга барыйм әле
Җаннарым сихәтләнсен.
Күреп халкымның мирасын,
Йөрәгем ләззәтләнсен.

Бирешмәдең, Казанкаем
Укларга, сөңгеләргә.
Җирләреңне кумәр идем
Чәчкәләргә, гөлләргә.

## Эстәрлебаш яклары[1]

Җирнең асыл ноктасы
Эстәрлебаш исемле.
Шул якларга ашкындыра —
Әллә соң син тылсымлы?

*Кушымта:*
Урманнарыңда чияләр
Килче, килче, дияләр.
Син кабызган гыйшык утын
Әллә инде беләләр?

Кайтыйм әле, күрим әле
Эстәрлебаш якларын.
Күңелемнән җуйыйм әле
Сагыну газапларын.

Туган ягым әни кебек
Изге дә, кадерле дә.
Мәхәббәтем шуңа көчле,
Сүнми дә, сүрелми дә.

## Укыйбыз сиңа дога

*Фән Вәлиәхмәтовка*

Сандугачларга тиңләрлек
Моңнар иясе бит син.
Халкымның иҗат күгендә
Йолдыз булып балкыйсың.

Төрки илләрендә син үз,
Татар телле булганга.
Уфа–Казан якыная
Фәннәребез булганга.

Өздер әле тальяныңда
Һәйкәлгә тиң җырларны.
Халкым сусаган көйләргә
Күмдер әле җиһанны.

Моң ургылган йөрәгеңнән
Җырлар чишмәдәй ага.
Гомер теләп, саулык теләп
Укыйбыз сиңа дога.

[1] Фәнир Галимов көе

# Фәнирә Ибраһимова

*Мин, Ибраһимова Фәнирә Габделхәй кызы, 1956 елда Тәтер-Арслан авылында туганмын. Урта мәктәпне тәмамлагач, БДУның филология факультетында белем алдым. Юнәлтмә белән Благовар районына килеп, озак еллар шунда укытучы булып эшләдем.*

## Европада татар җыры

**Мәңгелек җәй илен сискәндереп,**
**Гүзәл бер сер булып дөньяга,**
**Татар гына җырлар, татар гына сөйләр,**
**Татар гына көйләр моң ага.**

**Тальян сыздыруын чит аһәңнең**
**Алыштыра алмас йөз, меңе.**
**Исең китәр: бер уч кассетага**
**Сыеп беткән татар күңеле.**

**Сайлап кына көйгә сүз тезелгән,**
**Һәр тибешен тоеп йөрәкнең.**
**Шулай язган: күңелләрне айкар**
**Җыры–моңы булган милләт мин.**

**Татар җырлый үзәкләрне өзеп,**
**Татар җырлый җанны эретеп,**
**Татар җырлый биетерлек итеп**
**Кыйтгаларның барын бер итеп.**

**Гибралтардан «Сарман буйкайлары»н**
**Ялгыз ай да тыңлый үрелеп.**
**Без китәрбез. Татар җырын сагынып**
**Кипарислар елар түгелеп.**

## Борынгы кунак

**Ышанмаган, әйдә, ышанмасын,**
**Ышанганнар, тыңлап карагыз.**
**Безгә кунак булып килгән, имеш,**
**Борынгы бер ерак бабабыз.**

**Әйткән, имеш, сезне күрер өчен**
**Сайладым, дип, юлның авырын.**
**Бик күрәсем килде сезнең чорның**
**Техник могҗизалар авылын.**

**Үзе болай буйчан, бик таза ди,**
**Затлы тиреләргә төренгән.**
**Безнең халык аның тирәсендә**
**Үтә фәкыйрь булып күренгән.**

**Могҗизалар эзләп күп йөрсә дә,**
**Очратмаган һаман кирәген.**

Аптыраудан кинәт катып калган,
Күреп гади бакча көрәгең.

— Бу бит минем көрәк. Ул соң әллә
Сезнең музейларда торамы?
Киләчәге аңа җавап биргән:
Бу, дип, безнең төп эш коралы.

Балта күреп, бабай гаҗәпләнгән,
Тырма күреп авыр сулаган.
Чалгы, китмән күргәч, башын кашып,
Озак кына нидер уйлаган.

Сизми калган хәтта тораташтай
Юл өстендә кинәт туктавын,
Күреп алгач авыл хатынының
Дуртаяклап басу утавын.

Әйткән, имеш, авыр ыңгырашып:
— Ник гасырлар үттем алданып?
Шушымени сезнең космик үсеш?
Шушымени сезнең «алдалык»?

Сезнең чорда күргән «техника»ны
Үзем ясап эшкә җиктем мин.
Үз коралым түгел, сезнең эшне
Күрер өчен сәфәр чыктым мин...

Юатканнар. Бераз тынычланган
Кешелекнең ерак бабае.
Шунда салмак кына тамак кырып
Сүз алган ди авыл агае:

− И борынгы бабай, матди яктан
Нульгә тигез икән арабыз.
Яшәү өчен син дә көрәшкәнсең,
Җан асрыйк дип без дә чабабыз.

Минем сиңа бик шәп тәкъдимем бар:
Килгәч, үтеп күпме дәверне,
Әллә, тәвәккәлләп, үзең генә
Шефка аласыңмы авылны?

## Кайда безнең депутат?

«Кандидатны каршылагыз!» —
Тыпырдата хуҗабыз.
Каршылыйбыз, ничек инде
Хуҗабыздан узабыз?

«Тавыш бирсәгез, отарсыз,
Калмассыз ялгыз, ятим!» —
Кандидатка мактау җырлый
Ярдәмче Локман хәким.

Кандидат гади зат түгел,
Хәернас улы икән.

Хәернас улы Ходаның
Почти уң кулы икән.

Аны сайласак, дөньябыз
Оҗмахка әйләнәчәк,
Авыл хуҗалыгы, үсеп,
Космоска бәйләнәчәк.

Сайлау көне үзе рәхәт,
Җитәкчеләргә рәхмәт.
Кемне сайларгасын төртеп
Күрсәтә рәис Әхмәт.

Сайлыйбыз, чөнки һәркемнең
Оҗмах күрәсе килә,
Тәмле оҗмах җимешләре
Ашап үләсе килә.

Халык наказлары белән
Алдар капчыгын төяп,
Мәскәүгә китте депутат...
Калганын язмыйм... Оят...

Өч ел үтте. Буш кырларны
Кызганып җилләр тарый.
Авыл тиеннәрен саный,
Мәскәүгә карый–карый.

«Кайда син, ник югалдың?» — дип
Кычкырсак та җиде кат,
Тавыш бирми. Адашкандыр,
Ахры, безнең депутат.

Мәскәүләрдә фатир алган,
Кырымда – вилла диләр.
Фатиры да, вилласы да
Бик хәтәр, җилле диләр.

Тагын сайлау. Мескен авыл
Сәясәт колы икән.
Бүген кандидат килә ди,
Бусы кем улы икән?

## Татар теленә

Сиңа мәдхияләр җырламадым,
Зурламадым сине табында.
Мин беркайчан кулга сүзлек тотып
Өйрәнмәдем сине таныргa.

Табигатем мине туганда ук
Синең кызың итеп яраткан.
Өлешемә тигән көмешем син,
Анам белән тигез яратам.

Ә анага булган мәхәббәт ул
Һәрбер күзәнәктә, тамырда.
Яшәешең шуннан тора икән,
Ник дөньяга сөрән салырга?

Кайсы телдә яшәү җайлырак дип
Мин бервакыт план кормадым.
Беркайчан да «Фая» булмадым мин.
Беркайчан да «мама» булмадым.

Бу дөньяда тәүге сулышымнан
Язмышым һәм моңым син минем.
Балигъ булгач, гомерлеккә сайлап
Алган хезмәтем дә син минем.

Башка телләрне, юк, түбәнсетмим,
Безнең якта андый гадәт юк.
Бар телне дә бик өйрәнер идем,
Тик өйрәнеп булмый — сәләт юк.

Мин беркайчан зур сүзлекләр тотып,
Өйрәнмәдем сине таныргa.
Мин туганда татар булып тудым,
Татар каны минем тамырда.

# Рәфгать Рысаев

*Рәфгать Шәмгун улы Рысаев 1939 елны Тәтер-Арслан авылында туа. Урта мәктәпне тәмамлагач, колхозда радиомонтёр, терлекче, 1960-1965 елларда ветеринария врачы булып эшли.*

*Әлеге көндә дә туган авылында яшәп иҗат итә. 2010 елда Башкортстанның Татар телле язучылар берлегенә кабул ителде.*

## ТАРТАЙ ТЕЛЕННӘН ТАБА

ХИКӘЯ

— Әни, әйдә тизрәк, сарыклар кайта! — Әнисә, Тегермән тавы башыннан авылга төшеп килгән көтүне күреп, хәбәрен Нәсимәгә житкерде дә, көндез үк әзерләп куйган тал чыбыгын кулына тотып урам буйлап йонбикәләренә каршы йөгерде.

— Әй, унган да инде шушы кызыгыз, — дип күзе белән озатып калды күршеләре Биби, Әнисәнең картәнисе белән капка төпләрендә бәйләм бәйләп утырган килеш. — Ходай бәхетен бирә күрсен берүк.

— Әйе, моның кебек тә бала күргән юк иде. — Хатирә кинәнеп ахирәтенең фикерен куәтләде. — Торганы ут бөрчәсе. Яңа унбере тулуга карамастан, белмәгәне юк. Өйдәге бөтен эшне эшли. Бакчасын да утый, суын да сибә, атна саен палас, келәмнәрне тышка алып чыгып, җилләтеп, кагып кертә, ашарга пешерә, теге лушкүте иренсә, сыерларына хәтле сава.

— Ул ата ялкауга ни житә калды инде, — дип саплы якка салам кыстырды Биби. — Ханбикә кебек кулларын бөеренә таяна да, боерык кына бирә.

— Укуга да шәп Әнисәбез. — Хатирә оныгы белән горурлануын дәвам итте. — Быел да отличница.

Шулчак ашыкмый гына атлап урам уртасыннан Нәсимә үтеп китте.

— Шәбрәк бул! — дип кисәтеп калды биеме. — И-и, мыштырдыксың да инде, Әнисәнең киткәненә биш былтыр лабаса!

— Пошмас! — Биби дә эчендәген ирекkә чыгарды.

— Кичә бер бәрәннәре кайтмаган иде. Бу барып житкәнче тагын көтү авылга кереп таралыр, табалмаслар әле. — Хатирә уфтанып бетүгә, ахирәтләрнең игътибарын тузан туздырып бу якка жилдерткән ГАЗ-53 машинасы җәлеп итте.

— Йөрерләр инде, — дип сукранды Биби. — Шул көтү кайта башласа, малга бер тынгылык юк.

— Бәйрәмнән болар. — Авылдагы хәл-әхвәлне энәсеннән-җебенә кадәр белгәнгә «обком» кушаматы тагылган Хатирә бу юлы да алдан алды. — Яңа хужа язгы чәчүне тәмамлау хөрмәтенә механизаторларга сый оештырган бит. Олыраклар бая ук таралышты, ә болар — печмәгән кәҗә тәкәләре — утырганнардыр дөньяларын онытып.

— Дөнья ищу аларга! — Биби танау очына ук төшереп кигән күзлеген маңгаена күтәреп, үзләре каршындагы чатка житкәч кырт авылга борылган машинаның кабинасын айкады. — Теге аръяк Сәлимнен төпчеге түгелме сон рульдәгесе?

— Әйе, Азамат, — дип җөпләде Хатирә. — Эчкәч йөрергә түгел дә бит, житмәгән инде боларга, эзләнеп чыкканнар.

— И-и, бозылса да бозылыр икән бу яшьләр, исең китәрлек. Өйләним, дөнья көтим дию юк, бар кайгылары — эчү.

— Чиләгенә күрә капкачы, ахирәт. Замана нинди, халык шундый. Үзең уйлап кара, коммунистлар ничек иде? Уттай эш вакытларында аракы сату бөтенләй бетә, көндез чыра яндырып эзләсәң дә табалмыйдыр идең. Ә хәзер? Круглый сутки пожалыста. Шуның өстенә, һәркемдә — төнлә туган. Хуҗалык һаман да чөгендер үстергәч ни, песогын капчыклап бирә, фәләк-фәләк бал кой да, көмешкә чыгарып эч, артыгын сат. Күрүче дә, тыючы да юк. Ә элек? Төн уртасына кадәр өй борынча иснәнеп йөреп, сәмәй эзлиләр иде. Әләгеп кара, штрафы — сыер хакы!

— Ә халык алдындагы ыстрамы тагын! — Биби җәелә биреп, хәтер күленә чумды. — Исем-фамилияңне район гәзитендәге «Хурлык тактасы»нда басып чыгарып, бөтен миргә рисвай итәләр!

— Аннан соң, эчтем дип эшкә чыкмый кара, айлык хезмәт көн нормасын тутырма! — «Обком» да иркенләп киерелде. — Идарә утырышы, административ комиссия, партком, исполкомга куеп иманыңны укыттылар. Икенче кат ыстаканга үрелгәнче шуны уйлыйсың.

— Үрелсәң, милициядә унбиш сутки, ЛТПсы бар. Эшең дә эшләтә, бер унайдан дәвалап та кайтара.

— Менә бит ничек көрәшкән бу зәхмәт белән начар коммунистлар.

— Көрәш дигәннән, яңа хуҗа әле дә тырышып карый инде ул. Үткән көз авылның бар алкашларын төяп, Эстәрлетамакка алып барып, кодировать иттергән иде. Тик тегеләре җайлап барыбер үз юлларына төшеп беттеләр. Шуннан кыш Абдуллинога бер өшкерүче карчыкка җибәрде. Кайтканда Әкчүннән аракы алып, юлда ук җырлашып эчкәннәр ди.

— Соң, шулай булмыйни, өшкереп кайтарган, әлбәттә, безнең кебек ачык авызларны алдап акча җыючылар бит алар. — Хатирәнең сүзен урамнан бер өер сарык-кәҗә куып килеп менгән кыз бала бүлдерде.

— Әби, сине Нәсимә апа чакырды, тиз генә төшсен, диде.

— Нәрсә, бәрәннәрне аералмыйлармы?

— Юк, Әнисә машинага тапалган.

— ???

Бу коточкыч хәбәрне ишетүдән йөрәге атылып чыгар чиккә житкән Хатирә үз-үзен белештерми урам буйлап чапты. «Уф, баламны, артык имгәнмәгән булса гына ярар иде, Ходаем,» — дип тели-тели йөгереп атлый торгач, көтү олы урамга чыгучы тыкрык мөешендә бая үтеп киткән машина күзенә чалынды. Тирә-ягын халык сырып алган. Фаҗига юл читенә утыртылган тупыл агачы төбендә булган, ахрысы, күпчелек шунда кайнаша. Җаны уч төбенә якынлашкан Хатирә, кинәт күз аллары караңгыланып, башы әйләнүдән чак егылмый калды. Аның алдында гәүдәсе биленнән урталай өзелеп икегә бүленгән Әнисәсен кырын төшеп кочаклаган килене ята иде.

— Хараплар гына иткәнсең баламны! — Хатирә эчендә кайнап чыккан ут-ялкынын учлап-учлап килененә сипте. — Күзле бүкән, нәрсә карадың, әйтеп калдым бит, шәбрәк атла, дип. Яныңдагы кызыңны да саклый алмаган нинди әнкә син? Әнисәм урынына үзең үлсәң, лутчы булыр иде...

Шулчак, кемдер шалтыраткан күрәсең, яннарына кабина башында ялт-йолт ут уйнаткан ГАИ Уазигы килеп туктады. Шактый айныса да һаман очкылыгы тоткан Азаматның һәм шаһитларның күрсәтмәләреннән шул мәгълүм булды: исерек кешедәй чайкала-чайкала, унга-сулга бәргәләнеп барган машина көтү белән күзгә-күз терәшкәч, сарыкларын куып килгән Әнисә өстенә ябырылган бәладән юлдан читкә тайпылып котылырга чамалый. Ләкин күзе тонган Азамат тормозга басам дим ялгыш газга баса да машинасын туп-туры Әнисәгә юнәлтә. Шул минутта мажара урынына килеп житкән Нәсимә, яшен тизлегендә кабина баскычына сикереп менеп,

рульгә ябыша, ләкин борып өлгерә алмый, буфер кызыкайны тупылга китереп кыса.

Димәк, гаеп балада да, әнкәдә дә түгел, исерек Азаматта. Ләкин бу хакыйкать Хатирәнең аңына һич кенә дә барып җитмәде. Килене газизенең — баш, үзе аяк як гәүдәсен күтәреп өйләренә кайтканда да, аннан соң да Нәсимәгә әллә нинди нахак гаепләр такты, очраган һәр кешегә яманатын сатты.

— Кит, артык кыланма, күрәчәге шул булгандыр Әнисәнең, язмыштан узмыш юк дигәннәр, — дип Биби күпме аркылы төшсә дә, ахирәтенең кинәшен ишетергә дә теләмәде. Шундый шәп, булдыклы нәселгә эшкилмәгән килен эләгүгә йөрәге әрнеде.

— Халыктан курыкмасаң, Алладан курык. Бүгенге белән генә түгел, киләчәк бар, картайган көнеңдә килененең кулына калуың ихтимал. — Ахирәтенең бу дәлилләренә дә саңгырау калды Хатирә.

Һич көтмәгәндә, чәчкәгә йомарланган чагында гомере өзелгән Әнисәне бөтен авыл һәм мәктәп зурлап, хөрмәтләп соңгы юлга озатты. Азаматны кулга алдылар.

Исәннәр өчен сизелмичә бер атна үтеп тә китте. Бүген Әнисәнең җидесе. Нәсимәләр ике яктан да агай-энеләрен җыеп, Коръән укыттылар. Бер Василәләр генә килә алмады.

— Чөгендергә төштек, аш-су кайгысы юк әле, — дип җаваплады ул телефон аша.

Чакырылган кешеләрнең җыелып бетүен көткән арада дөньяви хәлләр хакында сүз куертканда мулла бабай: «Аштан, бигрәк тә Коръән ашыннан олы булырга кушмаган китап, — дип кисәтүне кирәкле тапты. — Өстәвенә, матайлары бар, ике-өч сәгать вакыт каян килеп кая китмәгән».

— Ай, халык кыланганны кыланыйк, башкалардан артта калмыйк дигәннәрдер инде, — дип акланды Хатирә.

— Безнекеләр яңа чәчте, аларныкы чыккандамыни? —Һәрчактагыча, Биби сүзнең төбенә тоз койды.

— Безнең хөрәсәннәргәме соң мишәрләр белән ярышу. — Хатирә төкерек чәчә-чәчә күршеләрен мактарга тотынды. — Бар яклап та бер баш өстен бит алар. Менә, үзең уйлап кара, колхозыбызның кәмәсе комга терәлгәч, авылыбызның булдыклы яшьләре Себергә юлланды, ә аларда — юк. Шуңа колхозлары әле дә элекке хәлендә, уңышлары да зур. Мисалга чөгендерне генә китерәм. Нинди елны да ике йөз центнердан калганнары юк. Песогын да көрәп ала халык, Василәләргә, әйтүе генә ансат, ун капчык бирделәр.

Нәсимә, киләсе кешеләре килеп беткәч, барысын да табынга дәште. Хатирәне, олыга санап, түргә, бер ир аша мулла кырына утырттылар. Бүлмә эчен хәзрәтнең җырга тартым аһәңле тавышы матур монга күмде.

Укылырга тиешле аятьләр укылып, хәер-садакалар таратылганның соңында бирелләсе ашлар бирелеп, табынга фатиха кылгач, халык хушлашыр алдыннан Хатирә тагын бер тапкыр үзенең кемлеген күрсәтеп алды.

— Һәр ата-ана үз баласын кадерләп тәрбияләп үстерергә тиеш, безнең килен кебек карап торып тапатырга түгел, — диде ул. — Сезгә бер соравым бар мулла абзый, шундыйларга Ходай Тәгалә җәзасын бирәме?

Шулчак почмактагы телефон шалтырады. Хуҗа буларак, трубканы Нәсимә алды. Чыбыкның теге очында күп елаудан тамагы карлыгып беткән Василә иде. — Без дә олы фаҗигагә юлыктык, чөгендердән кайтышлый олы юл аша чыкканда,  машина Айдарыбызны бәрде.

Василә — Хатирәнең ике сүзнең берендә киленәнә үрнәк итеп куйган мактаулы кызы, Айдар Әнисәдән бер генә яшькә бәләкәй оныгы иде...

Авылда иң киеренке чор — печән өсте житте. Хатирәләрнең чабынлыгы

елдагыча Җәннәт тугаенда. Үлән каерылып үскән. Барын чабып алганда, бер хафасыз кыш чыгачаклар. Житмәсә, быел иртә яздан үзләренә ат та юнәттеләр. Шуна, авылдан нибары өч чакрым ераклыкка йөрисе булса да атка утырып барып кайткач, рәхәтлекнең чигенә чыктылар. Жирәнкәйләре яшь, житез, өйдән бөтен эшләрен бетереп, халык белән бергә кузгалалар, әмма жәяүлеләр килеп житкәнче бер тын чабып өлгерәләр. Кич тә шулай. Көтү кашлакта күренгәч кенә жыйнала башлыйлар, ә капканы маллар кайтуга барыбер ачып өлгерәләр. Шуна эшләре елдам барды быел. Гомер булмаганны көннәр дә аяз торды. Печән яшел көенчә, хуш исе белән жыеп алынды. Башка чакта кҮбәләрне чүмәләләргә салып, аннан бер урынга тарттырып эскерткә куялар иде. Әле, атлары булгач, жәйдән үк өйләренә ташырга уйладылар. Ире, шуны күздә тотып, фурманын алдан ук зур, кин итеп ясады. Көне буе жыйган печәннәре ике йөккә шыплап керә дә бетә. Хатирә башта тора, ире төйи. Бастырыклап бәйлиләр дә, парлап утырып кайталар. Абзар башлары зур, ян яклап ике шифер биеклектә стена ясап эшләнгән, шунда өя баралар. Ара ерак булмагач, көненә ике юллыйлар. Хатирә үзе дә аптырап куя шәплекләренә. Инде житмешне куалар, ни ире, ни ул картлыкның ни икәнен дә белмиләр. Һаман шул заман чакларындагыча дөнья көтү. Аерма тик шунда — элекке кебек колхоз эшенә бару юк. Ә калганы бар да элеккечә. Хәер, элеккечә дию бик дөрес тә түгел. Элек бер сыер да бер бозау, дүрт баш вак мал калдыралар иде кышкылыкка, шуннан артыгы рөхсәт ителми иде. Хәзер замана үзгәрде, күпмегә көчең житә, шул кадәр тот, чикләү юк. Хатирәләр дә башкалардан калышмаска тырышалар. Ике сыерыннан көн дә ике чиләк сөт сава ул. Анысын да атнасына бер — якшәмбедә генә үткәрә, калган алтысында сөт жыючыга тапшыра. Бердән, үзенә эш кими, икенчедән, аена жиде-сигез йөз сумлык була. Акчаның кайчан да зыяны юк, иш янына куш дигәндәй, ярап куя. Ике сыердан ике бозау ел да башмакка әйләнеп тора. Берсен суеп саталар, кесәләренә сигез-тугыз мең керә. Киләсе жәйгә Жирәнкәйләре дә колынлар, Алла боерса. Нишлисең, авыл кешесенең тормышы мал белән бара. Шуңа иренмәскә, бигрәк тә жәй йокламаска туры килә. Анысына күнегәсе юк Хатирәгә. Гомере буе колхозда сыер савып, сәгать дүрттән торып өйрәнгән. Әлеге дә баягы жәй көне, ятып өлгермисең, торырга кирәк. Иртәнге савымга хәтле карангылы яктыда үз сыерыңны саумый чарың юк. Бер иш хатыннар, көтүен куа да, бер тын ятып йоклап ала, ә син бу чакта йөгерә-йөгерә утыз биш сөтбикәнең хәстәрен күрәсең. Аннан кайту белән хатын-кызның мәңге бетмәслек йорт мәшәкатьләре. Кич тә шул ук хәл. Исәнлегең корычтай булмаса, һич түзмәле түгел. Рәхмәт әти-әнисенә, чагылларда үскән имән ныклыгы биргәннәр Хатирәгә. Аллага шөкер, шушы яшенә житеп бүльнис ишеген ачып кермәде, тәүлегенә унсигезәр-егермешәр сәгать аяк өсте чабып та хәлдән таеп егылмады. Улы белән кызы да үзенә ошаганнар, тырышлар, уңганнар, чәмләнеп дөнья көтәләр. Тик менә килене белән кияве... Берсе ата ялкау, икенчесе — алкаш. «Шушы афәтләр аркасында югалттым күз нурларымны», — дип сыкрана аның йөрәге.

Әле дә, йөк башында торганда, күз алдыннан Әнисә белән Айдары китмәде. Шулчак карашы алан читендәге тирәклеккә төште һәм, зиһене ачылып, кабат дөньялыкка кайтты.

— Монысы соңгы йөк, тагын кайчан киленә әле яланга, бер унайдан колмак та жыеп кайтыйк, — диде ул иренә, бастырыкны кысып бәйләгәч һәм шап-шап атлап тугайга кереп китте. Бераздан ярдәмгә ире дә килеп житте. Шулай агачтан-агачка күчә торгач, куаклык эчендә яткан матур гына аланга килеп чыктылар.

— Бәракалла, үләненең шәплеге! Тугай уртасында кеше биеклек сарут! Әйдә, иртәгә киләбез дә чабабыз.

— Чуашлар жире бу, — дип аркылы төште ире. — Иясе чабалмый торадыр.

— Чабарга булса, чабар иде инде. Киләбез дигәч, киләбез.

— Ай-һай, кеше хакы, килешер микән?

Ләкин Хатирәме соң ире сүзен ишетә торган хатын?! Икенче көнне көтү куу белән килеп тә җиттеләр. Ире, гадәтенчә, атын тугарып, арба төбендәге аркан бәйләменә үрелде.

— Нәрсә сихерлисең шуны, — дип ризасызлык белдерде Хатирә. — Тезгененнән бәйләсәң дә тора бит инде. Сиңа шул бәйле арканны ярты сәгать буе чишеп, көрмәк ясап вакыт уздырырга булсын.

— Ай, Алла, сиңа ярамас инде! — Һәр хәрәкәтенә кысылып, бәйләнергә сәбәп эзләгән хатынына ачуы кабарган ир арканны атып бәрде дә, атын тезгененнән фурманга бәйләде.

Яңа чүкелгән чалгылар, үлән куе, биек булса да, җинел кистерә. Аланның кап уртасыннан аркылы төшеп, өчәр пакус чыккач, тын алырга туктадылар.

— Тамак кибәргә әйтә, бар әле, әйрән сыекла, — дип боерды ире.

— Ана бит чәй, шуны гына эч.

— И-й, салкын әйрәнгә җитәме соң! — Хатирә нишләптер бу юлы карышмады.

Чишмәгә төшкәч, иренең сүзенә кызыгып, үзенә ярамаганын белә торып әйрән чөмергән иде, ярты пакус та чабып өлгермәде, эче быгырдарга тотынды. — Әй, дошман, тапты вакытын. — Хатирә алан-йолан каранды. Тирә-якта үз картыннан башка беркем дә юк юклыкка, ләкин чабынлык уртасына утыруны әхлаксызлыкка санады. Өстәвенә, янына якынайган саен исе укшытачак. Ә ашказаны, кайнап чыккан шулпа сыман, үрле-кырлы сикерүен белә. Уйланып торырга тәкате калмады Хатирәнен, кулындагы чалгысын ташлады да, бот арасын кыса-кыса, таллыкка атлады. Фурман тапкырыннан үткәндә атларын әллә җен куркытты, әллә кигәвен тешләде, бертуктаусыз тыпырчынып, тартылырга тотынды.

— Әй, син, карале, атын дөнья җимерә! — дип кычкырды Хатирә, куак төбендә бушанып утырган жиреннән. Ләкин аланның теге башындагы ире килеп җиткәнче Җирәнкәй кушаяклап күккә ыргып читкә омтылды да, тезгенен өзеп томырылып чалгы өстеннән чабып узды. Тегесе һавага күтәрелеп, ике-өч метр ераклыкка барып төште.

— Син дә инде, бала-чага кебек, чалгынны аяк астына ташлагансың. Бер-бер жире киселмәгән булса ярар иде дә бит. — Хәйри кереп күздән югалган таллар ягына карап-карап торды да, «Артыннан бармый булмас», — дип, тезгеннең өзелеп калган очын чишәргә кереште.

Хәйри дөрес чамалаган, беркайда тукталмый туп-туры өенә сыпырткан хайван юл буена канын агызып барган булып чыкты. Хәйри кайтып житеп, капка төбендә көтеп торган Җирәнкәен лапас кардасына кертте дә, урам аша гына яшәгән ветврач артыннан китте. Шөкер, ул өйдә булып чыкты. Кулына һәрвакыт тулы әзерлектәге чемоданчыгын тотып, йөгереп-атлап кереп тә житте. Арткы уң аягының киселгән бәкәлен карап, юып чистартты, порошок сибеп бинт белән кат-кат урап бәйләде дә: «Аягына басуы икеле, сеңере өзелгән», — дип, бөтенләй өметсез диагноз куйды. Көзгә кадәр абзарда асрап, бер дә булмаса ашатып суярга ниятләделәр. Җәяү барып, шул елга буенда печән чабучы көтүче белән сөйләшеп, яланда калган арбаны кич аның атына тагып алып кайтырга туры килде. Иртәгәсен сумка белән ашамлыкларын күтәреп җәяү атладылар. Ярый әле кичә чалгыларын тал арасына яшереп калдырганнар иде. Бару ягына йөкләре җинел булды анысы. Аланны чабып бетереп, кич кайтканда исә... телләре салынды.

Өч көннән тырма, сәнәк күтәреп барсалар... печәннәре чүмәләдә утыра.

— Теге көтүче белән сөйләш, иртәгә таң яктысы белән кайтару чарасын күрергә кирәк, — дип кужытты Хатирә.

— Кит, монавы дүрт чүмәлә өчен гаугалашып йөрмибезме әллә? — Хәйри икеләнде. — Ни дисәң дә, безнең җир түгел бит, гаеп үзебездә.

— Андый икәнсен, үзем сөйләшәм.

Шөкер, аты буш булып чыкты егетнең. Хәйри үз фурманын җигәсе иде дә, әлеге дә баягы Хатирәсе аркылы төште. — Ат тугарып-җигеп вакытны заяга үткәрмә, арба — арба инде, тизрәк китүенне чамала, — диде.

Бардылар, ике чүмәлә төяделәр. Гадәттәгечә, Хатирә башта торды. Бастырыклап кысып, кузгалыр чак житкәч: «Дилбегәне бир дә, бар, әйберләрне җыйна, атны үзем алып чыгам», — дип шәплеген күрсәтте.

— Кабаланма, арбасы ышанычлы түгел, тигез урында чайкала, өстәвенә, анавы чокыр ярын кырынга менәсе, мин ас яктан сәнәк белән йөкне күтәрешми булмас ул, — дип үз фикерен житкерде ире.

— Күп теленә салышма, җәһәтрәк таярга кирәк безгә! Мин сәнәкне менә шушылай кадап, йөкнен иң читенә утыргач, шул житмәс дисеңмени?! — Хатирә үзсүзләнеп дилбегәне кулына алу белән атын кузгатты. Хәйри әйберләрен алырга кирегә китте.

Күп тә үтмәде, колагын хатынының ачыргаланып кычкырган тавышы кисеп үтте. Янына йөгереп килсә, йөк чокыр эченә ауган, Хатирә арба астында калган. Бастырыгын чишеп, печәнен читкә ыргытып, хатынын чак тартып алды.

— Нинди зәхмәтле урын булды бу? — Хатирә куллары белән җиргә таянып, сукрана-сукрана аягына басарга итте, ләкин авыртуга түзә алмый чәрелдәп кычкырып кабат җиргә ауды.

Хәйри фурманын утыртты да, йөген төяп тормыйча, хатынын күтәреп салып, туп-туры авыл бүльнисына чапты.

Район хастаханәсендә рентгенга төшереп, умыртка баганасының сынганлыгын ачыкладылар. Ике ай ятып та, аягына басып йөри алмады Хатирә. Ахырда инвалидлык юлларга кушып, өенә кайтардылар.

Төрле яклап мендәрләргә терәп утыртсалар, бер тын утыра алды, ә болай күп вакытын ятып үткәрде. Кулына тотып ашарга да рәте юк иде.

Төп авырлык, әлбәттә инде, Хәйри өстенә төште. Әмма начар киленгә дә өлеш чыкты. Ике сыер саву, идән, кер юуу, өй җыештыру, биемен мунча кертү, өс-башын карау, киемен алыштыру, ашарга пешерү кебек эшләрне ул башкарды.

Болары гына житмәгән, хафа өстенә яфа тудырып, мал дуктырының күзаллавы расланды. Хәйри ярасын көн аралаш юып бәйләп, күпме генә тырышмасын, атлары аягына басмады. Аптырагач-йөдәгәч, иткә симертте. Кар явып, дөньяга чын-чыннан кыш хакимлек итә башлагач, бер якшәмбедә суярга ниятләде. Ләкин күз төбәп торган күршесе шул ук эш буенча район үзәгендә яшәгән улларына киткән икән. Хәйри урам бастырып эзләсә дә, башка кеше таба алмады. Улы белән сөйләшеп килеште дә, өмәне иртәгәгә кичектерергә уйлады. Әмма Хатирәсе бу яңалыкны ишетү белән каршы төште.

— Үзеңә нәрсә булган, кулыңа пычак тота белмисеңмени, тот та үзең чал, — дип җикерде.

— Аны бит әле тәүдә егытырга, аннан ныклап аякларын бәйләргә кирәк. Яшь ат бит ул, юклы-барлы башмак түгел, — дип үз сүзен сүз итәргә тырышты Хәйри.

— Тагын нәрсә уйлап чыгарасың, хәчтерүш! — Хатирә күзен акайтып,

тәнен аркылы тишәрлек усаллык белән иренә карады. Хәйригә буйсынудан башка чара калмады. Гадәттә дүрт-биш кеше башкарган эшкә өчәүләп тотындылар. Ал аякларын тышаулагандай бәйләп, арканның очын арткы аягының бәкәле аша чалып алып, корсак астыннан гәүдәсе аркылы сыртына ураттылар да, икәүләп тартып егып та салдылар. Өлкән яшьтәге тәҗрибәле Хәйригә аякларын бәйләүне йөкләделәр. Янбашына тезләрен терәп, гәүдәсе аша сузылган бауны тарткан улы арткы уң аягын алгы аякларына якынайту белән Хәйри өчесен бергә уратып бәйләде дә, бавының очы белән дүртенчесенә үрелде. Шулчак атлары җан ачуы белән аягын селкеп җибәрде һәм Хәйринең башына кабызды.

Хәйри үлмәсә дә, баш миенә кан савып, сукыраю, телсез калу өстенә, җинел генә эшләрне үтәүдән дә мәхрүм ителде.

Шулай итеп, гариплекнең ни икәнен башларына да китермәгән ир белән хатын йөгерә-атлап йөргән җирләреннән эш килмәгән килеңнәре кулына калдылар.

# Наилә Гыйззәтуллина

*Мин, Гыйззәтуллина Наилә Кадыйр кызы, 1954 елда Хәлекәй авылында туганмын. Бүгенге көндә район Пенсия фонды идарәсе җитәкчесе булып эшлим. Мәктәптә укыган елларымда ук район гәзитендә шигырьләрем чыгарыла иде. Һөнәрем буенча икътисадчы булсам да, әдәбияттан аерылмадым...*

## Саваплар җыям

**Гөнаһ, савапларым күпме:**
**Санар чак җитеп килә,**
**Ни бәя — җыйган-кылганым?**
**Көннәр җилә дә җилә.**

**Күз-яшь түгеп рәнҗетердәй**
**Хәлләр кылмадым бугай,**
**Алган тәрбиям чигеннән**
**Чыкмый яшәдем болай.**

**Бәлки, туры әйтүемә**
**Рәнҗегәндер кем елап,**
**Кемнең хаклы булганлыгын**
**Ачыклап бирде еллар.**

**Яшьлегем, шәплегем белән**
**Кызурак идем мин.**
**Хәзер сүрелдем, тик рәхмәт**
**Ишетердәйне сөйлим.**

**Авырны әйтмимен авыр**
**Булганда да үземә,**
**Саваплар җыяр чак җитте:**
**Чыктым гомер көзенә.**

## Яңгыр тама тәрәзәмә

**Тәрәзәмә килеп бәрелделәр**
**Яңгыр тамчылары тып та тып,**
**Тәгәрәшеп буй-буй аккан сулар**
**Ирексездән мине елатты.**

Пыяланың тышкы ягын юа
Изге яңгыр, изге саф сулар,
Эчке яктан — тозлы күз яшьләрем.
Күңелемдә меӊ төрле уйлар.

Юк, яңгырга рәнҗеп еламыймын.
Җир сусаган — ява вакытлы,
Буй-буй аккан сулар юллар булып
Агызалар кебек вакытны.

Шул уйлардан эчем пошып китте,
Күңелем торган икән тулып та,
Яңгырдан соң балкып кояш чыгар,
Югалырлар булган болытлар,
Мин дә таштым кушылып яңгырларга,
Таралсын дип моңсу минутлар.

## Сиңа шигырь язам

Шигырь язам дигәч сиңа атап,
Аптырап та калдың бер мәлгә,
«Ни дип язасың, йә, тагы да ныграк
Сөя башладыңмы соң әллә?
Язмыйча әйт, үземә генә», — диеп
Көлдең, язганда мин кичләрен.
Бик беләсең килде күңлемдәге
Ярсып ташкан йөрәк хисләрем.
Җиткерә алсам иде уйларымның
Әйтәлмәгәннәрен тел белән,
Син масаеп, берчә горурланып
Кабат-кабат укырың беләм.
Бәхетлемен шигъри юлларыма
Якты образ тудырганыңа.
Уйда, яннарымда синең булу
Бәхетемне тулыландыра.
Телем белән күңлемдәген, иң-иң
Әйтмәгәнен аңлатыр өчен
Табалмадым тәмле, таңгал сүзләр,
Язар өчен ярату хисен.
Элек әйткәннәрем гади кебек,
Эзлим матуррак, яңасын.
Тик үзеңә генә таман сүзне
Каян гына, каян табыйм соң?!
Үзем уйлыйм: әйдә, кадерлемә
Сүзләр эзләп үтсен бу гомер.
Табалсам да язмыйм: янсын һаман
Йөрәгемдә хисле ут-күмер.

# Зөлфия Гыйзетдинова

*Зөлфия Зиннәт кызы Гыйззетдинова 1961 елны Үч-Әсән авылында укытучы гаиләсендә дөньяга килә. Шигърият дөньясы аны бәләкәй чагыннан ук үзенә тартып, ымсындырып тора. Хәзерге вакытта ул — Эстәрлебаш район гәзите редакциясе хезмәткәре.*

## Ник боектың әле, улым?

**Ник боектың әле, улым?**
**Башкаеңны тоткан кулың.**
**Саргайттымы әллә йөрәгеңне**
**Барыр юлың?**
**Карашларың томаланган, улым,**
**Нигә әле кинәт кенә сулдың?**
**Сискәндереп сизгер күңелеңне**
**Бүлендеме әллә җырың?**
**Ник боектың әле, улым?**
**Җаның тапмый җайлы урын.**
**Тәүге тапкыр кулың тапты**
**Йөрәк турын...**
**Ник боектың әле, улым?**

## Ул мәхәббәт исемле

**Йөрәгеңнән йолкып алдың,**
**Онытырмын дисеңме?**
**Озын-озак юлларыңда**
**Югалтырмын дисеңме?**
**Төшләреңдә мине күреп**
**Эзләмәмен дисеңме?**

**Язмыш юлларына килеп**
**Тезләнмәмен дисеңме?**
**Икебезнең арасында**
**Моңсу шәүлә дисеңме?**
**Ул мин түгел, ул син түгел —**
**Ул мәхәббәт исемле!**
**Онытырмын дисеңме?**

## Иман кайтыр

**Үзем — татар, телем — алтын,**
**Дустым — башкорт, теле — якын.**
**Ничек итеп чит итим соң**
**Үз илемнең урыс халкын?!**
**Гомер буе әби-бабам**
**Кайгы бүлгән мукшы белән.**
**«Сезгә, безгә бер Алла» — дип**
**Йомыш юллап чуаш килгән.**
**Ата-анам йортыннан да**
**Өзелмәгән мосафирлар,**
**Төрле телдә сүз сөйләнгән,**
**Яңгыраган милли җырлар.**

**Нигә әле бүген килеп**
**Тел аерып, ил бүләләр?**
**Шул ил өчен Җәлилләр бит**
**Аяк үрә дә үлгәннәр.**
**Явыз Иван коеп түккән**
**Татар каны тере әле,**
**Тукайны тудырган татар**
**Илен гөлгә төрер әле.**
**Өмет яна күкрәгемдә:**
**Телем матур, телем батыр,**
**Телебезне саклый алсак,**
**Илебезгә иман кайтыр.**
**Иман кайтыр!**

## Гөлсинә Басыйрова

*Басыйрова Гөлсинә Гали кызы – укытучы. Иҗат итә, укучыларында да шигърияткә кызыксыну уята, аларның иҗади сәләтләрен үстерә. «Туган якны өйрәнүчеләр» түгәрәген алып бара.*

### Укытучы хатирәләре

**Чал чәчеңнең бөртекләрен саный-саный,**
**Кул чукларың җыерчыклы йөзләреңне буйлый-буйлый,**
**Яшьлегеңдә үткәннәрне уйлый-уйлый,**
**Бик текемләп, фотосурәт битләреннән**
**Күз нурларың кемне эзли?!...**

**Кулда алсу чәчәк гөлләмәсе..**
**Тирә-ягым укучылар белән тулы**
**Мин уртада – йөзем нурлы..**
**Ә... бу бит минем чыгарылыш сыйныф булды..**

**Монысы менә бик күптәннән мәртәбәле галим инде....**
**Сүз җәүһәрен эзли-эзли үргә менде..**
**Һәм... Беренче партада утырганы Инсаф алда!**
**Летчик хәзер, зәңгәр күкне иңләп оча корыч атта.**

**Кара, кара, һич үзгәрмәс Нурсиләме?!**
**Мәктәптә дә менә шулай нур сибә ул.**
**Нурлар кала, укытучы, изге хезмәт көчеңнән дә**
**Эзләр булып, якты нурлы хатирәдәй,**
**Уйлар кала, буыннарны бәйли алган җепләр кебек...**

# Гаян Арсланов

*Мин, Арсланов Гаян Минәхмәт улы, 1938 елны Тәтер-Арслан авылында дөньяга килгәнмен. Шушында урта мәктәп тәмамлап, Магнитогорскида тау училищесында укыдым, Донбасс шахталарында күмер казыдым. Башкортстан авыл хуҗалыгы институтында белем алып, 1966 елны Эстәрлебаш районының «Правда» колхозына баш зоотехник булып эшкә кайттым, «Башптицепром» трестында өлкән зоотехник, Башкортстан кошчылык фабрикасында һәм «Башнефть»нең авыл хуҗалыгы бүлегендә баш зоотехник булдым.*

## Котлыйм сине, Казан!

**Күңелемдә шигырь туган иде**
**Сине, Казан, тәү кат күргәч тә.**
**Тапшырылмый калды әлегәчә**
**Китми калды хатка төргәч тә.**

**Вакыт микән җитенкерәмәде,**
**Очрашу көттемме тагы да?**
**Гашыйкларча исәрләнеп, күңел**
**Һаман булса сине сагына.**

**Кабан күлең төшләремә керә,**
**Кырлай якларына укталам.**
**Тарихыңны укып, Сөембикәң**
**Язмышына килеп тукталам.**

**Музеена керсәм, Сәйдәшеңнең**
**Үзен күргән төсле буламын.**
**Кулымдагы тере чәчәкләрне**
**Тукай каберенә куямын.**

**Әхмәт Ерикәй, Җәүдәт Фәйзи белән**
**Утырдым мин берчак табында.**
**Күпме мәгълүмат бирде алар**
**Татар язмышлары хакында.**

**Державинны татар диде алар,**
**Суворов та безнең милләттән.**
**«Өлкән туган» ник аяусыз безне**
**Чукындырган икән, нилектән?**

**Һәр гасырда мәшһүрләрең булган...**
**Ульяновны Ленин иткәнсең.**
**Җетедән дә җете талантларны**
**Киң дөньяга күпме сипкәнсең.**

**Шигыремне кемнәр укыр икән,**
**Яздым аны Тукай телендә.**
**Гореф-гадәтләрем нәкъ сезнеңчә,**
**Яшәсәм дә башкорт илендә.**

**Өметләрем чынга ашар әле,**
**Гомер булса, булса исәнлек.**

Милләт намусына тап төшермәм,
Ихтыяр көче миндә җитәрлек.

Котлыйм сине, данлы Казанымны,
Меңьеллыгың белән, мең кабат
Тугры калып татар язмышына,
Яшь бөркетләр тудыр, куй канат!

## Мәңге санлый белерләр

*Муса Җәлил рухына*

Мостафадан безгә кадәр
Алтмыш чакрым нибары.
Борыннардан кешеләрнең
Уртак булган моң-зары.

Йомышка да, кунакка да
Йөргәннәр сездән — безгә.
Кияү дә, килен дә төшкән,
Килешеп уртак сүзгә.

Нәкъ илле ел үтеп киткән
Сездә тәү булганыма.
Алганга бер чибәр кызны
Кодалап туганыма.

Юллар төшеп, килеп чыктым
Тагын сезнең якларга.
Үз күзләремә ышанмыйм —
Моны ничек аңларга?

Юк теге чак күргән авыл,
Арынганнар чүп-чардан.
Якташларың элеккечә
Газап чикми моң-зардан.

Үткәнендә тизәк сугып
Гомер иткән бәндәләр
Яңа тормышта яшиләр,
Шәһәргә тиң хәлдәләр.

Синең дә нигез ташыңны
Сипләп, музей ачканнар.
Йорт каршыңдагы сыныңа
Алтын төсен япканнар.

Кайтып күрә алсаң икән
Бүген авылың әгәр.
Аптыраштa калыр идең,
Кая кылдым дип сәфәр.

Шикләнмимен, йөз яшьләрең
Тагын, тагын килерләр.
Милләттәшләрең рухыңны
Санга суга белерләр.

## Башкортстан

Башкортстан, минем Башкортстан —
Күп милләтле, шаян җырлы ул.
Бөркет оя кора тауларына —
Диңгезгә тиң иген кырлы ул.

Куенында ниләр ятмый аның,
Байлыгының белмим исәбен.
Калачларын күкрәгемә терәп,
Дусны сыйлар өчен кисәмен.

Балларының тәме тел очында,
Җанга шифа кымызы — уртласаң.
Сый-хөрмәтле булыр авызларың,
Һәр милләтен аның хупласаң.

Әй, күңелем, шаян күбәләктәй
Талпынасың — дәртле чакларың.
Башкортстан, гүзәл Башкортстан,
Сагындыра Туган якларым.

# Мәҗит Кәримов

*1933 елны Турмай авылында туганмын. Эстәрлебаш татар урта мәктәбен, соңыннан Хәрби диңгез флоты өчен авиация техниклары әзерли торган училищены тәмамладым. Хезмәтемне Төньяк флотта башладым. Армия сафында башкарган соңгы вазифам — ПВО системасына караган үзәк базаларның берсендә бүлек башлыгы.*

## ГАРИП МӘХМҮТ

ХИКӘЯ

Ниһаять, Киев!

Без, Хәрби дингез авиациясе техник училищесына китеп баручы утыздан артык курсантлыкка кандидат яшь егет, әлеге тукталышны зур түземсезлек белән көтеп алдык. Соң, ни генә димә, Киев Киев инде ул — рус шәһәрләренең анасы — шәһәрдә йөреп, тарих дәресләреннән, әдәби әсәрләрдән билгеле җирләрдә булып, аларны үз күзебез белән күреп, кулларыбыз белән капшап карарга иде исәбебез, әмма алай булып чыкмады: без бара торган училище урнашкан Новгород — Волынский шәһәре аша китә торган поезд сәгать ярымнан кузгала икән, һәм юл буе корган планнар үзеннән-үзе юкка чыкты. Берни дә эшли алмыйсың: билетларны компостировать иттек тә...

Әйе, азрак вакыт бар иде әле, һәм вокзал тирәсен булса да караштырып керергә булдык.

Киевта безне аптыраушта калдырганы вокзалда аяксыз да кулсыз гарип-горабаның күплеге булды. Чынлап та, бихисап иде алар — барысы да гамәлдә урта яшьләрдәге ир-ат, әмма юк-юк та араларында хатын-кызлар да күренгәли — поезд көтү залының бер почмагын тоташы белән алар басып алган. Мескеннәрне озата баручылар да шунда ук. Күренеп тора, соңгылары әлеге халыкнын һәрвакыт үзләренең күз алдында булуын тели, алай гынамы соң, үз теләкләренең һичшиксез үтәлүен зур уяулык һәм зирәклек белән күзәтә.

Бәдрәф тә әлеге халык белән тулы иде, әйе, күпчелек инвалидлар. Каршымда гына шуларның берсе, утыз белән кырык арасындагы әзмәвердәй иркәй миңа арты белән баскан да, кече йомышын үтәп маташа, ә янында...

Әйе, аптырап киттем — хатын-кыз. Башта анламадым әле, теге лилипут хатыннарның берсе микән дип торам — буйга кып-кыска, аннан гына күзләрем дүрт булды: әлеге апа аяксыз иде — тезләреннән чак кына астанрак киселгән ике аягына да ниндидер калын күн капчыкка охшаш әйбер кигән, житмәсә уң күзе кара чүпрәк белән капланган.

— Иплэп, Мәхмүт, иплэп, китер, каптырам, — диде хатынкай безнең күрше авыл мишәрләренә генә хас йомшак тавыш белән. Әйе, саф татарча эндәште ул, әмма аңа һич тә аптырамадым — кайда гына юк ул безнең халык, татар белән дөнья тулы. Шул мәлне иркәй эшен бетереп безгә табан

борылды һәм мин коелдым да төштем, күзләрем янә дүрт булды: абзыйның ике кулы да терсәктән өстә киселгән, ул кулсыз иде. Әйе, ике кулы да юк... «Мәхмүт, — диде бит әлеге хатын, — Мәхмүт...»

Шунда ук яшьтәшем Вилнең атасы, әле булса авылдашларым гел алама яктан искә алган Мәхмүт абзый искә килеп төште. Ул да безнең әтиләр кебек сугыштан кайтмады, хәбәрсез югалды. Малайлары нәкъ безнең сыман эт типкесендә үсте, әниләре исә, Мәхмүт абзыйның хатыны була инде, сугыш беткәч икесен дә балалар йортына тапшырды да, Эстәрлетамак иркәенә кияүгә чыкты. Кече малае кайдадыр, анысының язмышын белмим. Вилне исә җидене бетергәч тә ФЗОга җибәрделәр. Балалар йортындагыларның бик азына гына тәти иде бит ул мәлне белем алуны дәвам итү бәхете, аларның сәләтлеләренә генә сигезгә барырга рөхсәт иттеләр. Ә Вил... Беләм мин аны, дүрт классны бергә бетердек — укуга да, эшкә дә ялкау иде. Ут күршеләре Нәҗми бабай аның турында: «Тач атасы, суйган да каплаган, шулкадәр охшамаса...» — дип кенә җибәрә иде.

Әйе, бу абзый, таныдым мин аны, чынлап та — Мәхмүт Губкин иде. Губкин дип ни. Анысы кушаматы була инде. Абзыкайның чын фамилиясе Латыйпов иде.

Безнең авыл артык зур түгел: көнчыгыштан көнбатышка табан беткәнче чакрым ярымга сузылган бердәнбер, киң генә урам буйлап ике яклап тезелгән, күбесенең башы салам белән ябылган эреле-ваклы өйләр. Йортлар иркен, алар аерым хуҗалыкның барлык хаҗәтләрен тулысынча канәгатьләндерерлек итеп төзелгән — биредә мал абзары, келәт, бәрәңге базы гына түгел, арба-чана, «карандас»-«фурман», сука-сабан һәм башка авыл хуҗалыгы инвентарен, тормыш кирәк-яракларының барысын да куеп була — урын җитәрлек. Бик күпләренең түрендә дүрт-биш баштан да ким булмаган кышлау умарталары утырган җиләк-җимеш бакчалары да бар. Әйе, салам абзар-кура, өй кыекларын ябу өчен иң кулай, иң арзан, киң кулланыла торган материал, әмма авылда сирәк кенә калай түбәле өйләр дә очрый. Ихаталарның күпчелеге читәннән, таш коймалар да бар, тик бөтенләй ихатасыз утырган өйләр дә юк түгел. Алай гынамы соң... Мәсәлән, ире тәүге герман сугышыннан кайта алмый, кайдадыр ятып калган Гайнижиһан әбиләрнең бәдрәфләре дә юк: өйдән ерак түгел генә утырган, ата-бабадан калган таш чиннек һәм вәссәлам! Ин кызганычы шул: андыйлар бер ул гына түгел.

Ә авылыбыз матур, барыбер матур, каршыдагы Тимер тау башыннан караганда уч төбендәге кебек күренеп тора, ике яклап урам буйлап үскән агачлар арасында утыра ул. Ә Латыйп карт тыкрыгындагы карт карама үзенә бертөрле ямь биреп тора. Юан ул, ифрат юан. Без, түбән оч малайлары, үзебез үлчәп караганыбыз бар: аны кочаклар өчен биш малай кирәк. Бераз бушрак була, әмма күп түгел. Ә дүртебезнең генә колачы җитми.

Мәхмүт абзыйның дөньясын һич кенә дә түм-түгәрәк, бөтен яктан да килешкәннәр рәтенә куярлык түгел иде: читәннән үргән ихата, каралты-кура — барысы да салам башлы. Ә урам капкасы бөтенләй юк — шулай калган минем хәтердә Мәхмүт абзый Губкинның йорты. Анысы дөрес, авылда һәммәсе дә син теләгәнчә генә бармый, беренчедән, мохтаҗлык зур — әле тегесе кирәк, әле монысы җитешми, берсен рәтләсәң, икенчесе кыйшая башлый. Йорт хуҗасы нәрсәнедер бастырып куярга өлгерми, якында гына нидер авып төшә. Аннан соң тагын шунысы да бар бит әле — колхоз. Хәзер авылда беркем дә үзенә үзе хуҗа түгел, материаль ягы да чамалы...

Тирә-якта урман күп ул күплеккә, анда йөзәр ел утырган агачлар бихисап, өчәр гасыр яшәгән имәннәр очрый. Әмма... Хөкүмәтнеке бит ул, каравылчылар — яман усаллар...

Мин белеп бетермим инде, өлкәннәр сөйли: Латыйповлар нәселләре белән иренчәк, үшән, гомумән, эшкә йомшак булганнар. Эшләргә көрсенеп, ашарга юксынып көн иткәннәр, җирләрен, хәзергечә әйтсәк, күршеләренә арендага биргәннәр дә, үзләре урак күтәреп, «баяр» игенен урырга йөргәннәр. Әмма яна властьны бик хуплап, кушкуллап, яратып каршы алган алар. Егерменче елны авыл буйлап өй борынча тентү ясап, халыкның кышкылыкка дигән игенен генә түгел, чәчүлеккә дигәнен дә кырып-себереп талап йөргәннәр. Питердән килгән бәндәләрнең беренче ярдәмчесе Мәхмүт Губкинның атасы Хәҗекәй Латыйпов булган. Халык, халык сөйли, ә ул бит инде булмаганны сөйләми. Чынлап та шул чама булган — егерме беренче елгы, авыл халкының яртысын теге дөньяга озаткан ачлыкның нигез ташын салучыларның берсе ул булган.

«Алма агачыннан ерак төшми», — дигән борынгылар. Тормыш исбатлаган хак сүз — Губкин да атасыннан ерак китмәгән. Мин бик белеп бетермим инде, картәнием мәрхүмә сөйли торган иде. Имеш, авыл байларын пыран-заран китереп, талап йөргәннәр арасында күптән үсеп буй җиткергән, гаилә корган кече Латыйпов та буталып маташкан. Бүген колхоз «кәнсәләре» урнашкан өйнең хуҗасы Рәхим Гәрәйне сөргенгә сөргәннәр. Ә гаиләсен, бер әйбер дә бирмичә, Иглин ягына, «Красный ключ» дигән төбәккә озатканнар, мөлкәтен исә шул тирәдә чуалган җыен әтрәк-әләм, бушбугаз үзара бүлешкән. Губкинга да тигән, аны да онытмаганнар, сарык түшкәләре генә дә биш-алты данә эләккән аңа.

Безнең әти колхозга бик соң, иң азаккыларның берсе булып керде. Үз дөньясы белән яшисе килде аның. Ел да чирәм ачты, тары чәчте, әмма барыбер ул дигәнчә барып чыкмады — быел сөргән җирен икенче елга бирмиләр иде... Ә «налог» дигән әйбернең чуты юк иде.

Бүгенгедәй хәтеремдә... Белмим, әти җыйган уңышын хөкүмәткә тапшырып бетергәндерме, күрше-күлән колхозчыларның берсенә кертеп яшергәнме, әйтә алмыйм, әмма араларында Губкин белән аның сыңары, югары оч Тимербай да булган, авылның иң алдынгы, иң актив кешеләреннән торган комиссия килгәндә безнең буралар буш булып, анда җилләр исеп тора иде. Иң нык кычкырганы Тимербай, иң әшәке сүгенгәне Губкин булды. Өнәми иде авыл халкы, Тимербайны да, Губкинны да яратмады, хәтта бала-чагаларны да әллә нинди әкияттәге җен-пәри белән түгел, әлеге ике мәлгунь белән куркыталар иде. Киреләнеп, көйсезләнеп маташкан кечкенәләргә: «Әнә Тимербай килә», — дисәләр, шым булалар иде бахыркайлар, ә инде ул чакны «Губкин» сүзен ишетсәләр, бөтенләй сәке астына кереп качарга әзерләр иде.

Алай да Губкинның бер килешкән ягы бар иде: аның кебек оста, моңлы һәм дәртле итеп гармун уйнаган кеше авылда гына түгел, бөтен районда да булмагандыр. Чынлап менә: җәй көне кич белән капка төбенә чыгып утыра да, тальянкасын тартып җибәрә, малай. Юк, без, үсеп килгән бала-чага гына түгел, мөгаен, галәм үзе, әйләнә-тирә, ялан-болын, хәтта бакчадагы: «Аллага шөкер, көз үтте, эссе бетте, тын алулары җиңеләйде» дип шатланган шомырт-чияләр, урамда үскән сылу каен кызлары, акация агачларына кадәр дөньяларын онытып аны тыңлаганнардыр, ә инде дәртләре эчләренә сыймый тышка бәреп чыккан яшь-җилкенчәк турында сөйләп торасы да юк — Мәхмүт абыйларының гармун күтәреп урамга чыгуы була, аны әлеге егетләр, яңа чабата кигән чибәр кызлар уратып та ала.

Әле генә үзәкләргә үтеп керер, бөтен күрше-күләннең ушын алырдай «Җирән кашка», «Таштугай» көйләрен сыздырган Губкин, билгеле, яшьләр теләгән кире кага алмый, бию көенә күчә: «Бас, кызым, Әпипә,

син басмасаң, мин басам...» Анын тирәсендә әлеге үзләренчә-барынча киенеп-ясанып алган, матурлыклары белән хур кызларыннан калышмаган кызлар, типсә тимер өзәрлек, ялкын кебек житез, учына алып кысса, комнан су чыгара торган егетләр бөтерелә башлый. Аннан соңмы? Аннан сон — сугыш... Хәзер ул егетләрнен күбесе юк инде — кайтса, шул уннан бере генә әйләнеп кайта алгандыр. Аларнын да күбесе яралы, кемдер чатан калса, кемнендер кулы чулак. Алар гынамы сон? Кызлар... Теге кич саен дөньяга сыймый тыпыр-тыпыр биегән хур кызларын да озаттылар фронтка. Юк, барсын да түгел, кайберләрен генә алдылар. Әмма ул мескеннәрнең дә байтагы кайта алмады — кемнәрдер хәбәрсез югалса, кемнәрдер кичләрен уенга чыга торган Энекәй тугайларыннан еракта ятып калды.

Әйе, сугыш беткәч, Мәхмүт Латыйпов хакында «хәбәрсез югалды» дигән язу килде. Юк икән, югалмаган Губкин абзый, менә, әллә кем түгел, үзе минем алда басып тора, чынлап та ул, яшьтәшем Вилнең әтисе.

Мин, билгеле, аңа таба атладым һәм исәнләшергә кул сузып: «Исәнме, Губкин абзый», — дип ычкындыра яздым, чак-чак тыелып калдым.

Аның белән элек тә шул чама исәнләшкәнем бар иде инде. Мәңге онытасым юк: искә төшкән саен колагым авырта башлый.

Мәхмүт абзыйның үзе булмаганда исеме белән атаучы юк иде: Губкин да Губкин. Билләһи, шулай! Без балаларны олыларны ихтирам итәргә, алар белән беренче булып исәнләшергә өйрәтәләр иде ул чакта. Балачак балачак бит инде... Юк, укырга төшмәгән идем әле ул мәлне — урамда каршыга килгән күрше абый белән башлап исәнләштем. Авыл жирендә «сез-без» юк инде, барсы да бер-берсенә «син»дип эндәшә, мин дә шулай: «Исәнме, Губкин абзый», — дидем, ә абзый исә мине эләктереп алды да, колагымны борырга тотынды. Урамда булды бу хәл — ул боргалый, мин кычкырам, колак бит ул нык авырта, түзәр әмәл юк, ә күршебез сүгенүен белә: «Күрсәтермен мин сиңа Губкинны», — дип жикеренә, житмәсә, әти белән әнигә тел тидерә: «Бала үстергәннәр, тәрбия бирә белмәгәннәр», — ди. Әл дә каршы як Мәрфуга әби килеп чыкты, аралап алды. Куркып тормады тегеннән: «Бигрәк оятсыз икәнсең, Мәхмүт улым, — диде, — бала белән бала булмасаң».

Әйе, бу юлы аның белән кул бирешеп күрешеп булмый...

— Бәтәч, Мәхмүт абзый! Сез бит бу, исәнмесез?

Татарчалап инде, татарчалап. Таныды мине, каршыда кем басып торганына тиз төшенде.

— Кара әле, улым, син Әнвәр малае Зөфәр бит! Әй... Ходайның рәхмәте! Вәт, әй, әзмәвердәй егет булган.

Чынлап та шулай ди, билләһи, шулай — Ходайны исенә төшерә, кайчандыр утызынчы еллар уртасында чатан Нәкый белән парлашып авылыбыз мәчетенең манарасын кисеп йөргән бәндә димәссең үзен.

Абзыкай исә дәвам итә, очрашу шатлыгы йөзенә чыккан, үзе сөйли, һаман тәмле телләнә:

— Тфү, тфү, күз тимәсен, Аллаһы Тәгалә исәнлектән аермасын үзеңне, сугыш гарасатын күрергә язмасын.

Киттек инде шуннан сөйләшеп, теге патшалар жәяү йөри торган жирдән чыгып поезд көтү залының бер почмагына, башка гарип-горабалардан читкәрәк барып утырдык. Татарча сөйләшәбез, күбрәк Губкин сөйли, кайчак аңа Фәүзия апа кушыла.

— Минем хәлләр шулайга әйләнеп китте, улым. Менә бит, хәтта сине кочаклап, чәчеңнән, аркаңнан сыйпап сөя дә алмыйм. Кырык икенче елдан

бирле шулай җәфаланам. Фәүзия апаңа рәхмәт, — Мәхмүт абзый күзе белән безнең янда утырган әлеге аяксыз хатынга күрсәтте, — ул бу дөньяда минем бердәнбер таянычым. Таянычым гына түгел, куанычым. Икебез бер көндә, бер җирдә, бер сәгатьтә шундый хәлдә калдык...

Шулай икән шул, Фәүзия апа санитарка булган, Мәхмүт абзыйның яраларын бәйләгән дә, икенче кеше янына ашыккан, аннан өченчегә... Әмма шул акланда үзе дә аяксыз калган.

— Ярый, Зөфәр улым, без — без инде ул, безгә хәзер беркем дә, берничек тә ярдәм итә алмый, сөйлә, авылданиләр бар? Сугыштан кемнәр исән-сау әйләнеп кайтты? Әле ни хәлләр булып ята? — Билгеле, тәүге сорау балалары, хатыны турында булды. Сөйләдем барын да, түкми-чәчми житкердем абзыйга.

— Исән-имин кайтучылар өлкән яшьтәгеләр, әлеге шул тылда, обоз-кухня тирәсендә чуалганнар гына. Алар барсы да баеп кайтты сугыштан — ат арбасына чак-чак сыя иде аларның ганимәт-яу маллары. Ә колхоз рәисе Фәттаховның исә кып-кызыл төскә буялган ике тәгәрмәчле матае да бар иде — ялтырап, күз явын алып тора, андый нәрсә ул мәлне бөтен районда юк иде. Олы бер штабта ашнакчы булган Фәттахов зур командирларның тамагын туйдырган. Ә калганнар? Кайсы аяксыз, кайсы кулсыз дигәндәй, җыен гарип-гораба — инвалидлар, ә герман сугышы беткәнче көнчыгышта утырган якташлар исән-сау кайтты, японга каршы сугыш корбаннары арасында безнең авылдашлар булмады — анысы хак, кем әйтмешли, Ходай саклаган. Авыл хәлләреме? Анысы билгеле инде: авылның дөньясы — кәкре-бөкре мөрҗәсе, халыкның күпчелеге ач-ялангач яшәде...

Мин сөйләдем, Губкин абзый йотлыгып тыңлады. Ә нәрсә сөйләргә? Шул инде — әлеге дә баягы карт шайтанның таягы, кара сыер аягы — начар, бик начар иде авыл тормышы, начар яшәде гади колхозчылар, ә аталары, гәзитләрдә язылганча, канлы сугышларда Туган ил өчен башын салган яугирләрнең гаиләләренә, аларның ярты ятим сабыйларына икеләтә авыр булды.

Губкин абзый олы малаена Вил исемен Ленин бабай хөрмәтенә кушкан — Владимир Ильич Ленин. Әмма аның Виле дә нәкъ безнең кебек нужаны күп ашады, әнисе аны ташлап кияүгә киткәч, безгә караганда да авыррак булгандыр әле ана...

Мәхмүт абзыйга мин дә сораулар бирдем. Шул инде — гадәти сораулар: кайда, кайчан, ничек? Яшермәде, мескен, барсын да ачыктан-ачык сөйләде: пленда булган ул, әсирлеккә яралы көенә эләккән. Әллә бәхетләренә, әллә бәхетсезлекләренә каршы румыннар кул астына эләккәннәр, шуңа күрә ул да, Фәүзия апа да исән калганнар, югыйсә германнар җирдә аунап яткан, ярдәмгә мохтаҗ сугышчылар белән бик тәкәллефләнеп тормаганнар — тотканнар да сүзне автомат иптәшкә бирә торган булганнар.

Соңыннан, үзебезнекеләр әсирлектән азат иткәч, Киевтан утыз-кырык чакрым гына бер аулак җирдә урнашкан гарипләр йортында очрашкан бу икәү.

— Башта чыдарлык иде, — диде алар икесе бер авыздан. — Тирә-якта урман, эргәдә генә инеш агып ята. Тимер юл да ерак түгел, якында гына станция. Кулыннан килгәннәр анда еш булды, ә инде электричка вагоннарына менә алган сукыр-букыр, аксак-туксаклар исә үзләренең яшәү урыннарыннан еракка ук китеп, күрә алганы дөнья карап, күрә алмаган дөм сукырлар — үзләрен күрсәтеп, теләнеп-хәер сорашып йөрделәр. Булды, булды, андыйлар да күп иде. Ләкин безнең халыкның

алай йөрүе, әдәпсез кылануы кемгәдер ошамады. Сон, шулкадәр инвалидның совет шәһәрләре урамнарын пычратып йөрүе кемгә ошасын. Өстәгеләр әллә кайда түгел, Мәскәүне, халыкка күренеп торган совет чынбарлыгын әлеге мәхлуклардан тазартырга булганнар. Безнең халык арасында шундыйрак сүз йөри.

— Шулай, туганкаем, — монысы инде Фәүзия апа, — хәзер безне яңа җиргә, имеш, бөтен яктан да килешкән, яшәү өчен барлык шартлар да булдырылган приютка күчерәләр. Тик шунысы — ул, безнең ишеләр өчен махсус төзелгән оҗмах, бер күл эчендә утрауда дип сөйлиләр.

Аның сүзен янә Мәхмүт абзый куәтләде.

— Чынлап та шулай, Зөфәр улым, бездән котылырга тырышалар — ату аларны. Ату, ничу кайда эләксә шунда дөнья пычратып йөрергә! Шулай, майт якасын, бәхетле совет халкының күнеленә тап төшереп буталмасыннар аяк астында. Шундыйрак безнең эшләр, тора-бара нишләр, безне куып йөрткән ачы язмыш кайдан һәм кайчан килеп тагын тешләр. Өтөрмә дип, алай ук булмас та, бәлки, әмма анда безне көткән нәрсә һич оҗмах түгел. Ярый, хәерлегә булсын инде, хәерлегә, тәкъдирдә хикмәт, тәкъдирдә, ләүхелмәхфүздә шулай язылгандыр...

Шул арада ыспай гына киенгән бер абый микрофон аша команда бирде:

— На посадку!

Әлеге Аллаһ каргаган, язмыш тарафыннан җәберләнгәннәр командасы бердәм хәрәкәткә килде, барсы да перронга чыгу ягына юл тотты. Үзләре йөри алмаганнар — коляскада, сукырларны күзлеләр житәкләгән.

Мәхмүт абзый да хушлашырга ашыкты:

— Ярый, улым, исән бул. Берүк безнең көнгә калырга язмасын. Аллаһыдан шуны сора, үзеннең генә түгел, балаларыңның балаларына безнең көнгә төшәргә язмасын. Үтенечем шул: авылга кайтып: «Мәхмүт мөртәтне күрдем, фәлән-төгән», — дип сөйләнеп йөрмә. Мин бөтен кардәш-ыру, агай-эне өчен генә түгел, мине белгән таныш-белешләр өчен дә хәбәрсез югалган кеше. Шулай да, кара әле, Зөфәр...

Ул, сүзен әйтеп бетермәстән, әлеге аяксыз хатынга борылды: «Фәүзия, нит әле, минем орденны сүтеп алып, бу егеткә бир әле, төсем итеп саклар. Чур, түлке, ни, Зөфәр, барсы да сөйләшкәнчә — мин биргәнне беркемгә дә әйтмисен, бу дөнья өчен мин юк, хәбәрсез югалган бер бәндә».

— Кит әле, Мәхмүт абзый! Миңа нигә ул кеше ордены? Үзең тагып йөре, «Кызыл Йолдыз»ны бит күзең матур, буең зифа булган өчен генә бирмиләр...

— Ал, ал, Зөфәр туган, миңа аның бер кирәге дә юк, ал, әйттем бит инде, истәлегем булыр...

# Лилия Сабитова

*1964 елны Хәлекәй авылында туганмын. Башкорт дәүләт университетының филология факультетында татар теле һәм әдәбияты укытучысы белгечлеге алдым. 1990 елдан Эстәрлебаш башлангыч мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты дәресләрен укытам.*

## Назламадың мине, быелгы яз...

**Ашыгамын...
Әллә күрмәдем дә
Агачларның яфрак ярганын.
Бу язда мин башка язлар кебек
Бозларны да озата алмадым.**

**Бу язда мин һич тә исермәдем
Яшел яфракларның исенә.
Сокланмадым матур чәчәкләргә,
Сискәнмәдем сөю хисеннән.**

**Күрмәгәндәй булдым каеннарны.
Нигә күңелем шулай ваемсыз?
Әллә үзем, әллә тормыш шундый:
Көннәр үтә, ләкин — җыр-моңсыз.**

**Нигә тетрәтмәдең йөрәгемне,
Күңелемә нигә кермәдең?
Гүзәл язым, ә бит килгәнсең дә,
Нигә инде мине күрмәдең?**

**Күзем текәп бары киләчәккә,
Имеш, килер бәхтем ягына,
Ашыкканмын, үткәнмен мин шулай
Күз дә салмый бәхет язына.**

* * *

**Сиңа һаман барып җитәлгән юк
(Поездларны күпме озаттым).
Сөюемне йөрәгемә җыеп,
«Кайтыр!» диеп күңел юаттым.**

**Мәхәббәтнең олы тылсымын мин
Ераклыклар аша татыдым.
Ерактасың, әмма йөрәктәсең:
Син — кадерлем, син — иң якыным.**

# Рәис Байгилдин

*Мин Елембәт авылында дөньяга килгәнмен. 1965 елда урта мәктәп тәмамладым. БДУнын филология факультетында укып йөргәндә шигырь язу белән мавыгып киттем. Әлеге көндә Эстәрлебашта гомер итәм.*

## Татар кызына

**Сәхнәләрдә күрсәм татар кызын,**
**Биегәнен милли киемдә,**
**Йөгреп менеп, кызның пары булып,**
**Әй, биисем килә минем дә.**

**Нинди гүзәлсең син, татар кызы,**
**Кисәң әгәр милли киемең.**
**Тыйнаклык һәм сөйкемлелек синдә,**
**Аккош йөзүләре — йөрүең.**

**Нинди генә егет гашыйк булмас,**
**Син йөрергә чыксаң, аппагым,**
**Озын итеп үреп толымнарың,**
**Башкаеңа киеп калфагың.**

**И, замана! Сәхнәләрдә генә**
**Калды бары милли матурлык.**
**Милли кием киеп йөрер өчен**
**Кирәк инде хәзер батырлык.**

**Хәзер инде кызлар гүзәллекне,**
**Күрсәтәләр шәрә ботларда.**
**Мини итәк, ачык түшле кофта,**
**Чалбар кисә — ертык артларда.**

**Аңласаңчы, сылу татар кызы,**
**Тиз биздерә мондый «матурлык».**
**Милли кием ки дә, чык урамга,**
**Күрсәт, кызым, күрсәт батырлык!**

# Гаяз Үләев

*Гаяз Фәрвәҗ улы Үләев 1940 елны Эстәрлетамак педагогия институтын тәмамлый. Эстәрлебаш районы, Эстәрлетамак шәһәре мәктәпләрендә төрле педагогик вазифалар башкара.*

## Язмыш микән иркәләде...

**Язмыш микән иркәләде —
Шактый сәер яшәлде:
Акыл яшьләй иртәләде;
Картайгач, дәрт яшәрде...**

**Тел төбендә мәңге саклыйм
Балтырган ашы тәмен.
Тик нигәдер тансыкламыйм —
Чымырдап китә тәнем!**

**Дубленка киеп утырган —
«Жигули» йөртә бабай.
Балачактан карап тора...
Киндер ыштанлы малай...**

**Кечкенәмен — төпчек кенә,
(Көчкә җирдән күренәм!)
Өметем зур киләчәккә —
Бөеклеккә үреләм!**

**Кайчак үзем баласыман —
Бераз масаю тоям:
Хатын меңнәр арасыннан
Мине ич сайлап куйган!**

**Ышанам, ул башкаларны
Әле дә теләмәстер.
«Ошамый», — дип, балалар да
«Яшь әти» эзләмәстер!**

**Мин — нәкъ ямьсез тышлы китап,
Башта күз дә салмыйлар.
Ике битем укысалар,
Күзне ала алмыйлар.**

**Йончысам да, картаймадым,
Тик алга барам әле.
Заман начар дип зарланмыйм,
Яңа юл ярам әле!**

**Шигъри<br>ят юлында йөрим —
Шигырь моңында эрим...**

## Ай кызы

**Ходай Тәгалә татарын
Бигрәк тә яраткан бит!
Бар дөньяга ямь булсын дип
Җир буйлап тараткан бит!**

**Татар җирдә генә түгел,
Җиһанда да бар икән!
Айның көянтә-чиләкле
Кызы да... татар икән!**

## Арыдым... арганнардан

**Арыдым... арганнардан,
Тумый картайганнардан.
Ир уртасына җитеп тә,
Бәлигъ булмаганнардан.**

**Арыдым... зар-елаулардан,
Булдыксыз булулардан.
Атай тапканны таратып,
Ыштансыз калулардан.**

**Арыдым шапрынулардан,
Данга табынулардан.
Алга карап, артка барып
Ялган куанулардан.**

**Оялам... оялмаулардан,
Уяна алмаулардан.
Яныр-янмас пыскып ятып,
Кабына алмаулардан.**

**Арыйм... кешегә баз казып
Арый алмаганнардан.
Күрше уңышына көеп,
Күмергә калганнардан!..**

## Әйдүк, көткәйнек

Әйдүк, әйдүк! — дип татарча
Эти кодага дәшә.
«Йәй үк көткәйнек!» — тип, әсәй,
Кунак менән һөйләшә.

Татар эти, башкорт әни
«Алып кайтканнар» мине.
Кем булырга тейеш һуң мин —
Аңлаталһындар ине!

Туганмым башкорт иләндә,
Мин — башкорт татарымын.
Өйләндем мишәр кызына —
Кем булыр балаларым!?

«Башлы татар!» — дип шаярта
Беренче улым — Касыйм.
«Я не татар!» — дип шапырта
Кече оныгым — Максим...

# Хәлимә Назарова

*Хәлимә Мәҗит кызы Назарова Тәтер-Арслан авылында туа. 1953 елны мәктәпне тәмамлап, шушында ук немец телен укыта башлый. Читтән торып Башкорт дәүләт педагогия институтына укырга керә. Эстәрлебашта 1959 елдан бирле яши. Беренче урта мәктәптә, аннары 107нче авыл профессиональ-техник училищесында лаборант булып эшли.*

## Аулак өй

Аулак өйдә яшьләр кич утыра,
Шәл бәйлиләр, мамык эрлиләр.
Сәке уртасында чепи лампа,
Тирәсендә кызлар җырлыйлар.

Өлгер кулларына күз иярми,
Күз артыннан күзләр тезәләр.
Әче хәсрәтләрен эчкә йотып
Бөтен авырлыкка түзәләр.

Аулак өйдә бары ике егет:
Берсе кулсыз, берсе аяксыз.
Аяксызы гармун алып килгән,
Йөри алмаса да таяксыз.

Ут эченнән алар шулай кайткан,
Шинельләрдә дары исләре,
Яралары әрнеп сызласа да,
Сүрелмәгән йөрәк хисләре.

Сыңар куллы егет аяксызга:
— Уйна, — диде, — дәртле көйләрне, —
Утырмагыз боек, биеп калыйк,
Дер селкетеп шомлы өйләрне.

Үзе биеп китте оча–куна,
Берчә чүгеп, берчә калкынып,
Ул кызларны биергә чакырды,
Тыпырдатып басып, талпынып.

Гармун уйный дәртле бию көен,
Күпме биеп аяк талмады.
Җылы хисләр тулды күңелләргә,
Кайгыларга урын калмады.

Менә шулай, ул чак аулак өйләр
Җырлатты да безне, уйнатты.
Яшәү көче биреп йөрәкләргә,
Өмет чаткылары уятты!

# Хисаметдин Исмәгыйлев

*Хисаметдин Шәрәфетдин улы Исмәгыйлев 1953 елны Гөлем авылында туган. Хәзер Турмай авылында яши. Гомере буе ветврач булып эшләгән. Районның татар иҗтимагый үзәге җитәкчесе.*

## ЯВУРАЙ[1]

Институт тәмамлап, «Искра» колхозында эшли башлаган мәл. Идарә кырыннан үтеп барышлый колхоз рәисе Кунафин Габделхак абзый чакырып алды да:

— Исмәгыйлев туган, бар әле, тиз генә Тәтербаштан теге Ягарны алып кил, — диде.

— Ярый, тик кайда яшәгәнен белмим бит, — димен.

— Склад мөдире Клавдий сине көтеп тора, анардан сорарсын, — ди бу.

Ат шәп. Үзем мал духтыры булгач, колхозның иң ару атлары арасыннан сайлап алдым. «Ә» дигәнче Тәтербаш авылы уртасында урнашкан кибет кырына килеп тә життем. Тәтербаш Тормай авылына өч кенә чакрым. Кибет алдында берничә ир һәм хатын басып тора. Алар белән исәнләштем дә, хатыннар ягынарак борылып:

— Миңа склад мөдире Клавдия апа кирәк иде, — дим. Тәүдә шаркылдап көлделәр, аннан үзара чуашча сөйләшеп, чөкердәшеп алдылар. Мин аптырабрак калдым, ничектер уңайсыз булып китте. Әллә дөрес әйтмәдемме, әллә инде кушаматы белән дәштем микән дип. Чөнки хатыннар ирләр белән басып торган бер абзыйга күрсәттеләр. Вәт, малай, нигә инде миңа аның исемен кыстырырга? Склад мөдире диган булсам да, житкән бит инде. Теге абзыйдан:

— Сез склад мөдире буласызмы? — дип сорыйм.

Ул җавап биреп тормады, баш кына какты.

— Ә сез яңа мал духтырымы? — дип сорап куйды аннары.

— Әйе, — дим.

— Алайса, бар, Явурайны ал да, складка килегез, мин шунда булам, — ди бу.

— Ярый, шулай да сезнең атыгыз ничек соң, абзый? — дип сорамый түзәлмәдем.

— Бәй, әле үзең әйттең дә инде. Мин ни, шул Алексеев Клавдий булам, — ди бу. Мин аптырап:

— Ә чын исемегез? — дим.

— Чын исемем дә, юри исемем дә Клавдий минем, әтиләр шулай кушкан, — дип, тагын аптыратты. Теге мин алып килергә тиешле Егоровның исеме Явурайдыр дип чамаладым. Боларның кайсысы чын исеме, кайсысы ләкаб икәнен белмим бит инде. Үземчә болар барысы да чуаш исемнәре дип уйлыйм. Үзем аптырыйм: чуаш исемнәре йә Николай, йә Геннадий, йә Александр кебек урыс исемнәре булырга тиеш. Сонрак кына белдем: чуашларда Рәшит тә, Финур да, Еварис та бар икән...

Склад мөдиренә:

— Явурайның өен белмим бит әле, — дим.

— Кемнән сорасаң да, әйтерләр. Зур капкалы, зәңгәр тәрәзәле өйдә тора ул, урамның сул ягында.

— Ярый алайса, хәзер алып киләм, — дидем дә, киттем зур капкалы, зәңгәр тәрәзәле өйне эзләп. Минем әле Тәтербашның бу зур үзәк урамыннан беренче

[1] Хикәядә чын булган хәлләр үзгәртмичә бирелгән. Әсәрнең үзәгендәге зат белән сөйләшкән кеше — мин. *Автор сүзе.*

тапкыр гына үтүем. Барам шулай, ә капкалар, малай, барысы да зур, кин һәм матурлар. Бизәкләп-бизәкләп, агачны сырлап ясалган. Үзенә бер төрле матур, әллә ничек, нур сибеп торалар кебек. Әйтерсен лә чуаш кызлары матур итеп киенеп, капка урынына үзләре чыгып басканнар да, елмаеп, «безгә кунакка кер», дип чакырып торалар. Чуаш халкын унган диләр иде, менә кайда раслана икән бу.

Шулай уйлана-уйлана, капкаларга сокланып барам. Каршыга бер апа килә. Үзем чуашча бер сүз белмәгәч, урысчалап исәнләштем дә, Явурайны сорыйм. Апам томыраеп мина карап тора, шуннан нәрсәдер исенә төшергән кебек:

— Урысча белмәп, — диде дә, тагы кабатлап, «урысча незнам» дип, күзләрен челт-челт йомып мина карап тора. Аптырагач, татарча:

— Егоров кайда тора? — дим. Шуннан апам мине аптыратып:

— Үзеписнең татар икән, нигә аны пашта ук шулай әйтмисен, — дип куймасынмы! Мин Егоровнын йортын сорыйм.

— Пестә Егуровлар пик күп, кайсы Егуров кирәк сескә? — ди хәзер бу. Мин:

— Явурай Егоров, — дим.

— Өе менә каршыгызда, әнә, үзе дә йортында йөри, — дип, биек урыс капкалы йортны күрсәтте дә, китеп тә барды. Рәхмәт әйтергә дә өлгермәдем. Ә теге йорттагы ир безнең сөйләшкәнне ишетепме, әллә бүтән сәбәп беләнме, үзе капка төбенә чыкты да, мине күрмәмешкә салышып, арты белән борылып, капкасынын тотка-биген боргалап, шак та шок китереп төзәтергә тотынды.

Мин бу ир янына килдем дә, тамакны кырыбрак:

— Мина Явурай абзый кирәк иде, аны председатель чакырта, — дим. Бу минем якка борылмый гына бик катгый, кырыс, мин әйтер идем, түрә тавышы белән, юк, алай гына да түгел, армиядәге командирлар тавышы белән, урысчалап:

— Беренчедән, исәнмесез, яшь кеше. Икенчедән, мин Явурай түгел, ә Еврей. Өченчедән, мин Егоров Андрей Михайлович. Ә син мин Тормай авылында төзеткән ветеринария участогында яшисен, — дип турайды да, минем якка борылып, хәрбиләрчә честь биреп сәламләде, елмаеп, кулын сузды һәм: — Менә нәрсә. Мине ярат һәм ихтирам ит, чөнки мин Эстәрлебаш районында мал духтырларынын ин өлкәне, — дип, минем кулны бик озак кына кысып, селкеп торды. Аннары: — Йә, сөйлә, яшь кеше, — дип, татарчага күчте.

Ә мин аптыраудан ачылган авызымны да ябарга онытып, мингерәү кеше кебек басып торам. Чөнки бу бит элек-электән безгә, Гөлем авылына килеп, бездә кунып, ашап-эчеп йөргән кеше, ягъни әткәйнең Ягур пелеше. Алар бер-берсен бажа дип тә йөртәләр иде әле. Колхоз икегә аерылгач, соңгы елларда гына безгә килми башлады бит әтинең Ягур пелеше. Бу бит — үзебезнең Әндри абзый. Ә Әндри абзый сорауларны яудыра гына.

— Үзең кайсы яктан?

— Гөлем авылында туып-үстем, — дим.

— Кайда укыдың, нәрсәләр бетердең? — ди. Монысын да сөйләп бирдем. Ә ул һаман сораша.

— Ә фамилиян? — Мин фамилиямне әйткәч, Әндри абзый, «Син Шәрәфи малаемы?» — диде.

— Әйе, — дим инде.

— Ә мине таныйсынмы?

— Танудым. Мин сезне әткәйнең Явурай Әндри пелеше дип беләм, — дим. Әндри абзый:

— Явурай түгел, Еврей дип әйттем бит инде, — ди.

Мина шулай итеп әтинең пелеше Егоров Андрей Михайлович белән янадан якыннан танышырга туры килде. Хәзер инде очрашкан саен Әндри абзый әтигә күп сәламнәр әйтеп кала. Әти дә үз чиратында анын турында сорашып кына тора һәм сәламнәр әйтә.

Әндри абзый һәрвакыт:

— Минем бажа ни хәлдә? Миннән күп сәлам әйт, — дип кала торган иде. Ул әтине «бажа» дигән саен мин эчтән генә: «Вәт чукынган чуаш, ничек инде минем

эти ана бажа булсын. Минем әни — башкорт, эти — татар, ә Әндри абзый һәм аның хатыны Вера түти — чуашлар бит дип уйлыйм. Мөгаен, алар икесе дә бер хатын-кыз тирәсендә чуалганнардыр. Сугыштан соң ир-ат аз. Ул вакытта бит ун хатын-кызга бер-ике ир-егет туры килсә, бик хуш инде. Тормышның бер почмагына басып карасаң, гаиләле ирнең ялгыз хатыннар янына йөреп, ирләре сугышта һәлак булган һәм ир-ат назыннан мәхрүм калган хатыннарның әзме-күпме күңелен күреп, аларны иркәләүләре гөнаһтыр да ул. Тик үзләренең ялгыз, ир-ат назыннан мәхрүм булып гомер итүләренә алар гаепле ме? Юк, әлбәттә, юк. Менә каһәр суккан сугыш, шул сугышны оештырган ил башлыклары гаепле бит.

Шулай Әндри абзыйлар белән колхозда терлекчелек тармагында эшләп йөрибез. Ул һаман гел эткәйгә — бажага сәлам әйтеп кала... Жәй башлары. Без Әндри абзый белән жәйләүдәге башмакларга укол кадап, эш бетергәннән соң ял итеп ятабыз. Күктә кояш кыздыра, бөтен жир ямь-яшел. Һавада сирәк-саяк, төрле-төрле сурәткә кереп, эреле-ваклы болытлар ялкау гына агылалар. Сабан тургайлары сайраша. Кояш безне жылысы белән иркәләсә, битне салмак кына искән жил назлый. Сәхрә инде, сәхрә!.. Шунда мин Әндри абзыйга үземне күптән борчып йөргән сорауны бирдем. Чөнки аны этидән сорап булмый бит инде.

— Әндри Михайлович, ә нишләп әле минем эти сиңа бажа була ул? Әллә яшьрәк чагыгызда бергәләп яшь түтиләр янына гөнаһ кылырга йөрдегезме? — дим.

Әндри Михайлович чалкан яткан жиреннән миңа борыла биребрәк ятты да, елмаеп-көлеп куйды.

— Анысы да булырга бик мөмкин, без бит ирләр. Ә сугыштан соң, үзең беләсең, — дип, нидер уйлап туктап калды да, аннары сүзен дәвам итте. — Юк, син яшьрәк шул әле, белеп бетермисең. Синең әниең белән минем хатыным Вера түтән — икесе дә Авыргазы районыннан. Берсе — Бәгәнәш, берсе күрше Талник авылыннан. Бер елга суын эчеп, бер жирнең икмәген ашап үскәннәр. Менә шул яклап ул миңа бажа була... — Әндри абзыйның кәефе әйбәт. Шуны чамалап, тагын бер сорау бирдем:

— Әндри абзый, нишләп сине бөтен Тәтербаш, хәтта бөтен «Искра» колхозы Явурай дип йөртә? — дим.

— Әйттем бит, Явурай түгел, ә Еврей. Явурай дип әби-сәбиләр, дөресрәге, олылар әйтә. Чөнки чуаш халкы кайбер авазларны үзенчә яраклаштыра һәм татарчасы бөтенләй бозылып ишетелә. Менә сине дә бит Хисами дип түгел, ә Кичәми диләр. Ә Еврәй кушаматын миңа этине тәмуггтан алып кайткан елны райкомда куштылар. — Тавышы ничектер үзгәреп, карлыгып китте абзыйның. Ана күземнең кырые белән генә карыйм. Әндри абзыйның йөзе дә каралып, житдиләнеп китте. Бераздан ул, уфтанып.

— Әй, улым, улым. Бар иде заманалар, искә төшерәсе дә килми, — дип, мине шулай «улым» ук дия башлады, һәм, ничектер, сагышлы итеп:

— Их, малай, — диде дә, тынып калды.

Аның авыр уйларын бүләсем килмәде. Әндри абзыйга шундый тозсыз сораулар биреп газаплы хатирәләрен уятуым өчен әллә ничек үземә дә унайсыз булып китте. Чалкан борылдым да, теге ялкау болытларны һәм аларга тия язып сайрый-сайрый очкан сабан тургайларын күзәтәм. Ә Әндри абзый уфтана да уфтана. Мин дәшмим. Шулай бераз яткач, Әндри абзый карлыккан тавыш белән әкрен генә сүз башлады. Абзыемның тавышы ничектер тоныкланып, моңсуланып калган иде.

— Мин үзем сугыштан 1947 елны гына кайттым. Германиядә булдым. Немецлар алдында ару күренер өчендер инде, безне бик яхшы ашаталар. Өстә ПШ гимнастерка, аякта яловый итекләр. Ә өйгә мин хәтта күн плащ-пальто киеп кайттым. Трофейный әйберләр дә хәтсез генә. Дөресрәге, штабта хезмәт иткәнгә акчаны да мул гына түләделәр. Күн пальто киеп, чумаданнар күтәреп шулай кайтып төштем, малай, авылга. Үземнең үй буенча авылдашларның һушын аласым килгән иде. Киресенчәрәк булып чыкты шул. Авылда шундый хәерчелек. Сугышта жиңелгән немец авыллары белән безнең жиңгән авыллар арасында жир белән күк арасы. Дөрес, авылдашлар аптырамады түгел, аптырадылар. Эстәрлебаштан бер тарантас яллап кайткан идем. Шул тарантаска утырып авылның бер башыннан керүгә урамда карт-коры түгел,

хәтта бала-чагаларга кадәр юк булды. Авыл тып-тын. Күрәм инде, тәрәзә пәрдәләре һәм капка ярыкларыннан гына мине күзәтәләр. Авыл мине шау-гөр килеп каршы алыр дип уйлаган идем. Киресенчә килеп чыкты. Азактан гына белдем: алар мине районнан, йә Эстәрлетамактан килгән берәр уполномоченный налог җыючы, йә берәр оешма кешесе дип белгәннәр икән.

Өйгә кайтып кердем. Өй дисәң, хәтере калыр, инде яртылаш җиргә сеңгән, кыйшаеп беткән бер мунча инде. Ә өйдә авыру әни белән кырык ямаулы күлмәк кигән сеңелкәш. Соңгы кәҗәне бүре егып киткән, ә әтине ике кат Себергә озатканнар. 58нче статья белән. Үзең беләсеңдер инде моның нинди статья икәнен, тагы да пункт А-10.

Нинди статья икәнен белмәсәм дә, яткан җирдән генә «әйе, әйе», дип, белгән кеше кебек баш кагам. Ә Әндри абзый сөйли дә сөйли.

— Ике контузия һәм берничә яралану галәмәте инде. Шулар булмаса, армия сафында тагын хезмәткә калырга иде әле. Сәламәтлек шәптән булмагач, мине демобилизовать иттеләр дә инде.

Шулай колхозда җинел-җилпе эшләрдә йөрим. Контузияләрне исәпкә алып, мине клуб мөдире итеп куйдылар. Матур гына эшләгән булам. Өйне әзрәк зурайтып, төзекләндереп җибәрдем. Кулдан килгәнчә колхоз эшләрен дә башкарам. Өйдә икмәк, он күренә башлады. Бер тана үстереп, сыерлы булдык. Яңа гына мәктәпкә укытырга килгән Вера түтәнә өйләнеп җибәрдем.

Әмма, кемнен күзе тигәндер инде, малай, әллә көнләшүдән микән, мине авыл бригадиры күрә алмый башлады. Әллә шунардан, әллә бүтән сәбәп булды, мине клуб мөдирлегеннән бушаттылар. Янәсе, мин — халык дошманы баласы. Мин нинди халык дошманы баласы булыйм ди. Күкрәк тулы орден-медальләр. Сталинның бит әйткән сүзе бар. Улы атасы өчен җавап бирми, дигән. Киттем райкомга. Анда да шул сүзне сөйлиләр. Хәтта Вера түтәнә дә: «Ни эшләп син халык дошманы баласына кияүгә чыктың, аерыл, аерылмасаң, үзеңне дә мәктәптән куабыз, — дип әйтәләр икән. — Социализм балаларын укытырга хакың юк», — дип әйткәннәр, малай. Шулкадәр гарьләндем. Райкомнан чыгып, Учитель тавын турыга мендем дә, Эстәрлебашка карап уйланып утырам. Бөтен авыл уч төбендәге кебек күренеп тора. Елыйсылар килде, малай. Шунда ничектер әти искә килеп төште. Ул да, бахырың, шулай нахакка рәнҗетелде бит. Мона кадәр аның юньләп искә дә төшкәне юк иде. Башта кулак дип сөрделәр, умартасы күп иде. Чөнки аннан кайтып озак та тормады, умарталарын юри үтергән дип тагын җибәрделәр. Соңгысында инде, халык дошманы дип, бөтенләйгә алып киткәннәр. Анда мине сугышка алганнар иде инде.

Шул Учитель тавында үземә сүз бирдем: дөреслекне табарга. Шуннан башланды инде минем мажаралар. Тегеннән белешмә кәгазе, моннан пичәтле кәгазь, култамгалар җыям. Уфага да берничә тапкыр бардым. Юк кына бит, малай, син халык дошманы баласы, бетте-китте. Җитмәсә, шулай дөреслек эзләсәң, әтиең янына җибәрәбез, дип тә куркыталар. Үзеңне дә алып китәләр бит дип әни белән сеңелкәш елашалар. Ул хатын кайгыра. Сөйләмә инде, малай, искә төшсә, әле дә тәннәр чымырдап китә. Уфада да эш барып чыкмагач, җыендым да Мәскәүгә киттем бер көнне. Ни булса, шул булыр дип. Кесәдә бер йөк белешмә, пичәтле кәгазь. Ярый әле күрше Безгин авылыннан ике дус фронтовик абзый миңа белешмә язып биреп, үзләренең имзаларын куярга курыкмадылар.

Шулай Мәскәүгә килдем. Сорашам, белешеп йөрим, ничек Кремльгә, Сталин янына керергә икән, дип. Юк, малай, булмый гына бит. Вокзалда кунып йөрим. Үзем кебек берәү көн саен төрле вокзалда кунарга кирәклеген өйрәтте. Алайса, ди, хәзер үзеңне яшереп куярлар, кем икәнеңне дә онытырсың, ди. Бер айдан тәки милиция эләктерде, и ябып та куйдылар. Бөтен документларны алдылар. Бетте баш, дип уйлыйм. Ике тәүлектән соң гына иртән бер түрәгә алып керделәр. Ә аңа кадәр кайгыруларны үзем генә беләм дә, Алла шаһит. Бөтен кәгазь-белешмәләрне энәсеннән җебенә кадәр укып чыктылар. Теге түрә сораша, мин сөйлим. Мине, дим, бер гаепсезгә эшемнән алдылар, мин фронтовик, әнә орден-медальләр, дип өстәлдә яткан орденнарга күрсәтәм. Теге һаман:

— Монысын ни өчен бирделәр дә тегесен ни өчен бирделәр? — дип сорый. Мин әйтәм инде.

Әйбәт кеше булып чыкты. Үзе дә фронтовик икән. Мине тынлады, чәй эчерде, ничегрәк Кремльгә керергә, ничек пропуск яздырып алырга өйрәтте. «Син, — ди, — Сталин янына керә алмассың. Ул зур илнең бүтән зур мәшәкатьләре белән мәшгуль. Шуна да син иң яхшысы: йә Руденкога, йә бүтән берәр түрә башлык кырына керергә тырыш», — дип, мина акыл өйрәтте. Һәм мин аның акылын тотып эш иттем. «Әтиең турында ләм-мим, алайса, чынлап та, туган авылынны бүтән күрә алмассын», — дип тә кисәтте. Менә шулай итеп йөри торгач, Руденко[2] янына керергә пропуск алуга ирештем. Ә бит пропускны да болай гына бирмиләр. Иң тәүдә син мунча кереп килергә тиешсең. Шулай чиратка бастым. Халык күп. Көн саен төрле вокзалда кунам, аннан Кремль кырындагы Кызыл мәйдан артында мунча керәм һәм, юынганга белешмә алып, пропускка чиратка торам. Ә мунча безнең кебек ерак өлкәләрдән килүчеләрне юындыру өчен икән. Имеш, тегендимондый чир алып кермәсеннәр Кремльгә. Мунчадан соң костюм-чалбар, эшләпә, ботинка сатып алып кияргә куштылар. Шулай итмәсәң, пропуск юк. Барлы-юклы акчага киендем, малай, ни эшлисең бит. Мина бит ничек булса да үземнең бер гаепсезгә эштән куылганны исбат итәргә кирәк. Югыйсә мина туган авылда гына түгел, районда да эш бирмәячәкләр. Эш бирмәү генә түгел, яшәтмәячәкләр. Изаланып йөри торгач, тагын бер ай үтеп китте. Ә эч яна, авылда чәчү бетте, печән чаба башладылар. Минекеләр ничек икән, бәрәнге утырта алдылар микән, печән хәлләре ничек икән? Юньләп йоклаган да юк. Уйлана-уйлана шыр сөяккә калыр идем, ярый әле, пропуск алгач, Кремльдә очсызга гына, артып калганчы ашаталар. Мин хәтта азрак матурланып, түгәрәкләнеп тә киттем. Шулай йөреп, күп кешеләр белән танышып-дуслашып беттем. Күп нәрсәләр белеп, күп нәрсәләр күреп, күп нәрсәләргә өйрәндем. Безнең чуаш халкы бит болай карап торуга гына юаш. Ә без хәйләкәр бит. Шундый булмасак, күптән милләт булудан туктап, үлеп беткән булыр идек. Шулай астан гына күзәткәләп йөрим, малай. Анда да НКВД шымчылары бар, әй, һушын китәр. Бер бетеренгән генә ир кисәге елап-елап үз кайгысын әле бер кешегә, әле икенчесенә сөйли. Кайбер башлыкларны сүккәләп тә ала, үзе дә колак салып, тынлап йөри. Бер-ике кеше җыелып сөйләшә башласа, мыштым гына шунда барып баса да, тынлап тора. Бер-ике атна югалып тора. Ә аның урынына икенчесе йөри башлый. Менә шулай, туган. Бар бит кешеләр, ә?

Безне аерым бер бүлмәдә Руденко янына кергәч нинди тәртиптә сөйләргә, нинди сорауларга ничек җавап бирергә күнекмәләр ясаттылар. Әгәр ялгышсаң, тагын бер атна чират көтәсең. Менә шундый хәлләр. Әкият инде, әкият.

Руденкога язылган булсам да, мине аның бер урынбасарына кертеп җибәрделәр. Ник икәнен сөйләп тормыйм, барыбер «шыттыра бу Еврей» диярсең. Килеп кердем. Теге урынбасар мина шундук ошамады. Кычкыруын кычкырмый, әмма һушны алды.

— Нишләп йөрисең кызу печән өстендә? Сина колхоз да, ил дә кирәкмимени? Үзенне генә кайгыртасың, — дип китте, малай. Мине күзенең агы белән утыргычка кадаклап та куйды. Үзәкләргә үтеп керә, мин синайтим. Күзе белән турырак караса — йөрәк чәнчи, баш чатный башлый. Читкә карасаң, «мина туры гына кара», ди, шундый тыныч итеп. Ә әйткән сүзе миләргә барып бәрелә. Үземнең ник туганыма да, ник монда килгәнемә дә үкенә башладым. Әтине монда да искә төшереп алдылар. Баш зынлый башлады. Хәзер егылам, хәзер егылам, ничек тә түзәргә кирәк, дип утырган чагымда, бүлмәгә кечерәк буйлы, үзенә бик килешеп торган прокурор формасы кигән бер кеше килеп керде. Теге урынбасар тынып калды, каушап та китте. Яна килеп кергән бәндә миннән сорау ала башлады: кем мин, кайдан, ни йомыш? Урынбасар минем өчен җавап бирә башлаган иде, аны кул селтәп туктатты да, ниндидер эш кушып, бүлмәдән үк чыгарып җибәрде. Орден-медальләрне күзеннән үткәрде. Сугышны кайда тәмамлаганны сорады. Мин барысын да сөйләп бирдем. Тик үземнең иң соңгы чиктә генә ярдәм сорап мөрәҗәгать итә ала торган урыным бар икәнен генә әйтмәдем. Бу — сер иде.

[2] Руденко Р.А. – ул чакта СССРның генераль прокуроры. *Ред.*

Миңа әлеге түрә бик таныш кебек тә, таныш түгел дә кебек тоелды, кем икәнен үзеннән сорарга кыюлыгым җитмәде. Шушы кеше миңа:

— Бар, кайт, үзең кайтып җитүгә билгеле булыр, хәбәр бирербез. Эшенә кире урнашырсың, — дип мине шатландырды. Бу хәбәрдән соң мин бөтен дөньяны кочаклап алырдай булып, дәртләнеп киттем һәм, әтине дә азат итәргә кирәк иде, дип авыз гына ачкан идем, теге бәндә кырт кисте.

— Бездә гаепсезләр утырмый, ул — җинаятьче, һәм гаебен аклаганчы утырачак, — дип, сүз беткәнен аңлатып, ишеккә күзе белән генә ишарәләде дә, телефоннан кемнедер кыздырырга да кереште. Мин рәхмәтләр әйтеп өстәлдәге үзем җыйган төрле белешмә-кәгазьләр тутырган калын папкага үрелгән генә идем, бу адәм, миңа карап та тормыйча, папканы бармаклары җәелгән учы белән каплады. Бармаклары нечкәләр хатын-кыз бармаклары кебек йоп-йомры. Мин, саубуллашып, чыгып киттем. Үҗәтлек бит инде, алгы бүлмәдәге ярдәмчедән барыбер сорадым. Кем була бу кеше, дип. Ярдәмче, миңа күзен алартып карады да, аптырап:

— Син нәрсә?! Кем белән сөйләшкәнеңне дә белмәдеңме? Бу бит Руденконың үзе, — дигәч, күз алларым караңгыланып, тез буыннарым калтыранды. — Әйе, хәзер үзем дә таныдым, бу чынлап та Руденко иде. Менә хәзер искә төште. Тик газит-журналларда һәм стенадагы плакатларда ул яшьрәк һәм матуррак күренә иде.

Менә шулай минем Мәскәүгә сәяхәтем азагына җитте һәм мин икенче көнне поезд белән үзебезгә — Башкортстанга кайтып киттем.

Өйгә кайтып керергә дә өлгермәдем, мине райкомга чакырттылар. Анда мине бик яхшылап пешекли-пешекли «тәрбияли» башладылар.

— Нишләп син башбаштакланып Мәскәү кадәр Мәскәүгә киттең? Хөкүмәт башлыкларын җәфалап-бимазалап йөрисең? — дип кыздыралар гына, малай. Мин дәшмим. Болар бөтенләй кызып киттеләр.

— Без хәл итәрлек эшне Мәскәүгә җиткергәнсең. Районның данын сатасың. Бу эшне без бер сәгатьтә хәл итә идек, — дип һаман төкерек чәчәләр. Мине тагын куркыта башладылар. — Киләсе атнада бюро була, шунда синең тәртибеңне тикшерәбез, сине партия сафыннан чыгарабыз, әзерләнеп тор, — дигәч, минем түземлегем бетте. Тынычрак булырга тырышып тирән итеп тын алдым да:

— Сез мине партиягә алмадыгыз һәм мине партиядән чыгара да алмассыз, — дидем. — Мин сугышта кан коеп йөргәндә сез, тыл күселәре, монда җылыда хатыннарыгыз куенында яттыгыз. Мине куркытмагыз. Мин иптәш Руденкога үзем кердем һәм ул киләсе елның шушы вакытына мине тагын чакырды, — дип тә өстәп куйдым. Монысын инде арттырыбрак җибәрдем. Шулай итмәгәндә болар миңа барыбер тыныч кына эшләргә ирек бирмәячәкләр иде. Озак уйлап тормыйча, ишекне шапылдатып яптым да, чыгып киттем.

Сәркәтип кыз кием шкафы янында арттан куып җитеп, мине яңадан эшкә алулары турындагы боерыкны тоттырды һәм пышылдап кына:

— Сез, абзый, бик кайнамагыз, аларга да җиңел түгел. Кичә генә үзләрен Уфага чакыртып, бик каты кыздырдылар, — диде дә, борылып, тек-тек басып китеп тә барды.

Шулай итеп, мин яңадан кызыл йортта, ягъни клуб мөдире булып эшли башладым. Миңа авыл халкы да, колхоз җитәкчеләре дә хәзер «халык дошманы» баласы дип әйтмиләр. Миңа караш бөтенләй үзгәрде. Әмма кемнәрдер барыбер астыртын гына аяк чала, явызлык эшли. Йә клуб тәрәзәсен ватып китәләр, йә йозакның ачкыч тишегенә мәте тутыралар. Бер юньсезе хәтта төнлә кыекка менеп, мичнең морҗасын яртылаш сүткән. Ә мин бирешмим. Шулай тарткалашып эшләп йөргәндә, әни исеменә Красноярск шәһәреннән бер сәер хат килеп төште. Хат эчендә әллә нинди хәбәр юк. Исәнлек-саулыкны, һава торышын сорашкан, бездә суыклар башланды, дигән һәм шуның ише юк-бар. Әтидән дияр идем, әтинең кай тарафларда утырганын да белмибез. Әллә исән, әллә... Әмма хатта: «Почетка кунакка килегез», — дип чакырган бер грузин. Хатның язылу вакыты бик сәер. Әле ул вакыт җитмәгән. Анда 1951 ел, 31 декабрь дип язылган һәм астына беленер-беленмәс кенә сызып куйганнар. Ә хат тышындагы пичәттән карасаң, хат сентябрь азагында

язылган һәм бу вакытның астына да сызып куйганнар. Укып чыктым кат-кат. Безнең таныш грузин да юк бит. Аптырадым. Мин Германиядә маршал Чуйков Василий Ивановичның штабында хезмәт иттем. Шуның өчен әлләни кыенлык тудырмады бу хатны укып, грузинның нәрсә язарга теләгәнен аңлавы. Төрле шифровкалар белән таныш бит инде мин. Хатны кирегә дә укып чыктым. Юл аша да, сүз аша да укыдым. Ә астагы язылу вакытын куеп укырга соныннан гына башка килде. Укып чыксам, анда болай дип язылган: «әтиегезне килеп алыгыз, ул үзе генә кайта алмый». Ә әти яза да, укый да белми. Гаҗәп бу! Хатны кем язган соң?

...Әндри абзый сөйли дә сөйли. Ә мин, чалкан ятып, болытлар күзлим һәм тыңлый бирәм. Миңа кызык...

— Алла бар ул, улым, мин хатны укый алдым, ә укый алмасам ни була иде? Минем бу хатны укый аласымны кем белгән икән? Гаҗәп, бик гаҗәп. Аллаһы Тәгалә мине дә, теге хатны язган адәмне дә үзе эшкәрткән. Менә шуннан соң үзең аңла инде...

Германиядән алып кайткан трофей кием-салымны, сыерны сатып әз-мәз акча җыештырдым да, үз исәбемә ял алып дәваланырга барам дип чыгып киттем. Мин бит ике тапкыр контузия алган кеше. Яралар да бар. Себернең үзенә — Красноярск каласына матур гына барып җиттем. Аннан Канскига бер грузовикка утырып киттем. Тышта ноябрь азагы. Суыклар кырык градуска житә. Кански дигәннәре бер район үзәге икән. Туры НКВДга кердем. Руденкога пропуск бар иде, шуны күрсәттем. Бик ярап куйды.

— Менә, дим, мин Руденконың үзендә булдым. Анда әтинең Почет дигән поселокта икәнен белдем, аны күрергә барам, дим. Озак сөйләшеп тормадылар. Архивларында бөтен кәгазьләр һәм документлар бар. Шуннан карадылар, әтинең нинди лагерьда икәнен әйттеләр. Чынлап та, әти Почет дигән поселоктан ерак түгел бер лагерьда икән. Ә анда барырга юл юк. Нишләргә? Яхшы кешеләр әйттеләр, аена бер тапкыр анда почта бара икән. Почтага барып сөйләштем. Ун көннән генә кузгалачаклар икән. Ә сине алмыйбыз, рөхсәт юк, диләр. Киттем янадан НКВД бүлегенә. Андагы түрәнең үзенә бер «ярты» алып кереп эчкәч кенә «ышанычлы» дигән кәгазь алдым. Шуннан соң гына этләр җигеп йөри торган бер тунгус кешесе ризалашты. Чөнки мин барасы җиргә тик эт белән генә барып була икән. Менә шунда инде мин беренче тапкыр эт җиккән чанага утырдым. Утырдым дип әйтүе генә рәхәт. Чумадан белән биштәрне генә чанага салдык. Ә калганын йөгерә-атлый җәяүлибез. Тау төшкәндә генә утырабыз. Шулай итеп, ике йөз чакрымнан артык араны бер атна дигәндә үтеп, җәһәннәмнең әллә кайсы почмагына урнашкан Почет поселогына килеп төштек. Карга күмелеп беткән, Алла тарафыннан бөтенләй онытылган бер шайтан оясы инде. Кыскасы, тагын өч көн үткәч кенә әти булырга тиешле лагерьны эзләп таптым.

Үзем алып килгән иң яхшы яловый итекне, хром пальтоны киеп, лагерь канцеляриясенә килеп, үзем белән таныштырдым. Башта аптырадылар, мине тикшерергә килгән берәр түрә дип уйладылар, ахры. «Сакчы солдатларыгыз кайда?»— дип сорыйлар миннән. Лагерь түрәсе үзе каядыр киткән икән. Ярдәмчеләренә әйтмәгән булган минем киләсене. Документларны күрсәткәч кенә тынычландылар, шулай да бик үк ышанып бетмәделәр. Мине лагерь идарәсе урнашкан йортның бер башындагы бүлмәгә урнаштырдылар. Лагерь начальнигы белән икенче көнне генә таныштым. Ару гына кеше икән. Мине әйбәт кабул итте.

Лагерь дигәнең озын-озын бараклар инде. Бер унлап барак булыр. Чәнечкеле тимерчыбык белән уратып алынган алынуын, тик вышкаларда сакчылар гына юньләп күренми. Лагерь начальнигы аңлатты: кыш көне бер зек та качмый икән, шуңа да аларны сакламыйлар да. Тик Почет поселогына гына җибәрмиләр. Нишләп бу авылга Почет дип исем биргәннәрдер, монда «Почет»ның әсәре дә юк. Себернең иксез-чиксез кинлекләрендә югалып, Алла тарафыннан онытылган, тирә-ягын тайга басып алган, карга күмелеп беткән бер авыл инде. Электр уты да юк монда. Бу «поселок»та бары лагерьда гына иске паровозга көйләнгән электр генераторы һәм ике агач яру җайланмасын эшләтә торган дизель двигателе бар икән.

Лагерь түрәсеннән соң канцеляриягә кердем. Егоров Михаиллар өчәү булып чыкты. Берсе 1949 елны ук азат ителгән. Ул кайдадыр шушы тирәдәге бер авылда яши диделәр. Берсе миннән чак кына олырак. Ә өченчесен күптән түгел генә агач басып үтергән икән. Шулай да теге грузин кешесе язган хат йөрәккә жылы бирә һәм мин, бер солдат ияртеп, әтине бараклар буйлап эзләп киттем. Табып чакыртып китерәбез дигәннәр иде дә, әтине үзем эзләп табасым килде.

Әйе, малай, Германиядә Бухенвальд һәм Освенцим, Дахау концлагерьларын күргән кешегә мондагы күренеш бер дә чит түгел. Барысын да сөйләсәм, бу Совет хөкүмәтенә «яла ягу» булыр иде. Кереп күрдем теге Егоровны. Юк, әти түгел. Ә лагерьда эшкә чыкмаган зеклар мина бер кыргый жанварга караган кебек карыйлар. Хәтта берсе минем яннан үтеп киткәндә хром пальтоны тотып, сыпырып карарга да өлгерде. Мина лагерь лазаретына барырга куштылар. Киттем шунда. Дару исе сеңеп беткән бер барак инде. Стеналары известька буялган. Салам матрацлар. Карап чыктым. Минем әтигә охшаган бер кеше дә юк. Мине дә беркем танымады. Егоров Михаил дигәннәре бер шәүлә инде. Кәкрәеп каткан тере бер скелет. Мин тегеләй дә, болай да сораштырып карыйм. Юньләп сөйләшә дә алмый. Бу бичара күп торса бер-ике көн торыр, ахры. Врач әйтүенчә, күптән ята икән. Паралич суккан. Безненчә, зәхмәт суккан була инде. Монда өченче ай ята, ди. Шунда мин теге кесәдәге хатны шушы врачка күрсәттем.

— Әйе, бу элекке врачның почеркы, менә ул тутырган журналлар, — ди. — Тик ул көз көне үк азат ителеп, икенче урынга күчеп китте. Мөгаен, кайтып киткәндер, — ди. — Мине аның урынына яңарак кына китерделәр..

Шуннан Почет поселогына кабат киттем, теге 1949 елны ук азат ителгән Егоровны эзләп. Мине монда хәзер танып торалар, абзагызга монда ихтирам һәм хөрмәт! Өстә нинди киемнәр икәнен беләсез. Анысыннан да бигрәк әле мин бу тайга эчендә, таулар арасында урнашкан шушы шайтан оясына әтисен эзләп килгән иң беренче кеше икән. Урамда бер карчык туктатып, мине кочаклап елады да хәтта. Сүзен дә әйтәлми, минем аркадан сыпыра. Чак-чак аңладым тегене. Мине улына охшаткан икән. Ике улы, ике кызы бар икән. Тик алар әбидән баш тартып, икенче фамилиягә күчкәннәр. Әби, үзем шулай куштым, ди. Аны да килеп алачакларына һаман ышана. Ул да сугыш беткән елны ук азат ителгән булса да, бу жәһәннәм оясыннан кайтып китәргә ни акчасы, ни сәламәтлеге юк икән.

Әбидән чак котылдым. Янымнан кинәт кенә китеп барырга вөжданым житмәде. Арттан ияреп тә әле күпме елый-елый килде. Теге Егоров Михаил йортын тиз эзләп таптым. Бер бәләкәй генә авыл йорты инде. Тик өй бикле, өй тубәсен кар басып киткән. Монда күптән кеше яшәмәгәнлеге күренеп тора. Күршеләреннән сораштым. Картны бәрәңге чыгарганда зәхмәт суккан. Әле ул лагерь лазаретында ята диделәр. Авылда бүтән дәваланыр урын юк бит. Шулай булгач, лазаретта үләргә яткан теге карт шул булып чыга инде.

Әйе, малай, мине тәмам төшенкелек биләп алды. Нишләргә дә белмим. Мөгаен, теге агач басып үтергән Егоров минем әтидер дип уйлыйм. Барып каберен карар идең, зекларны төркем-төркем ямнарга гына күмәләр икән. Алай дисәң, сентябрь азагында теге грузин докторы язган хатта бит: «Әтиең исән, килеп алыгыз», — диелгән. Аңламассың инде.

Авылдан лагерьга жәяүләп киттем, бер ун чакрымлап булыр бу. Көн кичкә авышты. Чатнама суык, әмма жәяүләгәч бик сизелми. Бик тә авыр хисләр белән үзем-үземне тоймыйча атлыйм. Беренче тапкыр әтине алып киткәндә мина ун яшьләр чамасы иде. Шуннан аны юньләп күргән булмады. Шуңа күрә минем — әтине, әтинең — мине күреп танымавы да гажәп түгел. Ишеткәнем бар иде, зеклар кайчакны үзләренең утыру вакытларын киметү өчен үлгән зекларның исем-фамилияләрен алалар икән. Әллә шулай булдымы бу?

Их, әти, әти! Алтмыш умартанны колхозга биргән булсаң. Анда үтереп бетерерләр дип курыктың шул...

Караңгы төште. Лагерьда прожекторлар «ялт» итеп тора. Зеклар эштән кайткан, кичке барлауга тезелгән.

Кемнәр генә юк монда: мыек та чыкмаган үсмерләр дә, картаеп, чак-чак таякка таянып йөргән ап-ак башлы бабайлар да бар. Мин тәүдә боларның берсен дә игътибарга алмадым. Минем үз кайгым көчле, болар барысы да халык дошманнары, хыянәтчеләр, караклар, барысы да безнең совет хөкүмәтенә аяк чалучылар дип уйлыйм бит инде.

Мине күрүгә, «гү» килеп торган лагерь тып-тын калды. Ике як вышкадагы ике прожекторның рәхимсез ут баганаларын миңа төбәлде. Шул кадәр тын һәм якты ки, хәтта канцеляриядән ерак булмаган подвалдан теге электр энергиясе бирә торган паровоз калдыгының авыр сулап ухылдавы да ишетелеп киткәли. Кинәт мин «Смирно!» дигән тавышка айнып киткәндәй булдым. Бөтен лагерь үрә катты. Кизү торган офицер шунда:

— Совет хөкүмәтенең дөрес, туры, акыллы политикасында тәрбияләнеп үскән һәм иректән үзенең зек әтисен күрергә килгән гади совет фронтовигы иптәш Егоров Андрей Михайловичка тигезләшергә! — дип ярып салмасынмы! Әллә ничекләр булып китте. Баштан аяк табаннарыма кадәр сәер бер көч мине калтыратып үтте. Соңыннан гына белдем: лагерь начальнигы керәсе урында нәкъ шул минутта капкадан мин килеп кергәнмен һәм теге кизү офицер, үзе дә көтмәгәндә, күнелендәге ихтирамны бөтен лагерьга ярып салган.

Йөрәгем туктап калгандай булды. Аңыма һаман барып җитәлми тора бу күренеш. Биш меңнән артык зек миңа карап үрә каткан. Барысы да яланбаш. Мин зеклар алдыннан китеп барам. «Шылт» иткән тавыш та юк. Хәрби гадәт буенча, мин дә күкрәкне киереп, уң кулны бүреккә — чигәгә куеп, честь биреп барам. Минем хром итекләр генә тынлыкны бозып, шыгыр-шыгыр итеп каткан карны таптыйлар.

Кизү офицер килеп минем колакка пышылдый:

— Аларга честь бирмәгез. Алар бит халык дошманнары, хыянәтчеләр, Совет хөкүмәтенә каршы кешеләр, — ди. Минем кулны тартып төшерергә чамалый. Мин исә бирешмим, мин аны ишетмим һәм сизмим дә. Мин шулай зеклар сафлары алдыннан шап-шоп атлап, бөтен лагерьга хәрбиләрчә честь биреп барам. Бу шундый сәер бер күренеш булды. Әллә мин парад кабул итәм, әллә зеклар миңа хәрби осмотр үткәрәләр — һичкем аңларлык түгел. Теге кизү офицер, минем кулны төшереп булмаячагын аңлап, кулын селтәп китеп барды. Зекларның үрә каткан сафларын честь биреп үтүгә, тирә якны өч тапкыр озак итеп янгыраган «ур-ра!» тавышы тетрәтте. Суыктан лагерь кыекларына кереп яшеренгән чыпчыкларга кадәр куркышын, пырхылдап очып чыктылар. Мин эчтән генә, монда да чыпчыклар бездәге кебек икән, дип уйлап куйдым. Шул чыпчыклар гына миңа чын тормышны искә төшерергә ярдәм итте. Югыйсә, инде сафлар күптән үтелгән булса да, мин һаман честь биреп барган булыр идем.

Аннары инде, башымны иеп, алар яныннан китеп бардым һәм үземә бирелгән бүлмәгә кереп аудым. Кичке ашны да ашап тормадым. Әллә ике йөзләп чакрымны этләргә ияреп йөгерә-атлый үткәнгә, әллә үткән көннәрдәге кичерешләр миңа авыр йогынты ясаганга, авырып киттем. Өч көн тора алмый яттым. Лагерь начальнигына рәхмәт инде, бөтен лагерьны аякка бастырып, мине дәваладылар. Бераз хәл кергәч, аерым бүлектәге НКВД хезмәткәре теге «парад» өчен кирәкне бирер дип шөлләгән идем дә, алай-болай тавыш булмады. Лагерьдагы офицерлар көн дә килеп минем хәлне белгәләп тордылар. Олы җирдә нинди үзгәрешләр булуы, халыкның ничек яшәве турында сорашалар иде. Офицер хатыннары һәм лагерьдагы ирекле эшчеләрнең хатыннары үзләре пешергән тәм-том, тайгада үскән гөмбә һәм җиләк кайнатмалары белән сыйлыйлар. Лагерь түрәсе күрше лагерьлардан да сораштырган. Анда да минем әтигә охшаган һәм минем әти булырлык кеше юк икән. Ә монда лагерьлар мин ишетеп белгәннәре генә дә алты-җиде, ә белмәгәннәре әллә ничәүдер әле.

Шулай хәр дөньядан килеп әтине эзләп йөрү бөтен лагерьга ниндидер бер көч-куәт бирде. Айлар, еллар буена бертөрле лагерь тормышыннан туйган зеклар өчен ниндидер шаккатмалы яңалык иде бу. Тоткыннар көндәлек эш күләмен арттыра башлаганнар. Бу хәл лагерь түрәләренә дә уңай тәэсир итми калмады: бөтен лагерь

«гү» килә: барысы да мине сөйлиләр, мине тикшерәләр. Хәтта күрше лагерьлардан да мине күрергә дип офицерлар килеп китте. Мин, күрәсең, барысының да күңелендә яшерен өмет уятканмын. Хәтта адәм сыйфатлары чак-чак сакланган зекта да. Аларны да килеп алырлар, аларны да якыннары шулай искә төшерәләрдер дигән өмет инде бу.. Ә өмет бит ул бик-бик зур нәрсә. Тик менә әтием генә юк. Аны белеп, аның турында сөйләрдәй кешене дә тапмадым, ичмасам.

Бераз хәл кереп, аякка баскач, кайтып китәргә җыендым. Ничек кенә кыен булмасын, миңа кайтып китәргә кирәк. Соңгы көнне үземне дәвалаган доктор белән саубуллашыйм дип лазаретка киттем. Авылдан алып килгән дуңгыз маен һәм ярманы аларга калдырырга булдым. Үзем һаман ышанмыйм, ничек инде әти эзсез югалырга тиеш, дип уйлыйм. Теге грузин докторы язган хат миңа барыбер ышаныч бирә. Хат сентябрь аенда язылган. Әле декабрь урталары. Бер дә булмаса, җәен иркенләп килеп эзләрмен дип, уйлана-уйлана лазаретка таба атлап барам. Юлда очраган зеклар мине үрә катып, баш киемен салып исәнләшеп озатып кала. Көндез бөтен лагерь урман кисә, лагерь эчендә карт-коры, чирле-чорлылар гына төрле вак-төяк эшләрне эшләп йөри. Минем уйларымны бер карт зек бүлде:

— Рәхмәт инде, улым, үз гомеремдә күпме төрмә-лагерьларда утырдым. Патша вакытында революцион эшләрем өчен утырттылар, ә хәзер контрреволюцион эшчәнлегем совет хөкүмәтенә комачаулый дип утырттылар. Аңламассың бу дөньяны. Тик миңа, безнең кебек зекларга ихтирам белән честь биргән беренче кеше — син булдың, улым. Дөньяда әле безне кешегә санаучылар да бар икән, — ди бу. — Без, алтынчы барак зеклары, әтиеңнең табылуын бөтенебез дә телибез һәм сиңа ярдәм итәргә тырышачакбыз, — дип, ул минем кулны озак кына кысып торды. Минем әтине табуымны бөтен лагерь тели иде, күрәсең. Бу карт зектан иплэп, бик итагатьле булырга тырышып аерылдым. Ә бабай чынлап торып елый, күз яшьләрен миннән яшерми дә. Бите буйлап агып, кырынмаган сакалына төшеп барган яшьләрен сүтелеп-тузып беткән бушлат җиңе белән сөртә-сөртә китеп барды бу.

Лазаретка кереп тагын бер тапкыр карап чыктым. Юк, мине таныган һәм мин танырлык бер кеше дә юк. Булган өметләр сүнде. Лазаретка килгәндә дә бик шәптән булмаган кәефем тәмам кырылды. Ә бөтен авырулар һәм лазаретта эшләгән медицина хезмәткәрләре, шунда төрле эш башкарган зеклар миңа шундый өмет белән, ышаныч белән карап торалар. Әйтерсең дә мин Гайсә пәйгамбәр, әйтерсең дә баш очымда изгелек нурлары балкып тора.. Ә үземнең эчемдә нинди утлар янганын нинди котып җилләре боз булып йөрәкне ялаганын Ходаем белән үзем генә беләбез. Мин төшенкелек дигән диңгезнең иң төбендәмен.

Алла юк диләр. Син, улым, моңа ышанма. Алла бар ул. Мин шушы гарип-гораба, авыру карт-коры зекларга карап:

— Тизрәк терелегез һәм түзегез, озакламый сезне дә азат итәрләр. Менә мин килдем бит, сезне дә туганнарыгыз искә төшерәләрдер, юксына-сагыналардыр. Вакыты җиткәч, сезне дә улларыгыз, туганнарыгыз килеп алырлар, — дип, зекларның күңелләрен күтәрергә, аларда өмет уятырга тырышып, соңгы тапкыр нотык сөйлим. Тагы нәрсәләр сөйләгәнмендер, хәтерләмим. Кырымда басып торган доктор хатын җиңемнән тартып, мине туктатты. Бераз икеләнебрәк торгач:

— Гафу итегез, сез нинди телдә сөйлисез? Без сез сөйләгәннең бер сүзен дә аңламадык, — дип, мине чынбарлыкка кайтарды. Үземнең чуаш телендә сөйләгәнемне шунда гына аңлап алдым. Ә бит авылдан чыгып киткәннән бирле чуашча бер авыз сүз әйткән булмады. Туктап калдым һәм бертуктаусыз тамак кырам. Тамагыма нидер тыгылды, күздән менә-менә яшь тәгәрәп төшәр төсле. Сөйләгән сүзләремне урысча кабатлыйм. Моңа кадәр гел урысча сөйләшеп, монда, лазаретта, үзем дә сизмәстән чуашча сөйли башлавым үзе бер могҗиза түгелмени? Күземнән менә-менә тәгәрәп төшәм дигән яшьне кешегә күрсәтмим инде, борылып чыгып китим дип кузгала башлаган гына идем, тагын бер могҗиза булды. Моңа кадәр паралич сугып, сүзен дә юньләп аңлата алмаган карт торып басмасынмы! Аяклары-куллары таяк юанлык кына, эче аркасына ябышкан бу карт... атлап китте һәм чайкала-чайкала миңа таба юнәлде. Ике кулын алга сузган, чәче ап-ак. Лазарет нарында ятканда

гына бәләкәй төсле күренгән икән. Үзе озын, үзе сөяк тә тире. Бары ике күзендә генә яшәү чаткысы бар. Ялгыз күрсәң, котың очар. Мин әле хәзер дә шөрли төшеп, артка чигеп куйдым. Минем янга килеп җитәргә бер-ике адым кала бу скелет карт кулларын сузып гөрселдәп ауды. Мүкәйләп килә, малай, мина таба! Куркудан ничек чыгып йөгермәдем дә, ничек йөрәгем ярылмады. Ходай нинди көч биргәндер, ничек үземне-үзем тыеп калганмындыр. Юкса үзем куркак та түгелмен. Сугышта үлемнең күзенә караган кеше, тик монда әллә нәрсә булды. Шулай да, куркуны җинеп, бу сөяк тә тирегә калган картны күтәрергә тырышып карыйм, юк, булмый. Ә карт минем итекләрне үбә, үзе бертуктаусыз нәрсәдер мыгырдый, нәрсәдер аңлатырга тырыша, ярты-йорты сүзләрен һич аңларлык түгел. Игътибарлабрак тыңласам... бу да чуашча сукалый түгелме соң?! Чынлап та, чуашчалатып: «Улым да улым», — ди ич! Минем исемне дә әйткән кебек бит. Тик минем һаман әле шушы скелетның әти булуына ышанасым килми. Шулай да картны күтәреп алдым. Бу минем битләрне сыйпый, аркадан сөя, үзе бертуктаусыз чуашча: «Улым, бәгърем!», — ди. Мин һаман моны бүтән кеше, тик чуаш кешеседер дип уйлыйм. Лагерьда күпме кеше мине кочаклап: «Улым, рәхмәт тә рәхмәт», — дип яратып елаштырып алды әнә. Шундый картларның берседер дип уйлыйм инде. Картның зур күзләреннән исә бертуктаусыз яшь ага. Ул тагын «Әндри», дип, минем исемне кабатлый. Әнинең һәм сенелкәшнең исемен әйткәч кенә, «бу бит минем әти!» дигән уй миемне ярып, яшен суккан кебек булды. Мин дә түзмәдем, елап җибәрдем. Икәүләп елашабыз. Әти мине кочаклаган, аркадан сөя. Мин дә әтине кочаклап алдым. Бу хәлне күреп торган медицина хезмәткәрләре дә, поселоктан килгән авырулар һәм зеклар да безгә кушылып елыйлар икән. Тик әлегә мин боларны күрмим. Дөньяда әти белән без икәү генә шатланышып елашабыздыр кебек иде. Бөтен лазарет елаганын миңа икенче көнне генә әйттеләр. Ә мин әтине, кадерле әтиемне күтәрдем дә, бөтен лагерь аша канцелярия кырындагы бүлмәмә алып киттем. Бөтен лагерь аша елый-елый әтине күтәреп барам...

«Их, малай», — дип, Әндри абзый көрсенеп тамагындагы төерне йотарга тырышса да, булдыра алмады. Бераздан тагын сөйләп алып китте. Ә мин күккә карап, кымшанырга да кыенсынып ятам.

— Әтине шушылай табуым электән шау-гөр килгән лагерьны бөтенләй аякка бастырды. Икенче көнне зеклар һәр барактан икешәр кешедән торган делегация сайлап, лагерь түрәләреннән ял сорарга барганнар. Лагерь түрәсе, тәүдә бу хәлгә шикләнебрәк караса да, зеклар бик үтенеп сорагач, риза булган. Чөнки зеклар, лагерь эчендә тәртип булачак һәм бүгенге эш көне күләмен икенче көндә үтәячәкбез, дип вәгъдә биргәннәр. Лагерь түрәсе белә: зеклар вәгъдә иттеләрме, алар, күзләре атылып чыкса да, вәгъдәләрен үтәячәк. Шулай итеп, ул көнне лагерьда ял игълан ителде. Актив зеклар бараклар арасына кызыл әләмнәр белән төрле лозунглар язылган транспарантлар элделәр. Хәтта «урка»лар да үз баракларын бизәп, әләм элгәннәр иде. Кичен бөтен лагерь иң зур баракка — клубка җыйналды. Зеклар көче белән әзерләнгән концерт оештырылды. Лагерьның политбүлек түрәсе бер сәгатьлек нотык сөйләде.

Минем шатлыгым бөтен лагерь халкы өчен олы бер бәйрәмгә әверелде... Шулай итеп, әтине таптым. Үләргә яткан әти дә җайлап рәтләнә, терелә башлады. Мин әтине лазаретның аерым бер палатасына урнаштырдым, үзем дә әти янына күчтем. Сөйләшеп сүз бетми. Тик әтинең генә сүзләре параличтан соң бик аңлашылып җитми. Һаман әле ышанып бетмим, әйтерсең лә бер тәмле төш кебек. Уянып китеп, төшем өзелмәсә генә ярар иде дип куркып торам. Әтигә шулай аз-азлап хәл керә башлады. Хәзер инде бу җәһәннәм төпкеленнән чыгу ягын кайгырта башладым. Январь үтеп бара. Тышта чатнама суык. Авыру әтине почта йөрткән этләр белән алып чыгу һич мөмкин булмаячак. Аларны да күпме көтәргә кирәк. Ул этләргә утырып чыгарга теләүчеләр күп, анда да чират.

Әтинең сөйләвенчә, кулындагы кәгазь дә шуны раслый, ул инде 1949 елны ук иреккә чыгарылган булган. Мин тәүдә барып күргән өй аныкы булган. Үзенең әзме-күпме хуҗалыгы да бар икән. Туган авылга — безнең янга кайтырга курыккан.

Кайтса безгә зыяны тияр дип уйлаган. Барыбер озак тотмаслар, кире җибәрерләр дип тә курыккан. Әти болай хәлле генә яшәгән. Хуҗалыгында унбишләп умарта, бераз бәрәнге һәм бер сыер бар. Үзе авырганда сыерны күршеләре карап торган. Шуңа да сыерны аларга очсызга гына бирдек. Бер баз бәрәңгене чиләкләп саттык. Биш баш умартасын лагерь түрәсенә бүләк иткән идек тә, ул риза булмыйча, бераз булса да акча бирде. Калган ун баш умартаны төрле кеше алды. Хәтсез акча җыелды. Тик кайтып китәргә генә бер рәт тә юк. Ары сугылам, бире сугылам, юк, бер нәрсә дә уйлап табып булмый.

Шулай төрлесен уйлап, йокысыз төннәр башланды. Һич кенә җаен таба алмыйм бит. Үземнең тормыш юлымны күздән кичереп ятам. Бер төнне шулай «келт» итеп Германиядә маршал Чуйков Василий Иванович кул астында хезмәт иткән чаклар, шунда аның әйткән сүзе искә төште. Безне, бер төркем штаб хезмәткәрләрен демобилизовать иткән чакта, ул безгә ак бәхетләр теләп, бергә яхшы хезмәт иткән өчен барыбызга да исемнәребез язылган кул сәгатьләре бүләк итеп, болай дигән иде:

— Дөнья булгач, төрле хәлләр була. Сез иң кыен, иң соңгы чиктә генә миңа шушы шифр белән мина, төн дими, көн дими, берәр тапкыр шалтырата аласыз. Мин сезгә кулдан килгәнчә ярдәм итәрмен, — дигән иде бит! Шифрны беркайда да, бер кәгазьгә дә язарга кушмады. Бары истә калдырырга гына кушты. Бер атна шикләнеп йөрдем. Шалтыратыргамы, юкмы дип. Ләкин бүтән чара калмады бит. Бер көнне лагерь түрәсенә, кемгә шалтыратканны әйтми генә:

— Мәскәүгә шылтыратып сөйләшеп алырга иде, — дим. Ризалыгын бирде. Таң белән поселокка киттек. Мин маршал Чуйковны иртән туры китереп булырга тиеш дип исәпләгән идем. Шулай иттек тә. Почта бүлегеннән шалтыратабыз. Биш минутлап вакыт үткәч, телефон «чаж-чож» килде, теге баштан: «Кабул итү бүлмәсе тыңлый, — дип хәбәр салдылар. Мин, үземнең исем-фамилиямне әйтеп, иптәш маршал Чуйков Василий Иванович белән тоташтыруны үтендем. Теге тавыш: «Бер минут», — диде дә, тынып калды. Көтә башласаң, бер минуты да озын бер гомер икән. Василий Иванович кул астында хезмәт иткән чаклар кинодагы кебек янә күз алдыннан үтеп китте. Мине сискәндереп, телефон тагын чыжлап алды да:

— Маршал Чуйков сезне тыңлый, — димәсенме! Дулкынланудан тавышым бетте, әйтер сүз онытылды. Телефондагы тавыш тагын кабатлап:

— Маршал Чуйков сезне тыңлый, — дигәч кенә телгә килдем.

Иң тәүдә үземнең исем-фамилиямне атадым. Германиядә хезмәт иткән чакларны исенә төшердем. Тагын нәрсәләр әйткәнмендер инде, лагерь начальнигы:

— Йомышыңны әйт, — дип кабыргага төрткәч кенә айнып киттем һәм йомышны әйтә алдым.

— Кански районы Почет поселогыннан авыру әтине алып кайтып булмый. Ярдәм итегез, — дидем. Тагынниләр сөйләшкәнбездер, берсе дә хәтердә юк. Мин шулкадәр дулкынланудан хәлем бетеп, стенага сөялдем. Әлеге шул контузия шаукымы инде.

Лагерь түрәсе элемтәче кызлардан бер стакан су белән валерианка сорап алып эчергәч кенә бераз хәл керде. Василий Ивановичның нәрсә әйткәне башта калмаган. Мин тик шуңа ышандым: ярдәм киләчәк.

Ял көне иде. Без әти белән җылы лазаретта сөйләшеп утырабыз. Әти авылдагы хәлләрне сорый, ә мин җавап бирәм. Зеклар да бүген ял итә. Иртәнге сәгать уннар тирәсендә ниндидер бер сәер гүләү тавышы ишетелә башлады. Тәүдә бик зәгыйфь кенә иде. Аннан көчәя төште, тагын акрынайган кебек булды. Мин бу тавышны таныдым. Чөнки сугышта ишеткән бар иде: бу — самолет тавышы бит. Тәрәзәдән карамакчы булган идем дә, тәрәзә тоң, бернәрсә күренми. Өстәрәк бер почмагын эретеп, шуннан карыйм. Бөтен лагерь гөрли. Кайда саклау командасы, кайда лагерь идарәсе хезмәткәрләре, кайда зеклар икәнен аңламассың, барысы да мәш килә. Лагерь капкасы бикле булганга, зеклар самолет карарга дип чәнечкеле тимерчыбыктан ясалган ихата буена тезелгәннәр. Солдатлар һәм идарә хезмәткәрләре лагерь кырындагы тигез яланга йөгерәләр. Күктәге җинел самолет лагерь өстеннән

бер-ике урады да, тигез ялан өстенә кар бураны туздырып, лагерьга якын ук килеп туктады. Берәр олы түрә килгәндер, мөгаен. Мин туңа башлаган тәрәзә «күз»еннән карашны алдым да, күнелле генә дөрләп янган учакка утын өстәп, тышка чыгарга булдым. Миңа да кызык булып китте, нинди самолет бу, ни эшләп йөри? Киенеп, лазарет бусагасына чыгып бастым. Бөтен халык урамда. Лазарет бусагасында басып торырга урын юк. Тышта суык булуына карамастан, йөри алырдай авыруларга кадәр бусагага чыгып тезелгәннәр. Сораштырам, тик нәрсә булганын, ни өчен самолет килгәнен беркем дә белми. Зеклар:

— Мөгаен, берәр тикшерү комиссиясе яисә берәр генералдыр, — дип, үзара күрәзәлек кылалар. Чөнки лагерьның яшәү дәверендә монда самолет тәү тапкыр килгән икән. Күпләренең самолетны да беренче күрүләре икән. Мин, ашыгып, яланбаш чыкканмын, шуңа да баш өши башлагач кире кереп киттем. Самолет кына күргән бар бит инде. Мин инде үземчә уйлыйм. Мөгаен, берәр яшерен пакет белән яшерен боерык алып килгәннәрдер.

Шулай да, түзмәдем, тыным белән эретеп, теге тәрәзә күзеннән тагын тышка карыйм. Бер төркем зеклар безнең якка йөгерәләр, берничә солдат та аларга ияргән. Берсен-берсе узарга тырышып йөгерәләр, үзләре нәрсәдер кычкыралар. Ни булыр икән бу дип тагын лазарет болдырына чыгып бастым. Йөгереп килеп җиткән зеклар да, солдатлар да барысы берьюлы бер-берсен бүлдерә-бүлдерә:

— Егоров, сезне лагерь начальнигы чакырта, сиңа самолет килгән. Мәскәү хәтле Мәскәүдән , — дип тезеп алып китteләр.

Мин тәүдә анламый торам. Шуннан, ышанырга да, ышанмаска да белмичә, киттем лагерь канцеляриясенә.

Лагерь начальнигы мине елмаеп, бусага төбенә үк чыгып каршы алды.

— Менә молодец! Менә сиңа чуаш! Урысның кулыннан килү түгел, төшенә дә керми бу эшләр, — дип, мине мактый.

Очучыларны ашатып, ял итәргә урнаштырдылар. Аларның үзләре белән сөйләшкәч кенә, безне алырга килгәнлекләренә ышандым. И шатландым да соң! Эчтән генә иптәш Василий Иванович Чуйковка рәхмәтләр укыйм.

Шушы вакыйга уңаеннан иртәгә ял игълан иттеләр. Бөтен лагерь халкы шат. Танышлар, таныш булмаганнар да мине тәбриклиләр, килеп кулны кысалар. Минем түбә күккә тигән. Авыз ерык. Үз гомеремдә мине болай олылаганнары юк иде әле. Һәм булмастыр да инде. Кичергән шатлыктан төне буе йоклый алмадым. Кешегә зур шатлык килсә, үләргә мөмкин дигәннәрен ишеткәнем бар иде, һәм моның дөрес булуына ышандым. Ярый әле доктор бик акыллы кеше икән, тынычландыра торган укол кадады. Барыбер йоклый алмадым.

Төнлә бер-ике тапкыр самолетны карап кердем. Тора, малай! Бу төшем түгел, өнем икән дип тагын кереп ятам. Түзмәдем, таң белән самолет янына киттем. Лагерь капкасы башындагы сакчы тәүдә туктаткан иде дә, мине таныгач, рөхсәт итте самолет янына барырга. Самолетның көрткә бата-чума тирә-ягын урап чыктым. Ә самолет тора, чукынган! Якын килеп сыйпап-сыйпап та карадым үзен. Менә минем бәхет кайда, менә ул минем шатлыгым һәм ышанычым!..

Таң атуга Почет поселогыннан да, күрше лагерьлардан да халык самолет күрергә дип җыелды. Кара яу кебек. Авылдан хәтта бала-чагалар, карт-корылар атлы чаналар белән килгәннәр. Үзеннән-үзе митинг башланып китте. Тәүдә лагерь начальнигы сөйләде. Аннан — самолет командиры. Совет властеның казанышлары, һава флотының үсеше, киләчәге турында нотык тотты. Аннан сүзне миңа бирделәр. Мин, киреләнеп, сөйли белмим, рәхмәт дип баш тартмакчы булган идем дә, бөтен лагерь «гү» килеп минем сөйләүне үтенде.

Мин Совет хөкүмәтенә, Сталинга рәхмәтемне әйттем. Дулкынланып, шатлыктан юньләп сөйли дә алмадым. Митингны шуның белән тәмамладык. Көн суык булуга карамастан, халык таралмады. Барысының да кәефе күтәренке, бәйрәмчә. Әйтерсең лә самолет аларны алырга килгән. Шундый хәлләр, улым.

Шунда, малай, бер кытай кешесе минем тирәдә бөтерелә бит. Әле алдыма, әле артыма чыга. Мин тәмәке тартырга уйласам, шырпыга хәтле кабыза бу. Җаен китереп:

— Хөрмәтле Егоров иптәш, мине дә Канскига алып кайтыгыз инде. Мин дә азат кеше бит. Утыру вакытым күптән чыкты. Тик кайтырга рәт һич юк, — ди бу.

— Самолетта урын юк, барлыгы җиде генә кешене ала бит, — дим.

— Сез рөхсәт кенә итегез, мин канатына утырып кайтырга да риза, — ди.

— Юк, булмый, самолет тулы, буш урын юк, — дим. Бу һаман үҗәтләнә:

— Самолетның чаңгысына бәйләнеп булса да кайтам, тик рөхсәт ит, — ди.

— Суык, туңып үләсең, — дим.

— Үлсәм дә үкенмим, тик мине моннан гына алып чыга күр, — ди, ялынып.

Мин һаман ризалашмыйм. Кытай минем учка бер янчык тоттыра.

— Монда алтын, ал, тик алып кына чык, — ди. — Мин алтынны кире тегенең изүенә тыгам. Кытай, егылып, аякларны кочаклый, үзе акырып елый. Ничек кенә җәл булмасын, аны ничек кенә кызгансам да, үз башларыбыз кадерле. Әгәр рөхсәт итсәм, шушы җәһәннәм төпкелендә торып калуыбыз бар бит.

Сәгать берләр тирәсендә күккә күтәрелдек. Зеклар безне күз яшьләре түгеп озатып калды. Самолет артыннан иң озак йөгереп баручы теге кытай булды. Самолет лагерь өстеннән ике тапкыр әйләнде дә, Красноярскига юл алды. Ике сәгатьтән без Красноярск аэропортында идек инде. Рәхмәт иптәш Василий Иванович Чуйковка, безгә поездга билет алып, урын бронировать итеп куйдырткан. Менә шулай, улым. Шушындый мажаралар белән март башында, өйдән чыгып киткәнгә биш ай дигәндә, чак кайтып төштек. Район үзәгеннән әтине җилкәгә күтәреп алып кайттым.

Кайтып бер атна да тормадым, мине тагын райкомга чакырталар. Шикләнеп куйдым, малай, үземә дә чират житмәде микән, дип. Ул елны тормыш хәлләре бик шәптән булмыйча, март азакларына колхозның малларын ашатырга ни печән, ни салам калмады. Беркайдан табар әмәл юк. Елга буендагы талларны, урмандагы йола агачларын кисеп ашата башладык. Ферма түбәсендәге салам ашалып бетте. Колхоз рәисе, авырып, Уфада больницада ята. Шунда мине райкомга чакырталар. Бардым. Бюрода безнең колхозны тикшерделәр һәм:

— Әйдә, колхозны житәклә, — диделәр. Мин каршы киләм. Болар:

— Син — коммунист, Себер кадәрле Себердән әтиеңне юллап алып кайттың, булдырсаң, син генә булдырасың. Син бит еврей кебек. Хәтта аннан да арттырасың, — диләр.

— Юк, мин чуаш бит.

— Син — чын еврей. Партия кушкан эштән баш тартырга синең хакың юк, — дип, тәки мине колхоз рәисе итеп тәгаенләделәр.

Ул язны һич онытмыйм. Нык тырышырга, көч салырга туры килде. Маллар 1952 елның җәенә исән-имин аяк бастылар. Ә мина «Еврей» кушаматы ныклап ябышып калды.

Әти өйгә кайтып төп-төгәл бер ел яшәде.

— Улым, син бит мине тәмугтан алып кайттың, оҗмахта үләм, — дип, кат-кат рәхмәтләр укый торган иде.

— Тәмуг эссе түгел, тәмуг ул — Себер суыгы, — ди торган иде мәрхүм, — шулай дип сүзен тәмамлады Әндри абзый.

Ул да баш астына кулларын салган. Күккә карап болытларны күзәтә, ә күзе тулы — яшь. Шуларның бер тамчысы җай гына чигәсе буйлап тәгәри... Кояш кыздыра. Сабан тургайлары биеп-биеп югарыда-югарыда очалар, алар күзгә нокта гына булып күренәләр һәм бертуктаусыз сайрашалар. Ялкау болытлар исә җай гына, үз юллары белән ашыкмый гына агалар да агалар. Җәйнең җылы җиле иркәләп битләрне назлый. Тирә-як ямь-яшел. Бер сүз белән әйткәндә, сәхрә-оҗмах инде бу тормыш...



Уртада Хәсән Туфан һәм каракалпак шагыйре Ибраһим Юсупов. Алар янәшәсендә Уралдан килгән милләттәшләр. Тукайның тууына 90 ел тулган көннәр. 1976 ел.



Солтан Габәши (1891 - 1942) – композитор, педагог, музыка-җәмәгать эшлеклесе.



Бер төркем язучылар «Казан утлары» уздырган җыелышларның берсендә. Сулдан уңга: Солтан Шәмси, Ркаил Зәйдулла, Әхсән Баянов, Тәлгат Галиуллин, Марсель Галиев, Наис Гамбәр, Марсель Зарипов. 1998 ел.



*Татарстан язучыларының X съезды утырышыннан бер күренеш. Алгы рәттә, сулдан уңга: Фәнис Яруллин, Фәрваз Миңнуллин, Рашат Низамиев. 1984 ел.*



*Татар галимнәре Төркиядә. Сулдан уңга: Нурмөхәммәт Хисамов, Хатыйп Миңнегулов, Гали Арсланов. Әдернә шәһәре. 2005 ел.*



*Шагыйрь, табиб Нәкыйп Каштанов һәм язучы Әхәт Сафиуллин. Редакциядә очрашу. 2003 ел.*

## ПАРЛАМЕНТ ҖИТӘКЧЕСЕНЕҢ ЯҢА ВАЗИФАСЫ

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Россия делегациясе составында Европа берлеге Җирле һәм төбәкләр хакимиятләре конгрессының XXIII сессиясендә катнашты. Сессия алдыннан пленар утырышлар кысаларында Конгрессның устав комитетлары составы расланды.

Конгрессның актуаль мәсьәләләр буенча комитеты рәисе вазифасына бертавыштан Татарстан парламенты җитәкчесе сайланды. Шулай итеп, Россия Федерациясе 1996 елда Европа Берлегенә кергәннән соң тәүге тапкыр буларак, төп комитетларның берсенә Россия, бу очракта Татарстан вәкиле җитәкчелек итәчәк.

## ШАГЫЙРЬ – РФ ПРЕЗИДЕНТЫ СОВЕТЫНДА

Россия Президенты Владимир Путин үзенең Указы белән РФ Президенты каршындагы Мәдәният һәм сәнгать советы президиумының составын раслады. Янартылган әлеге исемлеккә күренекле әдип һәм җәмәгать эшлеклесе, Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис та кертелгән.

Мәгълүм булганча, бу мәртәбәле Советның төп максаты дәүләт сәясәтенең мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге өстенлекле юнәлешләрен билгеләү һәм аларны гамәлгә ашыру буенча ил җитәкчесенә тәкъдимнәр әзерләүдән гыйбарәт.

## КАЗАНДА ХӘТЕР КӨНЕ УЗДЫ

Татарстан башкаласында 1552 елда Казанның Иван гаскәрләре тарафыннан яулап алынуына багышланган чара — Хәтер көне узды. Анда татар зыялылары, Татарстанның төрле шәһәрләре, Башкортстан, Чуашстан, Мари Иле һәм башка республикалар вәкилләре катнашты. Хәтер көне мәрасиме башкаланың Ирек мәйданында башланды, биредә Коръән аятьләре укылды, зыялылар чыгыш ясады. Хәтер көне Сөембикә манарасы янында җеназа намазы уку белән тәмамланды.

## ЯҢА МИНИСТР, ЯҢА ДИРЕКТОР

***

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миннеханов Указы белән 1 октябрьдә Энгель Фәттахов мәгариф һәм фән министры итеп билгеләнде. Премьер-министр Илдар Халиков коллективны яңа җитәкче белән таныштырды.

Энгель Нәвап улы Фәттахов 1961 елның 12 июнендә Актаныш районының Чишмә авылында туган. Укытучылар гаиләсеннән. 1983 елда Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлап, инженер-механик белгечлеге алган. Шулай ук монда аспирантурада укыган, студентларга белем биргән. Техник фәннәр кандидатлыгына диссертация яклаган. Туган ягында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең химия берләшмәсе баш инженеры, район хакимияте башлыгы урынбасары булган. Ике ел Сарман районы хакимиятендә эшләгән. 1998 елдан исә Актаныш районы җитәкчесе.

***

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры директоры итеп 30 яшьлек Илфир Якупов билгеләнде. Ул 2007 елдан бирле Камал театрында маркетинг буенча директор урынбасары булып эшләгән. Театрның элекке директоры Шамил Закиров вафат булганнан соң, Илфир Якупов директор вазифаларын башкаручы итеп билгеләнгән иде.

Илфир Илшат улы Якупов 2004 елда Казан дәүләт Мәдәният һәм сәнгать университетының актерлык бүлеген тәмамлаган. Аннары ТР Мәдәният министрлыгында әйдәп баручы белгеч, 2005-07 елларда Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында министр ярдәмчесе булып эшләгән.

## ИКЪТИСАД ХӘЛЛӘРЕН БЕЛҮ КИРӘК

«Татмедиа» ачык акционерлык җәмгыяте республика гаммәви мәгълүмат чаралары җитәкчеләрен һәм журналистларын «Алабуга» махсус икътисади зонасына кунакка

алып барды. «Татмедиа»ның генераль директоры Ирек Миңнәхмәтов әйтүенчә, мондагы заводларның ничек эшләвен күреп кайту һәркем өчен файдалы.

Махсус икътисади зонаның генераль директоры Тимур Шаһивәлиев сәнәгать мәйданчыгының бүгенге көне һәм киләчәктәге перспективалары турында сөйләде, журналистларның сорауларына җавап бирде. «Хәзер Алабугада 31 компания теркәлгән, 6сы инде эшли, калганнары проектлаштыру һәм төзелеш стадиясендә. 2015 елга теркәлгән резидентлар саны 60ка, 2020 елга исә 120гә җитәргә тиеш, зона территориясе икеләтә зурайтылып, 40 квадрат километрга җитәчәк. Төп кластерлар да билгеләнгән — автомобильләр һәм автокомпонентлар, төзелеш материаллары җитештерү, полимер эшкәртү, фармацевтика, азык-төлек, авиация сәнәгате, агач эшкәртү. Бүген махсус икътисади зона предприятиеләрендә 2,5 мең кеше эшли, киләчәктә исә 12 меңләп кеше кирәк булачак, бигрәк тә инглиз телен яхшы белгән инженерларга ихтыяҗ зур булачак», — дип билгеләп үтте Тимур Шаһивәлиев. Аннан соң гаммәви мәгълүмат чаралары вәкилләре бүген инде уңышлы эшләп килгән «Эр Ликид Алабуга», «Белая дача», «П-Д Татнефть-Алабуга Стекловолокно», «Форд Соллерс Елабуга» предприятиеләрендә экскурсиядә булды.

### ЛЕВ ГУМИЛЕВКА — ЧӘЧӘКЛӘР

Күренекле галим, тарихчы Лев Гумилевның тууына 100 ел тулды. Бу уңайдан язучылар, галимнәр, җәмәгать эшлеклеләре аның башкалабыздагы Тукай мәйданына куелган бюстына чәчәкләр салды. Шушында ук искә алу мәрәсиме булды. Аны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Р.Корбанов алып барды. Мәрәсимдә Татарстан Фәннәр академиясенең Тарих институты директоры Р.Хәкимов, Казан федераль университетының Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара мөнәсәбәтләр институты доценты К.Әхсәнов, шагыйрьләр Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Р.Зәйдулла, А.Ахматова һәм Г.Державин исемендәге әдәби бүләкләр иясе Л. Газизова чыгыш ясады.

### ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ

***

26 сентябрьдә Язучылар бинасында (Мөштәри урамы, 14нче йорт) идарәнең киңәйтелгән утырышы булып узды. Утырышта авыл хуҗалыгы министры Марат Әхмәтов белән мәдәният министры Айрат Сибагатуллин катнашты. Марат Әхмәтов бүгенге авылның хәл-халәте турында сөйләде, әдипләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирде.

Узган ел Актаныш муниципаль район хакимияте, күренекле якташлары — Татарстанның халык шагыйре Гамил Афзал исемен мәңгеләштерү йөзеннән, әдип исемендәге премия булдырган иде. Язучылар идарәсе быел әлеге премиягә сатирик язучы Фәнзаман Батталны (былтыр тәүге бүләккә Туфан Миңнуллин лаек булган иде) тәкъдим итте.

***

10 октябрьдә Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Вакыйф Нуриев җитәкчелегендәге бер төркем язучылар — Мөдәррис Вәлиев, Фарсель Зыятдинов, Фәйрүзә Мөслимова, Дания Гайнетдинова, Йолдыз Шәрәпова һәм Нәкыйп Каштанов Спас районының Көек авылында һәм Болгарда булып, күренекле язучы, әкиятче, шагыйрь, җәлилче Абдулла Алиш (1909-1944) рухын яд итүгә багышланган очрашуларда катнашты. Болгарда узган тантаналы әдәби-музыкаль кичәдә әлеге каләм әһелләренең барысы да, шул исәптән А. Алиш исемендәге премиянең быелгы лауреаты, шагыйрь, прозаик, табиб Нәкыйп Каштан һәм Алишның кан кардәшләре — журналист Азат Сөнкишев белән Гайшә Сөнкишева да чыгыш ясады. Кунакларны Спас муниципаль районы хакимияте башлыгы Камил Әсхәт улы Нугаев шәхсән үзе каршы алды һәм озатып йөрде.

***

Мәдәният үсешенә зур өлеш кертүе өчен «Казан театр училищесы» Татарстан Республикасы урта һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең актер осталыгы укытучысы **Шиһапов Мансур Әхмәт улына** «Татарстан Республикасының атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

***

20 октябрьдә Әлмәт районының Габдрахман авылында яшәп иҗат иткән каләмдәшебез **Азат Вәли улы Мөхәммәтгалиев (Азат Ганиев)** 71нче яшендә вафат булды.

# ХУШЛАШУ СҮЗЕ



2012 елның 6 октябрендә 74нче яшендә танылган шагыйрь һәм прозаик **Шамил Маннапов** вафат булды.

Шамил Мәгъйзь улы Маннапов 1938 елның 1 гыйнварында Татарстанның Әлки районы Татар Мулла авылында туган. 1957 елда Алпар урта мәктәбен тәмамлый, аннары өч ел Совет Армиясе сафларында хезмәт итә. 1960-65 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый.

Университетны тәмамлаганнан соң, Ш.Маннаповның хезмәт юлы тулысынча татар матбугаты белән бәйле: «Татарстан яшьләре», «Ватаным Татарстан» газеталары, Татарстан китап нәшрияты... 1989-2001 елларда «Казан утлары» журналы редакциясендә бүлек мөхәррире вазифаларын башкарды.

Ш.Маннаповның чын-чынлап зур әдәбият мәйданына чыгуы узган гасырның алтмышынчы елларына туры килә. Аның оптимистик рухлы, лирик-публицистик яңгырашлы поэтик әсәрләре бу елларда республика матбугатында еш күренә, күмәк җыентыкларда басыла. 1967 елда яшь шагыйрьнең «Беренче карлыгачлар» сериясендә «Яшьтәшләрем» исемле беренче җыентыгы дөнья күрә. 1970-1982 елларда аның биш шигъри җыентыгы һәм кыска хикәяләре, нәсерләре, лирик парчалары тупланган «Әти урманы» исемле проза китабы басылып чыга.

Үз әсәрләрендә автор, тормышның һәм заманның характерлы сыйфатларын игътибар үзәгенә алып, поэтик чаралар ярдәмендә аларның кеше күңелендә үзенчәлекле чагылышын тасвирларга омтыла. Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Кайту» (1981), «Апрель авазы» (1987), «Җиргә сыенам» (1990), «Өндәге төшләр» (1997) исемле шигъри китаплары әдипнең бу юлда туктаусыз эзләнүен, заман чынбарлыгын, җир-табигать белән кешенең бербөтен бердәмлеген раслап, яшәеш мизгелләрен чагылдыруда каләменең чарлана, күңел хисләренең фикри-фәлсәфи тирәнлеккә ирешә баруы турында сөйли. Бу сыйфатлар Ш.Маннаповның прозасында да ачык сизелә. Аның чәчмә әсәрләренә халыкчан гадилек, самими юмор, фәлсәфи гомумиләштерүләр хас («Ачы какылар», «Мәңгелектән елмаю», «Шаман мәзәкләре», «Тормыш сиратлары» җыентыклары).

Ш.Маннапов әдәби тәнкыйть һәм тәрҗемә өлкәсендә дә уңышлы эшләде. Ул шулай ук сәхнәләрдән, радио һәм телевидение аша еш башкарыла торган лирик җыр текстлары авторы буларак та билгеле («Керфегенә тамармын мин», «Рәхмәт сина», «Кичермәсләр» һ.б.)

Милли мәдәниятебезне үстерүгә зур өлеш керткәне өчен Шамил Маннаповка 1992 елда «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде. Ул шулай ук Һ.Такташ исемендәге әдәби премия лауреаты да.

Без тыйнак, гадел, ихлас каләмдәшебезне югалттык. Аның якты истәлеге күңелләребездә озак сакланыр.

**Татарстан Язучылар берлеге.**
**«Казан утлары» журналы редакциясе.**

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Беренче кар».

*Тышлыкның дүртенче битендә:* шагыйрь **Салават Рәхмәтулла**.

реклама

татмедиа

***Игътибар!***
***2013 елга «Казан утлары» журналына язылу дәвам итә.***

Журнал турындагы мәгълүматны һәм язылу тәртибен:

1. «Каталог российской прессы «Почта России» (Республика Татарстан. Республиканские журналы бүлегендә) – 86 биттә;

2. Интернетта Выпиши.рф сәхифәсендә;

3. «Агентство «Роспечать» / Подписка на российские и зарубежные издания» каталогында 233 биттә табарга була. Әлеге басмада күрсәтелгән бәя Россиянен Татарстаннан читтәге төбәкләрендә гамәлдә.

Журналның Интернетта рәсми сайты:
**http://kazanutlary.ru**

Белешмәләр өчен телефон:
**(843) 562-11-28**






Салават Рәхмәтулла

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)